ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2015



# Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ

## *2015 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында*

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) **Булатова Клара Гариф кызына**:

«Келәү: шигырьләр, повесть, хикәя», Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2013 ел;

«Сәяхәтнамәләр: шигырьләр», Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2013 ел;

«К солнцу лицом» («Кояшка йөз белән»), «Рухият», Казан, 2013 ел, китаплары өчен;

2) **Колмогорцева Ирина Константиновнага** – «Казан һәм Габдулла Тукай» график эшләр сериясе өчен;

3) Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының түбәндәге составтагы иҗат төркеменә: **Мөхәммәтҗанов Рәүфәл Сабир улы** (идея авторы, проектның сәнгать җитәкчесе), **Ковтун Георгий Анатольевич** (балетмейстер-сәхнәгә куючы), **Андреева Кристина Андреевна** (балерина, Җаникә ролен башкаручы), **Тимаев Михаил Иванович** (балет актёры, труппа премьеры, Батый хан Рухы ролен башкаручы) – «Алтын Урда» спектаклен куйган һәм аның сәнгать образларын тудырган өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н.Миңнеханов**

*Казан, Кремль,*
*2015 ел, 23 апрель,*
*№ ПУ-411*

# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ һӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**


Ренат ХАРИС. Хәтерләтеп татар язмышын. *Шигырьләр.* ....3

Антым белән илне якладым *(А.Алиш, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, Х.Мөҗәй, Ш.Мөдәррис, З.Нури, С.Хәким шигырьләре).* ....36

Нәби ДӘҮЛИ. Ату. *Хикәя.* ....41

Яши ул көн, яши һәм яшәр... *(Р.Вәлиев, Р.Мингалим, Р.Гаташ, М.Мирза, Г.Морат, Г.Әхтәмова, Ф.Тарханова, Ф.Мөслимова, Л.Шәех, Л.Фәтхетдинова шигырьләре).* ....45


**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**


Фирдәвес ХУҖИН. Без белмәгән сугыш. *Документаль бәян.* ....9


**БӨЕК ҖИҢҮГӘ — 70 ЕЛ**


Бөек Ватан сугышы. XXI гасырдан караш. *(И.Ибраһимов, И.Гыйләҗев, А.Кәбирова, Ә.Галләмова, Ш.Мостафин, Р.Юныс, Х.Бәдигый катнашында «түгәрәк өстәл»). Вакыйф НУРИЕВ әзерләде.* ....51

Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ. «Совет әдәбияты» журналы турында солдат хатлары. ....61

Шаһинур МОСТАФИН. Әтием әманәте. ....63

Рәис ЗАРИПОВ. Корпус командирлары. ....74

Ибраһим БИЕКТАУЛЫ. Милли каһарман генерал Хәсән Салихов. ....84

Ягъсуф ШӘФЫЙКОВ. Йөрәк хәтере. ....88


**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**


Илшат ВӘЛИУЛЛА. Шигъри мәйдан ни сөйли? ....93

*100нче бит:* Рәфикъ ЮНЫС. Җиңүнең көенечле катламнары. ....100


**ФӘН**


Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА. «Алар бит безне ташлап киттеләр...» ....103

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ....112


**СӘНГАТЬ**


Гәрәй РӘХИМ. Ветераннар гимны ничек туды. ....115

Филүсә АРСЛАН. Халкыбыз җәүһәрләре. *(Шәфыйка Котдусованың тууына 105 ел).* ....118

*Юбилейлар:* Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Остаз *(Мәгъсум Хуҗинның тууына 85 ел).* ....123


**ХӘТЕР**


Әлфия ШАМОВА. Сезнең язмыш сугыш уты белән үрелгән. ....128

Әнәс ХӘСӘНОВ. Безнең язмыш. *Истәлекләр.* ....139

*Тормыш язган хикәяләр:* Гөлнур ВАСЫЙЛОВА. *Хикәяләр.* ....175

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....177

*Ак җилкән:* Гадел КУТУЙ. Рөстәм маҗаралары. *Бәян.* ....180

Хәмзә ЗАРИПОВ. Кеше батыр турында поэма. ....184

«Казан утлары» архивыннан. ....86, 126

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1267).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.04.2015, график буенча 29.04.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1227. Тираж 4004.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Ренат
Харис

# ХӘТЕРЛӘТЕП ТАТАР ЯЗМЫШЫН

## Җиңү адымы шавы

Инде күпме сулар акты,
яңардылар иске юллар,
ләкин мәңге истә исән
утлы еллар, канлы еллар.
Адым саен балкып ала
шул елларның хатирәсе —
Бөек Ватан өчен кабат
ялкын эченә керәбез.

Инде күпме янгыр яуды
чәчәк аттырып гөлләрне.
Туфракка әйләнми икән
дәһшәтле еллар көлләре —
адым саен тузгып чыга,
әйтерсең лә кайнар болыт...
Сафларга басасы килә
корал тоткан солдат булып!

Инде күпме жилләр иссе,
киселмәде ил хәтере,
Жиңү хакына жан биргән
кешеләр исеме тере —
адым саен калкып чыга
һәйкәл булып батырлыкка.
Батырлык безгә юл ачты
тынычлыкка, матурлыкка.

Ренат ХАРИС (1941) — *Татарстанның халык шагыйре; Россиянең Дәүләт премиясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Утыз миллиард

Утыз миллиард йөрәк тибешемнең
күпмесе соң дулкын кубарды?..
Купкан дулкыннарның кайсы булды
дошманнарны бәреп егарлык,
авыр киртәләрне аударырлык,
киңәйтерлек кысан ярларны?..
Йөрәк тибешемне тыңлый-тыңлый,
бүген, никтер, шуны барладым...

Утыз миллиард йөрәк тибешемә
тагын күпме тибеш өстәлер?!.
Кайсылары ерак оныкларга
калдырырлар җылы истәлек —
эретерлек горурлыкларына
кинәт яуган канлы карларны?..
Йөрәк тибешемне тыңлый-тыңлый,
бүген, никтер, шуны барладым...

Утыз миллиард йөрәк тибешеннән,
авыр булсалар да танулар,
мин таныдым: кайбер дулкыннарда
«татар» дигән сүзнең даны бар —
чукраклар да шавын ишетерлек,
сукырлар да нурын сизәрлек,
безнең заман матурлыгы белән
алар заманын да бизәрлек.

## Медальләр чыңлавы

*Китә казлар Донбасска...*
Татар халык җыры

Әти сугыш кырларында йөргән
яклар тыныч түгел яңадан...
Төньяк Донец ярлары камышын
бомба еккан, ялкын ялаган...

Снарядлар кабат көнбатыштан
көнчыгышка таба очалар —
әйтерсең лә фашист заразасы
әтиемнән минем үч ала...

Мин кайчандыр, Донбасс якларында,
шахталарда шигырь укыдым —
шахтёрларның орденнары чыңын
зур залларда тыңлап утырдым.

Хезмәт орденнары тавышлары
гомер буе — бүген бигрәк тә —
әти медальләре чыңлавына
кушылдылар минем йөрәктә...

Аһ, кызганыч, матур чылтыраулар
янә әверелә набатка!..

Һәм уйларым оча, әтиемнең
яуда үткән юлын кабатлап...

Мин Донбасска тагын барачакмын,
сәясәтнең ватып тозагын.
Якташларга шигырь укырмын мин,
исни-исни шахта тузанын...

## Сөю биетә

Кешене бию биетми,
аны сөю биетә...
Сөю биеткән чагында
кеше кала биектә —
Ай, йолдызлар дөньясында
яши белгән нур булып,
Жир шарын коча алырлык
жылы булып, зур булып!..
Дөньяны кеше биетә
мәхәббәте көенә...
Мәхәббәте көчле кеше
бәхетенә тиенә.

## Гармун искә төште

Дөньяда гармун барлыгы
төште искә...
Каешларын иңгә салдым...
Баттым хискә...

Бармакларым төймәләрдән
таелгалый,
кирәклесен бик тиз генә
таный алмый —

өйгә кайткач, чит илләрдә
гомер чигеп,
әнисен таный алмаган
сукбай кебек...

Сизәм, сизәм — күңелемне
оят талый...
Ярый әле безне оят
уяткалый...

Бармакларымның хәтере
сыекланган...
Ләкин бөек көйләребез
әле калган...

Беравыктан алар кайтты...
Киттем уйнап —
дулап йөрдем гаҗәеп бер
дөнья буйлап...

Хисләрем канат кагынды...
Акты яшем...
Бөек көйләр хәтерендә
милләт яши.

## Тезген эзлибез

Йөрәк бәйрәмгә ашкына,
соңга кала диярсен!
Аргамакка атланабыз
тезгенсез һәм иярсез.

Изү ачык, чәчләр тузган,
маңгай һаваны яра...
Тезген очын табып булмый —
аргамак ургып бара!

Очып төшеп калмас өчен
дуамал ярышта без,
Тормыш дигән аргамакның
ялына ябышабыз...

Кайларга барып чыгарбыз
тапмыйча тезгенне без?..
Әллә инде тезгенне без
койрык яктан эзлибез?!.

## Мин дә кирәк

Сәнәк урынында сәнәк...
Көрәк урынында көрәк...
Көрәкне сәнәк итмәскә
минем ишеләр дә кирәк.

Татар башлы татарлар күп.
Башка башлылары сирәк...
Кәләпүш киючеләр бар...
Минем ишеләр дә кирәк.

Кайберебез — калкан акыл,
кайберебез — кылыч йөрәк...
Аларны эшсез тотарга
минем ишеләр дә кирәк.

Чүпләп җыючылар да бар,
алучылар да бар көрәп...
Һәркайсына булышырга
минем ишеләр дә кирәк.

Төрле чакта төрле-төрле —
кайчак азрак, кайчак күбрәк...
Үлчәү тигез торсын өчен
минем ишеләр дә кирәк.

Сапсыз сәнәк сәнәк түгел.
Нишли ала сапсыз көрәк?..
Аларга шәп сап булырга
минем ишеләр дә кирәк!

## Хыялый әңгәмә

*Мефистофель:*
Кешедән җан сатып ала идем...
Хәзер алмыйм... Хәзер кирәкми —
әшәкелек кирәгеннән ашкан
җан бозачак минем йөрәкне...

*Фауст:*
Мин бүген дә җан сатарга әзер,
Җирдәге бер гүзәл мизгелне
туктатырга алынучы булса...
Ләкин андый кодрәт сизелми...

*Харис:*
Мефистофель! Әдәпсезлегеңнән
тыелып тор инде чак кына...
Мин җанымны бушлай бирер идем
сугышларсыз бер ел хакына...

Доктор Фауст! Синең фикер белән
һаман килешмәскә тырышам —
килешә калсам, авыр булыр иде
кеше булып калу тормышта.

## Аяк баскан саен

Әй, Буам — ата-бабамнан
мирас булган төягем —
аяк баскан саен синнән
дәрткә дәрман төядем.
Йөрәктә һаман кузгалды
горурлыгым давылы —
илгә дан-шан өсти тора
синең бер йөз авылың:

Кырык Сайдак һәм Өчмунча,
Черкенен, Килдуразын,
Яңа Тинчәле, Янтуган
тибрәтә күңел сазын,
Альшихын, Кайбыч, Норлатын,
Наратбашың, Ташкичү,
Шәйморзан, Чынлы,Чәчкабың
кадерле безнең өчен.

Аксуы белән Суксуын,
Бик-Үтиен, Казмасын,
Раккисәген һәм Исәген
юксынырга язмасын.
Лашчын, Чурагын, Күзбиен,
Кыятын, Толымбаең —
рәхәт була исемнәрен
күргән-ишеткән саен.

Фролово таллыклары,
Каенлык урманнары,
серле, фантастик фильмнар
төшерергә дә ярый.
Зөя, Бола, Карлы суы
искиткеч илһам бирә —
алар шигырь, җыр, сурәткә
гүзәллек булып керә!

Әй, Буам — туган төягем —
үрче, җырла, эшкиндер!
Бу дөньяда безнең өчен
җәннәт баглары — синдер!

## Балкар чыршылары

Казан кирмәнендә тигез саф —
күк чыршылар тора тезелеп...
Чәбәләнеп үскән чаганнар
күрә идек монда без элек...

Үсә иде кәкре агачлар
ямь бирмичә җәен һәм кышын,
берсен-берсе этеп, сындырып —
хәтерләтеп татар язмышын...

Чыршы юлда имгәнмәсен дип,
тамырларын төреп балчыкка,
алып кайткан идек ерактан —
балкар якларыннан — Нальчиктан.

Күк чыршылар бездә үзләште,
үзләштерә торган көч барга:
ябалдашы сулый Казанда,
тамырлары утлый Болгарда...

Көязләнеп сафта торалар
үр түрендә, шәһәр үрендә...
Күк чыршылар аша карасаң,
Казаннардан Нальчик күренә,
татарларда балкар күренә,
балкарларда татар күренә...

## Бәйрәмнәр

Әгәр дә мин күрми калсам
бер ел чуваш Уявын,
җанымдагы матурлыкның
кими кебек буявы.
Мәхәббәткә сусавымның
сүрелгәнен тоямын,
әгәр дә мин күрми калсам
бер ел чуваш Уявын.
Сабантуйлар, Масленица,
асла[1] Уяв та үтә!..
Асылда адәми затны
бәйрәмнәр кеше итә.
Бәйрәмнәрдә чагында мин
җанда бетмәс дәрт тоям.
Яшәсеннәр Масленица,
Сабантуй, асла Уяв!

## Яшь шагыйрь

Ул тау күрә бер ком бөртегендә,
стаканга юып күзеннән...
Һәм сурәтли аны сүзлекләрдән
эзләп тапкан өч йөз сүз белән.

Үзе пәйда иткән тауны имә
шикәр итеп, ялап иренен...
Тәм бизләре тойган ләззәтен ул
мең сүз белән яза – иренми...

Ул гадине катлаулата әле,
чыра итеп яра төс-тәмне...
Һәм бер көнне кинәт сизеп ала
бардан юкка таба үскәнен...

Һәм Каф тавын, ком бөртеге итеп,
керттерә ул җилдән күзенә...
Һәм: «Күземә минем чүп керде!» – дип,
әйтеп бирә ул дүрт сүз белән...

[1] Асла – төп бәйрәм



Фирдәвес Хуҗин

# БЕЗ БЕЛМӘГӘН СУГЫШ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## Авыл булыр — Салавыч

Мирзәхмәт Муллахмәт улының сөйләвенә караганда, әлеге исем рәсми кулланышта Вот.Юраш дип (узган гасырның сиксәненче елларында юкка чыккан ошбу сала. Удмуртия биләмәләренә үк кереп торгангадырмы, вотяк (удмурт-ар) дигән сүздән кыскартылып, Вот.Юраш исеме белән йөртелгән) аталса да, кайсыдыр бер вакытта Балтач ягының Салавыч авылыннан күчеп килгән ике гаиләнең җинел кулдан әйтелгән «Салавыч» диюе, сонынннан халыкның аны гади генә шулай атый башлавына китергән. Җитмеш хуҗалыклы Салавычтан кала Вот.Юраш авыл советына тагын 22 хуҗалыгы булган Борисово (чукындырылган татарлар беренче мөмкинлек тууга кабат мөселманлыкка кайтканнар һәм авылларын һәрчак Каенлык дип атаганнар), 21 йорттан торган Калмыково кергән. Соңгысында урыслар яшәсә дә, Тукайча әйтсәк, алар татарлар белән тел вә лөгать алмашып, татар телен туган телләредәй яхшы белгәннәр.

Мирзәхмәт гаиләдә өлкән бала булып, 1922 елның 18 маенда Салавычта дөньяга килә. Аннан соң туган алты нарасыйның икесе төрле елларда сырхаулардан һәм кытлык-җитмәүчелекләрдән вафат була. Үсеп буй житкергән һәм фанилыкта үзләренә тиешле вакытларын яшәүче 5 туганның да икесе генә исән инде. Мирзәхмәт ага әйтүенчә, сиксән сигезенче яшен ваклаучы сеңлесе Мәгъруфә Әстерхан каласында гомер кичерә. «Соңгы утыз ел эчендә нибары ике-өч тапкыр күрешеп бер-беребезнең хәлен белештек», — ди фронтовик.

Салавычта дүрт сыйныф тәмамлаганнан соң, бишенчегә Иске Юраш авылының җидееллык мәктәбенә йөреп укый Мирзәхмәт Муллахмәтов. Кызганыч ки, әтисе еш авырый. «Улым, әниеңнен үзенә генә эне-сеңелләреңне тәрбия кылырга авыр, колхозга эшкә чык инде син», — ди гаилә башы, өлкән угланга бу сүзләрне әйтү авыр булса да. Егор Пономарёв атлы урыс агае колхоз җитәкчелеген ундүрт яшен тутырып кына килүче үсмерне үзе янына хисапчы ярдәмчесе итеп алырга күндерә. Бригадирлар китергән нарядларны исәпләү-теркәү, колхозчыларның хезмәт көннәрен билгеләп бару ише операцияләр тапшырыла малайга. Һәм ул сынатмый, эшен җиренә җиткереп башкара. Белем багажы биш класс белән чикләнсә дә, чут эшләрен заманына күрә ярыйсы

ук яхшы белә. Янә ике елдан, сельсовет секретаре рәисе армиягә алынгач, уналты яшьлек Мирзәхмәтне хозурына дәшеп, ана «портфелен» тәкъдим итә — үзен рәислеккә кыстыйлар икән. Монсыннан да баш тартмый Мирзәхмәт, ни дисәң дә күтәрелү бит. Егетнең тырышлыгын, кушылганны төгәл үтәвен югарыдагылар тиешенчә бәялиләр һәм 1938 елда Алабугада берничә районның активистлары өчен оештырылган «Совет төзелеше» дип аталучы дүрт айлык республика курсларына укырга җибәрәләр. Дүрт ай бер мизгел кебек үтә дә китә. Салавыч егетен район башкарма комитеты рәисе Елово авыл советына сәркатип булып барырга кыстый. Өйдәгеләр тамак туйдыру җәһәтеннән дә кытлык кичергәндә, ни йөзең белән чит авылга китеп бармак кирәк. «Юк» дигәнне ишетергә гадәтләнмәгән партия-совет босслары бу юлы хәлгә керәләр тагын — Мирзәхмәт Муллахмәтовның: «Мине туган авылым Салавычтагы изба-читальняга (бер үк вакытта китапханә ролен дә үтәүче, төрле кичәләр оештырылучы уку йортын халык шулай дип атаган) билгеләсәгез икән», — дигән гозерен канәгатьләндерәләр. Салавыч, Каенлык, Калмыково авыллары өчен мәдәни чаралар оештыруда, агитпропаганда эшендә төрле лозунг-плакат һәм белдерүләр язуда, Октябрь, Май бәйрәмнәрен үткәрүдә зур активлык күрсәтә махсус курслар үткән егет. Мәдәни-агарту эшләрен бу якларда мона кадәр күрелмәгән биеклеккә күтәрә. Аның бу юнәлештәге эшчәнлеге кая барып чыгар иде икән, хәзер әйтүе кыен. Бөтен өмет-хыялларны, матур уйларны Гитлер Германиясенең Советлар иленә сугыш башлавы чәлпәрәмә китерә.

## Сугыш

Сентябрь аенда медкомиссиядә каралырга дип хәрби комиссариаттан повестка килә. Әти-әни, туганнар, эне-сеңелләр һәм авылдашлар белән кочаклашып саубуллашу күренешләре авылдан киткәч тә күз алдында озак тора. Иптәшләре белән бергәләп:

Герман җире кара чирәм,
Әллә кайтам, әллә үләм...
Без авылдан чыккан чакта
Күтәрелде тузаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар...

— дип сузган җыр сүзләре дә колакта тиз генә тынмый. Мирзәхмәтнең сәламәтлегеннән очучы халкы да көнләшерлек. Шуңа күрә аны табиблар бертавыштан яңа гына оешып килүче һава десанты гаскәренә яраклы дип таба һәм Саратов өлкәсенең Энгельс каласында дислокацияләнгән беренче десант корпусының беренче бригадасы батальонына билгелиләр. Парашюттан сикерүләр, автоматтан ату күнекмәләре, марш-бросоклар белән атналарның үткәне сизелми дә кала. Декабрь башларында десант бригадасын дошман тылына ташларга әзерлиләр. Шулчак атаклы Себер дивизияләрен Ерак Көнчыгыштан башкала тирәләренә күчереп һөҗүмгә күчү һәм фашистларны куа башлау командованиене бу уеннан кире кайтара. Февраль аена кадәр десантчыларны тынгысыз киеренкелектә тоталар, бүген-иртәгә алгы сызыкка озату ихтималы турында кисәтеп, сугыш күнекмәләренә өйрәтүләрне дәвам итәләр. Ниһаять, 1942 елның февралендә беренче һава десанты бригадасын Люберцы тирәләренә ташлыйлар. Мәскәүдән 120 чакрымнар чамасы артка алып ташланган гитлерчыларны эзәрлекләү Смоленск янына җитәрәк туктап калган. Каршы яклар, локаль бәрелешләрне санамаганда, оборона тотып,

ара-тирә ялкау гына артиллерия дуэльләре алып бару белән чикләнә. Ике як та разведкалар оештырып, бер-берсен өйрәнә-капшый, язгы зур һөҗүмгә әзерләнә. Кызыл Армия командованиесе Смоленск юнәлешендә сугыш хәрәкәтләре башлап җибәргәнче дошман тылындагы Ейск каласы янәшәсенә десант бригадасын төшерергә ниятли. Унсигезенче февральгә каршы төндә әүвәл беренче бригада составындагы 200 кешелек төркемне җибәрәләр. Әгәр алар уңышлы һөҗүм җәелдерсә, башка батальоннарны да сугышка күтәрү, алар артыннан икенче, өченче десант бригадаларын рейдка җәлеп итү күздә тотыла. «ППШ» автоматлары һәм аларга бирелгән дүрт обойма патрон (һәр обоймада 71әр патрон), гранаталар белән коралланган 200 кешелек беренче төркемдә татар егете Мирзәхмәт Муллахмәтов тә бар. Аларны: «Хәерле сәгатьтә!» — дип, корпус командующие үзе озатып кала. Тик бик үк хәерле сәгатьтә булмаган икән шул.

## Беренче чирканчык

Бөек Ватан сугышында совет халкының гаять зур югалтуларга дучар ителүе күпчелек сугыш стратегларының дошманны тиешенчә бәяләп бетермәве һәм еш кына сәләтсез, төптән уйланмаган операцияләр оештыруына бәйле дип саный элекке фронтовик. «Кинофильмнарда, сугыш турында язылган китапларда вакыйгалар шомартып сурәтләнә, кызганыч ки, алар чынбарлыктан гаять ерак», — ди ул.

Немецлар йоклап ятмый, аларның разведкасы әйбәт эшли. Унҗиденче февраль төнендә һавадан ташланасы десант батальоны турында алар инде алдан белеп торалар һәм Ейск тирәсендә партизаннар тарафыннан ягыласы өч зур учак урынына (тегеләрен, бәлки, юк иткәннәрдер) 50 чакрымнар чамасы читтә өчпочмак рәвешендә үзләренекен тергезәләр. Очучыларның урынны билгеләүдә шулкадәр ялгышлык җибәрүе гаҗәп хәл, әлбәттә. Әмма факт — факт булып кала: ин яхшы әзерлекле дип саналган 200 сугышчы фашистлар чолгап алган урынга сикерә. Немецлар җирдән күккә яктырткыч ракеталар чөя. Дошман парашютчыларны чүпли генә инде. Шулай да йөзләп сугышчыга исән-имин төшеп житү насыйп була, араларында яраланучылар да бар. Батальон командиры һәлак булган, рота һәм взвод командирлары да күренми диярлек. Шөкер, батальон комиссары исән калган икән, ул төркемне кыенлык белән бер йодрыкка туплап, гитлерчылар белән сугыша-сугыша аларны якындагы урманга алып керүгә ирешә. Шуннан соң үзебезнекеләргә кушылу өчен атналарга сузылган җәфа чигүләр башлана. Төннәрен генә хәрәкәт итәләр, фашистлар белән зур бәрелешләргә кермәскә тырышалар. Берничә көнгә исәпләп бирелгән коры паёкны (ысланган казылык, тушёнка) мөмкин кадәр кысып тоталар. Урманнарда кып-кызыл булып утырган өшегән миләш тә ачлыкны басарга ярдәм итә. Сусауны кар йотып басалар. Март урталарында мең бәлаләр белән фронт сызыгы аша үтеп, үзебезнекеләргә кушылалар. Аралары сирәгәйгән, житү сакал-мыеклы, тәмам йончыган-таушалган хәлдә. Үзләрен ни көткәнен белгән булсалар, шулкадәр тырышырлар иде микән? Особистлар көнен дә, төнен дә каталажкага ябылган десантчылар янына көтмәгәндә кереп сорау алулар белән тинтерәтә. Күпме кеше гомерен саклап калган батальон комиссарын беренче көнне үк каядыр алып китәләр. «Сатлык-провокатор» ярлыгы тагып, тыл күселәре булып оялаган подвалларында атып үтергәннәрдер, мөгаен. Солдатларга да иман әһеле күрсәтмиләр. Һаман бер үк сораулар: нигә дошманга сатылдың, нинди корткычлыклар эшләргә куштылар?

Кемдер өстән әмер ирештергәндерме, ниһаять, десантчыларны элек

хезмәт иткән частьларына кайтаралар. Адәм рәтле паёкка куеп, тире белән сөяккә калганнарны ипкә-юньгә китерү өчен кешечә тәрбияләргә дә кирәк бит әле. Ашавың гына булсын, яшь организм тиз тернәкләнә анысы. Инде март ахырларына яңартылган-тулыландырылган батальонны беренче десант корпусы составында Ленинград ягына таба күчерәләр. Бөек Новгород тирәләре була бу. Командование Волхов фронтында һөҗүмгә күчеп, ике урыннан немец оборонасын өзүне һәм аларның тылына төшеп, зур группировкаларын камалышта калдыруны планлаштыра. Тик хәйләкәр дошман бу юлы да өлгеррәк булып чыга, 3-4 көнгә алданрак җитешеп, фронтның беренче һәм икенче линияләрен дә өзеп, тирән тылга үтеп керә, безнең армияләр аяныч хәлдә кала (генерал Власов үз армиясен Волхов фронтында дошманга тапшырган).

## Корпусларны — дивизияләргә

Фашистлар бөтен бер Волхов фронтын тар-мар китергәндә, ни өчен югары әзерлекле һава-десант бригадаларын, корпусларын ярдәмгә ташламаганнардыр, һич аңлашылмый. Сабак булмаган микәнни соң?

Хәрби тарих материалларыннан билгеле булганча, Бөек Ватан сугышы елларында Кызыл Армиянең 6,2 миллион солдаты әсирлеккә төшкән. Шуның дүрт (!) миллионы 1941 елда ук. Германиянең коры җир гаскәрләре штабы башлыгы Ф.Гальдер үзенең көндәлекләренә менәниләр дип язган: «Саллы өлеше юк ителгән совет дивизияләрен ашыгыч төстә аннан-моннан өйрәтелгән, сугышу техникасын үзләштермәгән контингент белән тулыландырып, килгән шәпкә сугышка кертәләр. Ансы да бер йодрык астында түгел, ә аерым-аерым таркалган көчләр белән эшләнә, нәтиҗәдә алар зур югалтулар кичерәләр. Урысның сугышу тактикасы: 3 минутлык артналёт, аннары — пауза, аннан соң — пехотаның «ур-ра» кычкырып атакага ташлануы, һәм ул дулкын-дулкын булып (кайчагында андый дулкыннар саны 12гә җитә) озак дәвам итә. Никтер бу чагында артиллерияләре дәшми. Шулар нәтиҗәсендә аларның югалтулары гаять зур».

Десантчыларны сугышка кертәсе урында Новгород өлкәсе авылларына батальонлап һәм роталап тараталар. Югары командование нинди критерийлардан чыгып фикер йөрткәндер, тик десантчылар арасында корпусларның күбесен укчы гвардия дивизияләре итеп үзгәртәчәкләр икән, дигән сүз тарала. «Җил исми яфрак селкенми», — ди халык. Имеш-мимешләр дөрескә чыга. Кырык икенче елның июнь башларында Мирзәхмәт Муллахмәтов хезмәт иткән беренче һава десант корпусын Мәскәү янына күчереп, 37нче укчы гвардия дивизиясе итеп үзгәртеп коралар. Мирзәхмәтләр бригадасы 69нчы полкка әверелә. Дивизиядә өч пехота полкы, дүртенчесе — артиллериянеке. Һәр пехота полкында 200ешәр сугышчыдан торган аерым автоматчылар ротасы бар. Монда «иң-ин»нәрне кертергә тырышалар, чөнки гаскәрләрне автоматлар белән коралландыру әле киң колач алып кына килә. Моңа кадәр өстенлек күбрәк винтовкаларга бирелгән, алары да җитешми. Солдатларны атакага күтәргәндә офицерлар еш кына: «Үлгән иптәшегезнекен алырсыз», — дип әйтә торган булалар. Сугыш башындагы уңышсызлыкларның саллы өлеше шуның белән аңлатыла да инде: яланкул баштанаяк коралланган фашист солдатына каршы (аларның күбесенең кулында — «Шмайссер» автоматы) барып кара син!

Гитлерчылар Мәскәүне кырык беренче елгы кампанияләре вакытында турыдан-туры ала алмагач, икенче елның май ахырларында Дон буе далаларыннан һөҗүмгә күчеп, Сталинградка чыгарга һәм, Иделне кичкәннән соң, кабат башкалага ыргылырга җыена. Аларның иң яхшы танк һәм мотопехота

дивизияләре инде юлларында киртә булган Кызыл Армия частьларын сытарга омтыла. Максатларына җиңел генә ирешә алмасалар да, сугыша-сугыша стратегик әһәмияткә ия калага якынайганнан якынаялар. Көчләр тигезсез шул: июль урталарына дошман инде Сталинград юнәлешендәге зур һөҗүмгә 18 дивизия (250 мең солдат), 740 танк, 1200 самолёт, 7500 туп һәм миномётын кертә. Совет гаскәре бу ташкынга 16 дивизия, 360 танк, 337 самолёт, 7900 туп һәм миномёт белән каршылык күрсәтә.

Утыз җиденче гвардия дивизиясен июнь ахырларында ашыгыч рәвештә Мәскәү яныннан Воронеж юнәлешенә күчерәләр. Тик Мирзәхмәтләргә немецның алдынгы частьларын ошбу шәһәр янында түгел, ә Дон елгасының аргы ягында каршы алырга туры килә — фашистлар оборонаны өзгәннәр икән. Тиз арада окоплар казып, ут нокталары урнаштыралар. Дошманның килгән уңайга елганы кичеп ары китү нияте барып чыкмый, әллә ничә мәртәбәләр кабатланган атакасын туктатып, суны кичкән җанлы көчләрен юк итәләр, исән калганнары чигенергә мәҗбүр була, беренче бәрелештә үк 12 танкларын яндыралар. Нәни генә уңыш та кызылармиячеләрне канатландыра. Өч атна дәвам иткән канкойгыч сугышларда максатларына ирешә алмагач, гитлерчылар тактикаларын үзгәртә, Донның аргы ягына чыгу ниятеннән ваз кичеп, башка юнәлешне сайлыйлар. Командование башка хәрби берләшмәләр белән беррәттән 37нче гвардия дивизиясен дә куркынычрак дип тапкан урынга — Сталинград тирәсенә күчерергә әмер җиткерә. Алар калдырган траншеяларга һәм ут нокталарына калмыклардан торган частьлар китереп урнаштыралар.

## Сталинград тәмугы — Мамай курганы

Һавадан бомбага тотулар, артиллерия утыннан һәм немецның көненә әллә ничә мәртәбә кабатланган һөҗүмнәреннән шактый югалтулар кичергән 37нче дивизияне тулыландыру өчен әүвәл Иделнең сулъяк ярына чыгаралар. Һәм сентябрь башларында сугышчан әзерлеккә китерелгән хәрби берләшмә елганы икегә бүлеп урнашкан «Заячий» утравы каршына куела. Кичүнең бирге ягы бик киң. Көн яктысында аннан чыгу мөмкин түгел, һавада «патшалык» иткән фашист «козгыннары» шундук пәйда була. Шуңа күрә полкларны батальонлап баржаларда төнлә ташыйлар. Күп чакрымнарга сузылган «Заячий»га аяк басуга озак тоткарламыйлар, аның икенче читендә салынган понтон басма күперргә куалыйлар. «Тизрәк-тизрәк!» — дип ашыктыралар командирлар, чөнки яктырганчы 200 метр озынлыктагы басмадан каршы ярга чыгып җитешергә кирәк. Сталинград «Заячий»дан 7-8 чакрымнар чамасы өстәрәк. Хәлләрнең биредә хөрти икәнлеге күренеп тора — аларны килгән уңайга сугышка кертәләр.

Дөньяда тиңе булмаган Сталинград сугышы турында күп яздылар. Күп нәрсәләр ачыкланды һәм дөнья җәмәгатьчелеге хозурына җиткерелде. Шулай да титаник бәрелеш-кырылышның без белмәгән (мөгаен, киләчәктә дә белә алмаячак) яклары, йөз меңләгән аерым детальләре калачыр. Вакыт пәрдәсе астындагы әнә шундый чиксез күп эпизодларның берсе — атаклы Мамай курганында үзе күргән-кичергәннәре турында менә ниләр сөйләде Мирзәхмәт ага:

— Адәм баласы түзә алмаслык шартларга да күнегә икән кеше дигәнең. Хәер, түзмичә кая барасың: бөтен тирә-юньдә — үлем, үлем. Фашист көндез бар булган тимер ташкыны, җанлы көчләре белән күктән һәм җирдән ябырыла, урыны белән елга ярына килеп җитә яза. Шәһәр үзе 70 чакрымга кадәр сузыла, ә ингә 3-4 чакрымнан артмый. Төнлә безнең гаскәр контрһөҗүмгә күчә, югалткан позицияләрне зур корбаннар бәрабәренә кире кайтара. Кайчагында нинди дә

булса объект, ныгытма тәүлегенә өч-дүрт һәм аннан да күбрәк мәртәбә кулдан-кулга күчә. Мирзәхмәт Муллахмәтов хезмәт иткән 69нчы полк та дивизиянең башка полклары кебек үк Мамай курганының үзәк өлешеннән, гаять көчле каршылык күрсәтүләренә карамастан, төньяк өлешкә кысрыклана. Аяк астында кайда немец, кайда үле совет солдаты ятканын да аерышлы түгел, кан елга булып ага. Монда — бик зур мәйданны биләгән трактор заводы. Фашистлар уңайлырак позициядә — өстә (Мирзәхмәт Муллахмәт улы сөйләвенчә, очар кошлар биеклегендәге яр өсте тигезлегеннән соң башланып киткән манзара — киртләч-киртләч рельеф хасил итеп аска төшкән калкулыклар рәвешендә күз алдына килеп басты. Анда, берничә чакрым киңлектә, кала урнашкан, янәшәдә үк — завод). Никадәр тырышып, яңадан-яңа көчләрен сугышка кертүгә карамастан, дошман һаман совет дивизияләрен елга суына себереп төшерә алмый. Алар тәмам аптырашта: кайбер частьларында юньләп сугышыр кешесе дә калмаган кебек, тик һөҗүмгә күчүләре була — әллә каян гына бөтен төр кораллардан ут ачалар һәм контратакага күтәреләләр, штык сугышына ташланучыларның күбесе яраланган, башлары бинт белән уралган. Исәпсез-сансыз бәрелешләрнең берсендә Мирзәхмәт янында гына мина ярылудан нык контузия ала. Шартлау дулкыны әллә кая читкә алып ыргытса да, ни гаҗәп, ул хәтта яраланмый да. Тик колаклар берни ишетми башлый. Аңа медсанбатка яки госпитальгә, һич югы лазаретка барырга кирәк. Ә кайда соң алар? Һәркемнең үз тормышын үзе кайгыртудан башка чарасы юк. Авыр яралылар иң элементар ярдәм дә күрсәтелмәүдән (еш кына хәтта андый мөмкинлек тә юк) үлемгә дучар ителгән, җиңел яралылар кулларындагы коралларын төшермичә дошманга каршылык күрсәтүен дәвам итә. Мирзәхмәт тә дөм саңгырау килеш гитлерчыларга автоматтан ата, гранаталар ыргыта. Ул аларны үтермәсә, үзен үтерәчәкләр. Дөнья белән бәйләп торган ишетү сәләте югалса, кеше үзен ярымфантастик хәлдә тоя икән: тирә-якта һәр секунд үлем чәчеп ут давылы котыра, ул ана төштәге кебек кенә. Ана бәхет елмая (мондый шартларда шулай әйтергә яраса), атна чамасы үткәч, колак барабаннарын кыскан саңгыраулык чыртлап ачыла һәм ефрейтор Муллахмәтов кинәт кенә реаль яшәү белән үлем дөньясына әйләнеп кайта:

— Дивизиянең һәр полкында (бүтән полкларда да шулай) 200 сугышчыдан торган аерым автоматчылар ротасы бар иде, — дип сөйли фронтовик ветеран. — Октябрь урталарына безнең автоматчылар төркеменнән нибары 18 кеше исән калды, шулар исәбенә рота командиры белән политрук һәм бер взвод командиры да керә. Хәлләр гаять хөрти, фашистлар белән маңгайга-маңгай бәрелешләрдә югалтулар өстенә дошман снайперларының безнең участоктагы сугышчыларны кыр куяннарыдай чүпләп торулары да тенкәгә тиде. Озакка сузылган дуэльдән соң ике фашист снайперының берсен безнең мәргәннәр юк итте анысы.

Немецларның позицияләре уңайлырак урында. Аларга кызылармиячеләр казыган окоплар, урнаштырган ут нокталары һәм ныгытмалары уч төбендәге кебек ачык күренә. Снайперлар өчен генә түгел, көн яктысында «гади» фашист та бер җирдән икенчесенә күченүчене тере мишень урынына атып аудара. Шуңа да ярымкамалышта калган 18 автоматчысы белән рота командиры 16 октябрь төнендә хәлиткеч ыргылышка әзерләнә. Исәбе — үзебезнекеләргә кушылу. «Үлсәк, сугышып үләрбез!» — ди ул. Кызганычка каршы, полк штабы белән генә түгел, элемтә — батальоннныкы белән дә юк. 1941-1942 елларда (хәтта 1943 елда да) Кызыл Армия гаскәри берләшмәләре арасында чыбыклы элемтә булганлыктан, ул еш өзелә һәм аны ут астында ялгап та булмый (аерым частьлар идарәсез калганлыктан, аларны тар-мар китерү дошман өчен берни

түгел; сугыш башындагы унышсызлыкларның төп сәбәпләреннән берсе дә шул). Немец сугышка берничә ел алдан әзерләнгән: аның танк армадалары һәм мотопехота дивизияләре арасындагы синхрон бергәлек радиоэлемтә аша тәэмин ителгән. Гитлер армиясенең ил үзәгенә үк чагыштырмача җиңел үтеп керүе шуның белән аңлатыла.

Сталинград казанында әлегәчә исән калып дошманга каршы торучылар өчен, ярый әле алдан әзерлеген күреп, һәр йорт подвалында диярлек азык-төлек запасы туплап калдырганнар: ашыйм дисәң — тушёнка, эчәм дисәң — спирт җаның теләгәнчә! Эчәр өчен суга кытлыктан автоматчылар «пятачогы»на төшеп ярылган тирән бомба чокырында җыелган яңгыр суы коткара. Һәр ике як атналар-айлар буена сузылган эреле-ваклы сугышлардан тәмам хәлсезләнеп кыска вакытка тынып калган. Ике якта да резервлар юк диярлек. Рота командиры форсаттан файдаланып калырга карар кыла һәм 18 «бөркет»ен ияртеп төн карангылыгына атлый. Өч йөз метрлар чамасы үтәләр автоматчылар, дүрт йөз. Каядыр читтәрәк барган атыш тавышларыннан кала бу тирәдә бернинди тавыш ишетелми. Биш йөз метрлап ара узганнан соң, капитан тукталырга кушып кулын күтәрә. Чит телдә сөйләшкәннәре ишетелә — немецча түгел. Кемнәр булыр? Һәрхәлдә безнекеләргә охшамаганнар. Рота командиры калган сугышчыларының гомерен куркыныч астына куярга теләмичә, кире элекке позицияләренә кайтуны кулай күрә. Мирзәхмәт Муллахмәтов белән бер урыс егетенең фамилияләрен атап: «Әнә теге йортка кереп урнашыгыз, иртән көн яктыргач вазгыятькә карап эш итәргә кирәк булса, дошман белән бәрелешкә керерсез», — дип әмер бирә, Мирзәхмәткә кул пулемёты тоттырып. Запаска гранаталар да бирә.

## Яралану

Октябрь таңы көттереп ата шул. Мирзәхмәт белән иптәше төнне керфек тә какмыйча үткәрәләр. Дошманның борын төбенә килеп ояла да, йокларсың ди бар. Шушы вакыт эчендә егет әллә ниләр уйлап бетерә, 20 еллык гомернең бөтен ваклыкларына кадәр хәтер иләгеннән үткәрә. Инде фронтка алынуына бер елдан артык үтеп, шуның 8 ае ут эчендә узса да, ничектер ул каршысына килеп баскан үлем өрәге турында уйламаган. Әллә җае булмаган шунда? Хәер, уйланып торырга вакыты андый түгел. Ә монда — командирлары сугышчан бурыч куеп, катгый әмерен ачык белдергәч, карышып булмый. Буйсынмый хәлең юк. Аларның күрәләтә үлем казанында калдыруларын белсәң дә, «есть, товарищ капитан!» дияргә туры килә. Тыңламасаң, ротный кобурасыннан пистолетын чыгарып маңгаеңа терәп атачак! Андый очракларны күргәне бар инде. Хәрби чор законнары буенча дөрес эшләгән дип, «особистлар» үк аның бу гамәлен хуплаячак. Әмеренә буйсынсаң, аны үтәргә кирәк. Күңелдә барыбер кечтеки генә булса да өмет уты бар: бәлки, берәр җае чыгар, әнә ич, командир вазгыятькә карап эш итәрсез, ди. Бәлки, тозактан атышсыз гына ычкыну җае табылыр? Шундый уйлар белән юанырга тырышып, Мирзәхмәт алдагы тәрәзә аша әледән-әле горизонт шәйләнергә тиешле тарафка күз ташлады. Ниһаять, көттереп кенә таң атты. Мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар ачыграк ишетелә. Тәрәзә катына шуышып барып, каршы якка күз салса, анда немецлар түгел, румын солдатларының окоп казуын күрде. Аларны кигән формаларыннан, погоннарыннан танып була. Димәк, биредәге немец частьларын румыннарныкы белән алыштырганнар. Тегеләрен тулыландырыр өчен икенче эшелонга озатканнардыр. Румыннар немецлардан кайтышрак сугыша, әлбәттә. Тик моңа карап кына җиңеллек килер микән?

Бер румын офицеры казыла торган окоп каршына баскан да көрәкләрен эшкә җиккән берничә солдатка үз телендә нидер анлата. Шулчак Мирзәхмәтнең башында бик әйбәт план туды: ул кулдашын элекке позицияләренә кайткан иптәшләре янына җибәреп карарга ният кылды: «Әгәр румыннарга каршы ут ачсак, иң күп дигәндә дә 8-9ын гына дөмектерәчәкбез, алар безне камап әсирлеккә төшерәчәк яисә шушы йорт эчендә ут төртеп яндырачак. Кемнәр икәнен белдек. Бар, кайтып, капитанга хәлне аңлат. Әгәр рөхсәт итсә, ак флаг болгасыннар, аннары мин дә кайтырга тырышырмын», — дип, автоматчы кулдашын мөмкин кадәр саклык белән төнлә кергән ишектән тышка озатты. Ярый әле румыннар берни сизмәде. Офицер аларга арты белән тора, бу да ярдәм итте. Шуыша-шуыша урыс егете үзебезнекеләргә җитте бугай, чөнки ул яктан ак флаг болгаулары күренде. Мирзәхмәтнең эченә чак кына җылы йөгерде, димәк, өйне ташлап китәргә рөхсәт. Тик ничек бу тозактан чыгарга, ишек нәкъ менә дошман позицияләренә карый бит. Иптәшенең китүен ярымкараңгыда ярый абайламадылар, румын офицерының аркасы белән басуы һәм солдатларын сөйләштерүе дә коткарды. Хәзер андый чак түгел, аны чыккан уңайга күреп алачаклар һәм дистәләгән коралдан ут ачып теткәләп бетерәчәкләр, иң яхшы дигәндә дә әсир төшерергә тырышачаклар. Дошманда әсирлекнең ни икәнен аның ишеткәне бар инде. «Нишләргә соң әле, бу капкыннан ничек ычкынырга? Шушында бетәрмен микәнни?» — дип уйлады ул, чарасызлыктан нишләргә белмичә. Шулчак күзе почмакка сөykәп куелган кечкенә ломга төште. «Базга төшеп, йортның нигезен казып карарга кирәк! — дигән уй чагылып узды миендә. — Иске агач йортның нигезе таштан өелгән булырга тиеш». Чыннан да шулай икән. Мөмкин кадәр тавыш чыгармаска тырышып, башта балчыкны базга иште, аннары ташларны куптарып, гәүдәсе сыярлык тишек ясавы авыр булмады. Йорттан чыккач, утыз метрлап аска таба шуышканнан соң, трактор заводы янәшәсенә салынган чуен юл канавына килеп эләкте. Әнә шул канау коткарды да инде аның гомерен, дошман күзенә чалынмыйча инкүлектән шуышу һәм үзләренең «пятачок»ларындагы иптәшләренә кушылу әлләни катлаулы булмады.

Адәм баласына бәхет өчен күп кирәкми: әлегә ул исән, ротный күрсәтмәсе белән алдына тушёнка ачып куелган, спирт китергәннәр, ярты кружка чамасы иң кадерле сыекча — су да бар хәтта (2-3 көн элек кенә бомба чокырындагы су эчелеп, бер өлеше парга очып түкәнгән иде. Мең бәлаләр белән, караңгы төннәрнең берсендә, Иделгә төшеп ике чиләк су алып менделәр, һәм аны хәзер күз карасы кебек саклап тоталар). Мирзәхмәт ашыйсы, аннан битәр үтереп эчәсе килүен тойды. Хәл керсен өчен, азрак спирт уртлап, артыннан су йотуга, ни дә булса кабарга өлгермәде, дошман артиллериясе ут ачты. Снарядлар әле тегендә, әле монда ярыла. Сугышчылар окопларына төшеп чума. Әлегә каршы яктан танкларның үрмәләве, пехотаның килүе дә күренми. «Озак көттермәсләр, хәзер күренерләр», — дип уйлап куя дошманның сугыш тактикасына күнегеп беткән Мирзәхмәт. Чыннан да артналёт тынар-тынмас, танклар артына ышыкланып, румын солдатларының килүе күренә. «ПТРның ике генә патроны калды, иптәш капитан», — дип кычкыра танкка каршы мылтыктан атучы солдат. «Төбәп гусеницаларына атарга, калганнарын гранаталар белән каршылыйбыз!» — дигән әмерен ирештерә рота командиры. Беренче «бронебойный» бушка оча. Икенче ату — ур-ра! — алдан килгән танк тукталып бер урында әйләнә, димәк, нәтиҗә бар. Янә өч танк кала. Кайбер сугышчылар окоплардан чыгып, «Тигр»ларга каршы үрмәли, кулларында граната бәйләмнәре. Әнә, инде тагын берсе яна, аннары — икенчесе. Соңгы танк кирегә борыла түгелме? Әйе, шулай! Пулемёт тыкылдый, дошманның алгы сафлары чалгы белән чапкандай ауганы күренә.

Мирзәхмәт янәшәсендәге исән калган иптәшләренең автоматларыннан ут ачуын күреп-сизеп тора, аның да автоматы кыска-кыска чиратлар бирә. Аннары командирларының һөҗүмгә өндәгән боерыгы янгырый. Окоплардан чыгып, сугышчылар ярсулы кул һөҗүменә ташлана. Ә штык сугышында совет солдатына тиңнәр юк. Чабып барган чагында Мирзәхмәт нindidер мизгелдә чак кына читкә тайпылып, артка борылып карый, һәм шул нәрсә аның гомерен саклап кала — фашист өстәге «оя»сыннан йөрәгенә дип аткан ядрәсе (снайпер атканын сугыш тыңгач ачыклыйлар) аркасыннан кереп, үпкәсен тишеп үтә һәм уң кул сөяген чәрдәкли. Кулының каты яралануы егеткә беренче мәлләрдә тәненең башка урыннары да җәрәхәтләнүен ачыкларга мөмкинлек бирми. Дошманның бу һөҗүме дә кире кайтарыла. Вакыты белән күз аллары карангыланса да, Мирзәхмәт тешен кысып булса да түзәргә тырыша. Чөнки аның югалтып егылса, беркем дә үзенә ярдәм итә алмаячагын белә ул. Күпме авыр яралылар тиешле медицина ярдәме күрсәтмәүдән үлделәр инде. Санитарлар катастрофик рәвештә житешми. Хәер, очраганнары да нинди ярдәм күрсәтә ала соң? Яраны кысып бәйләсәләр генә инде. Еш кына кайда үзебезнекеләр, кайда дошман икәнлеген дә белмәгән шартларда, авыр яралыларны тылга озату турында уйлыйсы да юк. Алар — язмыш кочагына ташланган, алар — үләчәк. Бераз соңрак, мең бәлаләр белән Себер ягыннан булган бер татар егете белән (уң кулының бер бармагын өздергән ул миһербанлы зат очрамаса һәм мине житәкләмәсә, тәмуггтан исән килеш чыга алмаган булыр идем, ди Мирзәхмәт ага) елга буена төшеп житкәндә, вакытлыча яралыларны җыю пункты хезмәтен үтәүче бинаһая зур ике бәрәңге подвалының берсенә керә алар. Андагы күренеш аяусыз сугыш чынбарлыгыннан да коточкычрак: кайсы кулсыз, кайсы аяксыз, кемдер күзсез, ә кемнеңдер эчке органнары агып чыккан хәлдә иңәндә аунап яткан меңләгән бичараларның ярдәм сорап кычкыруларыннан, елауларыннан һәм ыңгырашуларыннан, һәм илерүләреннән чәчләр үрә тора. Сәламәт психикалы кеше дә бу күренешкә озак түзә алмый. Бу бичаралар шулай ук һәммәсе язмыш кочагына ташланган, аларны елга аръягына эвакуацияләү белән беркем шөгыльләнми. Андый мөмкинлек юк һәм була да алмый. Дошман елга ярына ук өстән һәм астан, уннан һәм сулдан бөтен хәрби куәте белән дөмбәсләгәндә, Сталинградның һәм илнең язмышы кыл өстенә куелган. Мондый чакта корбаннар белән исәпләшәләр димени?!

## Җәфа чигеп йөрүләр

Үзенә ярдәм итәргә алынган Себер егете озатуында, күңелдә авыр тәэсир калдырган бәрәңге подвалыннан чыкканда, Мирзәхмәт «пятачок»та (андый «пятачоклар»ның Мамай курганында исәбе-хисабы юк) калган иптәшләрен хәтеренә төшерде. Унжиденче октябрь көне иде бу. Советлар үзәгендәге чал Идел буена урнашкан «корыч» кала өчен тарихта тиңе булмаган 17 июльдә башланган сугышның 18 ноябрьдә тәмамланачак беренче өлеше төгәлләнергә нәкъ менә бер ай калган көн. Мирзәхмәт Муллахмәтов аларын инде күрмәячәк, ул безнең гаскәрнең 19 ноябрьдә һөҗүмгә күчеп, Паулюс армиясен кырык өченче елның 2 февралендә Сталинград астында тар-мар китерүен, 300 мең кешелек үз группировкасының әсир төшүен дә күрмәгән. Ерак Татарстанының иң төньяк-көнчыгышында урнашкан Салавыч егете бу вакытта тирән тылдагы госпитальләрдә булачак. Кем белә, әгәр яраланып, үз аягы белән тылга эләгә алмаса, ул, бәлки, көне-төне ут өермәсе котырган бу тәмугта исән дә калмас иде (күп еллар узгач, Мирзәхмәт ага Сталинград фронты командующие генерал-полковник (1942 елда шул чинда — соңрак армия генералы) А.И.Еременконың Сталинград сугышы турындагы мемуарларыннан составына аларның 69нчы

полкы кергән 37нче гвардия дивизиясеннән шәһәр өчен барган сугышларда нибары йөздән артык кешенең генә исән калуын укып белә. Димәк, исән калу — нуль дәрәҗәсендә!) Саубуллашканда, ярасын кысып бәйләгәннән соң, әлегә исән булган иптәшләре аның белән кочаклашып саубуллашалар. «Имин генә икенче эшелонга чыгып җитәргә тырыш, безнең хакта дөреслекне башкаларга да җиткер!» — дип эндәшә рота командиры. Бөтенесенең үзәкләре өзелә инде, чөнки белеп торалар: бу аларның якты дөньяда соңгы саубуллашулары. Инде басма-күпердән «Заячий» утравына үткәндә шуларны уйлап ефрейторның күзенә яшь элпәсе эленә.

«Заячий»да яралыларга беренче ярдәм күрсәтteләр. Себер татарының кул бармагы гына өзелгәнлектән, сөйләшеп тә тормадылар — кире бордылар. Алгы сызыкта җанлы көчләр катастрофик төстә җитешми, шуңа күрә җиңел яралыларны гына түгел, кулына корал тотып дошманга каршылык күрсәтә алырлык җитди җәрәхәт алучыларны да ут эченә куалыйлар иде. Мирзәхмәтнең коткаручысыннан исемен сорап калырга да башына килмәгән. Соңыннан илтифатсызлыгы өчен үзен озак битәрләде ул, «исән калсаң ярар иде», дип теләкләр теләде. Утраудан сул як ярга чыгу җинелләрдән түгел, кем ничек булдыра инде. Сталинград «казан»ына озатылучы батальон һәм полкларны гына төн карангылыгында баржаларга төяп тегеннән «Заячий»га китерәләр, чөнки алар «пушка ите» булырга кирәк. Ә утраудан тылга әләгергә теләгәннәрне үз ирекләренә куйганнар диярлек. «Суга батучыны коткару — батучының үз эше» дигән кебегрәк инде. Шулай да алай ук түгел икән: эреле-ваклы көймәләр ике якка да йөреп тора, хәтта саллар белән дә чыгалар. Исән калу — анысы бәхет эше. Һавада еш пәйда булган фашист очкычларының авиаударына туры килмәсәң ярый ул. Андыйга юлыксаң, су төбенә китмәвең икеле. Мирзәхмәт бер көймәгә әләгеп, су дәрьясын кичкәндә, андый хәтәргә тарымады, рәхмәт төшкере. Шулай да дошман артиллериясе бу тирәләрне онытмый икән: әле ялкау гына, әле көчәйтеп, снаряд арты снаряд яудыра, су өстендә күтәрелгән фонтан баганалары әллә кайларга чәчелә. Кайчагында фонтаннарга ияреп, төгәл туры килүдән йөзгечләрнең һәм алар өстендәге кешеләрнең теткәләнгән өлешләре, барысы бергә буталып, өскә күтәрелә дә, ниндидер бер мизгелдә, җирнең тарту көченә буйсынып, аска ишелеп төшә. Баткан нәрсә бата, батмаганы су өстендә чайкалып йөзүен дәвам итә. Миллион еллар буена моның ишене күрмәгән борынгы елга үзе дә тилерер чиккә җиткән бугай, югыйсә аның суы коңгырт катыш кызыл төскә кереп, ыңгырашып акмас иде. Елга булып аңа аккан адәм канын үз суына сеңдереп бетерә алмый, тилмерә булыр.

Ниһаять, аргы яр. Мирзәхмәт үзен бик начар хис итте. Башы ярылырга җитеп авырта, күңеле болгана. Ике тәүлек чамасы авызына валчык та капканы булмаса да (азрак спирт һәм су эчүен санамаганда), ни гаҗәп, ашыйсы килми. Шуңадыр инде, бар гәүдәсен хәлсезлек баскан. Өстәвенә снайпер пулясы чәрдәкләп сындырган уң кулы сызлый. Каядыр башынны төртеп ике-өч сәгать чамасы булса да черем итеп алсаң иде — ярамый. Кемгәдер ияреп, карангыланганчы берәр якындагы лазаретка барып җитәргә кирәк. Ялгыз башы атларга көче җитмәгәнлеген егет ачык тойды. Шунда ул үзенә кирәкле юнәлешкә атлаучы офицерны шәйләп алды. Яше буенча аннан чак кына өлкәнрәк булыр. Кай җире яралангандыр, анысы күренми, һәрхәлдә җәрәхәте артык авыр булырга охшамаган, чөнки аяк атлаулары ук җилле. Менә кемгә иярергә кирәк. Мирзәхмәт сызлануларын онытып, офицерга (энгер-менгердә петлицасындагы кубикларын аерып бетермәде):

— Иптәш командир, миңа лазаретка кадәр кулыгызга тотынып барырга рөхсәт итсәгез икән, — дип эндәште. Уңай җавап ишетермен дип, ул тегенең

инбашына да орынган иде. Тик ялгышты. Теге адәм борылып, ана акаеп карады.

— Уйди отсюда, сопляк. Без тебя тошно, — дигән ысылдауга охшаган аваз чыгарып, Мирзәхмәтнең бинт белән уралган кулыннан эләктереп, көч белән этеп җибәрде. Егетнең кыргый авыртудан күзеннән утлар күренде, һәм ул ниндидер төпсез бушлыкка чумды.

Аңына килгәндә, җир өстенә карангылык пәрдәсен япкан иде инде. Хәер, октябрь төне булса да, чын карангылык дип тә булмый торгандыр, чөнки Сталинград тарафындагы әллә ничә чакрымнарга кадәр сузылган уттөтен казанының биниһая дәү ялкыны биешеп, тирә-юньне инглиз язучысы Герберт Уэллсның фантастик романнарында сурәтләнгән марсианнарның Җир цивилизациясенә һөҗүмен хәтерләтә. Мирзәхмәт көч-хәл белән аягына торып басты. Каядыр бару турында уйлыйсы да юк. Ярый әле ерак түгел элекке еллардан торып калган печән кибәнен күреп алды. Авыртуын җиңәргә тырышып, печән кибәненең бер читенә үзе кереп ятарлык бер куыш хәстәрләп, шунда сыенды. Никадәр йокларга тырышса да, күзенә йокы кермәде. Сызлануы гына җитмәгән, башына әллә нинди уйлар кереп тинтерәтте. Кеше ышанмаслык тәмугтан исән килеш чыгып та, менә шундый шартларда һәлак булыр микәнни? Беркемнең беркемдә эше юк. Нигә адәм балаларының бәгыре таштай каткан? Теге офицер ярдәм итә ала иде бит. Ул ярдәм итү түгел, сугып очыручы. Егет кабат сибирякны исенә төшерде. Андагы халык кырыс табигать шартларында яшәгәнгәме, миһербанлырак, күрәсең. Биредә хәзер дә хәрәкәт аз түгел, үтенеп сорасаң, берәр рәхимлесе очрап, бәлки, ярдәм дә итәр. Тик егетнең ялынып йөрер чамасы да, теләге дә юк иде.

Уйлары аны авылына алып китте. Кайчан соңгы тапкыр әти-әнисеннән хат алды соң әле ул? Июнь ахырларында бугай. Анда хәлләрнең җиңелдән булмавын, умачлык онга да кытлык икәнлеген язганнар. «Безнең өчен кайгырма, фронт өчен эшлибез. Ачка үлмәбез әле, хәзер җәй көне балтырган, ат кузгалагы үсә инде, аларны ашап торабыз. Сез генә тизрәк Гитлер мәлгуньнең муенын сындырып, җиңү белән әйләнеп кайтыгыз», — дип язганнар. Үзе өйгә шуннан соң: «Воронеж юнәлешенә күчерәләр, мөгаен, шунда дошманны туктатырбыз», — дип кыскача гына җавап хаты юллады (хәлләрнең шундый кискен төс алуын беркем дә күз алдына китермәгәндер). Аннан соң дүрт ай чамасы вакыт узды — бер-берсе турында хәл-әхвәл белешмәүләренә дә шулкадәр. Әллә үкенечле уйларыннан, әллә кулының сулкылдап сызлавыннан егет каты ыңгыраша башлады.

— Кем анда? — дигән аваз аны айнытып җибәрде. Хатын-кыз тавышы. Бу вакытта монда (чагыштырмача аулак урында) кем йөрер? Эндәшүче санитар булып чыкты. — Син нишләп ятасың монда? — Мирзәхмәтнең авыр яралы хәлендә печән кибәнендә ятып калуын белгәч, күрер күзгә 55-56 яшьләрдәге хатын бик аптырады. — Өч сәгатьләр чамасы элек яралылар төялгән машинаны озаттым, урыныннан беркая кузгаласы булма, төн урталарында чираттагы машина китә, — дип кисәтте әнисе яшендәге хатын, яралы егетне башыннан сыйпап. Ул, кызганып, егеткә фләгасыннан су эчерде, азрак ипи белән ысланган казылык тоттырды. Капкалап алгач, Мирзәхмәткә сизелерлек хәл керде.

Санитарка сүзендә торды, төн урталары булгандырмы, Мирзәхмәт яткан кибән янына полуторка машинасы килеп туктады.

— Сталинград лачыны, син исәнме? — булды санитарка хатынның әле тукталып җитмәгән транспорттан сикереп төшкәч беренче соравы. Изге күңелле кешеләр шулай да дөньяда бетмәгән әле дигән уйдан егетнең эченә җылы йөгерде. — Бар, улым, шофёр янәшәсенә кабинага утыр, — дип апа аңа җайлап урнашырга да булышты.

Кузов яралылар белән тулы. Аларның авырлары бар, уртача авырлыктагы яралылар да күренә. Андыйларны лазаретта азмы-күпме сипләгәннән соң, кабат фронтка озатачаклар. Кемнәрдер яралары әрнүгә тешләрен кысып булса да түзәргә тырыша, кемнәрдер сүгенеп тешләрен шыгырдата. «Ой, маменька, мама», — дип сулкылдаучылар да юк түгел. Андыйларга, кагыйдә буларак, унсигез дә тулмаган. Борын асты да кипмәгән малайлар коточкыч сынауларга ничек түзсен соң? Бигрәк тә кала жирендә күмәч ашап үскәннәрнең буыны сыек. Машина ачык дала юллары буйлап шактый озак барды. Арыганлык үзенекен итте. Мирзәхмәт жылы урында йокыга оеган. Ниндидер станциягә житеп туктауга, ул күзен ачты. Әле яктырмаган. Аягында йөри алганнар (хәер, аягында йөри алмаганнар аз, андыйларның күбесе тегендә үлеп калды) биредәге кыр госпиталенә үзләре керде, керә алмаганнарына булыштылар. Мирзәхмәт тә кеше ярдәменә мохтаж, аны бер шәфкать туташы житәкләде. Егетнең госпитальгә кергәндә инде жеп өзәрлек тә егәре калмаган, аягында чак басып тора иде. Тизрәк урынга яткырдылар. Хәлен аңладылар булса кирәк — ашыгыч рәвештә кан сала башладылар. Табиблар соңыннан ике литрлап кан бирелүен әйтте. Ничек түзгәндер, үзе дә аптырый. Мирзәхмәт аркасындагы авыртуны, андагы ниндидер чекердәвек юешлекне яраланган көненнән бирле тоя иде. Сынган кулының өзлексез әрнүе аңа артык әһәмият итәргә ирек бирмәде. Госпитальдә кан алып, азмы-күпме хәл кергәннән соң, нервысына тигән юешлекне янә ачык тойды. Шулай да, тупас мөгамәләле санитаркаларның һәм шәфкать туташларының ачуын китермәс өчен, бу турыда авыз ачмады. Госпитальгә китерүләренә дүрт көн дигәндә, аркасында гына түгел, инде яткан мендәрендә дә салкын юешлек сизеп, арада мөлаемрак күренгән бер яшь кенә яһүди кызына аркасына күз салуын үтенеп мөрәжәгать итте.

— О-о, егетем, синең калак сөяген астында да ядрә тишеге бар икән, нишләп монысын әйтмәдең? — дип сузды гажәпләнгән кыз. Ничек әйтсен соң, бу яңалыкны ефрейтор үзе дә хәзер генә белде. Мирзәхмәт берәр чарасын күрерләр, операция ясамасалар да, андагы ярасын һич югы жентекләп чистартырлар, марля повязкалар белән урап бәйләрләр дип көткән иде. Берсе дә булмады — шәфкать туташы яраны аннан-моннан эшкәртеп, лейкопластырь ябыштырды да вәссәлам. Мирзәхмәтнең сораулы карашын тотып:

— Өч-дүрт көннән сезне барыбер фронтовой эвакогоспитальгә күчерәләр, шунда карарлар, — дип кырт кисте.

Чыннан да бер атнадан аларны икенче госпитальгә күчерделәр. Тик монда да озак тоткарламадылар — распределительный пункт кебегрәк урын икән, яралыларның чуты юк, һәркайсы табиблар үзенең киләчәк язмышын хәл иткәнен көтеп ята. Мирзәхмәт төшеп калганнардан түгел, туган авылында сугышка кадәр үк башта конторда хисап бүлегендә, берникадәр авыл советында сәркатиплектә һәм «совет төзелеше» курсларында дүрт ай махсус укулар үткәннән соң, «читальная изба»да халык янында йөреп, шактый шомарды. Монда адәм рәтле медицина ярдәме күрсәтелмәячәген белгәннән соң, ул баш табибка сорау белән мөрәжәгать итте. Арыган чырайлы өлкән яшьтәге ир заты күзлеген маңгаена куеп, аңа шактый озак сынаулы карашын төбәп торганнан соң:

— Егетем, син чарланган күренәсең. Яшь булсаң да, Сталинград жәһәннәмендә байтак тапалангансың. Алай күп белгәч, әйдәле, мин сине яралыларга куратор итеп, алар белән Эльтон бистәсенә юллыйм. Хезмәт күрсәтүче персоналыбыз болай да житми. Ризамы шуңа? — дигән тәкъдимен ирештерде. Баш табибның шаяртып сөйләшмәве күренеп тора, әнә ич ничек житди карый. Минут эчендә Мирзәхмәтнең башыннан әллә ничә сорау йөгереп узды. Булдыра алырмы?

Егерме ике кешенең гомере өчен җавап бирәсе бит. Эчкәре тыл саналса да, юк-юк та бу тирәләрдә дошман кечерәк диверсия төркемнәрен төшергәли, дигән хәбәрләр йөри. Әгәр шундый төркемгә очрасалар?

Баш тартуы да унайсыз, куркак, бушбугаз икән дип уйлавы бар. Мирзәхмәтнең «ярар» дип ризалык бирүдән башка чарасы калмады.

— Молодец, бәркет! Мин синнән башка җавап көтмәгән дә идем. — Баш табиб зур канәгатьлек белән егетнең кулына 23 кешенең медицина картасын тоттырды. Артык сүз озайтып торуның кирәге юк иде.

Бу юлы да — инде төркем җитәкчесе сыйфатында — урыны кабинага туры килде. Җитмеш чакрым араны бернинди маҗараларсыз уздылар. Октябрь салкыннары якынлашса да, көньяк табигате кояш җылысыннан рәхәт иркәләнә. Бистә артык зур түгел, янәшәсендә боз күле җәйрәп ята. Шунда ук ап-ак тоз таулар тезелеп киткән. Болары сугыш башланганчы чыгарылгандыр инде. Хәзер чабалардырмы, әйтүе кыен. Хәер, җитештерүне туктатмаслар, тозга көндәлек ихтыяҗ беркайчан бетми.

## Чиләнүләр дәвам итә

Нинди хәлдер, Эльтон бистәсендә дә төпле стационар дәвалау курсы уздыру турында уйлап караучы да юк. Моның шулай икәнлеген Мирзәхмәт үз тиресендә белеп өлгерде. Оныткандa бер кулына уралган бинтын сүтеп, чәрдәкләнгән урынны аннан-моннан чистарткандай итәләр дә, кабат бәйләп куялар. Шуңа да яра һаман төзәлмичә, кызгылт шәмәхәләнеп тора, егет гангрена китмәгәе дип шөбһәләнә. Анысы да ерак йөрмәс. Өстәвенә, ядрә тишеп чыккан җәрәхәте генә түгел, беләк сөягенең җелегенә кадәр сызлый кебек (соңыннан, вакытында тиешле операция ясап, сөякне урынына утыртмаганлыктан, анын ялгыш ялгануы ачыклана). Аркадагы җөйне дә кайгыртучы юк. Ул да әледән-әле сулкылдап үзен сиздереп тора. Шулай да, тавыш куптаргач, шәфкать туташларыннан берәрсенә карарга кушып күрсәтмә бирәләр. Игътибар даулаучыга ризасызлык белдергән кыяфәттә, шактый тупас кыланып, элекке пластырьны куптаралар һәм, үлекләгән урынны ярып чистартканнан соң, кабат янасын ябыштыралар. Бөтен күрсәтелгән ярдәм шул. Монда дәвалануны дәвам итсә, тыныч шартларда булып та теге дөньяга олагу ихтималын чамалап (госпитальдә кеше үлмәгән көн сирәк, сугыш чорына сылтап, үлем сәбәбен тикшерүче дә юк), тынгысыз татар егете госпиталь начальнигын үзен башка урынга күчерүләрен сорап кабат тинтерәтә башлый. Аның кебек дәвалау сыйфатыннан канәгатьсезлек белдерүчеләр унга җыела икән. Андыйларны туплап Эльтоннан нибары 30 чакрымдагы калага (фронтовик аның исемен хәтерләми) барырга тәкъдим итәләр, тимер юл белән. Ризалашалар инде. Күченергә теләүчеләр төркемне җитәкләүне Мирзәхмәт Муллахмәтовтан үтенәләр. Ярар, әйдә, ялгызың баруга караганда бергәләп сәфәр чыгуың күңеллерәк булыр. Тик монда да аларны беркем көтеп тормый. Госпиталь буйлап көнозын бер бүлмәдән бер бүлмәгә йөрүләр бернинди нәтиҗә бирми. Мирзәхмәт арып-талып, тәмам хәлсезләнеп аны тышкы якта көтеп утырган иптәшләре янына чыга. Бернишләр хәл юк, хәлне унай якка үзгәртер чама күренми.

— Егетләр, гаептән булмасын, — дип һәр яралының карточкасын үзенә тоттыра. — Калган юлны аерым-аерым дәвам итәрбез, икешәрләп-өчәрләпме, анысын мин хәл итмим. Кабат Эльтонга кайту мөмкин түгел, анда юл ябык, ә биредә алмыйлар.

Кәефләре нык кырылган яралылар кайсы-кая таралыша. Араларында бер Түбән Нижгар мишәре дә булган икән. Мирзәхмәт аның белән киңәшләшеп,

иң әүвәл Каспий диңгезе ягына баручы поездларга утырырга ниятли. Тик кая ди инде ул вагон эченә әләгүләр. Аларның командировочныйларында дәвалану урыны Эльтон дип күрсәтелгән бит. Димәк, алар — качып йөрүчеләр. Вокзалларда кайнап торган хәрби патрульгә эләксәң, ике дә сөйләшмиләр, кулларына богау салып, тикшерү изоляторына озаталар. Ничек тә патруль күзенә чалынмаска тырышып, кузгалып киткән тимер юл составына үрмәли. «Товарняк» икән. Карыннары ачыгуны вагон өстенә менеп кунаклагач кына сизәләр. Баштарак бу турыда уйларга вакытлары булмый. Менә хәзер үтереп ашыйсылары килә. Капчыкларында сохари кисәге дә юк ичмасам. Мирзәхмәт каядыр балык исе килүен абайлап ала. Иелеп, астан килгән иснең чыннан да балыкныкы икәнен белә.

— Берәр ничек эчкә үтә алабызмы? — дип сорады юлдашыннан. Көрәктәй зур куллы, таза гәүдәле мишәр малаеның гына вагон төбәсен куптара алуын ул белә (теләсә дә, сыңар кул белән күп көч сорый торган андый мәрәкәне үзе башкарып чыга алмый), чөнки әмер итеп түгел, кинәшләшкән атлы кыланып, аны корып өлгергән планын чынга ашыруда үзенә компаньон итәргә уйлады. Тегесе шул сүзне генә көткән диярсең, Мирзәхмәт тагын ни дә булса әйтеп өлгергәнче, бик үк яна булмаган төбә тактасын инде куптара да башлады.

— Эшлибез аны, нишләп эшләмәскә, — дип сөйләнеп, хасил булган тишектән аска ук төшеп бара. Бәхеткә каршы, вагон эченә шыплап селёдка балыгы тутырылган кисмәкләр төялгән икән, һәм алар, шөкер, артык түбәндә дә түгел. Бер мичкәне ачып, капчыкларын балык белән тутырдылар, шунда ук тамак ялгап алдылар. Тозлы балык соңыннан эчәсене китерде, әлбәттә. Ничава, монысына гына түзәргә була, берәр вокзалда төшеп калганнан соң сусауларын басарлар әле. Вагон өстендә озак качып барып булмый, теләсә кайсы вакытта күреп алулары бар. Шуны уйлап, чираттагы вокзалларның берсендә җайлашкан «оя»ларын ташлап калдырдылар. Аңа кадәр куптарган такталарны каплаган рәвешкә китерделәр. Аннары балык чәлдерүләре дә күрә торып ачка түләселәре килмәгәннән бит инде.

## Туган якка!

Мишәр егете белән юллары Рузавка чатында аерылды. Ул — мишәрстан тарафларына, язма героебыз, барып чыкса, Татарстан башкаласына кадәр кайтырга ният кылды. Яралы ефрейторның юлы уңды: Сарытауга кайтучы бер төркем офицерлар белән бер вагонга туры килде. Күпне күргән фронтовик-офицерлар иркен кыланалар, юл дәвамында ашап-эчеп, кәеф-сафа корып күңел ачалар. Алларында ризыкланырга тушёнка, ысланган колбаса, куертылган сөт, плиткалы шоколадтан алып, эчәр өчен спиртын-аракысын гына түгел, сырасына кадәр чыгарып тезәләр. Шул чагында арадан берәү хыялланып:

— Эх-х, сыра өчен закускага тозлаган балык булса икән ул! — дип куйды. Күптәннән шау-шулы компанияне читтән күзәтеп, төкерекләрен йотып кайткан ефрейторга шул сүз житә калды.

— Андый нәрсә миндә бар ич, — диярге җөрьәт итте. Офицерга шул житә калды:

— Әй, ефрейтор, син нишләп почмакта гына утырасың, ну-ка, бире кил, дигән әмерен очырды. Боерык әйтүче капитан гына түгел, майор, подполковниклар да ана инде кызыксынып карый. Авызына хуҗа булмагансың икән, хәзер инде чигенергә соң, теләсән-теләмәсән дә буйсынырга туры килә. — Әйдә, энекәш, сугышта болай жебеп басып тормагансыңдыр, җәһәтрәк атла, — капитанның карашында тамчы да ачулану юк, ул дустанә елмаеп, кече составка караган

хәрбине ихластан табынга чакыра. Шаяртмаган булсаң, бер унайдан юл капчыгындагы байлыгыңны безнең белән дә уртаклаш, дию инде. Кыюлыгы, кирәк чагында тиешле чикләрдә әрсезләнә белүе Мирзәхмәткә бу юлы да ярдәм итте. Аның бар булган мөлкәтен (тозлы балык кына инде, әлбәттә) уртак табынга чыгарып салуы үзенә өлкән офицерлар хәзинәсеннән сыйланырга җай ачты. Билет тикшерүчеләр генә түгел, поезд вагоннары буйлап та пассажирларны энә күзеннән үткәрүче хәрби патруль шау-шулы компаниягә якын килмәде. Монысы аның бигрәк зур бәхет иде. Офицерлар табында калган ашамлыкларны җыештырып тормадылар, вагоннан төштеләр. Балыкка мөкиббән капитан саубуллашканда, Мирзәхмәтнең кулын кысып:

— Яшь кенә булсаң да, сугышта бездән дә күбрәк кыенлык күрергә өлгергәнсең (егет аңа, кызыксынгач, Сталинградта яралануы һәм аннан соңгы тормышын кыскача сөйләп биргән иде). Кыяфәтеңнән күренеп тора, күңелең яхшы синең, Ходай ярдәменнән ташламасын үзеңне, исән-сау терелеп аякка басарга һәм дошманны җиңгәч, туган ягыңа әйләнеп кайтырга язсын, — дип теләкләр теләде. «Сугыш озакка сузылыр», — дигән фаразны да беренче тапкыр аннан ишетте Мирзәхмәт.

Сарытауның тимер юл вокзалындагы госпитальдә булса да иске повязкаларын сүттереп, янадан бәйләтмәсә, юлын дәвам итәр чамасы калмаганын егет ачык сизде. Яраларының сулкылдап сызлавы яхшы фал түгел, алар үлекләгән, күрәсең. Тик анда керсәң, патрульгә эләгәсеңне көт тә тор. Кермәсәң һәм беренче ярдәмне алмасаң, гангрена башлану ихтималы гаять зур. Күрә торып үлемгә барып булмас, дип уйлап, Мирзәхмәт госпиталь ишеген ачты. Күпме көннәрдән соң аңа монда беренче тапкыр югары профессиональ дәрәҗәдәге медицина ярдәме күрсәттеләр. Җәрәхәтләрен яхшылап караганнан соң, аларны чистартып бәйләгәч, доктор яшереп тормады:

— Күгәрченем, әгәр тиз арада стационарга ятып, җитди дәвалануга керешмәсәгез, финалның аянычлы тәмамлануы бар, — дип кисәтте.

— Мин Казанга кайтыр идем, — диде егет, өмет белән табибның күзенә текәлеп. «Анысын үзең хәл итәсең инде» дигән мәгънәдә тегесе җилкәсен генә җыерды. Дөресе шул: киләчәгенең иминлеген тәэмин итүне беркемнән таләп итеп булмый, барысы да фәкать үзеннән тора. Кәефе кырылган хәлдә госпиталь баскычыннан төшеп килгән чакта эләктереп алды аны патруль. Документларны кат-кат әйләндереп тикшерделәр.

— Монда соңгы пункт итеп Эльтон бистәсендәге госпиталь күрсәтелгән бит, — диде хәрби патруль башлыгы, яшь йөзенә канәгатьсезләнү чыгарып. Бәлки, яшьләре буенча бер тирә булгангадыр, ул алар кулына эләккән яралы белән хәленә кереп сөйләшергә тырыша кебек. Мирзәхмәт бөтен осталыгын җигеп нинди катлаулыкларга юлыгуын шәрехләргә тырышты. Лейтенант ефрейторның ялган сөйләмәвен күреп тора, Сталинград иттарткычыннан исән чыгуның да сирәкләргә генә тәтүен шунда булганнардан ишеткәне бар. Аңа хәтта «корыч» каланы гына түгел, аларның да иминлеген саклап калган батыр сугышчы алдында беркадәр оят та (тылдагы махсус патруль хезмәте нинди шартларда үтә дә, һәр адымын үлем сагалаган алгы сызыктагы фронтовик ниләр кичерә). «Нишләргә соң моның белән?» — дип уйлады ул, газаплы икеләнү кичереп. Әгәр хәзер алып китеп изоляторга япса, «особыйлар» ерткычланып имгәтеп ташлаячак, дезертирлыкта гаепләп, «өчлек» карары белән атып үтерүләре дә ерак йөрми. Лейтенант аны кулга алмаска булды. Шулай да катгый әмерен җиткерде: — Менә нәрсә, ефрейтор, — диде ул аңа. — Хәзер мин сине шәхсән үзем Казан ягына кайтучы поездга утыртып җибәрәм. Тик ишетсен колагың — Саранскига кадәр генә. Аңладыңмы — Са-ран-скига! — дип иҗекләп сузды

рәхимле бәндә. Мирзәхмәт хәлнең мондый борылыш алуын көтмәгән иде, күзенә яшь килде хәтта. Елдан артык сугышта йөреп, бу кадәр йомшарганы булмады, ә монда хисләрен йөгәнләп тора алмады.

— Рәхмәт, иптәш лейтенант, рәхмәт, — дип сөйләнде ул, яшьтиенең вокзал кассасыннан үзенә түләүсез билет алып бирүенә тәмам күнеле булып. «Ярар, әйдә, шуның белән бетерик», дигән мәгънәдә патруль хезмәте лейтенанты кул гына селтәде.

## Казан госпиталендә

Шулай да, поезд тәгәрмәчләренең «тук-тук, тук-тук» иткән тавышларын тыңлап кайта торгач, беренче мәлдә лейтенантның катгый тәкъдименә ризалашкан ефрейторның фикере үзгәрде — ничек тә өйгә якын булырга кирәк, дип уйлады ул. Лейтенантның кондукторга: «Саранскида төшәргә тиешлеген ефрейторның исенә төшерсәгез икән», — дигән гозерен ишеткән иде, шунлыктан Мордовия башкаласына якынлашканда, плацкарт вагонының иң өстәге шүрлегенә менеп ятты. Кондукторның, фамилиясе белән эндәшеп, вагон буенча әрле-бирле өтәләнеп йөрүен ишетеп торса да, эндәшмәүне артык күрде. Кондуктор аны алдарак төшкән дип уйлады бугай — эзләүдән туктады.

Ниһаять, Казан. Кырык беренче елның сентябреннән соң (фронтка бирелдән китте) үзгәргән дә кебек, үзгәрмәгән дә кебек ул. Кешеләр ничектер йомыла төшкәннәр һәм ашыгыбрак атлыйлар. Сугыш авырлыгы, «Барсы да — фронт өчен, барсы да — Җиңү өчен!» дип көнне төнгә ялгап эшләүләр, кибетләрдән аз күләмдә, ярлы ассортиментлы азык-төлекне дә бары тик карточкага гына бирүләре халыкны чарасыз иткән, күрәсең. Урамда очрап, Казан госпиталенең кайдалыгын сораган беренче кешесе — санитарка — шунда эшли икән, үзенә ияртеп, кирәкле корпуска кадәр алып барды. Солдат һәм санитарка — сугыш вакыты өчен гадәти күренеш. Һәм нәкъ менә урта яшьләрдәге ярымхәрби хатын-кыз белән кулы бинтланган рядовойның янәшә атлавы юлда очраган хәрби патрульләрдә шик тудырмады. «Яралыны санитарка озата бара: шуннан ни? Болай булса, унышлы килә бит әле», — дип уйлады Мирзәхмәт. Госпитальнең төп корпусына кергәч тә бәхет елмайды аңа. Бүлек мөдиренә документларны һәм медицина картасын куркып кына сузган иде, табибның алдындагы кәгазьләргә игътибар итмичә, аңа ничектер сәер генә карап торуын абайлап, «хәзер башлана инде, монда Эльтон түгел — Казан, — дип кычкырына башлар», дигән уйдан тирләп чыкты. Ишеткән соравы аны бөтенләй аптыраашта калдырды:

— Яраң бик сызлыймы, улым? — дип сорый икән бүлек мөдире.

— Ә, нәрсә дисез? — Мирзәхмәт сорауны ишетсә дә, көтелмәгәндә булгач, мәгънәсе аңына тиз генә барып житмәде. Инде аңлагач та, әле беләгенә, әле табибка карап, ни юрарга белмәде.

— Жәрәхәтеңне әйтәм, кайда яраландың соң? — дип сорады өлкән яштәге хатын, акрын тавыш белән. «Әгәр медицина картасына күз салса, минем кайда сугышканны, ничек яраланганымны шундук белә югыйсә, нигә үземнән сораша икән», дип баш ватты егет.

— Сталинградта, снайпер ядрәсеннән, — җавабын ишеткәч, табибәнең утырган урынында «дерт» итеп сискәнеп куюын күрде. Ул беравык уң кулы белән күзен каплап торды. Мирзәхмәт, гаҗәпсенеп, аның бармакларының җиңелчә калтыравын күзәтте. Бармакларының калтырануы гына бер хәл, урыс апасының инде тавышы да калтыранып чыкты.

— Кайсы дивизиядә сугыштың, балакай? — егетнең үз гомерендә мондый хәлне беренче күрүе. Моңа кадәр әле беркемнән дә шулай үз итеп эндәшкәне

юк иде, хәтта газиз әнкәсенен дә. Тегендә — фронтта һәм фронтка якын тылда күпчелек табиблар яралыларның гомерен чүпкә дә санамыйлар, мөгамәләләре тупас, кайчагында хәтта рәхимсез. Күрәсен, сәгать саен дистәләгән адәм балаларынын күз алларында, еш кына операция өстәлендә җан бирүләре аларнын бәгырьләрен катыра, ярдәмгә мохтажларга ярдәм итә алмау, үзләренең көчсезлекләрен тану җан авазы булып тышка бәреп чыга торгандыр. Тирән тылда хәл бүтәнчәрәк, күрәсен.

— Утыз жиденче номерлы гвардия дивизиясенең 69нчы полкындагы аерым автоматчылар ротасы сугышчысы идем мин. — Үзе белән таныштырганнан сон, «кем дип эндәшергә микән?» дигән шикелле егет төртелеп калды. «Исемем — Анна Ивановна, икәү генә булганда «тётя Аня», дип дәшсән дә ярый», — дип, бүлек мөдире ярдәмгә килгәч, Анна Ивановна, 17 октябрь көнне Мамай курганында яраландым, — диде ул». — Мен бәләләр белән монда кадәр кайттым. — Анна Ивановна ефрейторнын медицина белешмәсен кулына алып игътибар белән укый башлаган, шулай да ара-тирә бүленеп, аңа жылы күз карашы ташлап алгалый.

— Без анламый торган ниндидер бөек көчнен, адәм балалары телендә язмыш дип аталучы нәрсәнен кушуы буенча монда килеп чыккансыңдыр инде син, балакай. Һәм нәкъ мина туры килгәнсендер. Югыйсә, башка кешегә эләксән, алдагы вакыйгаларнын ничек куерачагы турында сүз алып барырга алынмыйм. Һәрхәлдә, жинелләрдән булмас иде киләчәген. Минем ни әйтергә теләгәнемне анлагансыңдыр: Эльтон белән Казан арасы якын түгел, берничек тә юлларны бутаганмын дип котыла алмыйсын. Улым Алексейга ике тамчы су кебек охшагансың син. Ул да Мамай курганында сугышкан иде, тик анын дивизия номеры башка. Моннан бер ай элек «похоронка»сы килде. Син кереп каршыма баскач та «ул» дип уйлап шатлыктан чүт йөрәгем ярылмады, сугышта нинди хәлләр булмас. «Кара» кәгазен алып та исән калучылар бар бит. Аннары гына аңыштым: минем улым синнән яше буенча бераз өлкәнрәк иде, чины — өлкән лейтенант, соңгы хатында: «Мин хәзер рота командиры, аяусыз сугышлар бара, озак язмый торсам, аптырамагыз. Дошманны Сталинградтан кугач иркенләп һәм озын итеп язармын. Бәлки әле 4-5 көнлек отпускка да жибәрерләр, полк командиры шуның өчен тырышачакмын, диде. Очрашканга кадәр хушыгыз, кысып кочаклап үбәм әти белән әнине», — дип язган. — Анна Ивановна өстәл тартмасыннан сүзләрен ятлап бетергән өчпочмаклы хатны чыгарып Мирзәхмәткә сузды.

Нәрсә дип юатсын соң житмеш йортлы татар авылыннан чыккан гади татар егете әнисеннән дә өлкәнрәк яшьтәге урыс хатынын. Мәкерле дошман аркасында бердәнбер улыннан мәхрүм калган Аннага нинди генә юату сүзләре әйтсә дә, алар барыбер гади сүз генә булып калачак. Анын кебек балаларын, ирләрен яисә абый-энеләрен югалткан хатын-кызлар миллионнарча алар. Кырылыш давылы тынганчы аларнын саны тагын да артачак. Сугыш корбаннарынын һәркайсы газизләре, якыннарынын йөрәгендә мәнге төзәлмәс жәрәхәт булып, алар якты дөньяда сонгы сулышларын алганчы утлы хатирә булып яшәячәк. Ватан өчен башларын салганнар турындагы хатирә монын белән генә бетмәячәк, ул буыннан-буынга тапшырылып, дистәләрчә еллар, гасыр буе һәм аннан сон да дәвам итәр, мөгаен. Тик инде ул, чорлар үткән саен, ерак буыннар хәтерендә хәтер-хатирә булып кына сакланыр. Ә бүгенгесе? Бүгенгесе искиткеч авыр! Чыдасан — чыда, чыдамасаң — хет егылып үл! Шуларны уйлап, Мирзәхмәт Анна Ивановнанын (коткаручысынын!) хәлен чак кына жиңеләйтергә теләп:

— Тётя Аня, Сез алай бик бетеренмәгез инде, үлгән артыннан үлеп булмый бит, диләр мондый чакта безнең халыкта, — дип куйды.

— Ничек дисең, ничек, бөркетем? Үлгән артыннан үлеп булмый, диләрме? Кара син аны, искитмәле: дүрт сүздән торган гыйбарәгә нинди зур мәгънә сыйдырган татар халкы! — Анна Ивановна Мирзәхмәтнең шул сүзләреннән чак кына җанланып, керфек очларына кунган яшь бөртекләрен бармак очы белән җилпеп төшерде. Аннары: — И, кара инде син мине, ә. Үземнең проблемаларым белән сине тәмам интектердем бит. Ерак юлдан шундый житди җәрәхәтләр белән монда кадәр кайту болай да мең газап булгандыр, — диде ул. — Әйдәле, күгәрченем, бинтларыңны чишик әле. Тикшерүләрдән чыгып интенсив дәвалау курсы билгеләрбез. Мин үзем сине турыдан-туры дәвалауга алынам һәм исемем Анна Ивановна булмасын — бөтен көчемне сине, комиссовать иттереп, туган авылыңа кайтарып җибәрергә тырышачакмын. Сугыш газиз улкаемны йоткканы да житкән, хет аңа охшаган туганы булмаган игезәге исән калсын. Шул да миңа алдагы көндә эшләргә көч, яшәргә дәрман бирер, — дип сөйләнде. Ул егетнең яраларын җентекләп карагач «ах» итте.

— Монда болай да комиссия үзеңне бракка чыгармагае. — Беләк сөягенең чалыш торуын күреп, фронтка якынрак госпитальләрдә хезмәт итүче коллегалары адресына илтифатсызлыклары өчен катырак сүзләр әйтеп сукранды. — Ярый әле вакытында кайтып житкәнсең, тагын 2-3 көнгә сонарсаң, нинди дә булса ярдәм күрсәтергә безнең дә көчтән килмәс иде...

Кырык икенче елның җәе гаять корылыклы килгән иде. Елгаларда су саекты. Госпиталь янәшәсеннән агучы Казансуның урыны белән аркылы ерып чыгарлык җирләре булган, диләр. Хәзер инде ул боз катламы астында күренми. Мирзәхмәт Идел елгасын исенә төшерде. Ул да бит Казанның бер кырыен каймалап, дулкыннары белән ярны сыйпап, йөзләрчә чакрым ара үткәннән соң, инде нык киңәеп, үзенең түбән агымында «корыч» кала ярларын үтә. Хәер, егет аны беренче тапкыр күргән җәйдә ул инде тыныч түгел, өстендә бомба һәм снарядлар ярылудан шаулый-үкерә иде. «Заячий» утравы тирәсендә икегә бүленгән елга аңа гаять киң күренде. «Әле син аның янгырлы җәйләрдә ярларына сыеша алмавын күрсәң», — диделәр чыгышлары белән бу тирәдән булган полкташлары. «Хәзер ил буенча Бөек Октябрь революциясенең 25 еллыгын билгеләп үтәләр. Сталинградта бәйрәм кайгысы түгелдер, көне-төне кан коюлар һаман дәвам итә булыр. Безнең автоматчылар ротасыннан берәрсе исән калдымы икән?» — дип уйлады Казан госпиталендә ятканда Мирзәхмәт. Аның мондагы хәле белән андагыларның хәле — җир белән күк арасы бит. Яралануы үзенә башта чын трагедия булып тоелса, хәзер язмышның аны зур бәладән — үлемнән алып калуы икәненә төшенде. Бәлки, барып чыкса, Анна Ивановна биргән вәгъдәсен үтәп, өенә дә кайтарып җибәрә алыр. Ватанының патриоты булса да, еш кына мәгънәсез иттарткычны хәтерләткән сугыш кырында газиз башкайларны саласы килми бер дә. Бәләкәйдән карап үскән һәм һәрвакыт дошманны аяусыз кырырга рухландырган әкияти «Чапай» киносы чынлыкта дөреслектән бик ерак тора. Үзе елдан артык окоплар казып һәм шуларның салкын төбендә ятып, исәпсез мәртәбәләр атакаларга күтәрелеп һәм каршы як атакаларын кире кайтарып, парашютлардан сикереп, урманнарда ачка кангырап йөреп тә рәсми пропаганда белән чынбарлык арасында бернинди дә охшашлык юклыгына тәмам инанды ул.

Инде җир өстенә кар ятты. Анна Ивановнаның турыдан-туры вазифасы булмаса да, палатасына кереп аның хәлен белешмәгән көне юк. Иң яхшы даруларны яза ул аңа, кабат сындырып ялгаган кулына гангрена янамавына тулысынча ышанганнан соң, лангетны да үзе күзәтеп салдыра. Аның татар егетенә карата аналарча мөнәсәбәтен күреп, савыктыру бүлегенең башка хезмәткәрләре дә унай карыйлар. Яшь организм тиз тазара, хәтта кирәгеннән артык тиз бугай.

Шулай да Анна Ивановна Мирзәхмәтне «выздоравливающийся батальон» дип аталучылар янына күчерергә ашыкмый. Эшнең нәрсәдә икәнен сизсәләр, хәрби чор кануннары буенча үзен дә хөкем көтә югыйсә. Совинформбюро күптән инде радио буенча Кызыл Армия дивизияләренен Сталинград астында һөҗүмгә күчүен белдергән иде, ниһаять, 1943 елның 2 февралендә фельдмаршал Паулюс группировкасына кергән өч йөз мең солдат һәм офицерның (шуларның егермедән артыгы генерал) әсир ителүен әйттеләр. Бу — зур җиңү иде, Ватан сугышын совет гаскәрләре файдасына тамырдан үзгәрткән җиңү. Монда кечтеки генә булса да ефрейтор Мирзәхмәтнең өлеше дә бар, аның кебек дистәләрчә мең яраланып, хәзерге вакытта госпитальдә тазалыкларын ныгытучы (алар әле бәхетлерәк) һәм инде төгәл саны да булмаган, Идел ярларында мәңгелеккә башын салган исәпсез күп корбаннарның уртак өлеше бу.

## Кабат фронтка

Анна Ивановна Мирзәхмәт Муллахмәтовның барлык медицина белешмәләрен хәрби хезмәткә яраксыз табарлык итеп җайларга тырышса да, гарнизон медицина комиссиясе егетне сафка яраклы дип тапты. Бүлек мөдире йөз төрле хәйлә табып аны янә ике ай үзләренең госпиталендә тотты. Бу чагында «Казан» госпиталең югары чиндагы офицерларны дәвалау үзәгенә үзгәртү буенча эшләр бара иде, һәм инде Мирзәхмәтне һаман биредә калдыру куркынычка әйләнде. Анна Ивановна аны кабат гарнизон комиссиясе хозурына бастырды. Олы җанлы хатынның комиссия хөкеменә тәэсир итәрлек вәкаләте юк, ул тәкъдим итә генә ала. Ә Кызыл Армиягә сугышчылар кирәк, бик күп сугышчылар. Комиссия рәисе күзлек өстеннән Мирзәхмәткә сөзеп карый.

— Сез нәрсә, ефрейтор, бер дигән сәламәтлек белән һаман тылда җилләнәсез, күпкә кайтыш күрсәткечкә ия булганнарны да без алгы сызыкка озатабыз. Симуляцияме бу? — Зур властька ия табибның тавышында тимер чыңы. Шулчак кабинетның бер читендә утырган Анна Ивановна ярдәмгә килмәсә, ни әйтергә белмичә аптырап торган Мирзәхмәткә нинди вердикт чыгарылыр иде — әйтүе кыен.

— Коллегалар, аның сәламәтлеге миндә һаман борчу тудыра. Муллахмәтовны тагын ике айга «выздоравливающий батальонга» җибәрүегезне сорыйм. — Рәис кенә түгел, комиссиянең барлык әгъзалары «Казан» госпиталенең иң тәҗрибәле һәм иң абруйлы бүлек мөдиренә гаҗәпләнеп текәлгән.

— Анна Ивановна, сезне хөрмәт иткәнгә күрә генә барам бу адымга, дип баш чайкап, комиссия башлыгы сөйләшүгә нокта куйды.

Савыгу-адаптация үтүнең соңгы фазасы саналган үзәктәге дәвалану вакыты да үтеп китте. Хәзер инде Анна Ивановна гына түгел, сәламәтлек саклау министры үзе дә алып кала алмас ефрейторны фронтка җибәрүдән. Сугышта бердәнбер улын югалткан игелекле урыс хатыны татар егетен озатырга килгән әнә.

— Вәгъдәмне үти алмадым, кичер мине, улым, — дип күз яшьләре белән елый ул. Бер кулы белән Мирзәхмәтне муеныннан, икенчесе белән иңбашыннан кочаклаган. — Ничек тә исән калырга тырыш, яме, күрә торып үлемнең авызына ашкынма! — ди ул. Нәрсә әйтсен соң Салавыч егете, икенче әнисе кебек күрә башлаган бу апа аның өчен болай да булмастайны эшләде инде. Язмышны без, ничек теләсәк тә, үзгәртә алмыйбыздыр шул, бары төзәтмәләр генә кертәбез.

«Выздоравливающий батальон»нан тупланган ротаны Белгород өлкәсенә җибәрделәр. Җыелу пунктына «покупательләр» (частьларына солдатлар алырга килүчеләрне шулай атыйлар) килгән. Өстәл артына утырып, үз хозурына берәм-берәм кичәге яралыларны эндәшеп, аларга сорау бирүче артиллерист-

майорга туры килде ефрейтор Муллахмәтов. Чиратка алданрак басканнарның берничәсен ошатмыйча кире боруын (андыйлар, кагыйдә буларак, пехотага эләгә) да күреп-ишетеп торды. Майорның сораулары мондыйрак:

— Моңа кадәр артиллериядә хезмәт иткәнең булдымы? — Күбесе алдаша, чөнки иң зур күпчелек, исән калу ихтималы зуррак булганлыктан, «әйе», ди (пехотага һәрвакыт дошманның төп удары төшә). Майорның алдында һәркемнең «личное дело»сы булыр. «Әйе» диючеләргә «покупатель» туп установкасына кагылышлы сораулар бирә һәм хәйләкәрләрне тиз фаш итә. Чират элекке пехотачы ефрейтор Муллахмәтовка житте. Егет әйтәсе сүзен инде чамалап куйган — алдашмаска исәбе. Файдасы юк чөнки.

— Артиллеристмы? — дигән сорауга: — Юк! — дип җавап бирде. Берничә сугышчының күзгә төтен җибәрүеннән кәефе шактый кырылган майор бу юлы да «әйе» дигәнне көткән иде булса кирәк, кызыксынып, көтелмәгән җавап бирүчене баштанаяк күздән кичерде. — Пехотамыни?

— Башта — десантчы, аннары — автоматчы, — дигән җавабын ишеткәч, майорның кызыксынуы тагын да артты.

— Сугышка кадәр кем булып эшләден? — Агитпропаганда-культработник булуын, аңа кадәр берникадәр канторда исәп-хисап эшләре белән шөгыльләнүен белгәч, — Во, менә миңа шундый егетләр кирәк тә инде, значит чут эшләрен беләсең: нинди почмак белән, нинди ераклыкка атарга кирәклеген тиз генә исәпләп чыгара аласың, — дип, ефрейтордан төпченүен шул урында туктатты.

Мирзәхмәтләрнең җыелма ротасыннан аннан башка тагын 5-6 сугышчыны гына сайлап алды артиллерист-майор. Калганнарның кайсы — автобатка (шофёр булганнары), кайсы — штаб тирәсенә (бу төп категориягә эләгүчеләр гомумән бәхетле), кайберәүләр — сак хезмәтенә, күпчелек, әлбәттә, пехотага эләкте.

Аның яна хезмәт урыны 176нчы мотоукчы дивизиягә караган 171нче артиллерия полкында. Артполк — өч дивизионнан, һәр дивизион өчәр батареядан тора. Батареяларда 76 миллиметрлы орудиеләр. Мирзәхмәтне төзәүче итеп билгеләделәр. Батареяларда немецларның зур җәйге һөҗүмгә әзерләнүләре турында сүзләр йөри. Ул шушы Белгород тирәләрендә булыр, мөгаен, диләр. Гитлерчыларның Харьков янында Сталинград янындагы зур уңышсызлыклары үчен кайтарулары турында сүзләр йөри. Паульюс группировкасы әсир ителгәннән соң, Кызыл Армия дивизияләре фельдмаршал Эрик Манштейнның «Юг» дип аталган армия группаларын әзәрлекләп, Харьков тирәсендә чолгап алалар. Һәм җиңү — менә генә ул! Тиздән берничә йөз меңлек группировка Паульюс армиясе язмышын кабатлаячак. Алай булып чыкмый: әллә совет генералларының уңышлардан башлары әйләнә һәм алар уяулыкларын җуя, әллә Манштейнның стратеглык сәләтен бәяләп бетермиләр (Харьков давы совет-герман гаскәрләре арасында өченче зур бәрелеш буларак тарихка кереп калган — 1941 һәм 1942 елларда булып узган алдагы икесе шулай ук дошман файдасына тәмамлана — кырык өченче елның 19 февралендә башланып, 14 мартта тәгәлләнгән бу зур сугышны хәзер Русиянең хәрби уку йортларында хәрби осталык эталоны сыйфатында өйрәнәләр, имеш), камалыштагы дошман кинәт һөҗүм итеп бөҗраны өзә, һәм инде совет гаскәрләренең зур группировкасын үзе камап ала һәм чагыштырмача кыска вакыт эчендә 200 меңнән артык солдат һәм офицерны юк итә (шунын дистәдән артыгы — генерал). Менә сиңа Сталинградта биле сынган дошман. Иртәрәк шатланганбыз икән ич. Хәзер әнә Орёл — Белгород арасында кабаттан һөҗүмгә күчеп реванш алмакчы һәм янабаштан Мәскәүгә омтылмакчы. Булмый гына торсын, анысы барып чыкмас инде.

## Курск дугасы. Белгород–Харьков юнәлешендәге һөҗүм

1943 елның 5 июль таңында гитлерчыларның соңыннан тарихка Курск дугасы дип керәчәк өченче зур җәйге сугыш кампаниясе башлана. Бу вакытка инде Кызыл Армия зур куәткә ия танк һәм һава армияләре белән тулыландырылган, генераллар дошманның һөҗүм тактикасын яхшы ук белеп бетергәннәр һәм фронттагы вазгыять үткәндәге ике ел белән берничек тә чагыштырырлык түгел. Немец житешкәнче совет артиллериясе телгә килеп, каршы як позицияләрен берничә сәгать дәвамында ифрат көчле утка тота һәм аларның билгеле вакытка планлаштырган һөҗүмен кичектерә. Шуның белән үк дошманның мона кадәр уңышка китергән «кинәттәнлеге» барып чыкмый, һәм бу инде уңышсызлыкның башы булып чыга. Фашистлар айга якын һөҗүм итеп тә совет оборонасын өзеп, тылга төшү максатына ирешә алмыйлар. Кызыл Армия дивизияләре тиешенчә җавап биреп, кайбер юнәлешләрдә чигенәләр генә.

Күпсанлы бәрелешләрнең берсендә Мирзәхмәт наводчик итеп беркетелгән орудиенең командиры яралана һәм тупка командалык итүне сержант (хәзер инде сержант) Муллахмәтов үз өстенә ала. Август башларына гитлерчыларның киң фронт белән башланган һөҗүмнәре каршылык стенасын үтә алмыйча хәлсезләнеп туктала. Ә 3 августтан Кызыл Армия частьлары контр һөҗүмгә күчеп, дошманны үкчәсенә басып куа-куа, 23 августка инде аеруча ныгытылган район саналган Харьков тирәләреннән дә артка алып ташлыйлар.

Ике ел кан коюлы сугышларда катнашып, күп мәртәбәләр үлем белән күзгә-күз очрашып һәм очраклы гына исән калып, авыр яраланып та, бер мәртәбә дә хөкүмәт бүләге алмаган (югыйсә ул мона күптән лаек) туп командиры сержант Муллахмәтов, ниһаять, Белгород — Харьков операциясе өчен «За боевые заслуги» медале ала. Ике ай буена сузылган Курск эпопеясында 171нче мотоукчы дивизия һәм аның составындагы 176нчы артиллерия полкы да зур югалтулар кичерә — аларны, яңа көчләр белән тулыландырыр өчен, икенче эшелонга күчерәләр. Бер ай дәвамында ял иттергәннән һәм хәрби өйрәнүләрдә катнаштырганнан соң, дивизияне кабат алгы сызыкка кертәләр. Украинаны дошманнан чистарту җиңел генә бармый. Дошман һаман көчле. Анда инде 1941-1942 еллардагы җинеп килү рухы нык кимегән булса да, каршылык күрсәтү сәләте әле сүнмәгән. Мирзәхмәт икенче тапкыр яралана. Бусында җәрәхәте уртача. Дәваланырга тирән тылга озатуның хаҗәте юк — адаптация чорын кыр госпиталендә үтү дә җитә. Кабат сафка басканда, орудие командирының күкрәген беренче медале янәшәсендә «Батырлык өчен» медале дә бизи.

Тарихтан Украинаны фашистлардан азат итүнең 1943 елның гыйнварында башланып, СССР чикләреннән куып чыгарганчы, 1944 елның октябрь ахырына кадәр дәвам итүе билгеле. Ике елга якын вакыт эчендә 11 стратегик әһәмияткә ия һәм 4 фронт масштабындагы операцияләр үткәрелгән. Шулардан — Донбасс (13.08.43 ел — 22.09.43 ел), Корсунь Шевченко (1943 елның 22 декабреннән 1944 елның 17 февраленә кадәр дәвам иткән операциядә гитлерчыларның 55 мең солдат һәм офицеры юк ителә, 18 меңе әсир итеп алына), Львов — Сандомир (13.07.44 ел — 29.08.44 ел) һәм Көнчыгыш Карпат (8.04.44ел — 28.10.44 ел) дигән исем алганнары иң эреләрдән санала.

## Шулай да була икән

Сугышта кайчагында кеше ышанмаслык хәлләр дә була, Шундыйларның берсен әңгәмәбез барышында Мирзәхмәт ага да бәян итте. 1944 елның җәендә аларның часте Бессарабия белән Румыния чиге буйлап агучы Днестр елгасы

ярында торганда (ә, бәлки, елганың исеме башкадыр — 93 яшьлек фронтовик анысын төгәл хәтерләми), камалышта калган дошман солдат һәм офицерлары, еш кына елга аркылы йөзеп чыгып, әсирлеккә төшә торган булалар. Алар бу адымга чарасызлыктан — ачлыкка чыдар чамалары калмаганлыктан баралар. Берешәр, икешәр-өчәрләп тә, кайчагында — взводлап, ә кайчагында ротасы белән коралларын ташлап бирелә гитлерчылар. Берсендә, Мирзәхмәт Муллахмәтовлар батареясы пешекчесе кыр кухнясында сугышчылар өчен ашын һәм боткасын хәстәрләп мәш килгәндә, елга аша йөзеп чыгып ярга аяк баскан бер төркем кораллы дошман солдатларын күреп ала. Куркуга төшә инде, чөнки янында башка җан иясе юк, винтовкасын да әллә кая бер читкә сөяп куйган. Хәер, утлы корал инендә булса да бер ялгызы утызлап гитлерчыга каршы берни кыра алмас иде. Немец солдатлары якынлашканнан-якынлаша, алар ярымшок хәлендә баскан урында катып калган пешекче янына килеп җиткәннәр һәм үзләренчә нидер әйтәләр. Немецча бер авыз сүз анламаучы атып үтерүләрен көткән совет солдаты, ниһаять, тегеләрнең аш казанына төртеп күрсәтеп һәм куллары белән авызларына ымлап ашарга сорауларын аңлый. «Нишләргә соң әле?» — дип икеләнә пешекче. — Бирсәң, үзебезнекеләргә калмый. Бирмәсән, барыбер тартып алып ашарлар, ачудан үтереп ташлаулары да бар. Ни булса, шул», — дип, дошман солдатларының тамагын туйдырырга ниятли. Тик башта бөтен взводка автоматларны бер өемгә ташлап, икенче читкә барып утырырга кирәклеген ымнар ярдәмендә аңлата. «Тамак тәмугка кертә», — диләр бит. Туену бәрабәренә җинел генә ризалаша солдатлары белән фашист офицеры. Алар инде 1941-1942 еллардагы бөтен Аурупаны инләп атлаучы вермахт сугышчылары түгел шул, 1943 елгы сугышчылар да түгел. Алар — көннән-көн мораль яктан кикрикләре шиңгән, җинүгә өметләре сүнгән, ничарадан-бичара югары чиндагыларнын боерыкларын үтәргә мәҗбүр булган (күбесе, җае чыкса, гомерен саклап калыр өчен әсир төшәргә торучы) тере карачкылар гына. Пешекче кыр кухнясына артиллеристлар өчен ашауның әзерме икәнлеген белергә килгән бер солдатка әсир иткән офицерларны биреп җибәрә.

— Туплау пунктына илтеп тапшыр инде, — дип үтенә ул аннан.

Үзе яңабаштан батареяның личный составы өчен төшке аш әзерләргә керешә. Ач кешенең ачуы яман ди. Карыннары ачкан үзебезнекеләрдән: «Сезгә дигәнне немецларга ашатырга туры килде», — дип ансат кына котыла алмассың. Соныннан дивизия командованиесе күрсәткән батырлыклары өчен батарея пешекчесен һәм конвейер ролен башкарган сугышчыны «Батырлык өчен» медале белән бүләкли. Мирзәхмәт ага бәян иткән икенче очрак менә мондыйрак:

— Ялыктыргыч сугышлардан алҗып, «мин беркадәр черем итеп алам, орудиегә һәм якын-тирәгә күз-колак булыгыз», — дип, туп лафетына сөялеп утырдым һәм күземне йомдым. Йокыга оюымны сизмәдем дә. Күпме йоклаганмындыр, аткан тавышка сискәнеп уянып киттем. Карасам, ерак та түгел бер немец солдаты үлем алды агониясендә аяк-кулларын селтәп тыпырчынып ята. «Нәрсә булды? Каян килгән немец бу, кем атты аңа?» — дип сорыйм. Беркем бернәрсә эндәшми. Шулай да минем расчётка күптән түгел генә беркетелгән, сугышка кадәр җинаяте өчен төрмәдә утырган, соныннан зонадан дисбатка озатылган һәм акланып гадәти частька күчерелгән элекке зэкка күз ташлап алалар. «Синме?»— дип сорадым тегеннән каты итеп. «Әйе, мин», — ди. «Нишләп аттың? Әсир төшүчеләрне атмаска дигән Верховный башкомандующий әмерен беләсең бит?« Мина елга аркылы йөзеп чыгып, безгә бирелгән унтер-офицер бик кызганыч тоелды. Соныннан сөйләүләренчә, бармаклары белән дүрт баласы барлыгын күрсәтеп, исән калдыруларын тәгәри-тәгәри ялварып

сораган немецны теге бәндә, иптәшләре каршы килүенә карамастан, барыбер аткан. Адым саен янәшәдәге иптәшләренең үлемен күреп бәгырь күптән таш булып катарга тиеш кебек, тик барыбер җан кыюга күнегеп бетеп булмый: һәр үлем йөрәкне сызландыра. Мин бу адәм әтрәген устав буенча кулга алып, трибунал хөкеменә озата ала идем, тик янадан, түбән җан булса да, корбаннар саны артуын теләмәдем. Бары тик «мондый күренеш тагын кабатланса, үзенә үпкәлә!» дип кисәттем генә. Елга аша йөзеп чыгып әсирлеккә бирелүчеләр аннан соң да аз булмады.

## Алга — Көнбатышка

Бессарабия белән Румыния чигендәге немецларның зур группировкасын тармар иткәннән соң, Гитлер Германиясенең союзнигы булган Румыниягә юл ачыла. Башка хәрби берләшмәләр белән бергә сугыша-сугыша, 176нчы артиллерия полкы да кырык дүртенче елның көзендә Бухарестка кадәр барып җитә. Берничә ай дәвамында шактый җанлы көчләрен һәм хәрби техникасын югалткан частьларны икенче эшелонга күчергәннән соң, тулыландырып ,Висла елгасының Сандомар плацдармына ташлыйлар. Висланың аргы ягында ныгып урнашкан совет гаскәрләре фашистлар өчен каты чикләвек булып чыга — янадан-яна көчләрен җәлеп итеп, күпме генә плацдармнан бәреп төшерергә тырышмасыннар, ниятләре барып чыкмый. 1944 елның 5 декабрендә Кызыл Армия частьлары көчле һөҗүмгә күчә. Фашист табаны астында интеккән Аурупа илләрен бер-бер артлы азат итеп Германия территориясенә бәреп керәләр һәм кырык бишенче елның апрель башларына Берлиннан 90 чакрым ераклыкка кадәр якынлашалар. Моннан рейх башкаласын саклау ныгытмалары тезелеп киткән...

Бөек Ватан сугышының сонгы аккорды булып янгыраячак, йөз меңнәрчә сугышчыдан торган удар көчләр «көрән чума» оясына юнәлдерелә. (Соныннан союзникларның Америка гаскәре башкомандующие Эйзенхауэр, Советлар Союзы маршалы Жуковтан, гаҗәпләнеп: «Ничек шулай тиз арада катлаулы мина кырларын зарарсызландырып, ике атнада җиңүгә ирешә алдыгыз?» — дип сорагач, тегесе: «Мин мина кырына пехотаны керттем», — дигән җавабы белән шаккатыра). Шулай да 171нче дивизиягә Берлин операциясендә катнашырга туры килми. Чехословакия башкаласы Прага халкының баш күтәрүе һәм аларга оккупантларга каршы көрәштә ярдәм кирәклеге мәгълүм була. Совет командованиесе берничә дивизияне Прага юнәлешенә җибәрә. Эреле-ваклы бәрелешләр белән көньякка хәрәкәт иткәндә, өлкән сержант Мирзәхмәт Муллахмәтов җинелчә яралана. Шулай да аның кыр госпиталендә дәваланып ятасы килми, үз полкыннан аерылып калу ихтималыннан шикләнеп, госпитальдән качып китә. Өч көннән соң әйләнеп кайткан сугышчыны күреп санчастьтәге табиблар:

— Күпләр ничек тә исән калыр өчен төрле хәйләләргә баралар, ә син күрә торып хәтәр эзлисең, — дип баш чайкыйлар. Мирзәхмәт кулын гына селти, ярасын кабат бәйләтеп, батареясына ашыга. Бу вакытта инде рейх үзәгенең алынуы турында хәбәрләр килеп ирешә. Шатлыкның чиге юк. Шулай да Прагада — ополчение, аның тирәсендә Кызыл Армиянең регуляр частьлары корал ташламаган дошман белән сугыш хәрәкәтләрен дәвам иттерә. Чех ополченецлары шәһәргә контрольне тулысынча үз кулларына алганнар, диләр, ниһаять. Сигезенче майда Гитлер Германиясе һичсүзсез капитуляцияләү турындагы килешүгә кул куя. 1945 елның 9 мае — Бөек Җиңү көне! Роталарда, батареяларда бөтен халык җырлый-бии, берберсен кысып кочаклый, пилоткасын күккә чөя, кемнең кулында нинди утлы корал — шунардан күккә ата. Шулчак «фашистларның утыз меңлек группировкасы Прага яныннан узучы шоссе буйлап Австриягә үтмәкче була. Сугышка әзерләнергә!»

дигән әмер ирештерәләр. 176нчы артполк та дошманның камап алынган төркемен зарарсызландыру өчен шул тарафка тартыла. Тик Мирзәхмәтләрнең полкы турыдан-туры бәрелешләрдә катнашырга өлгерми — камалыштагыларның бер өлеше юк ителә, күпчелек корал ташлап әсирлеккә төшә. Әсирләр арасыннан кемдер алар арасында сатлык генерал Власовның булуын «тишә». Бөтен бер армияне сугышсыз-нисез немецларга илтеп тапшырган һәм соңыннан концлагерьлардан «РОА» («русская освободительная армия») составында хезмәт итәргә ризалык белдергән әсирләрне җыеп, фронтта Кызыл Армиягә каршы сугыштырган адәмне эзләп табуы особистларга әлләни кыенлык тудырмый. Уникенче май көнне бер җиңел машинаның багажнигында качып китәргә омтылганда тотып алалар үзен. Соңыннан Ватанны сатуда гаепләп атып үтерәләр (бөтен власовчыларны бер калыпка салырга ярамый торгандыр: Мирзәхмәт ага сөйләвенчә, алар еш кына алгы сызыкта совет сугышчыларына каршы ут ачудан баш тарталар; кайчагында үзебезнекеләр ягына чыгалар, тик анда аларны НКВДшниклар эләктереп, юк итәләр яисә ерак Себердәге ГУЛАГ лагерьларына озаталар).

Гаскәри берләшмәләрдәге җиңү эйфориясе тиз генә тынмый. Моңа Чехословакия Президентының совет сугышчыларына карата хәерхаһлы мөнәсәбәтләре дә сәбәп. Ул Прагада һәм башка кала вә салалардагы барлык сыраханәләрдә азат итүче Армия солдатларына түләүсез сый-хөрмәт оештырырга күрсәтмә төшергән. Атакаларга барыр алдыннан бирелгән фронтовой «йөз грамм»нарга тәмам ияләнгән урыс солдатына андый форсатны бир генә — мичкәнңнең төбенә төшә. Баштагы мәлләрдә офицерлар сүз әйтми, «кеше чыдамаслык шартларда каннарын күп койдылар, сыйлана бирсеннәр», дип карыйлар. Тик һәрнәрсәнең чиге булган кебек, бәйрәмнең дә ахыры була. Полк һәм дивизияләрне акрынлап киләчәктә дислокацияләнәчәк урыннарына озату башлана. Мирзәхмәтләр полкы Көнбатыш Украинаның Львов өлкәсенә күчерелә.

## Исәнме, туган авыл! Һәм тагын хуш инде!

Өлкән сержант Мирзәхмәт Муллахмәтов туган авылына хәрби хезмәттән 1945 елның ноябрь ахырында әйләнеп кайта. Ир затлары сирәк күренә: сугышка киткәннәрнең яртысы диярлек яу кырында башларын салган, кайберәүләр, Армиядә аларны алыштырырдай некрутлар булмаганлыктан, хәрби хезмәтен дәвам итә, әлегә алган яраларыннан савыгу өчен, госпитальләрдә дәвалану курсын үтүчеләр дә бар. Бөтен җирдә ачлык, жимереклек. Колхозда эшләргә Мирзәхмәт кебекләр бик кирәк. Шулай да егет Салавычында ныклап урнашып, җиң сызганып эшкә керешергә дә өлгерми, кабат действительный Армиягә чакыру ала. Ярый инде Хәләмгөл исемле чибәргә өйләнергә өлгерә. Исән барып, сау кайтса, хатыны кечкенәсе белән каршы алыр әллә.

Элекке фронтовикларны гаскәри берләшмәләргә җыюның сәбәбе халыкара хәлнең катлауланыуына бәйле икән. Имештер, Бөекбритания премьер-министры Уинстон Черчилль Фултонда Сәвитләр Берлеген шөбһәгә салган янаулы нотык белән чыккан, аңа союзникларның атом сугышы башлау ихтималы белән янаган. Югары власть эшелонындагылар, Икенче бөтендөнья сугышы башындагы хаталарны кабатламас өчен, әзерлекне алдан күрүне кирәк тапканнар.

Англия корольлеге утраулары Мурманскидан әллә кайдагы ераклыкта түгел. Әле күптәнме соң СССР белән Бөекбритания арасында төньяк боз диңгезе кәрваннары даими йөреп торды, бергәләп дошманның су асты көймәләре һөҗүменнән сакланды. Ул чагында союзниклар бер-берсенә ярдәмләшеп зур золымнан — Аурупаны фашизм свастикасы каплаудан коткарып калдылар. Ә хәзер нигә килешә алмыйлар? Ни житми адәм балаларына?

Мирзәхмәтнен дингез флотына бернинди катнашы булмаса да, су асты көймәсендә хезмәт итәргә кыстыйлар әнә. Анысы нигә кирәктер: өлкән сержант чиныннан баш тартып, гади матрос булып калырга өндиләр. Элекке десантчы, автоматчы, орудие расчёты командиры кемнендер капризын канәгатьләндерәм дип нигә әле ирешкән дәрәҗәсеннән баш тартырга тиеш ди — «юк!» дип кырт кисә ир-егет.

— Алайса крейсерга барасын! — диләр ана. Әмергә буйсынмый хәле юк инде. Хәрби рейдларга чыгып, 5 ай чамасы вакыт үтә. Бөек Октябрь революциясенен 29 еллыгы якынлашкан көннәр. Ул чорларда Армияне югары әзерлектә тоту өчен политхезмәткәрләр интенсив агитпропаганда эше алып баралар. «Ленкомната» дип йөртелүче «кызыл почмак»ларда язма лозунг-плакатлар, патриотик рухлы рәсемнәр һәм башкасы эленеп тора. Мирзәхмәт Муллахмәтов үзенең сугышка кадәр авылда әлеге төр һөнәр белән шөгыльләнүен әйткәннән соң, крейсер командирының сәяси эшләр буенча урынбасары, аны барлык башка вазифаларыннан бушатып, «кызыл почмак»ка рәссам итеп билгели. Мирзәхмәт әлеге бүлмәне шундый дәрәҗәдә бизи ки, Төньяк флоттан килгән инспекция ошбу манзараны күреп тел шартлата һәм арадагы югары чиннардан берәү өлкән сержантка кичекмәстән Мурманскидагы Флот йортына рәссам булып күченергә тәкъдим ясый. Андый форсаттан баш тартсаң, ахмаклык булыр. Айлар буе дулкын өстендә тирбәлеп, «дингез чире»ннән интеккәнче, иркен һәм тыныч шартларда көнеленә якын шөгыль белән әвәрә килүгә ни житә — ризалаша ир заты. Флот йортындагы хәрби хезмәткә бәйле мәшәкатьләр белән янә 5 айның үткәне сизелми дә кала. Ерак Татарстандагы Салавыч авылы белән котып чигендә урнашкан кырыс климатлы Мурманск арасында хатлар йөреп тора. Шундый хатларның берсендә хәләле Хәләмгөл: «Кыз булса, Рәйхана аты кушарсын, дигән иден, син әйткәнчә, туган балабызны шулай дип исемләдек», — дип яза. Мирзәхмәтнең башы күккә тия инде. Үзе жир читендә булса да, күнеле туган ягына ашкына, тизрәк гаиләсен, нәни кызчыгын кайтып күрәсе килә. Теләге фәрештәләрнен «амин» дигән вакытына туры килгәнме әллә, ул арада халыкара киеренкелекнең берникадәр йомшаруы сәбәплеме, 1922-1923 елларда туып, сугышның башында ук фронтка алынган һәм ахырына кадәр алгы сызыкта кан койганнарны (ул елгыларның Ватан сугышыннан һәр 100 кешедән өчесенең генә исән кайтуы билгеле) демобилизацияләргә дигән әмер алына. Бу вакытта табигатьтә кырык жиденче елның апреле тантана итә шул инде — Бөек Жиңүнең икенче елы якынлаша.

## Сүз соңында

Мирзәхмәт Муллахмәт улы Муллахмәтов үзенең үткән озын тормыш юлында ачлы-туклы балачак михнәтләрен дә, өрлек кебек егет чагына туры килгән каһәрләнгән сугышның әйтеп бетергесез газапларын да артыгы белән татыган. Туган авылы Салавычтагы тәмам жимерек колхозны (язмабыз башында телгә алынган Салавыч, Каенлык, Калмыково авыллары күптәннән үзләре генә түгел, исемнәре дә картада юк инде) 1947 елдан 1958 елга кадәр житәкләп, өстәгеләр фәрманы белән 1958 елда Иске Юрашка кушканнан соң, хәерчеләр рәтендә сөйрәлгән хужалыкны да алдынгылар рәтенә чыгарган һәм узган гасырның сиксәненче еллар башында миллионер колхоз иткән кеше. Утыз алты ел рәислек итү дәверендә аның күмәк хужалык көче белән өр-яңадан машина-трактор паркын, терлекчелек комплексын, ашлык эшкәртү һәм саклау мәйданнарын вә амбарларын төзетү өстенә, менә дигән ике катлы авыл Мәдәният йортын сафка бастыруын, житәкче постыннан китәренә бер ел алданрак заманча ике катлы урта мәктәпне файдалануга тапшыруда саллы өлеш кертүен һәм тагын санап тиз генә очына чыга алмаслык бик күп эш-гамәлләр кылуын да сагынып искә

алалар. 1983 елда, даими яшәү урынын Алабугада сайлап, РСФСР күләмендәге персональ пенсиягә чыккач та (1986 елгы үзгәртеп корулар вакытында андый мәртәбә юкка чыгарылды), кул кушырып өйдә утырмый, ПЛ-79нын ул чагындагы директорынын гозере белән уку йортынын төп корпусын төзетүдә проект белән эшләр барышынын тәнгәллеген ике ел дәвамында күзәтеп-барлап тора (тиешле кысалардан тайпылышлар булса, аларны үзгәрттерә).

Тормыш иптәше Хәләмгөл апа белән алар якты дөньяга килгән ун балаларынын сигезен үстереп (икесе кечкенә яшьләрендә вафат, ин өлкәне дә инде гүр иясе) аякка бастырдылар. Аларнын күбесенә югары белем биреп, һәркайсын башлы-күзле иттеләр. Хәзер инде оныкларнын балалары бар. Кызганыч ки, пар канаты Хәләмгөл апа 1998 елда якты дөньялардан кичте. Аннан сон 11 ел дәвамында Мирзәхмәт ага ялгыз башы (балалар һәм оныклар хәлен даими белешәләр анысы) көн күрде. Ир затынын үзенә генә тормыш итүләре (бигрәк тә картлык житкәч) катлаулы шул. Балаларынын да кинәшен тотып, 2009 елда элекке фронтовик янадан парлы була. Үзебезнен кавемнән түгел дә инде — нишлисен, бу яшьтә әлләни сайланыр чама да юк.

Быелнын 9 маенда элекке СССР халыкларынын (объективлык өчен союзникларнын да дип әйтергә кирәк) фашизмны жинүенә 70 ел тула. Сонгы дистә ел эчендә фронтовикларга һәм тыл ветераннарына игътибар нык артты: аларга дәүләт исәбеннән бушлай фатир һәм башка төрле льготалар бирелә. Мондый унайлыклар тудыру күптән кирәк иде, чөнки аларнын зур күпчелеге унай шартлар тудыруны көтеп житкерә алмыйча бакыйлыкка күчте. Шартлар тудырылган очракта да, алар бәйрәм даталары һәм өлкәннәр көне якынлашканда гына искә төшмичә, даими нигезгә куелса, бигрәк тә яхшы булыр иде. Геометрик прогрессия тизлегендә елдан-ел саннары кимеп баручы сугыш ветераннарынын ин сонгысы да 10-15 елдан арабыздан китеп барыр. Алар бу дөньялардан сугыштан сон туган һәм яшьрәк буыннарга үпкә-рәнжеш белән китәргә тиеш түгелләр, юк — түгелләр! Ә язма героебызнын үзенә килгәндә, ул байтак өстенлекләрдән файдаланса да, кайчагында алар турында кайгыртырга тиешле хезмәтләрнен игътибарыннан читтә каладыр кебек. Әйтик, Татарстан күләмендә Бөек Жинүнен 70 еллыгына «70 ликов Победы» дип исемләнгән фотоальбомга ни өчен Алабуганын ветераннар советы анын исемен кертмәгән? Егерме сигезенче февральдә Казаннан махсус жибәрелгән фотограф 3 урыс һәм 3 татар фамилияле ветеранны (анысы сүзем юк, бәлки, квота буенча шулай тиештер) объективка алды, ә аны — юк! Югыйсә ул Сталинградның «магма» катламы саналган Мамай курганында кайнавы белән генә дә, һичшиксез, монарга лаек. Мирзәхмәт аганын үзе әйтүенчә, Алабуга төбәгеннән сугышка алынып, туры Сталинградка килгән 64 сугышчынын нибары өчесе генә (!) исән кайткан. Бу турыда уйланырга нигез бар, жәмәгать. Яна «табадан төшерелгән» документаль бәянымнын «Алабуга нуры» газетасында әле беренче өлеше генә дөнья күргән иде. Шул чагында мина өлкән яшьтәге бер ханым нәкъ менә: «Нигә исемлеккә кермәгән?» — дигән сорау бирде. Үзем дә мона нык гажәпләнсәм һәм ризасызлык белдерсәм дә — язучы кеше — ни эшли алам сон? Апага ошбу сорау белән телефон аша шалтыратырга кинәш итеп, кала ветераннар советынын телефон номерын бирдем. Актив гражданлык позициясендә торучы кешегә аннан нинди жавап биргәннәр дип уйлыйсыз? Әүвәл ныклап утырган урыныгызга тотыныгыз (басып торсагыз — утырыгыз), юкса, егылып китәрсез: «Чын сугышта катнашучылар күптән үлеп беттеләр инде!» — дигән чәрелдек тавышлы хатын. Һәртөрле советларда, президиумнарда «арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит» дип утыручылардан башка жавап көтеп булмыйдыр шул инде.

Тормышта бик тыйнак, сугышта булганнарын, гомумән, сөйләп йөрмәгән Мирзәхмәт ага Муллахмәтов шулай да Бөек Җиңүнең 60 еллыгын бәйрәм итәргә 2005 елның 9 маена Мәскәүнең Кызыл мәйданында үткәрелгән хәрби парадка чакырылган. Татарстаннан Әтнә ягы фронтовигы белән бергә барганнар алар тантанага. Ә Сталинградта (хәзерге Волгоград) сугыштан соңгы узган 70 ел эчендә нибары 3 мәртәбә булган, алары да үз инициативасы белән — узып барышлый. Әйтүенчә, берсе — Ял йортына дәваланырга барганда, икенче тапкырында — Әстерхандагы сеңлесен күрер өчен сәфәр чыккач, өченчесендә — тагын ниндидер йомышны йомышлаганда. «Мамай курганындагы грандиоз «Ватан-Ана» һәйкәл обелискы нәкъ без фашистларга каршы сугышкан позицияләр янәшәсенә тергезелгән», — ди ул. Шуннан ерак түгел 37нче укчы гвардия дивизиясе командиры, Советлар Союзы Герое генерал-майор Желедов Виктор Григорьевичның җәсәде дә җирләнгән икән (Сталинград тәмугыннан генерал үзенең нибары 100ләп сугышчысы белән генә исән чыккан һәм, Мирзәхмәт ага сөйләвенчә, дивизияләре шуннан соң Мәскәү янына җибәрелеп, анда башка төрле номерлы дивизия итеп үзгәртелгән һәм Калинин фронтында сугышка кертелгән. Дивизия командиры бәрелешләрнең берсендә һәлак булган, аның сугыш вакытындамы, әллә соңыннанмы — бирегә китереп күмелгәнен карт фронтовик төгәл генә әйтә алмады (җөмләдән, Мамай курганында соңгы сыену урыны тапкан полководецларның саны шактый күп диләр).

Дүрт ел дәвамында сугыш хәрәкәтләрендә катнашып һәм аннан соң тагын бер ел чамасы Хәрби диңгез флотында хезмәт итеп тә, фронтовик Мирзәхмәт Муллахмәтовның сугышчан бүләкләре өч медаль һәм бер III дәрәҗә сугышчан Дан ордены белән чикләнә. Юк, болар аның начар яисә аз сугышуыннан түгел, болар — аның кебек миллионлаган совет солдатларының күрсәткән (аларны кем күреп, барлап бетергән) тиңсез батырлыкларын бәяләп бетерә алмауларыннан. Гадирәк әйткәндә, андый мөмкинлек булмаудан. Аннары, хәрби тарих материалларыннан мәгълүм ки, 1941-1942 елларда Кызыл Армия солдат һәм офицерларын орден-медальләргә тәкъдим итү дә сирәк күренеш булган. Фронтларда гаскәрләр күбесенчә чигенү белән мәшгуль булганда, зурдан кубып нинди бүләкләү турында сүз алып барырга мөмкин ди!

Хикмәт орден-медальләрдә дә түгел. Мирзәхмәт аганың андый «ялтыравык»ларг, гомумән, исе китми. Ул колхоз председателе булып эшләгән елларында бүләкләрнең ниндиләрен генә алмаган да нинди дәрәҗәләргә ирешмәгән. Ил агасы үзе әйтүенчә, кеше: «Менә — мин! — дип күкрәк кагарга тиеш түгел, башкалар синең турыда яхшы фикердә булсын, башкалар хөрмәтләсен». Фронтта, алгы сызыкта кан койганнар турында бик күп китаплар яздылар, кинофильмнар төшерделәр. Ә менә вакытлы матбугатта киң җәмәгатьчелеккә танытып, Мирзәхмәт Муллахмәт улы турында кемнең дә булса күләмле язма бастырганын мин хәтерләмим. Бу үзе үк өлкән фронтовикның артык тыйнаклык күрсәтеп һаман күләгәдә калуы түгелме? Ярый әле, соңарганчы, акланмаган «билгесезлектә» калуын дәвам иткән ил агасына төртеп күрсәтүчеләр табылды. Ярый әле житештем.

# АНТЫМ БЕЛӘН ИЛНЕ ЯКЛАДЫМ

**Абдулла АЛИШ**

## Кыр казлары

Бүген иртән күрдем кыр казларын,
Көнчыгышка таба киттеләр.
Канат җилпи-җилпи, каңгылдашып,
Тигез сафка тезелеп үттеләр.

Юллар озын сезнең, кыр казлары,
Урал таулары аша чыгарсыз.
Канатыгыз юлда тузанланса,
Агыйделгә төшеп юарсыз.

Әйтер идем, әгәр телен белсәм,
Әманәтем алып кит, диеп,
Туган авылым аша юллар тотсаң,
Сөйгәнемә сәлам әйт, диеп.

**Муса ҖӘЛИЛ**

## Тик булса иде ирек

Карлыгач булса идем,
Канат кагынса идем,
Җидегән йолдыз батканда,
Чулпан йолдыз калыкканда,
Туган илем, якты өем,
Очып сиңа кайтыр идем,
Сызылып таңнар атканда.
Йә булсам алтын балык,
Ак дулкыннарны кагып,
Ярсып дәрья акканда,
Ташып ярдан ашканда,
Таң сөмбелем, нечкә билем,
Йөзеп сиңа кайтыр идем,
Күлне томан япканда.
Булсам житез аргамак,
Көмеш ялымны тарап,
Таң җилләре искәндә,
Үләнгә чык төшкәндә,

Чулпан кызым, таң йолдызым,
Чабып сиңа кайтыр идем,
Гөлләр хуш ис сипкәндә.
Юк, барсыннан да элек
Кылычым булса кынымда,
Карабиным кулымда,
Сине саклап, туган жирем,
Мин ирләрчә үләр идем
Данлы сугыш кырында.

Фатих КӘРИМ

## Кереш җыр

Мин рядовой солдат бу сугышта.
Тик бер нәрсәм белән аерылам:
Рядовойлар төнен йоклаганда,
Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.

Бер минут та башка тынгы бирми,
Окоп почмагында утырам,
Аламын да куен дәфтәремне,
Янып, җыр язарга тотынам.

Ут булмаган жирдә ай яктырта,
Жыр хакына кала йокылар;
Окопларда язган жырларымны
Хөрмәт белән дуслар укырлар.

Гадел КУТУЙ

## Туган ил

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта.
Калсаң да бездән еракта,
Күнелдә син һәрчакта.

Суың тәмле, кырың ямьле,
Шифалы һаваларың,
Сугышларда дан казанды
Синең батыр улларың.

Искә төшә җәйге таңнар...
Рәхәт иде ул чаклар,
Бүген дә әле янадыр күк
Без кабызган учаклар.

Искә төшә бәйрәмнәрең,
Табыннарың, казларың,
Бер карауда гашыйк иткән
Зифа буйлы кызларың...

И данлы ил, и шанлы ил,
Син минем туган илем,
Киткән чакта эчкән суың
Тәме авызда минем.

И туган ил, и матур ил,
Нур күмә калаларың,
Һәр иртә-кич сине, илем,
Сагына балаларың.

Безне озаткан сукмакларны
Капламасын үләннәр,
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сез көтегез, сөйгәннәр!

**Хәйретдин МӨҖӘЙ**

## Ант

Ташкент урамнарын беләм әле,
Канаулы да алар, сулы да.
Читләренә үскән тирәкләре
Шундый төзләр, шундый сылулар.

Бер әйләнеп чыккач, тагын да
Әйләнәсе килә яннарын.
Бөдрә башындагы кошчыкларның
Тыңлыйсы ла килә сайравын.

Гөлстандай матур илемне,
Сылу кыздай сөйгән җиремне
Мәсхәрәләү өчен таптарга
Дошман кузгалганын белдем мин.

Йөрәктә ант янды ут кебек,
Ачу ташты, ташкын су кебек.
Үч алырга диеп дошманнан,
Мин каршына чыктым юл бүлеп.

Җирдә үскән һәрбер гөл өчен,
Басып йөргән изге җир өчен,
Кайнар тиргә батып көрәштем,
Сөйгән анам кебек ил өчен!

Кызганмадым кайнарканымны,
Кызганмадым йөрәк-җанымны.
Дошман «җиндем!» дигән чакта да
Мин үзем гел өскә атылдым.

Минем антым, аның һәр сүзе
Йөрәктә ут кебек тордылар.
Һәрбер эшем, һәр адымым өчен
Секундомер кебек булдылар.

Мин йөрәктә антны сакладым,
Антым белән илне якладым!
Илем өчен булган көрәштән дә
Бөегрәк нәрсә тапмадым!

**Шәрәф МӨДӘРРИС**

## Сыерчык

Чәчәк булса ялкын каршысында,
Шиңми-кипми басып торырмы?
Кермә, кошым, монда — канлы кырга,
Яндырырсың нәфис йонынны!
Гөрли сугыш, көйри бөтен нәрсә,
Без дә монда җиргә сыендык.
Ягынннарга, төтен, сөремнәргә
Кермә, борыл, кермә, сыерчык!

Оч син, оч син, җилеп, купшыланып,
Тыныч кырга, иркен сахрага, —
Туган җирем табып, кунчы барып,
Кунчы барып минем капкага.
Йортыбызга төш тә симез, тәмле,
Татлы җим ал, мамык җыеп чык.
Сорар булса әнкәм минем хәлне,
«Ул сау», — диген шунда, сыерчык!

Вакыт җитәр, сугыш корымнарын
Кагар шунда шәһәр-авыллар.
Туган кырым, туган болыннарым
«Синме бу?» дип каршы алырлар...
Төшсә дә тик монда, сугышларда,
Чәчкә — кырау, биткә — җыерчык, —
«Синең теләк улыңа булышканга,
Ул шат», — диген, җаным, сыерчык!

**Зәки НУРИ**

## Һөҗүмнән соң

Атаканың иң кайнары үтте,
Инде җирдә тыныч төн яши.
Ишет, иркәм! Беләм, күнелең көтте,
Көр тавышым белән эндәшим:

...Пулемётым пешерміде кулны,
Ауганда да үләннәр көеп.
Чөнки аттым һәрбер патронымны
Лентага син тезгәнсең диеп...

Тиздән, бәлки, хатым барып җитәр,
Шатлыгымны сөйләр, серемне.
Ә мин көтәм, зур бер бәйрәм итеп,
Сине очратачак көнемне.

Һәрбер сүзен йөрәгемә салам,
Сәлам хаты синнән килсә дә,
Гүя шуннан көч һәм гайрәт алам,
Атакага кертәм кесәдә.

Тиздән, тиздән ерткыч муены сынар,
Җиңү нуры каплар күк йөзен.
Хатларыңның шунда соңгысына
Җавап булып кайтырмын үзем.

Сибгат ХӘКИМ

## Егетләре Казан артының

Сүз башланып китә буш арада
Сагынып язган сәлам хатыннан,
Моңлы җырчы узган урманнардан,
Безнең мәшһүр Казан артыннан.

Берсе аның Сәгъди күршесеннән,
Өчиледән очрый, Куәмнән.
Күтәрелгән халык зур сугышка
Ерак авыллардан — түбәннән.

Кузгалаклар җыйган болыннардан,
Мәктәпләргә йөргән юллардан,
Егылып, елап кайткан урыннардан,
Тальяннарга сеңгән моңнардан,

Әкиятләрдән, безнең мәхәббәтнең
Уелып эзе калган җирләрдән;
Бабайлардан килгән нигезләрдән,
Җырлап туйлар иткән өйләрдән,
Туган җирдән безне кем аерыр!

Туган ил һәм туган тел өчен
Гомерләрне хәтта кызганмадык.
Дошманнарның бик күп тәрлесен
Мәскәү читендәге сугышларда,
Белгород һәм Харьков янында, —
Дала фронтында, илнең тирән
Елгаларын кичкән чагында —
Онытмаслык итеп кыйнадык без —
Егетләре Казан артының.
Кер төшмәсен барыр юлларына,
Намусына татар халкының.

Нәби Дәүли

# АТУ

ХИКӘЯ

Василий әкрен генә торып ишек янына килде.

— Һер вахтман, — дип эндәште.

— Вас ис лус?[1] — диде тышкы яктан солдат.

— Ишекне ачыгыз әле, минем сезгә сүзем бар...

Вахтман җавап бирмәде. Ул барак стенасына эленгән телефон трубкасын алды да комендатура белән сөйләшә башлады. Бик тиз арада барак янында мотоцикл тырылдаган тавыш ишетелде, кинәт ишек төбенә житеп тынып калды.

Ишек ачылды. Василий чыгарга да өлгермәде, аның йөзенә фонарь яктысы төште.

— Һа, һер полицай, Герасимуф, — дип көлде Пауль. — Сез ничек биредә? Бездә полицайлар өчен аерым бина бар...

— Мин иптәшләремне эшкә үгетли-үгетли, вакытында бaрактан чыгып өлгерә алмадым, һер оберлейтенант...

— Гут, гут, — диде комендант. Һәм үзе белән ияртеп килгән солдатка Герасимовны полицайлар йортына алып барырга кушты.

Аерылышканда аңа полицай:

— Гутен нах[2], — дип әйтергә дә онытмады. Ләкин инде төн сыегаеп килә иде. Офык буйлары алланган, тиздән таң атар. Саф урман һавасы Герасимовның йокысын ачып җибәрде. «Менә хәзер балыкка барасы иде, — дип уйлады ул. — Енисей ярларында хәзер нинди матур таң туып киләдер... Юк, ул якларда әле бу сәгатьтә караңгы була. Хәер, үз туган якларында караңгы төне дә рәхәт. Күк йөзендәге йолдызлар ни тора! Тынлык һәм шул тынлыкта яр буендагы камышлар сиңа нәрсәдер сөйлиләр кебек тоела. О, туган яклар... Еракта, еракта...»

Комендатура белән янәшә, лагерь эчендә, бер җыйнак кына бина бар иде. Герасимов ишек төбенә килеп тә житте. Их, ераграк юл булсачы. Барасы иде таң йөзенә карап, барасы иде, барасы иде...

Герасимов бүлмәгә килеп керде. Караса — Шмарь. Ул инде өс-башына киенеп өлгергән иде.

Яңа полицай иске полицайга сәлам биреп маташмады.

— Бик иртә торгансың, әллә берәр җиргә барасың бармы? — диде. Шмарь тиз генә җавап бирмәде. Төн буе йокысыз арып шешенеп беткән күзләрен Герасимовка усал итеп текәде дә:

— Китәм! — диде. — Генерал Власов армиясенә. Мин бит үзем дә анда оберлейтенанттан ким булмам. Бу базда сасып ятканчы... Монда син яшә, ә вакыт житкәч, сине Гроссман үзе, маңгаена пистолет төзәп, атып үтерер. Көтеп тор, ком-мунист!

— Ә мин коммунист түгел, беләсең килсә, сиңа бу юлы чын дөресен әйтә алам. Әмма синең кебек этләр белән очрашканда, үземне коммунист дип саныйм...

Бу Шмарь өчен гаҗәп иде. Аның кеше йөрәгендәге мондый нечкәлекләрне төшенә алырлык акылы да, хисләре дә юк иде.

[1] Нәрсә булды?
[2] Хәерле төн.

— Ә син ни өчен үзеңне коммунист дидең Гроссманга?..

— Чөнки немецлар коммунистларны ярата төшәләр. Аларга синең кебекләр белән сөйләшергә дә кызык түгел, — дип көлде Василий. — Күрдең ич, оберлейтенант синең борыныңа ничек китереп салды. Инде шуннан соң да бернәрсә дә анламагач, сине кем дип атарга соң, Шмарь? Түбән җан син!

Шмарьның ачуы килде. Ул Герасимов белән бик каты итеп сөйләшергә дип кенә торганда, бүлмәгә вахтман килеп керде.

— Ком, — диде ул Шмарьга.

Шмарь кулына чемоданын алды. Вахтманга карап елмайды. Әмма солдатның йөзе җитди иде. Ул:

— Ком-ком, шнель, — дип кабатлады.

Шмарь агарынып китте. Куллары калтырый башлады. Бу нигә болай дорфа кылана әле, дип вахтманга нәрсәдер әйтергә җыенган иде дә, солдат инде ишекне аягы белән тибеп ачты.

— Ком, ком! — диде ул, каты кычкырып.

Шмарь Герасимовка тагы бер ачулы карап алды да:

— Очрашырбыз әле, әмма инде ул чакта соңгысы булыр, — дип әйтә-әйтә, вахтман артыннан атлады.

Герасимов таныш булмаган бүлмәдә бер ялгызы калды. Стенага күз ташлады. Бер якка ниндидер рәсем эленгән. Василий аңа игътибар бирмәде. Ул бик нык арган иде. Караваттагы матрацны кире ягы белән әйләндереп салды да, инде яртылаш йокыга киткән килеш, урын өстенә ауды. Бер-ике генә сәгать булса да йоклап алырга кирәк иде.

Капка янында Шмарьны туктаттылар. Чемоданын тартып алып, бер читкә куйдылар. Ганс килеп чыкты. Чемоданны каядыр алып китәргә кушты. Вахтманның мылтыгын тикшерде, затворын тартып, чактырып карады. Аннан соң:

— Фортиг! — диде.

Бу — барысы да әзер, алып кит үзен, дигән сүз иде.

Әле кичә генә гайрәтен кая куярга белми йөргән Шмарь кинәт телен йоткан кебек тынып калды. Нәрсәдер әйтергә иде дә, иреннәре кипеп китте. Ул аларны теле белән ялап чылатырга маташты. Әмма дә корыч игәү кебек каткан иде...

О, Шмарь, син бит немец лейтенанты формасын киеп, пистолет асып, ялтыравыклы итекләр киеп, шалт-шолт басып, беркөнне Василий алдына килеп басмакчы идең.

«Йә, егет, син мине таныйсыңмы?» — димәкче идең. «Инде сөйләшеп карыйк», — димәкче идең. Ә хәзер синең «мине кая озатасыз?» дип сорарга да көчең җитмәде. О, егет, егет...

Капка ачылды. Алдан Шмарь, арттан вахтман чыкты. Гадәттә, кемне кая гына алып китсәләр дә, ябык машинага утырталар иде. Ә бу юлы бер генә машина да күзгә чалынмады. Шмарь сагайды. Күңеле нәрсәдер сизенде. Шулай да ул үзен тынычландырырга тырышты: якын-тирәдәге станциягә генә барабыздыр, дип уйлады.

Алар юлга чыктылар. Инде таң сызылып килә. Агач башларына кояшның беренче нурлары кунган. Гүя алар канга манчылган. Ниндидер кош сайрый. Аның тавышы моңлы җырга охшый, ләкин нинди җырга? Шмарь исенә төшерә алмый.

Шмарь бер иркен сулыш алды. Язгы саф һава тәмле ширбәт шикелле күңелне күтәреп җибәрә. Тирә-як куе урман. Кая гына карасаң да, аллы-гөлле чәчәкләр. Шмарьга әллә нәрсә булды. Ул мондый язны гомерендә беренче кабат күрә шикелле. Ә бит мондый чәчәкле язлар күпме узган инде. Нигә соң Шмарь ул язларны әлегә кадәр сизми, күрми калды?

Уйлары йомгак кебек сүтелеп китте. Ул шул арада үзенең туган якларын исенә төшерде. Кайда калды соң әле ул еллар?

Кинәт вахтман:

— Һабст ду муттер?[3] — дип, Шмарьны үзенең ачы тавышы белән сискәндереп сорады.

Шмарь җавап бирмәде. Ул, кулларын артына куйган килеш, һаман бара бирде. Барган саен үзенең узган гомеренә таба атлый кебек иде. Шмарьга әле яна гына утыз яшь тулып килә. Утыз яшь күп тә түгел, әмма инде аз да түгел. Күп кешеләр бу гомердә инде югары белем алып, яки берәр һөнәрче, яки дипломлы инженер булып, тормышта үз урыннарын табып, инде баш-күзле булып, бала-чагалар белән яши башлыйлар. Ә Шмарьның беркеме дә юк иде. Аның әле бер генә кызны да янып-көеп, төннәрен йокламыйча, күндезләрен ут йотып сөйгәне булмады. Хатын-кызлар белән очрашты очрашуын... Ләкин нәрсә алар... Бүген бар, иртәгә юк.

Шмарьның авылда берданбер әнисе бар. Ләкин инде бик күп еллардан бирле ул аны күргәне дә юк, хатлар да язганы булмады. Ә менә хәзер шул карт ана улының күз алдына килеп басты. «Улым, сине кая алып баралар?» дип сорады шикелле ул, баш яулыгы белән күз яшьләрен сөртә-сөртә. Шмарь үзе дә сизмәстән:

— Әнием, әнием минем! — дип кычкырып куйды..

— Бас? — диде вахтман, Шмарьның бу сүзләрен ишетеп.

Шмарь бу юлы да җавап бирмәде. Ул борылып карады. Вахтман ни өчендер арттарак калып килә, Шмарь, искәрмәгәндә генә, мылтыгын тартып алмасын дип курка торгандыр, мөгаен.

Шмарь юл читеннән генә бер сары чәчәк өзеп алды. Иснәде. Бик хуш исле иде бу чәчәк. Шундый чәчәкләрне кайчандыр ул болыннардан кочак-кочак җыеп кайта торган иде. Бозау аларны бик яратып ашый иде. Ул менә хәзер дә шушы юл буйлап, шул чәчәкле болыннарга кайтырга теләде. Тик юл ул якларга таба бармый иде шул. Юл каядыр билгесез якка таба китә. Ә артта гомер кала, истәлекләр кала. Ул хатирәләр кайсы көйдерә, кайсы сагындыра, кайгыга сабыштыра. Ә кайсысы җанны өзгәләп сагышландыра. Әйе, сагышландыра. Шмарьның бит әле сагышның нәрсә икәнен дә белгәне юк. Кайгырган чаклары булды, шатланган чаклары да булды, әмма сагыш... Юк, Шмарь аны белми. Нәрсә соң ул сагыш? Шмарь кулындагы сары чәчәккә карады.

Әйт, чәчәк, син беләсеңме? дигән кебек җавап көтте һәм җавап та алды шикелле. Менә хәзер ул бу чәчәкне юлга ташлап калдырыр. Чәчәк шиңәр, аның инде беркемгә дә кирәге булмас. Шмарьның да язмышы шундый түгелме? Шмарьның да гомере шушы чәчәк кебек өзелеп калмыймы? Нигә соң ул тормышын башкалар шикелле матур итеп төзи алмады? Кем гаепле иде? Нигә ул укымады, һөнәр алмады? Нигә кызлар сөймәде? Нигә ул үзе теләп әсирлеккә төште, дошман станына килде? Ни өчен полицай булды? Ни өчен үз илдәшләрен җәберләде? Алар бит аны мәңге-мәңге каргарлар...

Шмарь бармагы белән чигәләрен тотты. Чигә тамырында дөп-дөп итеп кан тибешен сизде. Кемдер Шмарьның баш эчендә чүкеч белән дан-дан иттереп суга иде кебек.

Их, янадан туасы иде дә янадан тормыш башлыйсы иде. Юк, Шмарь ул чакта болай яшәмәс иде... Бәлки шул уйларны кешеләр сагыш дип атыйлардыр.

Кинәт юл ике якка аерылды. Берсе урман эченә, берсе тау буйлап түбән таба сузыла. Шмарь белә: бусы шәһәргә таба. Ул шул якка борылырга теләп атлый гына башлаган иде, вахтман:

— Линкс! — дип кычкырды. Шмарь тукталып калды. Солдат та тукталды.

— Сулга! — дип кабатлады ул.

Шмарь: «Нигә?» — дип сорамады. Ул бу юлның кая илтәчәген сизә иде.

Ләкин ышанасы килмәде. Бәлки анда башка берәр лагерь бардыр.

Шунда алып бармыйлармы икән, дип өметләнә иде ул. О, ул өметләр, өметләр...

Шмарь сул якка таба атлады. Барган саен урман караңгылана, салкыная иде.

[3] Әниең бар идеме?

Шмарь кинәт сискәнеп китте. Тәне чемердәде. Тешләре тешкә бәреләбашлады. Ул тагын туган анасын күз алдында күрде. Менә ул үзенең улы белән янәшә бара кебек. «Улым, сине болай кая алып баралар соң? Бу кара урманда бик куркыныч бит» — дип сөйләнә шикелле.

— Әнием, әнием! — диде Шмарь. Ләкин үз тавышын үзе дә танымады. Тавыш түгел, ниндидер пышылдау булып кына ишетелде. Шмарь үз-үзеннән куркып китте. Аякларының көче бетте, тәне камыр кебек ләпшерәйде. Адымнары әкренәйде. Ә вахтман ашыктыра, шнель, шнель дип кычкыра тора. Шмарь моны ишетми дә кебек. Ул һаман әнисенең йөзенә сокланып карый. Анасы, улым, улым, бәгырем минем, ди сыман. Шмарьның күзләре яшьләнде. Кинәт әнисе юл читенә чыгып басты да: «Хуш, улым, мин калам инде», — дип, күздән югалды. Шмарь инде барысын да аңлады. Аны бу кара киемле солдат атарга алып бара. Бу сукмактан күпләр узган. Әнә анда җир өемнәре күренә, әнә әзер базлар. Алар шахмат тактасындагы кебек итеп кара-каршы казылганнар. Берсе аша сикерсәң, икенчесенә мәтәлеп төшәсең. Әле моннан өч көнә көн элек ике поляк әсирен алып киткәннәр иде. Алар ракетага куелачак радиоаппаратларны бозганнар дип сөйләделәр. Саботаж ясаучылар. Ә Шмарь кемгә, нинди зыян китерде соң? Киресенчә, җаны-тәне белән бирелеп эшләде? Ә Гроссманга ошамады. Ни өчен?

Шмарь үзе дә сизмәстән:

— О, беләм, беләм! — дип кычкырып куйды. — Болар бит шулай яңа корал серен яшерергә телиләр. Алай дисәң, Шмарь яңа корал турында нәрсә белә соң? Аннан соң ул кичә генә комендатурада булган хәлне исенә төшерде. Гроссман өч качкынны «атып үтерелделәр» дип актка язып, яшереп куйды. Ә Шмарь, юләр, яхшы булыйм дип, «алар качтылар» дип дөресен әйткән булып маташты. Менә хәзер инде Шмарь үзе дә дүртенче кеше булып шул актка язылып куелыр... Гроссман өч качкын турындагы хәбәрне беркем дә ишетмәслек итеп, Шмарь белән бергә җир астына күмә. Кабер — ышанычлы урын.

Шмарь барды, барды да туктап калды. Инде теге базлар шактый якын иде. Ул кесәләрен актарып карады. Алар буш иде. Аннары ул күкрәгенә асылган калай номерны өзеп алды, учына кысып тотты.

Аның бу илдә бердәнбер һәм иң соңгы документы — шул калай кисәге иде. Менә шушы минутта әле Шмарьның җирдә яшәвенә шул калай кисәге шаһит иде. Шул калайда исеме дә, фамилиясе дә һәм узганы да. Тик анда кешенең киләчәге генә юк иде.

Шмарь иреннәрен кысып, күзләрен чекерәйтеп урманга карап алды. Ә урман, мин сине йотам дигән кебек, үзенең корбанын тып-тыныч кына көтеп тора иде.

— Мә, — диде Шмарь һәм үзенең номерын бөтен көче белән атып бәрде. — Мин яшәмәдем, мин дөньяда юк идем...

Уйланды: минем урында Герасимов булса, нишләр иде мондый чакта? Качар идеме? Юк, качмас иде. Хәтта башын да имәс иде Герасимов. Шмарь ни өчендер көнләште. Шул минутта ана каяндыр, ниндидер көч килеп керде сыман. Ул кинәт кенә башын күтәреп борылды да вахтманга карады. Вахтман шактый еракта, инде мылтыгын Шмарьга төзәгән иде. Шмарь урманны яңгыратып, ниндидер авыр, тонык тавыш белән көлеп җибәрде. Аннан соң эре-эре адымнар белән вахтманга туп-туры карап атлый башлады. Бер атлады, ике атлады. Өченче адымда ул мылтык көпшәсеннән гөлт итеп чыккан зәңгәр төтенне күрде. Шмарьның кулыннан чәчәк төшеп китте. Ул чәчәк аңа кып-кызыл булып күренде. Шмарь тезләнде, әмма кулы чәчәккә җитә алмады. Ул яңадан торып аягүрә басты. Алга карады. Анда вахтман инде мылтыгын түбән төшереп, Шмарьга карап тора иде. Шмарь тагын алга атларга теләде. Аяклар бармады. Алар җиргә ябышып калганнар кебек иде. Вахтман яңадан мылтыгын күтәреп Шмарьга төзәде. Шмарь, бар көчен җыеп:

— Минем әнием бар иде, бар иде! — дип кычкырды. Мылтыктан тагын утлы төтен бөркелде. Шмарь авып китте.

# ЯШИ УЛ КӨН, ЯШИ ҺӘМ ЯШӘР...

Разил ВӘЛИЕВ

## Егерме миллион

Балалар уйныйлар «сугышлы» уены,
Сугыш ул — аларга тик уен.
Ә минем уемда кайтмыйча калганнар —
Егерме миллион, егерме миллион.

Тол килеш картайды, агарды чәчләре,
Ишләрен тапмады күп куен.
Куенга алыр да терелтер идем мин...
Егерме миллион, егерме миллион.

Яз килгәч шыталар кан төсле чәчәкләр,
Котлыйлар Җиңүне — ил туен.
Мәйданда ут яна, мәйданда — чәчәкләр...
Егерме миллион, егерме миллион.

Карыйм да кояшка, эндәшәм дөньяга:
Тынычмы күңелең, ни гамең, ни уең?
Мин түгел, мин түгел, эндәшә дөньяга
Егерме миллион, егерме миллион!

Рөстәм МИНГАЛИМ

## Кешелек белән сөйләшү

Сугыш
Дан бирә.
Яхшы дан булырга мөмкин ул,
Мөмкин ул яман дан булырга.
Сугыш
Дан бирә...
Кешеләр!
Сугышны без аны
Үзебез тудырдык,
Үзебез үстердек,
Үзебез ашаттык —
Туймады...
Бабайларны без аңа ашаттык,
Әтиләрне без аңа ашаттык —
Туймады...

Әниләрне, сабыйларны
Ашаттык —
Туймады...
Мал биреп,
Дан алдык,
Җан биреп,
Дан алдык —
Туймады...
Бирсәк,
Безне дә алыр ул,
Ашар ул барын да.
Аннан...
Баласыз бишек төсле дан
Әйләнеп калыр Кояш янында.
Әйләнеп
таралыр, югалыр
Кояш янында.

**Рәдиф ГАТАШ**

***

Әтиемне юксынам.
Еллар үткән саен әнкәемнең чәчләрендә
Ак бөртекләр артуын күргәндә,
Йөземне аларга яшергәндә,
Әтиемне юксынам.

Җир ак чәчәкләргә күмелгәндә,
Баш өстендә ак болыт йөзгәндә,
Яңагыма кунып кар эрегәндә —
Ак фонда ул калкып чыга сыман.
Үткәнемдә, бүгенгедә,
Киләчәгемдә — ул балкып тора сыман.

Кояшта, бәлки, аның көлүе чагыла,
Йолдызларда аның карашыдыр;
Төсе итеп ал таңга табынам:
Яшел җирне саклап, кара җирдә калган
Әтиемне сагынам.

Изге агач — тынычлыкның тамыры тирәнрәк китә,
Мәңгелек гөл — шатлык һаман күбрәк үсә:
Тормыш матур, тулы бер җыр сыман...
Бер яфракны эзлим,
Бер чәчәкне күрмим,
Бер аһәңне тапмыйм, ул юк сыман.

Мине бер тапкыр да күрә алмаган
Әтиемне мин —
Тиздән инде аның яшьтәше — улы —
Сагынам һаман һәм юксынам.

Мөхәммәт МИРЗА

## Бер хәбәрсез югалганнар...

Мең үлемнән исән калганнар да
илдә кабат әсир ителгән...
Тоткын көне — өзеп ялганганы
берекмәс шул инде — кителгән...

Шайтан коткысында җаһил заман
күпме җанны кыйган угыннан...
Крематорийларның торбасыннан
канлы төтен күккә ургылган?..

...Җинеп җиңсез кайткан җил-егетләр...
Буш балактан кайткан зәр-ирләр...
Сан тулмаган тәндә җан йөреткән —
качып китеп булмый тәкъдирдән...

Ярлыкалып исән калганнардан
кемдер кайтмый калган иленә...
Алар бер хәбәрсез югалганнар
йә күчкәннәр ятлар исменә...

Ят җирләрдә ятка якынаеп,
ояларын корган ятларда...
Бүген алар гөнаһына кереп
кем гаепләр, кемдер яклар да...

Җан һәм Вөҗдан — вакыт мыскалында
күзең ачып йомган арада,
йә карала, йә агарып кала —
өс чыкканы — түбән табада...

Хак хөкемне хәтта вакыт түгел,
Бер Хак үзе генә чыгарыр...
Югалганнар — димәк,
тәкъдиренә тәгаенләнгәне шулайдыр...

Җанны биргән алырга да хаклы,
Җәбраил һәм Газраилләрнең
вазифасын бүлешкәннәр хакмы?
Колны сыендырган илләрнең
шәфкатенә шайтан күләгәсе
төште өшеттереп бәгырьне...
Вөҗдан һәм дан өчен түләнәсе
Бар кыйммәттән бер Җан кадерле!!.

...Алар бер хәбәрсез югалмаган,
хәтта җәсәдләрен җир алып
туфрак булгач, оныкъ, торыннары
фатихасын сорап ялварып,
җаннар кайта туган нигезенә,
җилләр булып ятып елыйлар...
Кичерелгән бар да вакыт белән...
Ә үзләре гафу сорыйлар...

Газинур МОРАТ

## Ул көн...

Һәммәсенә түзгән,
кунгән хәтер
Күнегалмас ләкин үлемгә.
Өчпочмаклы кайгы булып яши
Авылымда ул көн бүген дә.

Әбкәйләрнең сандык төпләрендә
(Ак бүзләре белән янәшә)
Өчпочмаклы кара хәсрәт булып
Яши ул көн, яши һәм яшәр.

Һәм вәхшинең яңа варислары
Табынганда кабат тәрегә,
Борманнардай посып ята ул көн
Ярчык булып — Илем тәнендә.

Замананың яңа залимнәре
Үрелгәндә кабат кынына,
Ракетадай посып ята ул көн
Җирнең күкрәк куышлыгында.

Һәммәсенә түзгән,
кунгән хәтер
Күнегалмас ләкин үлемгә —
Кара кайгы булып яши ул көн
Авылымда минем бүген дә.

Әбкәйләрнең сандык төпләрендә
(Туй күлмәге белән янәшә)
Соңгы
набат булып
күкри ул көн.
Хәтер белән хәтер ярәшә...

Гөлзадә ӘХТӘМОВА

## Сугыш хәсрәте

Юк әле, сугыш хәсрәте
Тиз генә бетмәс кебек:
Төшләргә керә шаһитләр
Интегеп, кара көеп.

Бар әле күмелмәгәннәр,
Җил исә ярдәм сорап.
Гап-гади солдат каскасы
Ятадыр анда сыкрап.

Яу үткән, әмма тынмаган
Халыкның җанында моң.
Кайгы-хәсрәт хатирәсе
Көчле, газаплы да соң!

Һәр йортның ишеген шакып,
Таралган «кара» хәбәр.
Ул кайгы өзә үзәкне,
Ах, хәтәр, хәтәр, хәтәр...

Кайтмаган кемнең әтисе,
Кемнең — яшь кызы, улы.
Беркемне дә ычкындырмый,
Явыз ул сугыш кулы.

Михнәтле хәтер киштәсе
Сугышка барганнарның.
Мәңге төзәлмәс яралы
Җаны ветераннарның.

Тәндә ядрә кыйпылчыгы.
Табиблар тора чүпләп.
Әмма
Сугыш газабын кичергән
Җаннарын булмый сипләп.

Яшәгән саен йөрәктә
Укмаша олы нәфрәт,
Миллионнарның җанын кыйган
Сугышка каргыш-нәләт.

Буыннан-буынга күчә
Ватан сугышы кайгысы.
Кисәтә яңа буынны
Мәңгелек ут яктысы:
«Кешеләр, булыгыз уяу,
Булсын монсы соңгысы!»

**Флёра ТАРХАНОВА**

## Башланмасын иде набаттан

*Бөек Ватан сугышында*
*Җиңү яулаган ватандашларга*

Канлы дәһшәтләрдә жингән көннән
Дистәләгән еллар үткәндә,
Шул вәхшәтнең кара кайгысына
Уралган йомгакны сүткәндә,
Ватан өчен утка кергән яуны,
Фашистларны кырган гаярь жанны
«Очратабыз» сугыш кыры буйлап
Солдат юлын урап киткәндә.

Шул юллардан тирән яра алды,
Чит туфракта меңләп ятып калды
Илне саклап башын салганнар.
Дошманны үз оясына кертеп,
Тамырына хәтле утта өтеп,
Кайтты Ауропаны азат итеп,
Жирнең астын өскә әйләндергән
Гарасатта исән калганнар.

Җиңү яулап биргән өчен безгә —
Теләкләрнең иң изгесе Сезгә:
Яу кырында калган сәламәтлек,
Капкалардан керми узган бәхет
Кайтсын иде, кайтсын кабаттан.
Киләчәкнең туар бер көне дә,
Йолдызлы һәм айлы бер төне дә
Башланмасын иде вәхшилектән,
Башланмасын иде набаттан.

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## Мин сугышта булдым...

Мин сугышта йөрдем әткәй белән,
Әткәй белән жиңү яулаштым.
Волхов сазлыкларын кичеп чыктым,
Камалышта калып, адаштым.

Әсирлекнең тойдым ачыларын,
Юкса, каян миндә мондый моң?
Шул хакларда китап укысам да,
Шул турыда кино карасам да,
Җаным белән әрнеп елыймын.

Әткәй белән әсирлектән качтым,
Исән кайттым мин дә сугыштан.
«Мин исән!» — дип әткәй сөенгәнгә,
Мин тормышны сөйдем тумыштан.

Сугыш беткәч, Сталиннар киткәч,
Мин туганмын жиргә, мин дәвам —
Әткәйсез дә, әнкәйсез дә күптән,
Ничә үлгән, ничә яралган!

Мин сугышта йөрдем әткәй белән,
Көрәсезме, әле мин исән!
Тынычлыкка жыр-мәдхия әйтеп,
Язгы жилләр булып мин исәм.

Ленар ШӘЕХ

## Моабит

*Төнге Берлин буйлап йөргәндә, очраклы рәвештә Моабит төрмәсенә юлыктым...*

Германия. Берлин. Төн караңгы.
Урамнарда утлар яна бит!..
Үзем сизми генә янәшәңнән
Узып барам икән, Моабит.

Син һаман да төрмә.
Заманасы
Үзгәрде дип йөрим эчемнән.
Дөньясында барган сугышларны
Туктатырга килми көчемнән!..

Әй Моабит! Җәлил Моабиты!
Күңелемдә йөргән Моабит!..
Ак карларны көтәм. Алар өчен
Никтер кызыллары ява бит!..

Без очраштык. Җәлил шигырьләре
Соры диварларның исендә.
Харап булды татар егетләре...
Плетцензее... төрмә мичендә.

Хәтерлисең. Әле онытмадың.
Мөмкин түгел хәтер яңарту!..
Аң артса да, хыял үзгәрешсез –
Бер шартлаган шарны кабарту.

Бу кешелек сабак ала белми,
Сугыш арты сугыш уенда.
Җәлил дәфтәрләре йөри кебек
Йөрәк тирәсендә — куенда...

Германия. Берлин. Төн караңгы.
Болытлардан яшьләр тама бит!..
Уйларыма чумып, янәшәңнән
Узып барам икән, Моабит...

Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА

***

— Ниләр күрдең, бабай, сөйлә инде,
Ниләр булды сугыш кырында?
Башын читкә борып уйлана да
Күзен сөртеп куя учы белән...
Юк, сөйләми бабай, һич сөйләми
Оныкларга — сугыш турында.

— Ниләр күрдең, әби, сөйлә инде,
Кызык безгә сугыш еллары!
...Сөйләмәде, никтер, әбиләр дә.
Тик сорауны биргәч, дерелдәп лә
Куя торган иде куллары.

Тартмаларда ята медальләре,
Җиңү белән котлау хатлары...
Түрәләрдән килгән ул юлларны
Балачакта инде ятладык...

Ничек кенә итеп ялынсак та,
Белалмадык ниләр булганын
Утлы, канлы сугыш кырында...
Сүзләр генә җитәр булмаган шул
Сөйләр өчен чиккән газаплары,
Йөрәкләрне өткән хатирәләр,
Онытылмас сагыш турында...

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ. XXI ГАСЫРДАН КАРАШ

***Тиздән Бөек Җиңүгә 70 ел тула. Бөек Ватан сугышы — тарихыбызның иң фаҗигале вакыйгасы. 1941-1945 — үткән гасырның иң дәһшәтле еллары. Тарих фәнендә бу сугышка объектив бәя бирелдеме? Аңа карата бүгенге караш нинди? 70 ел үткәннән соң, бу коточкыч афәт турында галимнәр, язучылар ни уйлый?***

***Бөек Җиңү елъязмасын дәвам иттерү максаты белән, без аларны «Казан утлары» журналы редакциясенә — «түгәрәк өстәл»гә чакырдык. Әлеге сөйләшүдә ТР Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, тарих фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәрләре, тарих фәннәре докторлары Айсылу Кәбирова, Әлфия Галләмова, Россия Федерациясенең Хәрби-тарихи фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, эзтабарларның «Хәтер яктысы» экспедициясе җитәкчесе, «Сүз» китап нәшриятының баш мөхәррире, эзтабар-язучы Шаһинур Мостафин, язучы, галим Хәнәфи Бәдигый, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рәфикъ Юныс катнашты. Сөйләшүне «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов алып барды.***



**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Үткән сугыш тарихын өйрәнү, аны татар халкы тарихы белән бәйләп өйрәнү бүген нинди кимәлдә бара? Бу темага галимнәребезнең карашы нинди?*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ:**



— Бу сорауны ике өлешкә бүлеп була. Беренчедән, сугыш һәм сугышның тарихта тоткан урыны, аның кешелек тарихы үсешенә йогынтысы. Икенчедән, бу сугышта татар халкының катнашуы һәм татар халкының язмышына бу сугышның йогынтысы.

Бөек Ватан сугышы нинди роль алып тора соң тарихта? Без аны бүген ничек аңлыйбыз, өйрәнәбез? Бу сугыш, һичшиксез, кешелек тарихында иң дәһшәтле, киң күләмле фаҗига. Андый сугыш тарихта башка булмаган һәм булмасын. Ул дөньяны үзгәртеп җибәрде һәм бөтен дөнья язмышында үз эзен калдырды. Тарих ул — үткәннәргә әйләндерелгән сәясәт, дигән бер акыл иясе. Тарихта булган һәр вакыйга бүгенге сәясәттән, бүгенге вакыйгалардан чыгып, аларга бәйле рәвештә бәяләнә. Бөек Ватан сугышын да бүгенге вазгыять яссылыгына куеп карау зарур.

Сугыш — күпкырлы күренеш. Ул хәрби бәрелеш кенә түгел. Аның турында сөйләгәндә һәм шулай ук язганда да монысы герой, монысы куркак, монысы хыянәтче дип кенә бәя бирергә ярамый. Сугыш — хәрби бәрелеш кенә түгел, ул тормышның бөтен якларын үзгәртә. Дәүләт өчен зур сынау ул. Икътисади, сәяси, әхлакый яссылыкта яисә милли үзаң җәһәтеннән карасаң да, аларның барысына да сугышның йогынтысы гаять зур. СССР өчен ул совет халкының зур батырлык

үрнәге, хыянәтчел идеягә каршы көрәш булды. Без аны ничек кенә борып карасак та, Советлар Союзы ул вакытта үзенең яшәеше, киләчәге өчен көрәште.

Икенче Бөтендөнья сугышын Беренче Бөтендөнья сугышының дәвамы дип карарга мөмкин. Һәрхәлдә, мин аны шулай дип карау яклы. Кайбер галимнәр аны бер сугышның ике эпизоды дип карый. Мин аның белән дә килешәм.

Без сугыш турында сөйләгәндә, Советлар Союзы өчен аның унай якларын гына күрсәтергә күнеккән. Болар — батырлык, ныклык, җиңү. Әмма сугыш һәрвакыт ике яклы. Тарихчылар ике позицияне дә карарга тиешләр.

**Айсылу КӘБИРОВА:**



— Сугышка һәрвакыт хәрби бәрелеш буларак кына бәя бирелде. Тыл гел күләгәдә кала килде. Республикабыз хезмәт ияләре Җиңүгә өлеш кертмәгәнме, халкыбыз кырларда, завод-фабрикаларда көнне төнгә ялгап эшләмәгәнме?! Сугышны берьяклы гына карарга ярамый дигән фикер белән тулысынча килешәм. Без тарих фәнендә аның тулы, адекват картинасын тудырырга тиеш. Советлар Союзы вакытында безнең игътибардан читтә калган төсләр дә булырга тиеш анда. Мин, беренче чиратта, сугышның мотивлаштыру факторларын, хезмәт депрессияләрен күздә тотам. Эшкә чыкмаганы яисә хәтта соңга калганы өчен кешене 5әр елга утырткannар. Бу хакта тарих өчен, фән өчен документлар бихисап.

Без совет халкының батырлыгы, бердәмлеге турында гына сөйләдек. Төптән уйлап карасаң, төрле кешедә төрле караш булган. Коллективлаштыру, 30нчы еллардагы репрессия җилләре — берсе дә эзсез генә узмаган. Мәсәлән, яшь егет армиягә бармас өчен бер капчык бәрәңге урлый һәм үзен кулга алуларын тели. Бу турыда да архивта документ бар. Ул әһәмиятле елларда халык арасында күпме гайбәт, имеш-мимеш йөргән. Без җинелгәнбез, имеш. Мәскәү немецларга бирелгән, имеш. Мәскәү яна, имеш. Үзләренә карата тиешле органнар тарафыннан чара күрелсә дә, нахак сүз сөйләүчеләр һәрдаим очрап торган.

Сугышның тискәре яклары да, унай яклары да, әгәр шулай әйтергә ярaса, булган. Мәсәлән, ул чорда дәүләтнең дингә карашы үзгәрә, ул аның белән вакытлыча килешеп яшәргә мәҗбүр була. Дини йолалар үткәрергә рөхсәт ителә. Дингә карата мөнәсәбәт рәсми рәвештә белдерелмәсә дә, һәрхәлдә дәүләт тарафыннан тыю-чикләүләр булмый. Шулай итеп дәүләт кешедә өмет-ышаныч, патриотик рухны сакларга тырыша. Сугыш елларында милләт буларак рухи асылыбызга кайту, тамырларыбызны барлау омтылышы да була. Мәсәлән, «Идегәй» дастаны нәкъ шул чорда дөнья күрә. Моның өчен Нәкый Исәнбәт зур көч куя. Халыкта патриотик рухны күтәрү өчен дәүләт милли идеягә мөрәҗәгать итә, милли традицияләрдән файдалана. Әмма мондый мөнәсәбәт озакка бармый, 1944 елда сугышта илнең җиңәчәгенә ышаныч тугач, тагын кысәтү, ябу, тыюлар башлана. Партия Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августында кабул иткән «ТАССРда идеология эшен көчәйтү турында»гы карары нәкъ менә шушы максатны күздә тота. Моңа кадәр шушындый ук карар Белоруссия, Украинага карата кабул ителгән була. Бу җәһәттән автономияле республикалар арасында Татарстан — беренче. Аннары әлеге пычак астына Башкортстан эләгә. Халыкларны депортацияләүнең очы да шуңа барып тоташа.

Бүген тарихчылар сугыш турында сөйләгәндә, Совет заманында телгә алмаган социаль факторларга, психологиягә, кешенең дөньяга карашына игътибар бирә. Фәндә һәм әдәбиятта да Бөек Ватан сугышының аңа тәнгәл һәм тулы масштаблы картинасын тудыру өчен нәкъ менә шулар җитми. Бу җәһәттән республикабызда байтак эш-гамәлләр башкарылды. Мәсәлән, «Хәтер китабы». Татарстанның Бөек Ватан сугышында бихисап югалтуларын, Җиңүнең күпме корбаннар бәрабәренә яулап алынуын күрсәткән гаҗәеп зур, титаник хезмәт бу. Сугышны өйрәнүгә галим Искәндәр Гыйләҗев тә зур өлеш кертте. 1941-1945 елларда республикабыз кичергән югалтуларны демография күзлегеннән өйрәнү дә фәндә яңа адым. Екатерина Кривоножкина һәм Васил Сакаевларның диссертацияләре шушы темага

багышланган. Гомумән, безнең галимнәр Бөек Ватан сугышы темасын өйрәнүдә һәм яктыртуда актив эшли. Бөтенроссия, шулай ук халыкара фәнни-гамәли конференцияләрдә дә аларның хезмәтләре югары бәяләнә.

**Әлфия ГАЛЛӘМОВА:**



— Икенче Бөтендөнья сугышы — гасырларның иң зур фаҗигасе ул. Сугышны иң әүвәл кешеләр арасындагы җан өшеткеч мөнәсәбәт буларак кабул итәргә кирәк. Бүген җәмгыятьтә таза рухлы пацифизм һәм толерантлык булдыру зарур.

Дөресен әйткәндә, соңгы вакытта Бөек Ватан сугышы темасын күтәргәндә, плюрализмнан читләшү күзәтелә. Бу теманы идеальләштерә башладык. Бөек Җиңү бүгенге рухи кризис чорында патриотик тәрбия бирүдә төп ресурсларның берсе буларак карала. Сугышны идеальләштерү, аны романтизм белән бәйләп аңлату — куркыныч гамәл. Ул кешенең аңын турыдан-туры милитаризацияләүгә китерә, анда агрессивлык хисен уята.

Бөек Ватан сугышы — тарих өчен күптән түгел генә булып узган этап. Без аны үзебезчә бәялибез, әчке цензура да үзен әледән-әле сиздереп ала. Киләчәктә тарихчыларның уй-фикерләре башкача булырга мөмкин.

Тумышым белән мин Брянскидан. Бу шәһәрдә партизан хәрәкәте бик киң җәелдерелгән була. Әлеге тема белән кечкенәдән бик кызыксынып үстем. Тарихка кереп китүем дә, мөгаен, шуннандыр. Миңа сугышның тере шаһитлары белән еш аралашырга туры килде. Фрося әби белән Женя әби бар иде. Беркөнне мин аларга бер батыр партизанкага һәйкәл куюларын, шәһәр урамнарының берсенә аның исемен бирүләрен әйттем. Әбиләр сискәнеп куйды. Женя әби болай диде: «Без партизаннардан немецлардан курыккан кебек курка идек. Авылны талап, кызларны мәсхәрәләп киткән чаклары булды. Өебездә торган немец Ганс исә паёгыннан безгә дә өлеш чыгара торган иде. Бу сүзләрне ишеткәч, шок хәлендә калдым. Сугышның тере шаһитлары әйтә бит моны. Мәктәптә безгә башкача сөйләделәр. Ул вакытта мин моны беркемгә дә әйтмәдем. Авыр, бик авыр бу хакта сөйләве. Сугышта һәлак булганнар безнең нәселдә дә шактый. Немецларның кансызлыгы, вәхшилеге турында күп ишеттем, күп укыдым.

Хискә бирелү, эмоциональ киеренкелек сугыш турында чын дөресен язарга комачаулый. Мәгълүматларны — унаймы алар, тискәреме — бөртекләп җыярга кирәк.

1944 елда милли республикаларга «һөҗүм» башлануын да әйтми булмый. Хәер, ул элегрәк тә күзәтелә. 1943 елда КПСС Үзәк Комитетының идеология эшен көчәйтү турында карары бар.

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Бу — бик кызыклы һәм бәхәсле тема. Сугыш темасы, гомумән, һәрвакыт зур кызыксыну уята. Беренче Бөтендөнья сугышының 50 еллыгы уңаеннан Польша журналында XX гасырга суд оештырганнар иде. Бер караганда, канлы гасыр бит: ничәмә-ничә революция, Беренче Бөтендөнья сугышы, Икенче Бөтендөнья сугышы. Икенче яктан карасак, нәкъ шушы гасырда колонизациягә нокта куелды, икътисад үсте, кеше космоска очты, виртуаль дөнья барлыкка килде һ.б.лар. Сугыш темасы белән дә шул ук хәл: аның да плюслары, минуслары бармы?*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ:**

— Моңа өстәп бер фикер әйтәсем килә. Без тарихка бер төрле генә карыйбыз. Безгә ошаса, аны кабул итәбез, ә ошамаса, әкият итеп күз алдына китерәбез. Безнең җәмгыять тарихны нормаль күзлектән карарга әзер түгел.

Заманында 90нчы еллар башында экраннарда «Легенда о Нараяме» дигән япон фильмы барды. Ул фильмда эротик күренешләр булганга, аңа халык агылды, әмма күпләр асыл мәгънәсен аңламады. Чынлыкта, гениаль фильм иде ул. Японнар

әлеге тасмада үз тарихының төрле якларын, шул исәптән пычрагын да күреп, аның турында югары дәрәҗәдә объектив әйтә алдылар. Шунын аша чистарындылар. Бу аларның халык буларак өлгергәнлеген күрсәтте. Алар пычрак күрсәтәбез дип төшермәгәннәр ул фильмны. Бу — японнарның үз тарихы турында аек фикер йөртә алуына бер дәлил.

Без Бөек Ватан сугышы темасына һаман берьяклы карарга тырышабыз: ике төс кенә кулланабыз: монысы — ак, монысы — кара. Мин үземнең фәнни эшемә алынганда да, төрле фикерләр булды, кайбер коллегаларым сугыш тарихындагы четерекле мәсьәләләрне шулай бер якка гына авышмыйча күрсәтә алырсыңмы, дигән сораулар да куйдылар.

Без 90нчы еллар башында бер борылыш кичердек бит инде — тарихны гел икенче якка бордык та куйдык. Элек каһарман булганнар хыянәтчегә әйләнде, хыянәтчеләр каһарман булды. Ул вакытта галимнәр дә, журналистлар да рәхәтләнделәр сенсация эзләп. Объектив, адекват тарих беркемне кызыксындырмады. Андый тенденция әле хәзер дә бар.

Бәлки, әлегә безнең җәмгыять тарихны объектив кабул итәргә әзер түгелдер. Ләкин бу фәнне үстерергә кирәк. Шул вакытта гына җәмгыять тә үсә ала. 70 ел — тарих өчен аз вакыт. Без әлегә Бөек Ватан сугышын тулысынча объектив бәяләргә әзер түгел. Чөнки ул безнең өчен эмоциональ вакыйга. Без әле һаман хисләр дәрьясында.

**Шаһинур МОСТАФИН:**



— Бөек Җиңүнең 70 еллыгы якынлаша барган бу көннәрдә уйланам, кат-кат уйланам... Сугыш «тегермәне» бик аяусыз булган бит! 1418 көн вә төн дәвам иткән дәһшәтле чорда 29 миллион 592 мең 749 кешенең гомере өзелгән. Димәк, һәр тәүлектә уртача 20 мең 896 кешенең җаны кыелган...

Шунысын да искәртеп үтим: әлеге коточкыч саннарны, күңелләрне сискәндерә-тетрәндерә торган фактларны мин Россия Федерациясенең Оборона министрлыгы Үзәк архивы (Мәскәү өлкәсе, Подольск шәһәре) китапханәсендәге «Гриф секретности снят» *(Мәскәү, Воениздат, 1993)*, «Россия и СССР в войнах XX века. Книга потерь» *(Мәскәү, «Вече» нәшрият йорты, 2010)* дигән китаплар аша белдем. Генерал-полковник Григорий Федотович Кривошеев җитәкчелегендә, Россия Федерациясе Хәрби Көчләре Генеральный штабы һәм Хәрби-мемориаль үзәк хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән бәһа биргесез әлеге җитди, фәнни-документаль хезмәтләр сугыш чоры тарихы белән тирәнтен кызыксынучы һәр кеше өчен бик тә кыйммәтле, чын дөреслекне ачыклаучы төп чыганаклардан саналалар.

Тик шулай да, үткән сугыш корбаннарына килсәк, бу өлкәдә серлелек пәрдәсе тулысынча ачылмаган әле. Иосиф Виссарионович Сталин 1946 елда, мәсәлән, «Правда» газетасы хәбәрчесенә биргән интервьюсында: «...немецлар белән сугыш вакытында, оккупация чорында һәм немец каторгасында Советлар Союзы үзенең җиде миллионга якын кешесен югалтты», — дип белдерә... Никита Сергеевич Хрущёв исә 1961 елда Швеция премьер-министры Эрландерга җибәргән хатында Бөек Ватан сугышы чорында һәлак булучыларның санын егерме миллион итеп күрсәтә... 1990 елда — Михаил Сергеевич Горбачёв җитәкчелек иткән чорда — бу сан егерме җиде миллионга җитте...

Чит ил тикшеренүчеләренең әлеге мәсьәләгә карата үз карашлары бар. Әйтик, америкалы социолог Н.Тимашевның 1948 елда ук игълан ителгән белдерүеннән күренгәнчә, СССР әлеге сугыш вакытында утыз җиде миллион ярым кешесен югалткан булып чыга. *(«Родина» журналы, 1991 ел, 6-7 кушма сан, 139нчы бит.)*

«Икенче Бөтендөнья сугышында күпме татар һәлак булган?» дигән урынлы-мөһим сорау да туарга мөмкин.

Заманында фашистлар «тырнагы»на эләгеп, әсирлекнең бөтен газапларын татыган һәм соныннан, концлагерьдан качып, үзебезнекеләргә килеп кушылган

туры-гадел сүзле солдат-әдип-рәссам Нәби ага Дәүли бу хакта болай дигән иде:

— Өч татарның икесе үлде. Ул чакта татар дүрт миллион ярым исәпләнә иде, кимендә ике миллион татар кырылды...

Ләкин Нәби ага ялгыша кебек. Сугышка кадәр татар кимендә ун миллион булган, дигән фикер көннән-көн ныгый бара. Һәр татар авылы уртасындагы дүрт кырлы ташка уелган дүртәр-бишәр йөз кеше исемлегеннән чамалап, Урал, Себер, Урта Азия, Кырым, Татарстан, Россиядән китеп һәлак булганнарның саны биш миллионлап булырга мөмкин. Ягъни, татар ирләренең житмеш-сиксән проценты һәлак булган, дигән сүз бу...

Әйе, сугышта үлгәннәрнең саны һаман да төгәл билгеле түгел әле. Ул каһарманнарның байтагы, үзләренең җәсәдләрен җир куенына индергәнне көтеп, дистәләрчә еллар дәвамында һаман ачык һавада, жил-янгыр, кар-буран астында ята бирә...

**Рәфикъ ЮНЫС:**

— Бу «түгәрәк өстәл»дә тагын бер галим катнаша дип исәпли алабыз: Мәхмүт Гәрәев. Ул — Россия Хәрби Фәннәр академиясе президенты, СССР Кораллы көчләре Генераль штабы башлыгы урынбасары булган кеше, армия генералы. Менә бу китабымда *(Татар гаме. Татар.кит.нәшр., 2013) (күтәреп күрсәтә)* аның белән әңгәмәбез дә бар. «Сугыш корбаннары күпме сон? Кайберәүләр илле миллионга житкерәләр бугай инде», — дигән соравыма ул болай дип җавап бирде: — Әйе, ахмак бер ярыш бара. Күбрәк сан уйлап чыгарыштан. Бу хакта сөйләргә хакым бар, чөнки заманында хәрби югалтуларыбызны исәпләү комиссиясенең рәисе булган идем. Фронттан алынган бөтен донесениеләрне дә җентекләп тикшердек. Бары 1941 ел буенча гына төгәл мәгълүматлар юк иде, чөнки сугыш башында күп кенә штаблар тар-мар ителгән. Шуңа да карамастан, дивизияләрдә башта күпме кеше булганын, аннан күпме өстәмә җибәрелгәнен һ.б. төрле мәгълүматларны янәшә куйгач, очына чыга алдык. Ватан сугышында безнең Кораллы Көчләребез 8 миллион 405 мең кешесен җуйган. Мона керә: һәлак булучылар, яралардан яки башкача үлүчеләр, хәбәрсез югалучылар, әсирлектән кайтмаучылар. (Тулы югалтулар, тыныч халыкны да кертеп — 27 миллион.) Мона тагын берлектәшләребез — поляк, чехословак, болгар һ.б. сугышчылар арасындагы югалтуларны да өстәргә кирәк — монысы 195 мең. Җәмгысы 8 миллион 600 мең була. Германия армиясе исә 5,5 миллион кешесен, берлектәшләре — финнар, венгрлар һ.б. — 1,2 миллион кешесен җуйган, җәмгысы — 6,7 миллион. Әйе, безнең югалтулар күбрәк. Әмма менә бу саннарга да игътибар итик. Немецлар үзләре үк биш миллион кешегезне әсир иттек дип язалар. Шунын 2 миллионы гына кире кайтарылды. Калганнары, димәк, үлгән һәм юк ителгән. Без исә, 2,5 миллион әсир алып, ике миллионын кире бирдек. Менә шунын исәбенә ул аерма!

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Минем әткәй сугышта ике аягын калдырып кайтты. Бабам — сугышта һәлак булган. Әткәйнең бертуган абыйсы хәбәрсез югалды. Әткәй аны эзләтеп кайларга гына мөрәҗәгать итмәде. Тик нәтиҗәсе булмады.*

*Хәбәрсез югалганнар бик күп. Кайда булулары ачыкланмаган шәхесләр бик күп. Аларны оныклары, оныкларының оныклары эзли, кызыксына. Бу мәсьәләгә карашыгыз нинди?*

**Айсылу КӘБИРОВА:**

— Бу мәсьәлә бүген аерым энтузиастлар кулында. Мисал өчен, Михаил Черепанов. Кайда гына чыгыш ясамасын, ул бер бик мөһим мәсьәләне күтәрә. Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалганнар булырга тиеш түгел, ди. «Компромат» юк икән, алар һәлак булганнар исемлегенә кертелергә тиеш. Европа илләрендә бу эш эшләнде. Бу мәсьәлә дәүләт дәрәҗәсендә хәл ителергә тиеш. Бүгенге көнгә Татарстанда хәбәрсез югалган 190 мең кеше исәпләнә. Шунын 22 меңе — Казаннан.

**Шаһинур МОСТАФИН:**

— Уйландыра торган фаҗига бу. Ә бит мәшһүр генералиссимус Суворов: «Яу кырында үлгәннәрнең соңгысы күмелмичә торып, сугышны беткән дип санарга

ярамый», — дигән үтә хикмәтле сүзләр әйтеп калдырган. Димәк, сугыш әле һаман да дәвам итә!..

Безгә батырларыбызны барларга, санларга, данларга вакыт!..

Шулай да... Сугышта һәлак булганнарны барлау йөзеннән, махсус эзләнү экспедицияләре оештыру, күп төбәкләрдә «Хәтер китабы» чыгарылу, партизаннар хәрәкәтендә, дошманга каршы яшерен оешмалар эшчәнлегендә катнашучылар, шулай ук әсирлектә булган, коллыкка куылган кешеләр турында яңа мәгълүматлар табылу, мәңге кереп булмастай тоелган серле архив ишекләренең ачылуы көнелләрдә якты өметләр уята. Һәлак булганнар һәм чын батырлар турында Галиҗәнап Вакыт үз сүзен өздереп әйтәчәк әле!..

Бөек Ватан сугышы елларында яу кырында, дошман тылында, диңгездә һәм күктә тиңдәшсез фидакарьлек үрнәкләре күрсәткән 11 мең 633 кешегә Советлар Союзы Герое дигән олы исем бирелә. Алтын Йолдызга ия булучылар арасында Татарстан уллары һәм кызлары да йөзәрләп санала.

Аларның тиңдәшсез, какшамас рухи ныклыгын, кыюлыгын-чыдамлыгын, Ватанга чиксез бирелгәнлеген күренекле хәрби эшлеклеләр дә югары бәяләделәр. Шулар арасыннан берничәсенең фикерләре белән танышып китик:

Советлар Союзы Маршалы Иван Степанович Конев: «...Татарстанда туган егетләр... арысланнар кебек сугышалар».

Советлар Союзы Маршалы Родион Яковлевич Малиновский: «...Мин, карт солдат буларак, сугыш кырларында татар сугышчыларын һәм офицерларын күп күрдем, һәм аларның сугышта какшамас ныклык күрсәтүләренә һәм корыч ихтыярларына һәрвакыт сокланып киләм. Советлар Союзының бәйсезлеге өчен алып барыла торган бөек көрәштә татар халкы үзенең сугыш эшендә чыдам һәм батыр йөрәкле солдатлары белән бөтен армиябез каршында хөрмәт казанды».

Советлар Союзы Маршалы Леонид Александрович Говоров: «...Татар солдатларының сугышчан әзерлекләре иң югары бәягә лаеклы... Алар сугыш кырларында татар халкының иң яхшы сыйфатларын — Ватанга чиксез бирелгәнлек, дошманга аяусыз нәфрәт, җиңү бәрабәренә үлемнән курыкмау, батырлык, кыюлык, чыдамлык һәм теләсә нинди шартларга да түзү сыйфатларын гәүдәләндерәләр. Татар сугышчылары Ватан алдындагы хәрби бурычларын намус белән үтиләр...»

Менә шушындый сүзләрдән соң, бирeдә каршы якның фикерләрен турыдан-туры гәүдәләндерүче гап-гади немец ефрейторы Рудольф Вольтангның үзенең якыннарына язган хатыннан ике җөмлә китереп үтәсем килә: «Монда безгә каршы бик күп татарлар сугыша. Мин хәтта төшемдә дә татар белән очрашмаска теләр идем...» *(«Батырлар китабы», Казан, Татар. кит. нәшр., 1945 ел, 13, 21, 22, 26нчы битләр.)*

Инде белгәнебезчә, татар каһарманнары сугышның иң хәтәр урыннарында булганнар. Сугышның иң хәлиткеч операцияләрендә дә татар хәрби командирлары күпләп катнашкан.

Баярак телгә алынган «Книга потерь» *(М., 2010)* дигән китаптагы мәгълүматларга караганда, сугыш чорында әсирлеккә эләккән татарларның саны нибары 2,2 процент кына булган икән (501нче бит).

Шушы фактлар үзләре үк безнең милләттәшләребезнең яу кырында, чыннан да, «арысланнар кебек сугышуларын» ышандырырлык итеп раслыйлар. Әсирлеккә дә алар үз теләкләре белән төшмәгәннәр. «Тәмуг оясы»нда да сынатмаганнар. Әйтик, Советлар Союзы Геройларыннан Моабит төрмәсе тоткыны — легендар шагыйрь Муса Җәлил, Брест крепосте каһарманы Пётр Гаврилов (керәшен татары), Ровно өлкәсе партизаннар берләшмәсенең шартлату төркеме командиры Николай Орлов (чын исеме — Гатаулла Минаев) иң авыр чакларда да коелып-югалып калмаулары белән бик күпләрне сокландырганнар. Аларның һәркайсы әсирлек газапларын татыган, әмма рухлары белән искиткеч көчле шәхесләр булып калганнар!

Әлеге каһарманнар — чын мәгънәсендә халкыбызның зур горурлыгы, рухи ныклыгы-мактанычы. Еллар үткән саен, шундый батырларның фидакарьлеге белән кызыксыну үсә-көчәя бара...

**Рәфикъ ЮНЫС:**

— Янә Мәхмүт Гәрәевкә сүз бирик әле.

— Сугыш вакытында татар кешесе батыр булган дигән сүз дөрес. Сугыш вакытында йөзгә кызыллык китергән бер генә татар кешесен дә очраткан булмады. Бөек Ватан сугышында иң күп Советлар Союзы Геройлары да, орден-медальләр белән бүләкләнүчеләр дә, иң күп яралanучылар, үлүчеләр дә — татарлар (халык саныннан процентлар белән чыгарганда).

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Бу чыннан да шулай. Татарлар гына түгел, башка халыклар да зур батырлыклар кылган. Мисал өчен, күптән түгел Ингушетия Республикасында булдык. Анда бу халыкның Бөек Ватан сугышында зур батырлыгын күрсәтә торган вакыйгалар турында ишетеп кайттык. Гыйбрәтле вакыйгалар! Таулыларның кыргый кавалерия дивизияләрен танк дивизиясенә каршы җибәрәләр. Алар барысы да кырылып бетә. Шуңа бәйләп минем сездән тарихта шәхеснең роле турында ишетәсем килә. Бу хакта ни уйлыйсыз? Безнең сугышка әзерлексез керүебез, беренче мәлләрдәге зур корбаннар, югалтулар өчен бердәнбер гаепле Сталинмы?*

**Айсылу КӘБИРОВА:**

— Сталин сугышка 1928 елдан бирле әзерләнә. Дошманның СССРга 1941 елның 22 июнендә бәреп керүе фактик яктан караганда дөрес. Чынлыкта агрессия күптәннән килә. Сугыш көтмәгәндә башланды, дип әйтү дөрес түгел. Дәүләтебез кылган гамәлләре белән бу сугышка башын үзе тыга. СССРда кешене, кеше гомерен кайгырту мәсьәләсенә җинел карыйлар. ГУЛАГ, репрессияләр — моның ачык дәлиле. Сталин кешеләргә арзанлы ресурс итеп карый. Гаугалы тарихчы Панасенков искәрткәнчә, СССР территориясендә сугышның беренче корбаннары — үзебезнең гаскәрләр эше, чөнки дошман һөҗүм ясауга, безнекеләр безнекеләрне — чик буенда репрессиягә дучар булганнарны ата башлый.



**Хәнәфи БӘДИГЫЙ:**

— Сугыш башлану мәсьәләсендә, миңа калса, идеологик каршылык ята. Советлар Союзында — репрессия. Германиядә — яһүдләрне эзәрлекләү. Советлар Союзында символ — Кызыл Йолдыз, Германиядә — фашистик свастика. Ике идеология бәрелеште.

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Хәзер элеккеге Совет илләренең кайберләрендә Бөек Ватан сугышы белән бәйле тарихны юкка чыгару бара. Һәйкәлләрне сүтәләр, дәреслекләрне үзгәртәләр. Польшадагы, Украинадагы хәлләрне ишетеп, күреп торабыз... Әллә безнең ил аларны фашизмнан азат итүче түгелме?*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ:**

— СССР фашизмны җиңүдә төп рольне уйнады. Бу бәхәссез! Шул ук вакытта Германияне җиңгәннән соң, Совет хөкүмәте немец оккупациясеннән котылган илләргә нәрсә бирде соң? Азатлык, ирек түгел, ә яңа режим. Совет режимы. Моның белән канәгать булу мөмкин түгел. Шуңа күрә мин бүген һәйкәлләрне сүтүгә тарихка, сугышка ревизия дип түгел, ә сугыштан соң булган хәлләргә, вакыйгаларга ревизия дип карыйм.

**Хәнәфи БӘДИГЫЙ:**

— Бүген сугыш һәм тыл ветераннары аз калып барса да, сугыш чоры балалары күп әле. Мин үзем дә шулар рәтенә керәм. Шул мохиттә үстек без. Сугыш вакытында тылдагы тормышның нинди булуын мин яхшы беләм. Хәерчелектә, коточкыч хәлдә яшәде халык. Бүгенге сөйләшүдә шуны искәрдем: сезнең — галимнәрнең тарихка булган мөнәсәбәтегез үзенчәлекле. Ул телевидение аша күрсәтелгән әңгәмәләрдән нык аерыла. Безнең сөйләшүдә шовинизм юк.

Әйе, бүген илдә Бөек Ватан сугышын идеаллаштыру тенденциясе күзәтелә. Чынлыкта исә әлеге сугыш гади халыкның үзен саклап калу өчен көрәшкә күтәрелүе иде. Халык үзен, гаиләсен саклап калу өчен көрәште. Моны геройлык итеп карау дөрестер.

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Кайчандыр фронтовик язучы Григорий Бакланов: «Сугыш турында әлегәчә «окоп дөреслеге» язылмаган», — дигән иде. Сугыш вакыйгаларын чагылдырган әдәби әсәрләрдән кайсыларын аерып атый алыр идегез?*

**Хәнәфи БӘДИГЫЙ:**

— Шәйхи Маннурның «Муса» романын аерып әйтер идем. Муса Җәлил поэзиясен тагын. Әмма сугыштан соң Совет власте чорында язылган әсәрләргә идеология йогынтысы бик көчле була. Алар Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына объектив бәя бирә ала дип әйтмәс идем. Сугышны дөрес яктырткан әдәби әсәрләр безгә бик кирәк әле.

**Шаһинур МОСТАФИН:**

— 1961 ел башыннан безнең татар балалары өчен «Яшь ленинчы» газетасы янадан чыга башлады (дәһшәтле сугыш елларында ул вакытлыча туктап торган булган). Шул елның февралендә легендар патриот шагыйребез — Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең 55 еллыгын зурлап билгеләп үттеләр. Шул уңайдан яраткан газетабызда әлеге горур шәхескә багышланган матур-мәгънәле сәхифәләр чыкты. Укучы балаларның да каһарман әдипкә багышланган шигырьләре басылды. Шуннан соң үзем дә 1961 елның 20 февралендә «Муса Җәлилгә» дигән беренче шигыремне язып, «Яшь ленинчы»га җибәрдем. Тора-бара хикәяләр, пьесалар да яза башладым. Әнә шулай, олуг әдәбият дөньясына кереп киткәнемне сизми дә калдым. Шуңа күрә мин гомерем буена Муса Җәлилгә һәм тагын Габдрахман Әпсәләмов дигән искитмәле әдипкә бурычлымын. Габдрахман аганың «Ак төннәр», «Алтын йолдыз», «Газинур» исемле китаплары минем тормышымда зур роль уйнады. Г.Әпсәләмов сурәтләгән Карелия төбәгенә дүрт мәртәбә махсус экспедицияләр оештырып, моңарчы билгесез булган каһарманнарны эзләп таптык, аларга һәйкәлләр куйдык, данлы исемнәрен шәһәр-авыл урамнарына бирдек.

Яраткан язучыларымнан-остазларымнан Ләбибә Ихсанованы, Самат Шакир, Шамил Рәкыйпов, Рафаэль Мостафинны, талантлы шагыйрьләребез Шәүкәт Галиев белән Илдар Юзеевны бик сагынып һәм яратып искә алам.

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ:**

— Шамил Рәкыйповның язмаларын искә алыр идем. Әмма мин соңгы 20 елда сугыш турында язылган әдәби әсәрләрне укымаска тырышам. Шулай да сугыш турында иң шәп язылган, гениаль әсәр дип мин Ремаркның «На западном фронте без перемен»ын атар идем. Анда турыдан-туры сугыш бәрелешләре юк та шикелле, анда кеше язмышы тасвирлана. Сугышның афәтен кеше язмышы аша күрсәтә әлеге әсәр.

Тарихка багышлап язылган әдәби әсәр — ул әсәр язылган чорның чагылышы. Ул шул чорның сәясәте, психологиясе белән бәйле. Ул сугышны өйрәнү өчен түгел, ә әсәр язылган чорны өйрәнү өчен мөһим.

**Әлфия ГАЛЛӘМОВА:**

— Заманында миңа Борис Васильевның «А зори здесь тихие» әсәре ошаган иде. Хәзер аның да сугышны мифлаштыруга нигезләнгән булуын аңладым.

**Айсылу КӘБИРОВА:**

— Мәктәптә укыганда, Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» дигән әсәре нык тәэсир итте. Гомәр Бәшировның сугыш чорын чагылдырган «Намус» романында тормышны объектив чагылдырырга омтылыш сизелә. Тик менә тарих үзе дә мифларга таяна шул.

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Әдәби әсәрләрдә тарихка, тарихи вакыйгаларга таяну ни дәрәҗәдә булырга тиеш?*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ:**

— Биредә төп мәсьәлә — җаваплылык һәм объективлык мәсьәләсе. Язучы ничек һәм нәрсәгә нигезләнеп яза бит әле. Генерал сугыш вакыйгалары турында бер төрле яза, солдат бөтенләй икенче төрле. Журналист боларның икесенекенә дә охшамаган фикер язарга мөмкин. Бу җаваплы эш. Шуңа күрә тарихи темага иҗат итүче язучы әзерлекле, фикерле булырга тиеш.

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Тарихчы яки язучы буларак, бүген ни турында укырга теләр идегез?*

**Әлфия ГАЛЛӘМОВА:**

— Сугыш турында язарга кирәк. Кешенең әйтер сүзе бар икән — әйтсен. Тик ул аны ничек итеп әйтә бит әле. Менә шунда хикмәт. Беренчедән, иҗат кешесенең таланты булырга тиеш. Икенчедән, ул сәяси амбицияләрдән өстен булсын, конъюнктурага бирешмәсен, әсәрне идеологизацияләүдән читтә торсын иде. Эчке һәм тышкы цензура аңа комачауламасын.

Батырлык турында да, батырлар турында да язарга кирәк. Бигрәк тә милли каһарманнарыбыз турында. Үзебезнең кече Ватаныбыз, якташлар сурәтләнсен иде әсәрләрдә. Әйе, вакыйгаларга объектив бәя бирергә, дөресен язу зарур.

Ветераннар белән очрашканда, әңгәмәләр корганда, шуны искәргәнем бар: теге яки бу бәрелеш, хәрби операция турында сөйләүдән бигрәк, алар күп чакрымнарга сузылган кичү-походларны, салкыннан газап чигүләрен, үлгән ат итен үзара бүлешүләрен, пуля астында немецларның күктән, самолёттан үз солдатларына дип аткан азык-төлекне эләктерергә тырышуларын, мәетләрне өеп ышык урын хәстәрләүләрен искә ала.

Сугыш — гайре-табигый күренеш, кешедә агрессивлык уяту. Ул — коточкыч хәл. Яшь буын менә шуны аңлап үссен иде.

Сугыш турында сөйләгәндә, елмаеп-көлеп искә алырлык мисаллар да булырга мөмкин. Мәсәлән, танышым фронтовик Әмиржан ага Германиянең үзендә матур тәэсирләр калдыруын сөйли. «Сугыштан кайткач, коймабызны буядым. Немецлардан күреп кайттым», — ди ул. Тагын әле Әмиржан ага Берлинда тешләрен алдырып, коронка куйдыра. Шул коронка 58 ел тора. Әсирлеккә эләккән совет солдатлары белән немец хатын-кызлары арасындагы мәхәббәт романнарын кая куясың? Чиста-саф хис белән, ихластан гашыйк булучылар аз булганмы?! Сугыш турында язарга алынгансың икән, иң элек аны сәяси структураларның үзара бәрелеше итеп карарга кирәк. Сугыш кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр арасында чик куймый.

Тылдагы авырлыклар турында бүгенге сөйләшүдә әйтелде инде. 50 еллык педагогик стажы булган бер укытучының сүзләрен онытa алмыйм. «Сугыш елларында тылда без күргәннәрнең иң яманы ни булганын беләсеңме? — диде ул, авыр сулап, — Юк, ачлык та, ялангачлык та түгел. Салкын мәктәпләрдә каз каурые белән газета поляларына язып азапланулар да түгел. Иң яманы — халыктан фронт өчен кирәк-ярак җыю иде. Җыймас идең, безне мәҗбүр итәләр. Комсомоллар, агитаторлар, имеш. Алты баласы белән өйдә ач утырган бер ананың соңгы бәрәңгесен тартып алгач, күзендәге нәфрәтне күрсәң. Юк, ул карашны мин мәңге оныта алмыйм». Менә шулай дип сөйләде чал чәчле мөгаллимә.

Яшәүнең, сынауларның соңгы чигенә килеп терәлгән кеше образы. Әдәбиятта шуны күрсәтәсе иде.

**Айсылу КӘБИРОВА:**

— Архивларда утырганда, колхоз рәисләренең үз-үзенә кул салулары турындагы документларга да юлыктым. Үлемнең мондый юлын сайларга аларны кем мәҗбүр иткән соң? Хәлбуки, өй саен кереп, дәүләткә бирер өчен авылдашларының соңгы ипиен алып чыгып китәргә, ризыкны авызларыннан өзеп алырга аның кулы бармый. Бу эшне партия органнары нык контрольдә тота, аннары халык азык-төлекне

үзе теләп бирә, диләр. Моңа охшаш фактлар турындагы материалларны бергә туплау мәсьәләсен Әлфия Галләмова 90нчы елларда ук күтәргән иде инде. Хәзер бу максатта мәктәпләрдә, югары уку йортларында бик күп эш-гамәлләр башкарыла. Сугыш турында һәркем үзенчә яза. Фактлар уңаймы, тискәреме, безгә аларның бөтенесен бергә туплап, мәгълүматлар банкы булдыру зарур. Киләчәк буыннар тарихчыларына бер таяныч булыр иде ул. Бу җәһәттән безнең архив идарәсе зур эш башкара. Совет чорында сугыш турында ике генә җыентык чыкты. Аның берсе — «Татарская АССР в годы Великой Отечественной войны» (1948), икенчесе — «Татария в период Великой Отечественной войны» (1963). 2004 елда «Татарстан один из арсеналов победы в Великой Отечественной войне» китабы дөнья күрде. Анда республикабыздагы оборона предприятиеләренең эшчәнлеге яктыртыла. Элек бу тема күләгәдә кала килде, чөнки бу хакта язарга ярамый иде. Без күпме самолёт эшләп чыгарылганын гына белә алдык. Предприятиеләр ничек, нинди шартларда эшләгән? Бу хакта язмадылар. 2009 елда — «Татарстан — Сталинграду» дип аталган документлар җыентыгы, 2010 елда — «Письма с фронта» (анда язучыларның да хатлары бар), 2011 елда — «Страницы социальной истории Татарстана в годы Великой Отечественной войны» (бу китапның төзүчесе буларак шуны әйтә алам: анда республикабыздагы иҗтимагый-сәяси, шулай ук криминаль хәлгә бәя бирелә, хезмәт фронты да, балалар тормышы да яктыртыла), 2012 елда — татар халкының татар фронтовикларына язган хаты һәм аңа җавап, 2013 елда «Дети в эвакуации», басылып чыкты. Күптән түгел типографиягә «Сборник дневников и воспоминаний» тапшырылды. Күргәнегезчә, ел саен бер китап!

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Илкүләм, дөньякүләм пацифизмга ничек ирешә алырбыз икән?*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ:**

— Моңа ирешү бик авыр булачак. Тарихыбыз, җәмгыятебез шундый ки, пацифизм дигән күренешне куркаклык, нииндидер тискәре күренеш дип кабул итә. Бер яктан караганда, моны аңлап була. Ләкин кешене пацифизм рухында ничек тәрбияләргә, кирәкме ул безнең җәмгыятькә, нәтиҗә бирерме? Болар бик катлаулы сораулар.

**Хәнәфи БӘДИГЫЙ:**

— Сугышка карата нәфрәт булырга тиеш.

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ:**

— Сугышка карата нәфрәт бездә тәрбияләнми, киресенчә, «героизация» бара.

**Илфак ИБРАҺИМОВ:**

*— Сугыш темасы — бик олы тема, шактый куркыныч тема. Сугыш турында язмаган язучы юктыр да. Без әлегәчә журналда фронтовикларның хатларына зур урын бирдек. «Казан утлары» язучылар өчен дә, тарихчылар өчен дә бер мәйдан булыр!..*

**Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

***Габдрахман Әпсәләмов:***

*— Мин журналга Бөек Ватан сугышы алдыннан килдем һәм аның аппаратында эшли башладым. Журналны халык никадәр ратканын сугыш елларында үз күзем белән күрдем. Бу хакта фронттан кайткач, «Кызыл Татарстан»[1] газетасында «Совет әдәбияты»[2] журналы турында «Солдат хатлары» дигән мәкалә дә бастырган идем. Гаҗәп ул хатлар!*

1972

# «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ» ЖУРНАЛЫ ТУРЫНДА СОЛДАТ ХАТЛАРЫ

Фронт газеталарында эшләгән вакытта безнең кечкенә генә көтепханәбез бар иде. Ул көтепханәнең төп байлыгы — «Совет әдәбияты» журналының сугыш елларында чыгып килә торган номерларыннан гыйбарәт иде.

Алгы кырыйда матур әдәбиятка мохтаҗлык гаять зур булганлыктан, без, хәрби корреспондентлар, командировкаларга чыккан чагында һәрвакыт, сугышчыларга кыйммәтле бер бүләк итеп, кыр сумкаларыбызга «Совет әдәбияты» журналын сала идек һәм аны туктаган бер частьта башыннан ахырына кадәр укып китә торган идек. Шуның белән бергә үзебезнең хәрби хәбәрчеләребезгә, агитаторларга, офицерларга һәм сугышчыларга журналны почта аркылы җибәреп торуны да оештырдык. Мондый вакытларда без редакция исеменнән сугышчы иптәшләргә: «Журналны укып чыккач, ротагыздагы яисә батальоныгыздагы бүтән иптәшләргә дә укырга бирегез. Ә барыгыз да укып чыккач, үзегезгә нинди әсәрләр ошавын язып, журналны яңадан безгә кайтарыгыз, ә без сезгә яңаларын җибәрербез», дип хат та яза торган идек.

Айлар, еллар үткән саен, безнең көтепханәбез журналның яңа чыккан номерлары исәбенә баеганнан байый барды. Фронтка «Совет әдәбияты»ның яңа номеры килүе редакциядә эшләүчеләр өчен генә түгел, фронттагы татар сугышчыларының зур өлеше өчен дә бәйрәм була торган иде. Карелия урманнарында да, салкын Заполярье тауларында да, Норвегиядә дә, соңыннан Маньчжурия кырларында һәм Харбин йортларында да татар совет сугышчылары «Совет әдәбияты»н сөеп, яратып укыдылар. Менә аларның үз хатлары шаһит. Ул хатларның күбесе минем исемгә яисә редакциянең бүтән работниклары исеменә килделәр. Ефрейтор Әхмәтша Әһлетдинов иптәш болай дип яза:

*«...Вә һәм дә шул да мәгълүм булсын: җибәрелмеш журналыгызны алдым. Без аны татар уллары бергә җыелышып коптилка яктысында, коптилканың мае беткәч, чыра яктысында укыдык. Бездә, Заполярьеда, хәзер көн бөтенләй булмый бит. Шуңа күрә гел ут ягарга туры килә. Безнең күңелебезгә Нәкый Исәнбәтов иптәшнең «Мәрьям» дигән әсәре бик ошады. Түлке аның ахыры юк. Сез ул пьесаның ахыры басылган журналны да безгә табып җибәрсә идегез. Безнең яшьрәк егетләрнең кайберләре Мәрьямгә гашыйк та булдылар. Хат язарга адресы юкмы дип тә сорыйлар. Мин Мәрьям живой кеше түгел, литературада гына икәнен аңлаттым. Безнең бер сугышчыбыз миңа ышанмады, живой булмаган кешеләр турында язарга писательләр җүләр түгел, ди. Син Мәрьямнең адресын безгә бирмәс өчен генә әйтәсең, ди...»*

Ефрейтор Габдерәхим Сафин иптәшнең алгы кырыйдан язылган хатында да шушындый кызыклы юллар бар:

*«...Безнең частьта татар, башкорт, казах һәм үзбәк сугышчылары өчен аерым политзанятиеләр үткәрелә, җитәкчебез өлкән лейтенант Фәсхетдинов «Совет әдәбияты» журналыннан «Икенче гомер» дигән бер хикәя укыды. Бу хикәя безне бик дулкынландырды. Гарифуллин Вакыйф иптәшнең яралары өчен үч алырга булдык. Бер атна эчендә безнең снайперлар группасы унбиш финны үтерде».* Журналда һәрвакыт басылып килүче Фатих Хөсни иптәшнең кызыклы хикәяләре, Атилла Расих иптәшнең сугыш хикәяләре, Кави Нәҗми иптәшнең «Фәридә»се, Мирсәй Әмир иптәшнең «Миңлекамал»ы турында укучылардан бик күп җылы хатлар килеп торды. Алар бу пьесаларның сәхнәгә куелу-куелмаулары белән, «Фәридә»нең музыкасын кем язуы белән, андагы арияләрнең көйләрен ничек белергә мөмкинлек барлыгы белән кызыксындылар.

[1] «Кызыл Татарстан» — хәзерге «Ватаным Татарстан».
[2] 1933-1965 елларда «Казан утлары» шушы исем белән чыккан. *Ред.*

Күп кенә хатларда: *«Г.Разин[3] иптәш үзенең «Намус»ын язып бетермәдеме әле? Кайчан бетерә? «Намус»тан бирелә торган өзекләр безнең йөрәкләрне генә жилкендерәләр... Без ул повестьны тулысынча укыйсыбыз килә»,* — дигән юллар кабатлана иде.

Житди мәсьәләләр, тәнкыйтьләр, хикәяләр белән беррәттән, сугышчылар журналдан ял иттерә, күңелне күтәрә торган әйберләр дә эзлиләр иде. Мәсәлән, Мирсәй Әмирнең «Мөстәкыйм карт йокысы» дигән юмористик хикәясе, Әнәс Камалның «Беренче апрель» дигән пьесасы сугышчылар арасында бик популяр булып, телдән-телгә сөйләнә башладылар.

«Совет әдәбияты»нда урнаштырылган шигырьләр, аеруча Фатих Кәрим, Әхмәт Ерикәй шигырьләре сугышчылар тарафыннан сөелеп укылдылар, сөйгән кызларына, әти-әниләренә җибәрер өчен күчереп алындылар. Менә сержант Зариф Хөснуллинның хаты. Ул аны Рыбачий ярыматавыннан яза:

*«Фатих Кәримнең шигырьләрен укый башласам, аерыла алмыйм. Аның әйткәннәре йөрәккә шулкадәр якын, аның хисләре шулкадәр безнекечә, әйтерсең ул безнең арада торып яза. Дөрестерме, юктырмы, ул үзе дә безнең кебек солдат диләр. Адресы булса, зинһар, җибәрегез, без аңа күмәкләшеп хат язар идек һәм кызылармеецлар рәхмәтен әйтер идек.*

*Бүген мин дәфтәрем тулганчы аның шигырьләрен күчереп утырдым...»*

Кардәш Карелияне немец һәм фин баскыннарыннан азат иткән вакытта безнең бер укчы бригадабыз дошман тылына десант итеп төшерелде. Свирь операциясе тәмам булгангача диярлек бу бригада өзлексез сугышлар алып барды. Аның белән бәйләнеш бары тик радио һәм авиация ярдәмендә генә булды. Газета һәм журналларны да аларга самолёттан гына ташладылар. Менә шушы бригадада хезмәт итүче старшина Мөхетдин Галләмовтан мин түбәндәге хатны алдым.

*«...Кәефебез яхшы. Финнарның котларын алып, урманнарны айкап йөрибез. Бүген самолёттан почта ташладылар. Бәхетсезлеккә каршы, капчык суга төште, — биредә атлаган саен күлләр йә сазлар бит. Юеш капчыктан минем исемгә сез җибәргән «Совет әдәбияты» журналы килеп чыкты. Мин аның һәрбер битен учак җылысында киптереп чыктым, аннары иптәшләр белән бергә җыелышып укый башладык.*

*Бу номерда сөекле шагыйребез Габдулла Тукай турында күп язганнар. Шушындый ерак җиргә Тукайның килеп җитүенә без чиксез шатландык. Аның турындагы мәкаләләрне, аның шигырьләрен без бик яратып укыдык. Иптәшләр журналны чыгаручыларга да, журналга язучыларга да, аны безгә җибәрүчеләргә дә зур рәхмәтләр әйтергә куштылар».*

Менә тагын бер хат.

*«Редакциядә эшләүче иптәшләр!*

*Бу хатны сезгә таныш булмаган кавалер орден Славы ефрейтор Шәйхетдин Хәбибрахманов яза. Мин Дальный Востокка килгәнче Восточный Пруссиядә сугыштым, Кенигсбергны штурмовать иттек. Шунда мин бер иптәштән «Совет әдәбияты» журналын алып укыдым. Миңа «Рөстәм маҗаралары» бик ошады. Тулысы аның продолжениесен таба алмаган идем. Менә хәзер Маньчжурияне үтеп, Харбинга кергәч, безнең полк агитаторыннан татарча газеталар һәм «Совет әдәбияты» журналын алдым. Ул журнал миңа бик ошады. Ну анда да «Рөстәм маҗаралары»ның продолжениесе юк. Агитатор капитан Закиров әйтә, редакциягә хат яз, анда бардыр, ди. Сез миңа шул журналны һәм тагын яңа журналларны җибәрә алмассызмы? Минем бик укыйсым килә».*

Шушындый эчкерсез, ихлас күңелдән ярату белән язылган солдат хатларын тагын да күбрәк китерергә мөмкин булыр иде. Ләкин китергән кадәресе дә «Совет әдәбияты» журналының безнең сугышчыларыбыз арасында яратып укыла торган бер журнал икәнен, Бөек Ватан сугышы елларында бу журнал фронтларның иң алдынгы сызыкларына барып җитеп, сугышчыларга җан азыгы бирүен, аларны явыз дошманны тизрәк тар-мар итәргә өндәвен, ягъни Бөек Җиңүебезгә үз өлешен кертүен күрсәтәләр. Бу — журнал өчен дә, аңа катнашучы татар совет язучылары өчен дә зур шатлык.

*«Кызыл Татарстан», 1946, №1*

[3] Гомәр Разин — Гомәр Бәшировның 1930-1940 еллардагы тәхәллүсе. *Ред.*

# ӘТИЕМ ӘМАНӘТЕ

*«Ватан-Ана ягына очкан ядрәләрне*
*күкрәгең белән каплау өчен генә дә*
*бу дөньяга килүең — үзе олы Бәхет!..»*
Леонид Леонов,
язучы-академик.

Элекке СССР, хәзер исә Россия Федерациясе карамагындагы Оборона министрлыгының Подольск шәһәрендәге (Мәскәү өлкәсе) Үзәк архивына еш барам мин. Биредә эзләнүче-тикшеренүчеләрнең куллары бөтенләй тимәгән бихисап документлар саклана әле. Дары исе сеңгән, чит-читләрен ялкын өткән, канга манчылган шул хәрби документлар каһарманнарыбыз турында бик күп нәрсәләр сөйли. «Серләр һәм чын хакыйкать мәгарәсе»нә килгән саен, Бөек Ватан сугышының монарчы билгесез саналган батырлары белән очрашам. Алар арасында **матросовчылар** аерым урын били.


*Әхмәтсафа Мостафин улы Шаһинур белән. 1981 ел.*

А.Матросов һәм аның рухташлары белән тирәнтен кызыксынуыма килсәк, моңа гвардияче каһарман әтием — Әхмәтсафа Мостафа улы (1925 —1982) төп сәбәпче. Ике атна элек кенә 18 яшен тутырган гвардия рядовое 1943 елның 15 октябрендә Псков өлкәсенең Невель районындагы Горушки авылын дошманнан азат итү өчен барган хәлиткеч һөҗүм вакытында үлем уклары сибүче дзот амбразурасын күкрәге белән каплый. Госпитальләрдә озак айлар буена дәваланып, Ходайның мең рәхмәте белән, үлемне җингән иң кадерле кешебез миңа шундый батырларны эзләп табарга васыять әйтеп калдырган иде. Озак еллар дәвамында шул изге әманәтне тормышка ашыру буенча җиң сызганып эшлим.

...Инде тарих китапларыннан, газета-журналлардан укып белгәнебезчә, 1943 елның февралендә Калинин фронтында актив һөҗүм алып баручы 22нче армия карамагындагы 91нче укчы бригаданың 2нче аерым батальоны рядовое — 19 яшьлек комсомолец Александр Матвеевич Матросов, Калинин өлкәсенең (хәзер Псков өлкәсенә керә) Великие Луки районындагы Чернушки авылы өчен барган сугышта, гранаталары һәм автоматында патроннары беткәч, үлем уклары сибүче дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән каплый — үз гомере бәрабәренә дисталәрчә сугышчан иптәшләрен котылгысыз үлемнән коткарып кала. Хәзер шунысы да тәгал билгеле — Үлемсезлеккә адымны Александр 11 сәгать 15 минутта ясый. Заманында легендар Зоя Космодемьянскаяны (1923 – 1941) җәзалаган 197нче немец пехота дивизиясе башкисәрләренә каршы көрәштә батырларча һәлак була ул... Кыз туганын кыю яклаган гаярь егет кебек!

СССР Югары Советы Президиумының 1943 елның 19 июнендә игълан ителгән Указы нигезендә А.М.Матросовка Советлар Союзы Герое исеме бирелә, ул хезмәт иткән укчы бригада исә 56нчы гвардияче укчы дивизиянең А.Матросов исемендәге 254нче гвардияче укчы полкы итеп үзгәртелә. Александрның исеме часть сугышчыларының 1нче ротасы исемлегенә мәңгелеккә кертелә...

Әнә шулай А.М.Матросов үрнәгендә зур фидакарьлек үрнәге күрсәткән батырларны без дисталәрчә еллар дәвамында «матросовчылар» дип атап йөрттек. Архивларда кат-кат эшләвебез, батырлар туган һәм һәлак булган урыннарга махсус

экспедицияләр оештыруыбыз нәтиҗәсендә безгә шундый каһарманнардан 438 кешенең исем-фамилиясе мәгълүм булды. Шуларның 250гә якыны — утыз яшькә дә житмәгән кешеләр. Якташыбыз Филипп Мазилинга исә (ул Татарстанның Аксубай районыннан) тиңдәшсез фидакарьлек үрнәге күрсәткәндә илле яшь тулган була!

Матросовчылар исемлегенә элеккеге СССР территориясендә яшәгән барлык милләт вәкилләре дә кергән диярлек. Араларында ике хатын-кыз — Николай Гастелло исемендәге партизан отряды разведчигы Римма Шершнева, медицина хезмәте кече лейтенанты Нина Бобылёва һәм ике яшүсмер — «Октябрь» партизан отряды диверсанты, шартлатучы Миша Белуш, 252нче укчы дивизиянең 332нче аерым разведка ротасы рядовое Толя Комар да бар...

Эзләнүләр барышында дулкынландыргыч фактларга да тап булдык: Бөек Ватан сугышы елларында А.Матросовка кадәр үк инде совет сугышчыларыннан алтмыш биш кеше (!) күкрәкләре белән дошманның ут ноктaларын томалаган икән бит! Шулардан иң беренчесе — танкист Александр Константинович Панкратов. Ул — Бөек Октябрь социалистик революциясе яшьтәше. Тумышы белән Вологдадан. Коммунист. Рота кече политругы. 1941 елның 24 августында Новгород янындагы Спасс-Нередица торак пунктында хәрби машинасы сафтан чыккач, Александр Константинович сугышчан иптәшләрен атакага күтәрә һәм дошманның ут ноктасын күкрәге белән каплый. Бу батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Легендар политрук турында 1941 елның 20 ноябрендә «Правда» газетасы да язып чыга...

Жыеп кына әйткәндә, 1941 елда ун сугышчы дошманның ут ноктaларын күкрәкләре белән томалый. 1942 елда бу сан — кырык дүрткә, 1943 елда йөз дә җиде кешегә җитә (1943 елдагылар арасыннан 1 гыйнвардан 27 февральгәчә — А.Матросов батырлык күрсәткән көнгәчә — тагын унбер кеше, күкрәкләре белән дошман дзоты амбразуралары каплап, фидакарьләрчә һәлак була). 1944 елда шундый батырлык үрнәге күрсәтүчеләр саны ике йөзгә якынлаша. 1945 елда җитмеш дүрт сугышчы үлем уклары сибүче дошман дзотлары амбразураларын күкрәкләре белән томалыйлар (бу исәпкә милитаристик Японияга каршы көрәштә яу кырында һәлак булган унөч матросовчы да керә). Әлеге каһарманнарның йөздән артыгы — коммунистлар, өч йөзгә якыны — ВЛКСМ әгъзалары...

Бер унайдан, шунысын да искәртеп узыйк: мондый фидакарьлек үрнәген иң беренче мәртәбә моннан күп еллар элек Пелёвин фамилияле сугышчы күрсәтә. Ул 1919 елның июнендә «революция бишеге» Петроград янындагы Керестенёво авылы тирәсендә генерал Юденичның акгвардиячеләренә каршы барган хәлиткеч бер көрәштә күкрәге белән дошманның ут өермәсен каплый... Башкортстанның Нуриман районындагы Иске Бөреч авылыннан ветеран педагог Габит ага Хәммәтнуровның безгә җибәргән хатыннан күренгәнчә, Гражданнар сугышы чорында Быков фамилияле солдат та шундый батырлык үрнәге күрсәткән икән — әлеге факт Советлар Союзы Маршалы К.Е.Ворошиловның истәлекләрендә сакланып калган.

Тик мондый егетлек үз вакытында тиешенчә бәя алмаган, киң яктыртылмаган... Инде Бөек Ватан сугышы чоры каһарманнарына килсәк, архивларда җентекле эзләнүләр алып барган саен, Панкратов-Матросов-Гафиятуллин кебек фидакарь җаннарның тагын да күбрәк булачагына һич тә шигебез юк...

Әлеге уй-фикеребезне раслау өчен, күренекле эзтабар-публицист Эд. Поляновскийның 1997 елның 29 гыйнварында «Известия» газетасында дөнья күргән гастеллочылар һәм матросовчылар турындагы күләмле язмасыннан бер өзек китереп үтәсебез килә:

«...С полковником в отставке Александром Петровичем Коваленко я познакомился в Подольском архиве. Он собирал данные о гастелловцах, талалихинцах, маресьевцах и матросовцах... Работа огромная, факты интересные. Матросовцев за войну набралось 470 человек. Из них 9 человек, закрывших грудью амбразуру, остались живы... 83 человека до подвига Матросова стали матросовцами».

Әнә шулай, Галиҗәнап Вакыт һәм тынгысыз эзтабарлар «матросовчылар» исемлегенә янадан-яна төзәтмәләр кертеп тора. Бары тик күңел биреп эзләнергә, архив документларын, үткәндәге тарих сәхифәләрен зур игътибар, нык түземлелек белән өйрәнергә генә кирәк!..

Шунысы сокландыра: дошманның ут ноктaларын күкрәкләре белән пехотачылар да, дингезчеләр дә, танкистлар да, чик сакчылары да каплаган. Ленинград шәһәрен

саклап калу өчен барган сугышларда гына да илле дүрт кеше шушы соңгы чарадан файдаланган. Каһарманнар арасында офицерлар да байтак.

Матросовчыларның кайберләре икәүләп яисә өчәүләп берьюлы амбразурага ташланган. Мәсәлән, 1942 елның 29 гыйнварында борынгы рус шәһәре Новгород янында коммунистлардан сержант Иван Герасименко, рядовойлардан Леонтий Черемнов һәм Александр Красилов, төнге һөҗүм барышында дошманның берьюлы өч дзотын күкрәкләре белән каплап, сугышчан иптәшләренә җиңүгә юл ачалар... 1942 елның 18 августында Сталинград өчен барган сугышларда комсомоллардан политрук Пётр Гутченко белән взвод командиры Александр Покальчук та шундый ук каһарманлык үрнәге күрсәткәннәр.

1944 елның 23 июнендә Витебск өлкәсенең Остров Юрьев (Осинторф) пункты өчен барган сугышларда татар халкының гаярь улы — гвардия кече сержанты, комсомолец Бари Шәвәлиев белән украин егете — гвардия лейтенанты Иван Ильченко икәүләшеп дошманның бер үк ут ноктасын күкрәкләре белән каплыйлар. (Бу хакта атаклы эзтабар язучы — Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, батырларны барлау өлкәсендә күпьеллык эзлекле эшчәнлеге өчен республикабыз каләм әһелләренең «Бәллүр каләм» иҗади бәйгесендә Гран-прига лаек булган Шамил ага Рәкыйпов «Чәчәкләр сөйли белә» дигән документаль бәян да язды.)

Татарстан улларының үз-үзләрен аямыйча сугышулары турында Советлар Союзы маршалларының, зур хәрби җитәкчеләрнең мактау сүзләре күпләргә мәгълүм. Инде үзебезнең матросовчыларга килсәк, аларның саны егерме биш кешегә җитте. Шуларның бишесе — офицер. Каһарманнарыбызның дүртесе — рус, берсе — чуаш, егермесе — татар халкы вәкилләре (милләттәшебезнең өчесе Башкортстаннан). Мондый ватанпәрвәрләр күбрәк булырга да мөмкин. Эзләнүләр дәвам итә...

Каһарман якташларыбызның туган җирләре — Татарстанның Аксубай, Арча, Әлмәт, Әлки, Баулы, Буа, Балык Бистәсе, Биектау, Бөгелмә, Кукмара, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Тәтеш, Чүпрәле, Югары Ослан районнары. Дүрт батыр — Казаннан. Башкортстандагы яугир милләттәшләребез исә — Дәүләкән, Учалы, Чишмә районнарыннан. Бу ватанпәрвәрләрнең каберләре Витебск, Гомель, Кировоград, Курск, Санкт-Петербург, Смоленск, Одесса, Орёл, Псков, Ростов өлкәләрендә, Новороссийскида, Карелиядә. Дүрт каһарман исә Венгрия, Германия, Польша җирләрендә мәңгелек йокыга талган...

* * *

...Инде легендар Александр Матросовның шәхесе турында да кайбер фикерләребезне әйтеп үтик.

Соңгы елларда ачыкланганча, әлеге каһарман комсомолецның биографиясендә дә озак вакытлар дәвамында серле «ак таплар» яшәп килгән икән. Тынгысыз эзтабарларның тырышлыгы нәтиҗәсендә, матбугат битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында аның кайда туганлыгы һәм чын исем-фамилиясе игълан ителде. Бу өлкәдә башлап йөрүчеләрнең иң тәүгесе — тугандаш Башкортстанда яшәп иҗат итүче талантлы журналист һәм эзтабар язучы Рәүф Насыйров. Аның «Совет Башкортостаны» газетасының 1988 елгы 228-230 һәм 233нче саннарында басылган «Син кайдан, Матросов?» һәм шул ук газетаның 1989 елгы 258-260нчы саннарында дөнья күргән «Мине «Матросов» диеп атагыз...» дигән дулкынландыргыч язмалары, эзләнү-ачышлары бик кызыклы. Әлеге авторның Уфада «Китап» нәшриятында 1994 елда рус телендә дөнья күргән «Откуда ты родом, Матросов?» дигән документаль-тарихи әсәре дә каһарман турында чын хакыйкатьне ачу юнәлешендә күнел ышанырлык төпле дәлилләрдән тора. Чыннан да, моңарчы А.Матросовка кагылышлы төрле документларда һәм аның хакында язылган китапларда батырның туган җире итеп Украина, Днепропетровск шәһәре күрсәтелде. Әмма бу дөреслеккә һич тә туры килми икән. И.Легостаевның «Бросок в бессмертие» китабына кереш сүз язган генерал-полковник И.Медников та бу хакта: «...Матросовның балачагы турында нинди дә булса дөрес мәгълүматлар сакланмаган», — дип искәртеп үтә. Тагын бер саллы дәлил: моннан байтак еллар элек «Правда» газетасында Мәскәү

язучысы, тарих фәннәре кандидаты М.Шкадаревичның Днепропетровскига барып, А.Матросовның туган җирен ачыклау белән шөгыльләнүе турында хәбәр ителгән иде. Әмма анда ул Матросовка кагылышлы берни дә таба алмый.

Мин үзем дә, Подольскидагы Үзәк архивта эшләгән вакытта, А.Матросовны бүләкләүгә кагылышлы документлар белән җентекләп таныштым. Тик аларда да батырның туган җире күрсәтелмәгән иде. *(Кара: 33нче фонд, 682525нче тасвирлама, 32нче эш, 305-317нче битләр).*

Ә кайдан, кем соң ул Александр Матросов?

«...Башкортостанның Учалы районындагы Кунакбай авылында туып үскән ул, — дип яза Р.Насыйров. — Матросовның чын фамилиясе — Мөхәммәтҗанов. Исеме — Шакирҗан. Әтисе — Юныс. Әнисе — Мөслимә...»

Ә ничек Мөхәммәтҗанов Матросов булып киткән соң? Аңа да җавап бар. Гражданнар сугышыннан гарипләнеп кайткан, өстәвенә сукыр да булган, әмма бик җор сүзле, шаян табигатьле, хыялга бирелүчән, әкиятләр сөйләргә яратучы Юныс солдат гаиләсендә 1923 елның 5 февралендә туа Шакирҗан. Әнисе үлгәч, әтисе Фәрхиямал исемле икенче хатынга өйләнә. Яшәү шартлары үтә авыр була аларның, иске генә мунчада көн күрәләр. Ашау-эчү ягы да бик такыр. Аптырагач, Шакирҗан 1934 елда, унбер яшендә, авылны ташлап, читкә чыгып китә. Шуннан соңгы тормышы балалар йортларында, хезмәт колониясендә үтә. Казанда да калган аның эзләре...

Үтә фәкыйрьлектә яшәгән туган авылына кире кайтаруларыннан шикләнеп, Шакирҗан үзенең туып-үскән төбәген дә, чын исем-фамилиясен дә үзгәртергә мәҗбүр була. Кыскасы, матрос киеменә, матрос биюенә гашыйк егет Саша Матросовка әйләнә һәм соңыннан шул исем-фамилия белән бөтен дөньяга танылa...

Тарихта мондый гыйбрәтле мисаллар шактый. Актаныш районының Зөбәер авылында туган атаклы партизан, Советлар Союзы Герое Гатаулла Минаев, мәсәлән, ил күләмендә Николай Орлов буларак яхшы билгеле. Бу хакта исеме югарыда хөрмәтләп телгә алынган эзтабар әдип Шамил Рәкыйпов «Мәтрүшкәләр һаман хуш исле» дигән кыйссасында бик җентекләп яза.

Башкортстандагы каләмдәшебез Рәүф Хәй улы Насыйровның югарыда телгә алынган русча китабында тагын бик кызыклы фактка тап булдым: Александр Матросов белән Шакирҗан Мөхәммәтҗановның фоторәсемнәрендәге искиткеч охшашлык, тәңгәллек! Бу хакта СССР Юстиция министрлыгының суд медэкспертизалары буенча Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институтыннан махсус белешмә дә бирелгән (171 бит).

Әлеге каһарманның нинди милләттән булуына килсәк, бу хакта армия генералы, хәрби фәннәр докторы, тарих фәннәре докторы, Россия Федерациясенең Хәрби Фәннәр академиясе президенты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев 2006 елда Мәскәүдә «Закон и порядок» нәшриятында чыккан «Татары. Воины. Труженики. Патриоты» дигән 396 битле китапның (авторлары — М.С.Хәкимов, М.А.Сәфәров) кереш өлешендәге язмасында болай ди: «...Александр Матросов (Шакир Мухаметзянов) — сын татарского народа... Его легендарный подвиг во время войны повторило много бойцов. Среди них более десятка воинов татар: Газинур Гафиятуллин, Барый Шавалеев, Абдулла Салимов... Многие из них не удостоены никаких наград...» (10-11 битләр). «Татар энциклопедиясе»нең 2014 елда Казанда дөнья күргән IV томында да Александр Матросовның татар булуы әйтелә.

Хәзер инде Саша-Шакирҗан тиңдәшсез батырлык үрнәге күрсәткән көнгә дә тукталып үтик.

СССР Оборона Халык Комиссары, Советлар Союзы Маршалы И.В.Сталинның 269нчы приказында әлеге дата 1943 елның 23 феврале дип күрсәтелсә дә, бу дөреслеккә туры килми. Александр 27 февральдә һәлак була. А. Матросовны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итүче командирлар әлеге датаны 23 февральгә — Кызыл Армиянең туган көненә күчереп, махсус шулай эшләгәннәр. Бу хакта А. В. Сульдинның «История Великой Отечественной войны. Полная хроника 1418 дней/1418 ночей» дигән 716 битле энциклопедик китабында *(М., изд-во «Астрель: Олимп», 2010)*, 351нче биттә язылган.

* * *

«Матросовчылар» дигәннән безгә хәзер искитмәле батырлык үрнәге күрсәтеп исән калган каһарманнарның да исем-фамилияләре мәгълүм. Госпитальләрдә озаклап дәваланганнан соң, терелеп, үз аякларына баскан ватанпәрвәрләрдән казакъ Сабалак Оразалинов, украин Владимир Майборский, грузин Георгий Майсурадзе, яһүд Товье Райз, рус егетләре Леонтий Кондратьев, Степан Кочнев, Александр Удодов белән бергә, татар каһарманнары Мансур Вәлиуллин, Әхмәтсафа Мостафин исемнәрен дә зур горурлык һәм тирән ихтирам хисләре белән искә алабыз.

Сүзебезне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: ялкынлы-кайнар йөрәкләре белән дошман ядрәләрен эреткән монарчы билгесез каһарманнарның да якты исемнәре, мәңгелек данга төрелеп, тиздән безнең арабызга кайтыр һәм күңелләребез күкләрендә йолдызлардай балкыр! Галәм — йолдызлары белән, халкыбыз исә үзенең батырлары белән матур бит...

...Патриот шагыйребез Муса Җәлил һәм аның көрәштәш дусларыннан алда, 1943 елда Берлинның Плетцензее төрмәсендә фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән атаклы чех язучысы — 40 яшьлек Юлиус Фучик сүзләрен һичкайчан хәтеребездән чыгармыйк: *«...Мин батырларның билгесезлектә калмавын, аларны һәр кешенең дә белүен теләр идем. Ул каһарманнарның һәркайсының үз исеме, карашы, уй-тойгылары һәм ышанычлары булган. Һәм шуңа күрә аларның, хәтта иң билгесезләрнең дә, газаплары тарихка мәгълүм шәхесләрнекеннән бер дә ким түгел. Сугышта корбан ителгәннәр Сезгә дусларыгыздай, туган-тумачаларыгыздай һәм үзегездәй һәрвакыт якын булсыннар!..»*

* * *

*Хәзер исә журнал укучыларыбыз игътибарына әлеге каһарман милләттәшләребезнең иң беренчесе — Сәмигулла Кәримуллин турында тулырак мәгълүматлы документаль язмабызны да тәкъдим итәбез.*

# ЯДРӘЛӘРНЕ ЭРЕТКӘН ЙӨРӘК

*«...Ләкин ышанмыйм мин үлемгә!*
*Шушы ышанычтан алып рух,*
*Мин үзем дә, минем җырым да*
*Ахыр минуткача политрук!..»*
Ренат Харис

Кукмара район газетасының беренче редакторы, легендар политрук Сәмигулла Гарифулла улы Кәримуллин. Александр Матросов, ягъни Шакирҗан Мөхәммәтҗановтан бер ел чамасы алдарак, 1942 елның 31 мартында, күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын томалап, сугышчан иптәшләренә җиңү өчен юл ачкан.

Дистәләрчә еллар үтү сәбәпле, инде саргаеп беткән фоторәсемнән безгә ачык йөзле ак күлмәк кигән бер ир-егет карап тора. «Нихәл, якташ?! Дөньялар тынычмы, тормышлар матурмы? Без түккән кан бушка китмәдеме? Җиремнең-илемнең киләчәге ышанычлы куллардамы?» — дигәндәй өздереп карый ул безгә.

Хәер, гаҗәпләнерлек тә түгел: гомере буе янып-ялкынланып яшәүче, якты киләчәк өчен көрәшнең иң алгы сызыгында үз артыннан күпләрне әйдәп баручы көчле рухлы кеше булган бит ул Сәмигулла Гарифулла улы! Сугышка кадәр ул әнә шулай гел актан киенеп йөрергә яраткан. Күңеле дә ак, намусы да пакь булган аның. Биографиясенә кагылышлы мәгълүматлар, хатлар, истәлекләр, архив документлары белән танышканда шуңа кат-кат инанасың...

Каһарман якташыбызның якты образын тулы итеп күз алдына китерүдә Кукмара эшчеләр бистәсендә һәм Казан шәһәрендә яшәүче бертуганнары Нурҗиһан апа белән Рабига апа Кәримуллиналар нык булышлык күрсәтте. Инде

өлкән яшьтә булуларына карамастан, һәр ике ветеранның да кәефләре әйбәт, хәтерләре яхшы...

Сәмигулла Гарифулла улының Иркутск өлкәсендәге Братск сусаклагычында судно капитаны булып эшләүче бердәнбер улы Рафаэль Сәмиевич та безгә ярдәм итте. Ул әтисенә кагылышлы документларны һәм фоторәсемнәрне күз карасыдай кадерләп саклый икән.

...1906 елның 30 июлендә элеккеге Мамадыш өязенең (хәзерге Кукмара районының) Югары Арбаш авылында ярлы игенче Гарифулла агай белән Шәмсенаһар апа гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә Сәмигулла. Баштагы ике балалары — Зәйнәп белән Нуржиһан — кызлар булганлыктан, алар гаиләсенә имана җире бик аз тия. Дүртенче бала булып Рабига атлы кызлары туганнан соң, Гарифулла агай, ачлык-ялангачлыкка чыдар әмәле калмагач, 1909 елда, гаиләсен ияртеп, Себер якларына бәхет эзләргә чыгып китә. Миллионер Михельсонның Анжеро-Судженскидагы күмер шахтасында эшли башлый ул. Биредә яшәгәндә Кәримуллиннарның тагын байтак кына балалары дөньяга килә. Әмма гаиләдәге ундүрт баладан (җиде малай һәм җиде кыздан) нибары җидесе генә исән-сау кала. Калганнары исә ачлы-туклы гомер кичерүдән, һәртөрле авырулардан бик яшьли үләләр.

Әнә шуңа күрә дә Октябрь революциясен үтә шатланып, якты зур өметләр баглап каршылый Кәримуллиннарның ишле гаиләсе. Үзләре укый-яза белмәгәнлектән, Гарифулла агай белән Шәмсенаһар апа, Советлар власте биргән зур хокуклардан файдаланып, кызларын һәм улларын ничек кенә булса да белемле итүне үзләренә олы бурыч-максат итеп куялар. Һәм бу теләкләренә тулысынча ирешәләр алар. Балаларының һәммәсе Мәскәү, Казан, Томск шәһәрләрендәге партия-совет мәктәпләрендә, вузларда, техникумнарда укып, төпле белем-тәрбия алалар. Кемнәр генә чыкмый әлеге ишле гаиләдән. Зәйнәп исемле иң олы апалары, мәсәлән, шактый еллар дәвамында ВКП(б)ның Кукмара һәм Балтач райкомнарында бүлек мөдире, икенче секретарь, беренче секретарь була. Башка кыз туганнарыннан Нуржиһан белән Рабига, югары уку йортларын тәмамлап, берсе — педагог, икенчесе табибә буларак, халыкның ихтирамын казаналар. Заманында хезмәт юлын ВЛКСМның Кукмара райкомында беренче секретарь булып башлаган һәм Бөек Ватан сугышы чорында Ленинград шәһәрен батырларча саклаган Мәгъсүм исемле ир туганнары исә, Казан елга техникумын тәмамлап, Кыргызстанның Рыбачье шәһәрендә — Ыссык күл пароходчылыгында шкипер булып эшли, исеме телдән төшми. Шамил исемле кече туганнары, Мәскәү урман хуҗалыгы институтында белем алып, Братск шәһәрендә үз белгечлеге буенча озак еллар житәкче эштә була.

Бөек Ватан сугышында бу гаиләдән ике бертуган батырларча һәлак була. Беренчесе — Гомәр. Кукмара бистәсендә 2нче урта мәктәпне уңышлы тәмамлаганнан соң, аны Куйбышев шәһәренә командирлар әзерли торган хәрби училищега укырга җибәрәләр. Шуннан ул үзе теләп яу кырына китә һәм якты киләчәгебез өчен чәчәктәй гомерен бирә.

Икенче каһарман — Сәмигулла Кәримуллин. Сугышка киткәнче ул сәяси чыныгу үтә. Якын туганнарының сөйләүләренә һәм хәзер инде мәрхүмә булган өлкән апалары Зәйнәп Кәримуллина-Нигъмәтуллинаның язма истәлекләренә караганда, Сәмигулла Гарифулла улы Томскида партия-совет мәктәбендә, Казанда коммунистик университетта укый. Ике ел Мәскәүдә Н.Нариманов исемендәге Көнчыгышны өйрәнү институтында дипломатлар әзерли торган факультетның төрек секторында белем ала. Шактый вакыт Новосибирскида «Азат Себер» газетасы редакциясендә эшли, аннары матбугат өлкәсендәге эшчәнлеген Татарстанда дәвам иттерә... 1929 елның көзендә илдә колхозлашу хәрәкәте башлангач, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты Сәмигулла Гарифулла улын Кукмарага эшкә җибәрә. Һәм ул биредә күмәк хуҗалыклар оештырып йөри. 1930 елның августында С.Г.Кәримуллин яңа оешкан Кукмара районында чыгарга тиешле «Колхозчы» исемле газетаның беренче редакторы итеп билгеләнә. Искиткеч тырышлык-тынгысызлык нәтиҗәсендә әлеге газетаның беренче саны шул елның 14 сентябрендә үк укучылар кулына килеп керә.

Кукмара районында эшне җайга салганнан соң, Сәмигулла Гарифулла улын 1933 елның җәендә Балык Бистәсе районына политбүлек газетасы редакторы

итеп билгелиләр. Биредә дә ул, МТС эше белән район кинлекләрен инләгән чагында, үзенең ин беренче чиратта журналист икәнлеген онытмый, республика матбугатына материаллар җибәреп тора. Бездә аның «Кызыл Татарстан», «Красная Татария» газеталарының актив хәбәрчесе булуы турындагы документлар да саклана.

1934 елның көзендә Сәмигулла янына яшьлек дусты Шәйхи Маннур кунакка килә. Шагыйрьнең «Гайҗан бабай» поэмасының туууна да нәкъ менә Сәми дусты сәбәпче була.

Соныннан, еллар үткәч, Ш.Маннур үзенең «Агымсуларга карап...» дигән әдәби-документаль әсәрендә *(Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1974)* бу хакта менә нәрсәләр яза:



*Шәйхи Маннур (уңда) якын дусты Сәмигулла Кәримуллин белән. 1934 ел.*

«...Инде сабан урагы бетеп килгән, алдынгыларның хәтта көлтәләре дә ындырга кереп, басулар бушанып кала барган чак иде. Район үзәгенең өс ягындагы әнә шундый ачылып калган бер басуына самолёт килеп төште. Соныннан «Кукурузник» дигән кушаматы чыккан самолёт. Политбүлек зонасына кергән колхозларның алдынгылары кинәшмәсе барган көн иде бу. Төштән соң кинәшмә кешеләре шул самолёт янына чыктылар һәм көтелмәгән сәер хәл башланды. Политбүлек башлыгы карт коммунист Вәли Шәфигуллин хатын-кызлардан ике кешене дәшеп алды да самолётка утырырга кушты. Кызларның йөзләрендә — шатлык, ә күзләрендә курку...

— Батыр булыгыз! — диде Вәли агай. — Сез бит алдынгылар! Барыгыз! Күкләрне әйләнеп, үзегезнең колхоз басуларын өстән карап төшегез...

Пилот аларны кабинага урнаштырды, һәм пропеллер җиле белән салам бөртекләрен очыра башлагач, самолёт кузгалды. Бармак буе озын яшел чикерткә куе камыл арасыннан очкан шикелле, сөзәк кенә алдырып, күккә менеп китте...

...Ниһаять, самолёт янында очасы соңгы кеше генә калды. Иллеләр тирәсендәге кешене бабай дип тә әйтергә була иде. Чал куна башлаган чәче белән калын коңгырт мыегы да шуны раслый. Башында дөнья күргән фетр эшләпә, өстендә җинел куртка сымак нәрсә, аягында күн итек.

— Ну, Гайҗан агай, хәзер синең чират, — диде Вәли Шәфигуллин...»

Менә шул чакта Шәйхи Маннур да, рөхсәт сорап, Гайҗан агай белән бергә самолётның «фанер әрҗәсе»нә чума һәм алар гомерләрендә беренче тапкыр чынлап торып күкләр кочагына менеп китәләр!..

«...Көтмәгәндә күргән бәхетле төш кебек, көтмәгәндә өзелеп тә калды бу очу. Ун минут уздымы-юкмы, еракталы зәңгәр Хыялстан планетасыннан тузанлы, камыллы Җирстан планетасына кайтып та килделәр. Кабиналарыннан чыкканда, икесенең дә куаныч-шатлыктан башлары әйләнә, аяк аслары чайкала кебек иде...

«Мин» дигән малай (Ш.Маннур әсәрдә үзен шулай атап йөртә) очуны гына түгел, юлдашы тиктормас картны да яратып өлгергән иде инде. Алар сөйләшә-сөйләшә политбүлеккә хәтле бергә кайттылар. Әшнәк дигән авылның алдынгы кешесе икән ул...

Сәми дустының фатиры элекке авыл баеның ярым шәһәрчә салынган зур бер йортында иде. Аның өч тәрәзәле киң бүлмәсе китаплар, газета-журнал тегелмәләре, агроном кабинеты шикелле, арыш, бодай, солы һәм төрле үлән көлтәләре белән тулган. Үзе ул, политбүлек газетасы редакторы буларак, редакция, кинәшмә һәм колхозлардан кайтып керми иде. Егет (ягъни шагыйрь үзе) шул бүлмәгә бикләнде дә, атна буе чыкмыйча дигәндәй, шигырь язды... «Гайҗан бабай» дигән бер әйбер иде бу...» *(кара: 398-402 б.)*.

Бәхетле язмышка дучар була Шәйхи Маннурның әлеге күләмле әсәре. Башта ул Казанда Нәби Мансуров мөхәррирлек иткән «Колхоз гәзите»ндә басылып чыга. Аннары, Гомәр Гали соравы буенча, «Совет әдәбияты» журналында да дөнья күрә. Радиодан да яңгыраталар аны...

Бәхет бер килсә килә бит ул! Шул ук елның азагында Ш.Маннурны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алалар. Иҗади эшчәнлеге үсә-куәтләнә барган шагыйрь егетне Татарстан Язучылар союзының ул чактагы җитәкчесе Ләбиб Гыйльми «Совет әдәбияты» журналына җаваплы секретарь итеп чакыра. Шәйхи Маннур анда журналның яна редакторы Гомәр Бәширов кул астында эшли башлый, бер-бер артлы үзенең китапларын да чыгара... Тырышлыгы хөкүмәтебез тарафыннан югары бәяләнә Шәйхелислам Фәрхулла улының. Татар әдәбиятын үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Ш.Маннур, республикабыз язучылары арасында беренчеләрдән буларак, 1939 елда Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек була!

Әлбәттә, Шәйхи дустын иң беренчеләрдән булып Сәмигулла Кәримуллин котлый. Ул инде бу вакытта Казандагы авиация заводында чыгып килүче «Крылья Советов» газетасына эшкә кайткан була.

1940 елның апреленнән С.Кәримуллин ВКП(б)ның Казан шәһәрендәге Ленин районы комитеты аппаратында эшли башлый. Бөек Ватан сугышына да шуннан китә ул. Башта Алабугада политруклар әзерләү курсларында укый. 1941 елның декабрендә аларны, эшелонга төяп, Әгерҗе тимер юл станциясе аша Казанга, аннары Мәскәүгә озаталар.

Кукмара тимер юл станциясеннән төн уртасында үтә Сәмигуллалар эшелоны. Шунда ул туганы Нурҗиһан белән очраша. Бу хакта ветеран-педагог үзе миңа нәрсәләр сөйли:

— ...Алабугада укыган чорында Сәми туганыбыздан (без аның исемен кыскартып шулай атап йөртә идек, үзе дә шулай дәшкәнне-язганны яратты) хатлар, открыткалар еш килеп тора иде. Безнең эшебезнең хаклыгына, дошманны тиздән җиңәчәгебезгә тирән ышаныч белән сугарылган булыр иде аның хатлары! Фронтка бик тә ашкынды ул, фашист-илбасарларны үз кулы белән тизрәк, күбрәк юк итәргә ашкынды!.. Һәм безне, «фәлән числода Кукмара аша үтәчәкбез» дип, хат аша кисәтеп тә куйды. Моны белеп алгач, әтиебез Гарифулла: «Нократ Аланы — зур станция, эшелон анда озаграк туктап торыр», — дип, Сәми туганыбызга ашамлыклар, җылы эчке киемнәр, бияләй-оекбашлар алып шунда ашыкты. Ә мин исә Кукмара станциясендә көтәргә булдым. Мәктәптә дәресләр тәгәлләнгәч тә шунда чаптым.

Ниһаять, төнге уникеләрдә эшелон килде. Бөтен җир караңгылыкка чумган булса да, кар яктысы бер-береңне шәйләргә мөмкинлек бирә иде. Аяк астындагы туң карны шыгырдата-шыгырдата эшелон буйлап исемен кычкырып чабып йөри торгач, Сәми туганыбызны тәки таптым бит! Хәрби киемнән иде ул. Вагоннан сикереп төште дә мине кочаклап алды. «Әти нишләп килмәде, әни ничек? Башка туганнар ни хәлдә? Рафаэль улымны нигә үзең белән алып чыкмадың?» — дип, шул арада үземне сорауларга күмеп тә ташлады. Мин ана өйдә барысы да тәртиптә икәнен әйткәч, ифрат сөенде. Рафаэльне һава бик салкын булу сәбәпле алып чыкмавымны әйткәч, әтинең Нократ Аланында очрашу көтеп калганын белгәч, бик тә көенде. «Кем уйлаган бит әтинең анда килерен, — дип уфтанды ул. — Нократ Аланында чакта мин солдатларга йоклар өчен нар-сәндерә ясау белән мәшгуль идем, шуңа күрә теплушкадан бөтенләй чыкмадым...»

Паровозның тиздән кузгалырга тиешлекне белдереп кисәтүле кычкыртуы безгә озаклап сөйләшергә ирек бирмәде.

Саубуллашканда, мин очучы ирем Хәйрулла Гафиятулла улы Әбсәләмовның Севастополь өчен барган сугышларда батырларча һәлак булуын әйткәч, Сәми туганымның тавышы корычтай чыңлап чыкты:

— Борчылма, Нурҗиһан апа, без ул фашист-илбасарларны үзләре кабызган дәһшәтле ут-ялкынында ныклап өтәрбез — Хәйрулла киявебез өчен дә, Ватан-ана хакына газиз гомерләрен биргән башка корбаннар өчен дә үчне тулысынча алырбыз әле! Ышан безгә: үлсәк үләрбез, әмма дошманны юк итеп үләрбез! Көтегез безне! Тиздән ил өстендә Җиңү кояшын балкытып кайтырбыз!

Фронттан эчке бер җылылык-кайгыртучанлык белән сугарылган хатлары еш килеп торды аның. Бер хатында Сәми туганыбыз үзенең якын дусты — яшьтәше Муса Җәлил белән очрашуы турында да тәфсилләп язган иде. Кайбер юллары хәтеремә дә сеңеп калган: «...Икебез дә политруклар, икебез дә элек бер үк

фронттагы каләм ияләре булганлыктан, безнен сөйләшер сүзебез күп иде... Казан шәһәрен, бергәләшеп үткәргән күнелле очрашуларны, истәлекле кичәләрне, уртак танышларны хәтердә тагын бер кат янарттык. Фашистларны тизрәк жинеп, туып үскән жирләребезгә, яраткан эшебезгә кайту турында хыялландык...»

Гомумән, язучылар, журналистлар арасында дуслары күп иде Сәми туганыбызның. Шәйхи Маннур белән алар, мәсәлән, Анжеро-Судженскида чакта ук якын танышлар иде. Бергәләшеп төшкән фоторәсемнәре дә бар хәтта. Хәзер алар Кукмара районының төбәк музеенда саклана... Гомумән, Сәми туганыбыз үзенең якты күнеле, эчкерсезлеге, гаделлеге, туры сүзле һәм тынгысыз йөрәкле булуы белән бик күпләрне үзенә тартып-каратып торды. Фронтта да шул асыл сыйфатлары белән Ватан сакчыларының күнелләренә юлны тиз тапкандыр дип ышанам!..

Бу юлларның авторында Сәмигулла Гарифулла улының фронттан язган соңгы хаты саклана. Гади дәфтәр битенә карандаш белән язылган ул. Әлеге кадерле тарихи документны безгә Нуржиһан Гарифулловнаның кече кызы — Кукмара район газетасы редакциясендә озак еллар дәвамында корректор хезмәтен башкарган Луиза Хәйрулла кызы белән аның ире — журналист, Бөек Ватан сугышы ветераны Габделхәй Камалетдин улы Камалетдинов табып биргән иде. Биредә аны тулы килеш, берниндн үзгәртүләрсез урнаштырабыз.

*«Исәнме, Зәйнәп!*

*10 мартта, Мәскәүне калдырып, Калинин шәһәренә килдем. Вакытлыча монда булам. Берничә көннән үземнең төгәл адресымны язып жибәрермен. Сиңа рәхмәт. Мәскәүдә чакта бер открытканны алган идем.*

*Минем хәлләргә килсәк, сау-сәламәтмен, үземне яхшы хис итәм.*

*Татарстаннан мин берүзем генә түгел. Монда минем белән Алабуга райкомыннан Шмелёв, Шиһабетдинов, Лаеш райкомыннан Крайнов, Сарман райкомыннан Хәлимов иптәшләр бар.*

*Калинин шәһәре немецлар тарафыннан бик нык жимерелгән. Аны аякка бастыру өчен күп көч түгәргә, зур чыгымнар тотарга кирәк булачак. Ә тормыш дәвам итә — нормальләшә бара. Немецлар басып алган чорда шәһәрне ташлап киткән күп кенә кешеләр бирегә — хезмәт фронтына ашкынып кайталар. Фашистлар шәһәрнең үзәк мәйданын үзләре өчен зиратка әверелдергән булганнар, хәзер халык аны шул хәшәрәтләрдән тазарта.*

*Мине яхшы белгән иптәшләрдән Гатауллинга кайнар сәлам тапшыр һәм адресымны бир. Аңа хат язып торачакмын мин, шуны әйтергә дә онытма.*

*Үзеннең тормыш хәлләрен ничек, кайда эшлисен? Безнен фронтовиклардан тагын кемнәр синен белән хәбәрләшеп тора? Гомәр, Хәйруш, Яков Николаевич һәм башкалар турында ниләр беләсен?*

*Мәскәүдә чакта Кукмарадан хат-хәбәр алмадым. Бүген туган якка — әти-әнигә, туганнарга да хат язып салам әле.*

*Фашистларны тулысынча тар-мар итәр көннәр тиздән килеп житәр дип уйлыйм. Шул ышаныч миңа көч һәм кыюлык өсти. Большевик исеменә ахыргача турылыклы булып, дошманны тәмам жингәнче, соңгы тамчы кайнар каным тамганчыга кадәр көрәшәчәкмен!*

*Кулынны кысып, кайнар сәламнәр белән, туганын Сәми.*
*15 март, 1942 ел.*
*Хат язу өчен адрес: г.Калинин, до востребования».*

Шушы бер хат үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли!

* * *

Безгә соңгы вакытта Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Подольск шәһәрендә урнашкан Үзәк архивында булып, атаклы якташыбызга кагылышлы хәрби документлар белән ныклап танышырга туры килде. Алардан күренгәнчә, политрук Кәримуллин 1941 елның сентябрендә Башкортстанның Сәфәр исемле татар авылында оешкан 361нче укчы дивизиянең 1204нче укчы полкында гаярь ир-егетләрчә хезмәт иткән. Дошманга каршы көрәштә күрсәткән зур батырлыклары

өчен 1942 елның 17 мартында алар дивизиясенә һәм полкына «Гвардияче» дигән мактаулы исем бирелә.

Шуннан соң озак та үтми, политрук Сәмигулла Кәримуллин батырлык үрнәге күрсәтә. 1942 елның 31 мартында Смоленск өлкәсенең Сычёвка районына караган Холмино авылы янында сугышчыларын хәлиткеч һөҗүмгә күтәрә ул. Көтмәгәндә көчле ут давылы уйната башлаган дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән томалап, солдатларының гомерләрен саклап кала һәм җиңүгә юл ача бу тәвәккәл-фидакарь җан! Дошман ядрәләре Сәмигулла Гарифулла улының Ватан-анага тиңсез мәхәббәт, илбасарларга каршы чиксез нәфрәт хисләре белән типкән ярсулы кайнар йөрәген үтәдән-үтә тишеп чыгалар. Коралдаш дуслары яраткан политрукларының вакытсыз үлеме өчен (бу вакытта әле аңа 36 яшь тә тулып җитмәгән була) гитлерчылардан аяусыз үч алалар, әлеге торак пунктта аларны тулысынча тар-мар итәләр.

Гвардияче политрук С.Г.Кәримуллинның «Социалистик Ватан өчен көрәштә биргән антына турылыклы хәлдә кыюлык һәм батырлык үрнәге күрсәтеп» яу кырында һәлак булуы турында Кукмара район хәрби комиссариатында берьюлы ике извещение саклана (кара: «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Кукмара районы буенча һәлак булган һәм хәбәрсез югалган сугышчыларның извещениеләре», 4нче эш, 1 том, 1942 ел, 447, 459 б.). Аларның һәр икесенә дә гвардияче полкның командиры һәм комиссары кызыл карандаш белән имзаларын куйган. Шунда ук 1436нчы номерлы кыр почтасы мөһере дә сугылган.

Беренче извещение Казанга — ВКП(б)ның Ленин райкомына адресланган, икенчесе — Кукмара эшчеләр бистәсенең Октябрь урамындагы 62нче йортта яшәүче Гарифулла Кәримуллинга — журналист-политрукның әтисенә.

Әлеге коточкыч хәбәр — үлем кәгазе барысын да тетрәндерә. Алардан, тылдагылардан, дошманны тизрәк җиңү өчен бары тик тырышып, көнне төнгә ялгап эшләү сорала. Һәм шулай итәләр дә — удар хезмәт вахтасына басып эшли Сәмигуллаларның ишле гаилә әгъзалары. Гарифулла агай да элеккечә киез итек фабрикасында яшьләргә хас энергия һәм житезлек белән эшләвен дәвам иттерә.

Сугышта һәлак булган туганнары өчен дә дошманны тар-мар итеп, туган якка күптән көтелгән Җиңү хәбәрен алып кайта Мәгъсүм солдат. Җитди йөзләрдә янадан елмаю кабына, күзгә шатлык яшьләре бәреп чыга, телләрдә дәртле җырлар тибрәнә.

Яу кырыннан кайтмаган уллары өчен дә яшәп һәм эшләп, 1952 елның 30 мартында дөнья куя Гарифулла агай. Әниләре – Герой-ана Шәмсенаһар апа исә 1959 елның 10 июлендә вафат була.

Шулай да Сәмигулланың улын кече яшьтә чагында ук үз тәрбияләренә алып, аякка бастырып өлгерәләр. Рафаэль унбиш яшенәчә Кукмарада алар гаиләсендә гомер кичерә. Аннары 1954 елда аны әтисенең бертуганы Шамил абыйсы үз янына — Төмән өлкәсенең Ханты-Мансийск шәһәренә алдыра. Биредә шактый вакыт яшәгәч, алар бергәләшеп Иркутск өлкәсенең Братск шәһәренә күчеп китәләр.

Рафаэль Сәмиевич, танкист буларак, Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, командование тарафыннан еш кына бүләкләргә лаек була. Журналист-политрук улы икәнен бер генә минутка да исеннән чыгармый ул. Һәрчак әтисенә охшарга, аныңча яшәргә омтыла. Хәзер дә — судно капитаны булгач та шулай.

Озак еллар дәвамында әтисенең каберен эзли торгач, Рафаэль Сәмиевич, ниһаять, максатына ирешә. Аңа Смоленск өлкәсенең Сычёвка район хәрби комиссариатыннан түбәндәге эчтәлекле хат килә:

*«...Сезнең сорау буенча эзләнүләр алып бару нәтиҗәсендә әтиегезнең — политрук Кәримуллин Сәми Гарифулловичның кайда җирләнүе ачыкланды. Ул безнең районның Василевский авыл Советына караган Холмино авылына күмелгән булган. Сугышта һәлак булучыларның район хәрби комиссариатында саклануы истәлек альбомында — «Сугышчан Дан кенәгәсе»ндә ул 1241нче кеше булып тора.*

*Хәзерге вакытта әлеге авыл Советы территориясендә аерым каберлекләр юк. Биредә һәлак булган барлык сугышчыларның гәүдәләре 1954-1956 елларда Сычёвка шәһәренең төньяк-көнбатыш өлешенә урнашкан 2нче номерлы хәрби каберлеккә — туганнар каберлегенә күчереп күмелде.*

*Каберлек уртасында Ватан-ана образын гәүдәләндергән хатын-кызга һәм илгә, азатлык һәм бәйсезлек бүләк иткән совет солдатына һәйкәл куелган. Әлеге изге урын һәрвакыт игътибар үзәгендә — яшеллеккә төренеп, чәчәкләргә күмелеп утыра. Аны карау, тәртиптә тоту эше Сычёвка урта мәктәбе укучыларына йөкләтелгән.*

*Һәр елны 23 февральдә, 9 Майда һәм 25 сентябрьдә (соңгысы — Смоленск өлкәсен фашист-илбасарлардан азат итү көне) биредә сугышта һәлак булганнарны искә алу митингы үткәрелә, туганнар каберлегенә һәм һәйкәл итәгенә күпсанлы веноклар куела...»*

1980 елның сентябрендә Кукмарада район газетасының чыга башлавына 50 ел тулу юбилее зурлап билгеләп үтелде. Тантана барышында Сәмигулла Гарифулла улының мәгърур исеме тирән ихтирам һәм горурлык хисләре белән кат-кат телгә алынды. Шул истәлекле көннәрдә «Хезмәт даны» газетасы редакциясе урнашкан бинада Матбугат музее ачылды. Газетаның беренче редакторы С.Г.Кәримуллинга багышланган зур стенд янында кешеләр аеруча күп булды. Һәркайсы аның турында күбрәк белергә тели иде. Экскурсовод ролен Сәмигулла Гарифулла улы турында безгә иң беренче мәгълүматларны биргән һәм район газетасы редакциясендә аннан соң эшләгән барлык редакторларны яхшы белгән матбугат ветераны Мәрьям Галиева башкарды.

1983 елда исә газета редакциясе аеруча актив хәбәрчеләр өчен журналист-политрук Сәмигулла Кәримуллин исемендәге еллык премия булдырды (хәбәрчеләрнең «Правда» газетасы редакциясе тарафыннан чакырылган I Бөтенсоюз киңәшмәсенең 60 еллыгы уңаеннан махсус эшләнде ул). Әлеге премия һәр елны Матбугат көнендә иң яхшы язмаларның авторларына бирелә. Лауреатларга акчалата бүләк һәм махсус эшләнгән Почёт дипломы тапшырыла, рәсемнәре исә газета редакциясенең Мактау китабына кертелә.

Район терлекчеләре ярышын тагын да җанландырыр өчен, газета редакциясе тарафыннан соңгы елларда Сәмигулла Кәримуллин исемендәге күчмә приз булдыру шулай ук зур роль уйный. Фермалар арасында әлеге зур бүләккә лаек булу өчен үзара ярыш кызганнан-кыза бара. Шунысы куанычлы: әле бер, әле икенче хуҗалык терлекчеләре яулый аны.

Югары Арбаш авылының һәм Кукмара эшчеләр бистәсенең яңа төзелеп килә торган урамнарына журналист-политрук Сәмигулла Кәримуллин исемен бирү дә истәлекле вакыйга булды.

Сәмигулла Гарифулла улының батырлыгын мәңгеләштерүдә Сычёвка шәһәре белән Холмино авылы хезмәт ияләре дә, мәктәп укучылары да үзләреннән мактауга лаеклы өлеш кертерләр, дип тирәнтен ышанабыз. Биредә дә журналист-политрук исемендәге яңа урамнар, парк-скверлар барлыкка киләчәгенә безнең шигебез юк. Чөнки Сәмигулла Гарифулла улы — шундый олы хөрмәткә лаеклы кеше. Аны һәм аның кебек каһарманнарны бу уңайдан борынгы грек мифологиясендә сурәтләнгән атаклы Прометейга тиңлисе килә. Ул легендар герой, җирдә кешеләр ыруын саклап калырга һәм аларның киләчәктәге бәхетле тормышларын тәэмин итәргә теләп, үз-үзен аямыйча, һәртөрле каршылык-киртәләрне җимереп үтә — аллалардан Ут урлап, адәм балаларына мәңгелек яшәү бүләк итә! Сәмигулла Кәримуллин кебек батырлар да, дөньяны башкалар өчен тоташтан караңгы төнгә — мәңгелек газапка әверелдерергә теләгән фашист-илбасарларга каршы тиңдәшсез көрәштә зур кыюлык-фидакарьлек күрсәтеп, кешелек өчен Яшәү утын саклап калдылар! Шуңа күрә дә журналист-политрук С.Г.Кәримуллин кебекләргә: «Сез бит — Прометейлар токымыннан!» — дип дәшәсе һәм чиксез рәхмәт сүзләре әйтәсе килә...

**Шаһинур МОСТАФИН,**
*әзтабар язучы, Россия Хәрби-тарихи фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы.*

# КОРПУС КОМАНДИРЛАРЫ

Бөек Ватан сугышында дистәләрчә татар командирлары полк һәм дивизияләр белән командалык итә. Составында ким дигәндә өчәр дивизия булган корпуслар белән командалык иткән милләттәшләребез дә бар. Болар — Советлар Союзы Герое генерал-лейтенант Гани Сафиуллин, генерал-лейтенант Якуб Чанышев, генерал-майорлар Минзакир Әпсәләмов, Иван Алиев, Александр Кирзимов һәм полковник Нәҗип Хәмитов. Бу язма — шулар хакында.

**Гани Биккенә улы Сафиуллин 1905 елда Арча районының Иске Кишет авылында туа, мәдрәсәдә укый.** 1920 елда әти-әнисе вафатыннан соң, караучысыз кала һәм үзе кебек ятимнәр белән ил гизә. 17 яше тулганда язмышы Казакъстанның Тургай далаларына китереп ташлый. Бирелә ул көтүче булып яллана, бераздан партиянең өяз комитетында йомышчы була, шунда комсомолга керә. Өч ел партиянең совет мәктәбендә укыган егетне Семипалатинск каласындагы комсомолның Бухтармин өяз комитетына инструктор итеп җибәрәләр. 1927 елдан Кызыл Армия сафларында: 1нче кавалерия дивизиясе составындагы 1нче совет казакъ полкында — отделение командиры һәм взвод командиры ярдәмчесе. Проскуров каласындагы Командирлар әзерләү курсларын тәмамлый. 1930 елда Мәскәүдәге ОГПУның (Берләштерелгән дәүләт сәяси идарәсе, 1934 елдан НКВД составында) Югары чик сакчылары мәктәбендә хәрби белемен күтәрү исә авылдан чыккан гади татар малаена хәрби карьерага юл ача. Милләттәшебез 1933-1939 елларда — ОГПУның 5нче Горький укыту дивизионы штабы башлыгы, НКВДның Ивановода урнашкан 9нчы аерым дивизионының штаб башлыгы, НКВД гаскәрләренең Сормоводагы 185нче полкы командирының беренче урынбасары, НКВД гаскәрләренең 178нче полкының штаб башлыгы һәм командиры. Әлеге полк 1939 елның апрелендә аеруча мөһим сәнәгать предприятиеләрен саклау буенча 103нче аерым батальон итеп үзгәртелә. Сафиуллин шул елның ноябрь аеннан шундый ук максатлар куелган 197нче полк командиры вазифаларын башкара. 1941 елда М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең кичке факультетын тәмамлый.

Сугыш башланганда, Көнбатыш фронтның 22нче армиясе составындагы 256нчы укчы дивизиянең 930нчы полкы командиры вазифасында Смоленск һәм Великие Луки калаларын саклап сугыша. 1941 елның октябреннән — Калинин фронтының 30нчы армиясе составындагы 178нче укчы дивизиянең 709нчы укчы полкы командиры. 1942 елның апреленнән полковник Сафиуллин — Көньяк-Көнбатыш фронт карамагындагы 28нче армиянең 38нче укчы дивизиясе командиры урынбасары. 1942 елның 15 июненнән 1943 елның 17 апреленә кадәр Казакъстанда оешкан шул дивизия белән командалык итә. Харьковка һәм Донбасска һөҗүм итүче дошман көчләренә каршы сугышларда чыныгу алган дивизия яугирләре Сталинград янында генерал-фельдмаршал Фридрих Паулюсның 6нчы армиясе гаскәрләрен камап алып тар-мар итүгә дә саллы өлеш кертә. Ил язмышы сыналган шушы орыш вакытында беренче алман генералын — 297нче гренадер дивизиясе командиры генерал-майор Мориц фон Дребберны — нәкъ менә Сафиуллин дивизиясе әсирлеккә төшерә. Берничә көннән аларга тагын бер алман генералы — 14нче танк корпусы командиры генерал-лейтенант Вернер Шлеммер бирелә. Сталинград янындагы җиңүләр уңаеннан, 1943 елның февраль ахырында 64нче армия (16 апрельдән — 7нче гвардия армиясе) командующие генерал-лейтенант Шумилов дивизия командиры Сафиуллинга генерал-майор (карары 3 февральдә чыга, №125) петлицалары тапшыра, ә инде 1 март көнне СССР Оборона халык комиссары И.В.Сталинның боерыгына ярашлы рәвештә, 38нче укчы дивизия 73нче гвардия укчы дивизиясе итеп үзгәртелә. Бераздан ул Сталинград исемен йөртә башлый.

1943 елның апреленнән генерал-майор Гани Сафиуллин 25нче гвардия укчы

корпусы оештыра һәм аңа командалык итә. Бу вакыйга геройның истәлекләрендә шактый җентекле итеп ташка басылып калган. Аннан күренгәнчә, ул чакта аңа армия командующие Шумилов шалтырата һәм тиз арада Хәрби советка килеп җитәргә куша. Степан Иванович ялгызы гына булмый, аның янында — Хәрби совет әгъзасы генерал Сердюк, армиянең штаб башлыгы генерал Ласкин һәм артиллерия командующие генерал Петров. Фронттагы вазгыять белән таныштырганнан соң Шумилов аңа:

— Корпуслар оештырыла. Хәрби совет сезгә гвардия корпусы оештырырга һәм аның белән җитәкчелек итәргә тәкъдим итә. Көчегез җитәрме? — дип сорау бирә.

— Армиядә миңа караганда өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк генераллар бар, — дип җавап бирә Сафиуллин. — Мин яшь бит әле, үземә бирелгән дивизиягә җитәкчелек итәр идем.

Командующий исә: «Сезне корпус командиры итеп билгеләү мәсьәләсе фронт командующие генерал Ватутин белән сөйләшенгән», — дип әңгәмәгә нокта куя. Сафиуллин оештырган 25нче гвардия укчы корпусына өч гвардия дивизиясе керә: генераллар Морозов белән Скворцов дивизияләре һәм командиры итеп полковник Козак билгеләнгән үзенең 73нче дивизиясе. Корпус Воронеж һәм Дала фронтлары карамагындагы 7нче гвардия армиясе составында Белгород-Харьков — һөҗүм, һәм Белгород белән Харьков калаларын азат итү операцияләрендә катнаша. Днепр өчен сугышларда үзен оста командир икәнен күрсәткән Гани Сафиуллинга СССР Югары Советы Президиумының 1943 елның 26 октябрендәге карары белән Советлар Союзы Герое (Алтын Йолдызының номеры — 1342) исеме бирелә. Аннары корпус сугышчылары 2нче Украина фронты составына кертелгән 7нче гвардия армиясе гаскәрләре белән Кировоград, Уманско-Баташанск, Ясско-Кишинёв, Дербецен, Будапешт һөҗүм операцияләрендә катнашып үзләрен даңга күмә. Шул чорда Сафиуллин корпусы Югары Башкомандующий Иосиф Сталинның ике дистәләп рәхмәтенә лаек була. 1944 елның 2 ноябрендә корпус командирына генерал-лейтенант званиесе бирү турында карар (№1540) дөнья күрә.

Тик, ни сәбәпледер, 1945 елның 18 мартында 2нче Украина фронты командующие Советлар Союзы Маршалы Родион Яковлевич Малиновский, «син яшь әле» дигән сылтау белән 25нче гвардия укчы корпусы командиры, Советлар Союзы Герое генерал-лейтенант Гани Биккенә улы Сафиуллинны 53нче армия карамагындагы генерал-майор Фёдор Афанасьевич Осташенко командалык иткән 57нче укчы корпуска күчерә. Үзенең яңа корпусы белән Гани Сафиуллин Братислава-Брно операциясендә катнаша. Аннары инде, генералның үз истәлекләрендә бәян ителгәнчә, Моравия башкаласы Брноны азат итүгә үк, корпусны алгы сызыктан чыгаралар һәм май башында эшелоннарга төяп, Ерак Көнчыгышка озаталар. Дөресен генә әйткәндә, сугыш тәмамланыр алдыннан, үзе оештырган һәм ике ел дәвамында командалык иткән корпустан аеру берниндн кысаларга да сыймый. Ә менә Җиңү табыныннан читләштерелгән Сафиуллин корпусына командалык итә башлаган Осташенкога 1945 елның 20 апрелендә генерал-лейтенант званиесе, ә тагын сигез көннән Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Бөтен хикмәт шунда! Әгәр Сафиуллин үз корпусында калса, аның йә генерал-полковник званиесенә, йә икенче Алтын Йолдызга, йә берьюлы икесенә дә лаек буласы шик уятмый.

Совет-япон сугышы барышында Сафиуллинның 57нче корпусы Байкал арты фронты гаскәрләре белән берлектә Хинган-Мукден һөҗүм операциясендә уңышлы хәрәкәт итә. Якташыбыз сугыштан соң да үз вазифасында кала, 1945 елның ноябреннән ул — К.Е.Ворошилов исемендәге Хәрби академия каршындагы югары академик курслар тыңлаучысы. 1947 елның апрелендә 38нче гвардия һава-десант корпусы командиры урынбасары итеп билгеләнә. Әмма төгәл ике елдан «әдәпсез тәртибе өчен» дигән формулировка белән вазифасыннан азат ителә һәм Балтыйк буе хәрби округы составындагы 11нче гвардия армиясенең 36нчы гвардия укчы корпусына керүче 10нчы гвардия укчы дивизия командиры урынбасары итеп «үрләтелә». Гани Биккенә улы 1950 елның ноябрь аеннан — шул ук хәрби округ

составындагы 16нчы укчы гвардия корпусы командиры урынбасары. 1956 елның августыннан Төньяк-Кавказ хәрби округына керүче 112нче укчы корпус командиры урынбасары булып хезмәт итә һәм 1957 елның июненнән, 51 яшендә запаска җибәрелә. Казанда яши, 1973 елда вафат була. Данлыклы якташыбыз ике Ленин, өч Кызыл Байрак, ике II дәрәҗә Суворов, ике II дәрәҗә Кутузов, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән. Казан урамнарының берсе аның исемен йөртә.

**Татар халкының каһарман улы генерал-лейтенант Якуб Җиһангир улы Чанышев та катлаулы тормыш юлы үтә. Ул 1892 елның 27 февралендә Уфа губернасының Эстәрлетамак өязенә (хәзерге Башкортстанның Авыргазы районы) керүче Тукай исемле татар авылында туа.** 1913 елдан — патша армиясендә хезмәттә. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Генерал Брусилов оештырган стратегик һөҗүм барышында кылган батырлыклары өчен Георгий тәресе белән бүләкләнә һәм унтер-офицер званиесе бирелә. Октябрь революциясеннән соң — Казан хәрби округы комиссары. 1917 елда Казан хәрби училищесын тәмамлый һәм прапорщик званиесендә хәрби хезмәтен дәвам итә. Рота командиры. 1918 елның декабрендә — Уфа каласы коменданты. Казанда «Болак арты республикасы»н бастыруда катнаша һәм ак чехларга каршы көрәшә. Ул командалык иткән 1нче тиз атучы татар позицион батареясы 1919 елның июнендә 1нче Идел буе аерым татар укчы бригадасы составына кертелә. Бригаданың командиры — Йосыф Ибраһимов, штаб башлыгы — литва-поляк татары генерал-майор Искәндәр Осман улы Тальковскийның улы Искәндәр Тальковский. Якуб Чанышев 1920 елның мартында бригада комиссары итеп үрләтелә, Урта Азиядә басмачыларга каршы сугыша. М.В.Фрунзе исемендәге РККА Хәрби академиясе каршындагы югары хәрби курсларда укый (1924 һәм 1927 еллар). 1929 елда исә Хәрби-сәяси академия каршындагы курсларны тәмамлый.

Инде генералның 1987 елда Казанда «Безне яшьлек йөртте...» исеме белән нәшер ителгән китабындагы истәлекләренә күз салыйк:

«Төркестанда басмачыларны тар-мар иткәч, партия карары белән бик күп сәяси хезмәткәрләрне, шул исәптән мине дә Мәскәүгә хәрби академиягә укырга җибәрделәр. <...> 1924 елда мин үзем өчен туган төбәккә әйләнгән Казанга кайттым. Монда мине — полк, соңрак 1нче Казан дивизиясе командиры итеп билгеләделәр. Тормышымдагы бу чор сигез елга сузылды».

1934 елда М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлагач, ул Урта Азия хәрби округына керүче 68нче Кызыл Байраклы Төркестан укчы-тау дивизиясе белән командалык итә. Кызганычка каршы, СССРны чолгап алган репрессияләр дәһшәтеннән Якуб Җиһангир улы да читтә калмый. 1937 елның 13 маенда Ташкент каласында нindidер В.М.Примаков дигән адәмнең әләге белән комдив Чанышевны кулга алалар. Аның ике ел ярым буена НКВД зинданнарында нинди газапларга дучар булуын бары тик фаразларга гына мөмкин. 1939 елның декабрендә Чанышев аклана һәм М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең гомумтактика кафедрасында өлкән укытучы булып эшли башлый. Ватан сугышы башлану турындагы хәбәрне ул Гродно каласы янындагы полигонда кыр өйрәнүләре вакытында ишетә. 1941 елның ноябреннән Көньяк-Көнбатыш фронтның 6нчы армиясе составындагы 103нче укчы дивизиягә командалык итә башлый. 1942 елның май аенда үз дивизиясе белән Харьков юнәлешендә башланып киткән һөҗүмнәрдә катнаша. Июнь аеннан Я.Ж.Чанышев — шул ук фронтка керүче 9нчы армия составындагы 333нче укчы дивизия командиры. Дивизия июль аенда Изюм каласы янында Төньяк Донец һәм Дон елгалары буйлап авыр саклану сугышлары алып бара. Шул сугышлар барышында дивизия командиры Чанышев яралана һәм аны госпитальгә озаталар. 1 октябрьдә аңа генерал-майор званиесе бирелә (№1618). Сәламәтлеге яхшыргач, К.Е.Ворошилов исемендәге Югары хәрби академиядә югары академик курслар үтә һәм Төньяк-Көнбатыш фронтның 68нче, аннары 38нче армияләре командующийларының урынбасарлары вазифасын башкара. 1943 елның август аеннан — Үзәк фронтның 70нче армиясе составындагы 96нчы укчы корпус командиры. Корпус 1944 елның гыйнвар-май айларында — 2нче Балтыйк буе, май-декабрь айларында — 1нче

Белоруссия һәм аннан соң, сугыш тәмамланганчыга кадәр 2нче Белоруссия фронтлары карамагындагы 70нче армия составында сугыша. Якуб Чанышев 1944 ел башыннан — генерал-лейтенант (22.2.1944. №1540). Аның корпусы Люблин-Брест һөҗүм операциясендә һәм Брест каласын дошманнан азат итү өчен барган сугышларда активлык күрсәтә. Шул сугышта күрсәткән батырлыклары өчен 1944 елның 10 августында генерал-лейтенант Якуб Чанышев командалык иткән корпуска «Брест» исеме бирелә. 1944-1945 елларда корпус Данциг һәм Гдыня калаларын азат итүдә катнаша. Аннары Көнчыгыш Померания һәм Берлин һөҗүм операцияләре кысаларында Висла һәм Одер елгаларын кичә, Тихоля, Бютов, Гарц, Нойштрелиц, Варен калаларын азат итүгә саллы өлеш кертә. Якуб Җиһангир улы сугыштан соң, 1946-1957 елларда К.Е.Ворошилов исемендәге Югары хәрби академиянең оператив сәнгать кафедрасында өлкән укытучы һәм курс башлыгы вазифаларын башкара. Бер искәрмә: 1945 елның 27 апрелендә 70нче армиянең Хәрби совет әгъзасы генерал-майор Савков һәм командующий генерал-полковник Попов генерал-лейтенант Чанышевны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр. Әмма 2нче Белоруссия фронты командующие, Советлар Союзы Маршалы Константин Константинович Рокоссовский да яклаган һәм раслаган үтенеч җавапсыз кала.

Якуб Җиһангир улы Чанышев гомере буена татарлыгы белән горурланып яши. Үзенең дусты, репрессияләр корбаны, Ирандагы элекке хәрби атташе, ГРУ полковнигы Һади Маликов белән бик еш Казанга кайта. Татарстандагы сәнгать, әдәбият, мәдәният әһелләре белән аралаша. Мәскәү каласындагы иҗтимагый тормыштан да читтә калмый. Узган гасырның 60нчы елларында татар иҗтимагый-мәдәни хәрәкәте лидерлары Әсәдуллаев йортын татар оешмасына кайтаруны үтенеп КПССның Мәскәү шәһәр һәм Үзәк комитетларына хатлар язалар. Аларның һәркайсында Якуб Җиһангир улының да имзасы бар. Аның бу күркәм сыйфаты тыныч тормышта гына түгел, ә бәлки кырыс сугыш елларында да һәрдаим саллы гамәлләре белән раслана. Шуңа мисал итеп Бөек Ватан сугышында катнашучы милләттәшләребезгә атап язылган «Ватан сугышы фронтларындагы улларына татар халкыннан хат» белән бәйле вазгыятьне китерергә мөмкин. Әлеге хатка миллион ярымнан артыграк кеше кул куйган. Ә инде шуңа җавап рәвешендә язылган «Икенче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан хат»ын имзалаган 4 меңнән артыграк яугирнең исемлеге нәкъ менә генерал-лейтенант Якуб Чанышев фамилиясе белән башлана. Аннан соң исемлектә — генерал-майорлар Фатыйх Булатов белән Хәбиб Ганиев. Бер фронтта — өч татар генералы!

Генерал-лейтенант Якуб Чанышев ике Ленин, дүрт Кызыл Байрак, I дәрәҗә Кутузов, II дәрәҗә Суворов, Октябрь Революциясе орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән. СССР орденнары белән медальләренең саны — 22. Моннан тыш геройның күкрәген Польшаның дүрт орден-медале һәм АКШның «Легион оф Мерит Соммандер» югары ордены бизи. 1987 елның 6 ноябрендә вафат. Ни үкенеч: Казанда күренекле якташыбыз хөрмәтенә бернәрсә дә эшләнмәгән.

**ГРУ генералы (4.06.1940), хәрби фәннәр докторы Минзакир Әпсәләм улы Әпсәләмов 1896 елның 10 декабрендә Казан губернасының Мамадыш өязенә керүче Югары Утар авылында (хәзерге Татарстанның Саба районы) туа.** 1914 елда мәдрәсә тәмамлый, тагын бер елдан экстерн белән авыл укытучысы һөнәренә имтихан тапшыра. Шул ук елны патша армиясенә алалар. 35нче запастагы Себер укчы полкында рядовой, аннары өлкән унтер-офицер булып хезмәт итә. 1917 елдагы февраль революциясеннән соң — рота командиры. 1917-1918 елларда мөселман сугышчыларының 3нче гренадер бригадасында солдатлар комитеты әгъзасы һәм 11нче армиянең Татар кызылармеецлар батальонында мөселман сугышчылары комитеты секретаре. 1918 елның март аенда ул чакта Польша составына керүче Ровно каласында алманнарга әсирлеккә эләгә. Ун айдан соң азат ителә һәм аклар хәрәкәтенә кушыла. 1919 елның апреленә кадәр Симферопольдәге каравыл командасында — взвод унтер-офицеры. Апрель-август айларында Көньяк фронтта Кызыл Армиянең партизаннар отряды командиры һәм Кырым мөселман хәрби коллегиясе рәисенең иптәше. 1919 елның сентябрендә РККАның хәрби академиясенә укырга керә.

Вакыт-вакыт укуын өзеп, хәрби разведка буенча махсус бурычлар үти: РСФСРның Бакуда урнашкан Төркия һәм Персия илләре каршындагы Вәкаләтле вәкиллегендә хәрби бүлек башлыгы урынбасары (1920 елның июне — 1921 елның феврале), РСФСРның Төркиядәге Вәкаләтле вәкиллегендә — тәрҗемәче (1921 елның июнь — август айлары), РСФСРның Төркиянең көнчыгыш провинциясендәге Генераль консуллыгы хезмәткәре (1921 елның август — сентябрь айлары). Шул чорда хәрби разведчик Минзакир Әпсәләмовның аттестациясенә: «Тырыш һәм хезмәт сөючән кеше. Яхшы итеп төрек телен өйрәнде», — дигән бәя төшә.

Төгәл өч ел дигәндә хәрби академияне тәмамлый һәм шул ук Вәкаләтле вәкиллектә хәрби атташеның секретаре һәм ярдәмчесе булып эшли (1922 елның октябре — 1927 елның мае). Аның эшчәнлегенә СССРның Төркиядәге вәкаләтле вәкиле Семён Аралов бәясе менә мондый: «Яхшы әзерлекле, төрек телен камил белә, тыйнак һәм төптән уйлап эш итүче кеше». Якташыбыз — 1927 елның ноябреннән 1931 елның ноябренә чаклы Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабының разведка бүлеге башлыгы. 1928 елда, бер үк вакытта М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академия каршындагы югары курслар да тәмамлый. Шул ук елның февраль аенда РККА штабының Разведка идарәсе башлыгы Ян Карлович Берзин кушуы буенча, «үз разведка эшчәнлекләре белән командованиегә зур файда китергәннәре өчен» бер төркем хәрби разведчик, шул исәптән Әпсәләмов револьверлар белән бүләкләнә. Тәҗрибәле разведчик хәрби хезмәттә дә сынатмый: 1931-1933 елларда ул Азәрбайҗан укчы дивизиясенең 1нче тау-укчы полкында командир һәм комиссар вазифасын башкара.

Минзакир Әпсәләмов — СССРның Персиядәге (1935 елдан — Иран) Вәкаләтле вәкиллеге каршында хәрби атташе һәм хәрби разведка резиденты (1933 елның июне — 1937 елның августы). 1937 елның сентябреннән 1938 елның гыйнварына чаклы РККАның Разведка идарәсендә. 1938 елның октябреннән 1940 елның сентябренә чаклы М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә эшли: тактика кафедрасында гомуми тактика укытучысы (1938 елның февраль-апрель айлары), махсус факультетның 2нче курс башлыгы (апрель-октябрь), разведка кафедрасы башлыгы (1938 елның октябре — 1940 елның сентябре). Кафедраны җитәкләгән чорда «махсус бурыч үтәү өчен» чит илдә озак вакытка сузылган командировкада була. 1939-1940 елларда совет-фин сугышында катнаша. Кызыл Байрак белән бүләкләнгән генерал-майор Минзакир Әпсәләмов — 1940 ел башыннан сугыш тәмамланганчыга кадәр — Төньяк-Көнбатыш фронт штабының разведка бүлеге башлыгы. Бер үк вакытта, 1940 елның октябреннән 1941 елның июненә чаклы — совет-фин сугышының нәтиҗәләрен өйрәнү комиссиясендә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1941 елның июнь-июль айларында көньяк-көнбатыш юнәлештә (Көньяк-Көнбатыш фронт штабы) махсус бурыч үти.

ГРУ җитәкчелеге белән конфликттан соң разведкадан гомумгаскәри хезмәткә күчерелә: 17нче запастагы укчы бригада командиры һәм Уфа гарнизоны башлыгы (1941 елның июле — 1942 елның августы), Көньяк Урал хәрби округына керүче 4нче запастагы уку бригадасы командиры (1942 елның августы — 1943 елның феврале). Февраль аенда генерал-майор Минзакир Әпсәләмовны «ышанычны акламау» сылтавы белән вазифасыннан азат итәләр һәм шул округның Хәрби советы карамагына җибәрәләр. Генералны шулай тинтерәтүләрендә хәрби разведка җитәкчелегенең «кулы уйнау» ихтималы бар. Шул ук вакытта разведка вәкилен хәрбиләрнең өнәп бетермәүләре дә бик мөмкин. Әпсәләмов май аеннан — кабат фронтта: әүвәл 18нче укчы дивизия командирының урынбасары, ә инде декабрь аеннан командир итеп билгеләнә. 8нче армия составында Әпсәләмов командалык иткән дивизия Мга посёлогы юнәлешендә башланып киткән һөҗүм операциясендә катнаша. 1944 елның гыйнварында дивизия һөҗүмгә күчә һәм дошманның ныгытылган оборонасын өзеп, мөһим тимер юл узелы саналган кала тибындагы Мга бистәсен азат итә. Моннан соң дивизия «Мга» исемен йөртә башлый. Новгород-Лужск операциясе барышында Тосно каласын азат иткән өчен генерал-майор Минзакир Әпсәләмов һәм дивизия Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнә. 1944

елның июнендә дивизия Карелия фронтының 7нче армиясе составында Свирск-Петрозаводск һөҗүм операциясендә катнаша. Һөҗүм барышында 18нче дивизия Свирь елгасын кичә һәм дошман оборонасын өзеп, 30 чакрым «тирәнлектә» алман гаскәрләре тылына үтеп керә. Дивизия сугышчылары тарафыннан 100дән артык торак пункты дошманнан азат ителә. Бу уңышлары өчен дивизия һәм шәхсән генерал Әпсәләмов II дәрәҗә Суворов орденына лаек булалар.

Генерал-майор Әпсәләмов 1944 елның августыннан — 131нче, ә сентябрь аенан 31нче укчы корпуслар командиры итеп билгеләнә. Карелия фронтының 14нче армиясе составындагы Әпсәләмов корпусы Петсамо-Киркенес операциясендә катнаша. Дивизия частьлары Петсамо бистәсеннән көньяк-көнбатыштарак дошман оборонасын өзәләр һәм 23 октябрьдә Никель бистәсен азат итәләр. Тиздән корпус норвег-фин чигенә чыга һәм сугыш тәмамланганчыга кадәр үзе яулаган территорияне саклый. Минзакир Әпсәләмов Карелия фронты һәм сугыштан соң Беломорск хәрби округына әйләндерелгән гаскәрләр составына керүче 31нче корпус белән 1944 елның сентябреннән алып 1946 елның апреленә кадәр командалык итә. 1946 елның маеннан 1959 елның августынача К.Е.Ворошилов исемендәге Югары хәрби академиядә өлкән укытучы. Аннары — СССР Кораллы көчләре Генштабы Хәрби академиясендә: фәнни-тикшеренү бүлеге башлыгы (1959 елның августы — 1962 елның сентябре), өлкән укытучы (1962 елның сентябре — 1967 елның июле), консультант (1967 елның июле — 1971 елның ноябре). 1967 елдан отставкада, 1971 елдан — пенсиядә. Узган гасырның 60нчы елларында генералның 70 яшьтән өлкәнрәк көе хәрби хезмәттә булуы — сирәк күренеш. Димәк, ул чын-чынлап үз урынында булган.

ГРУ генерал-майоры Минзакир Әпсәләм улы Әпсәләмов Ленин, дүрт Кызыл Байрак, I дәрәҗә Богдан Хмельницкий, II дәрәҗә Суворов, «Мактау Билгесе» һәм Азәрбайҗанның Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, шулай ук медальләр белән бүләкләнгән. Үкенечкә каршы, үз ватанында аның кебек сирәк легендар шәхес хөрмәтенә нәрсәдер эшләнүе билгесез.

**Генерал-майор (25.09.1943. №1050) Иван Михайлович Алиев — татар халкына мәгълүм булмаган каһарман милләттәшләребезнең берсе. Ул 1892 елның 19 октябрендә Тимер-Хан-Шура каласында (хәзерге Дагыстанның Буйнак каласы) туа.** 2010 елгы халык санын алу мәгълүматларыннан күренгәнчә, калада 63 меңләп кеше яши. Халыкның 76 проценттан күбрәген аварлар һәм кумыклар тәшкил итә. Сан буенча 7нче урында торучы татарлар исә — 205 кеше (0,33%). Соңгы елларда Бөек Ватан сугышында һәм аннан соң да, фамилияләре татарныкы булып та, исемнәре һәм әтиләренең исемнәре русныкы булып йөргән байтак генералларның чын атлары ачыклана башлады. Андыйларга Мордовиянең Ләмбрә районы составындагы Таласлау атлы татар авылында туган Советлар Союзы Герое генерал-полковник Фатыйх Хәсән улы Чураковны (Чураков Фёдор Харитонович), Ульян өлкәсенең Яңа Малыклы районына керүче Лабит исемле татар авылында дөньяга аваз салган авиация генерал-лейтенанты Әхмәтгәрәй Нәсыйбулла улы Рамазановны (Ромазанов Сергей Николаевич), Аксубай районының Яңа Ибрай авылы егете генерал-майор Алмас Мәхмүт улы Әдһәмовны (Адгамов Александр Михайлович), Норлат районының Урта Чаллы авылыннан чыккан генерал-майор Ибраһим Кәрим улы Сафинны (Сафин Игорь Кириллович) һәм башкаларны кертергә мөмкин. Татарстаннан, Мордовиядән һәм күрше Ульян өлкәсеннән чыккан татар генералларын шулай «яшергәнне» башка төбәкләрдә туып үскәннәрне тагы да ныграк буташтырулары тамчы да шик уятмый. Шуңлыктан, Алиевның (әлбәттә, аныкын гына түгел) чын биографиясен ачыклау, һичшиксез, кирәк һәм ул киләчәк эше. Бөек Ватан сугышында корпуслар белән командалык итүчеләрнең биографик сүзлегендә *(Великая Отечественная. Комкоры: военный биографический словарь / под. общ. ред. М.Г.Вожакина. — М.: Жуковский; Кучково поле, 2006. — Т.1. — 672 с.)* Алиев татар милләтеннән дип күрсәтелгән. Хәрби архивларда һәркем үз милләтен ничек күрсәткән — шулай языла.

Алиевны 1913 елда Рус император армиясенә алалар. 1916 елда Павлов хәрби училищесын тәмамлый. Прапорщик Алиев Беренче бөтендөнья сугышында катнаша: Румын фронтында җәяүле разведка командасы башлыгы. 1917 елның июненнән

Одессада урнашкан Кызыл гвардия отряды инструкторы, 1918 елдан РККА сафларында хезмәт итә. Гражданнар сугышы елларында Көньяк һәм Көнчыгыш фронтларда алып барылган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Август аеннан Шестопаловның Украинада хәрәкәт итүче партизаннар отрядында адъютант һәм начальник була. Ноябрь аеннан Кызыл Армиянең Курск Коммунистлар ротасында өлкән разведчик. Аннары Кызыл Армиянең аерым Курск марш батальонында хезмәт итә: батальон адъютанты, гренадерлар командасы башлыгы, батальон командиры. 1919 елның апреленнән — Көнчыгыш фронтның 5нче армиясе составындагы запас полкта: гренадерлар командасы башлыгы, техник рота командиры, аерым сапёрлар ротасы командиры һәм полкның хәрби-торак комиссиясе башлыгы. Төгәл бер елдан Иван Михайлович Алиевны Одессадагы комсостав курслары ротасы командиры итеп билгелиләр. Шул елның августыннан — Кара диңгез яр буе оборонасы штабының разведка мөдире ярдәмчесе һәм мөдир вазифасын вакытлыча башкаручы. Октябрь аеннан — 14нче армия составындагы 41нче укчы дивизия штабында разведка башлыгы ярдәмчесе һәм башлык вазифаларын вакытлыча башкаручы. 1921 елдан исә — Киев чик саклау округы ВЧКсының махсус бүлегендә оператив разведка отделениесе башлыгы ярдәмчесе, сентябрь аеннан — 194нче чик батальонында рота командиры. 1922 елның башыннан ВЧК гаскәрләренең 112нче аерым батальон роталары һәм махсус бүлекләр командиры, май аеннан — ГПУ гаскәрләренең аерым 113нче батальоны командиры. Август аеннан Украина хәрби округына керүче 23нче укчы дивизиянең 67нче укчы полкы командиры урынбасары, аннары 51нче Перекоп һәм 15нче укчы дивизияләрдә батальоннар белән командалык итә. 1924 елда Харьковтагы комсоставның югары кабатлау курсларында — әзерлек бүлеген, 1925 елда РККАның Югары хәрби-педагогия курсларын тәмамлый. 1925-1930 елларда Берләштерелгән Урта Азия хәрби мәктәбендә һәм Идел буе хәрби округының Саратовтагы мәктәбендә төрле вазифалар башкара. 1930 елның октябреннән Алиев — Төньяк Кавказ хәрби округына керүче 23нче укчы дивизиянең 66нчы укчы полкы командирының хуҗалык эшләре буенча ярдәмчесе. 1933 елның ноябреннән отставкада.

Иван Михайлович Алиев 1940 елның гыйнварында кабаттан РККА сафларына чакырыла һәм Урал хәрби округындагы Магнитогорск запастагы команда составының хәрби белемнәрен күтәрү курсларында батальон командирының тактик әзерлек буенча ярдәмчесе итеп билгеләнә. Бер айдан — әлеге курсларның тактика җитәкчесе. Төгәл бер елдан — сәяси состав курсларында уку-укыту бүлеге башлыгы. 1941 елның июль аеннан Ижау каласында оешучы 313нче укчы дивизиянең 1068нче укчы полкы командиры. Сентябрьдә дивизия Карелия фронтына җибәрелә һәм 7нче армия составында сугышка керә. Дивизия әүвәл Петрозаводск һәм Кондопога калаларын дошман һөҗүменнән саклый, аннары Медвежьегорск оператив төркеме составына кертелә һәм каланың көньягында оборонада тора. Декабрь башында дошман совет гаскәрләренең саклану линияләрен өзә һәм Пиндуши белән Медвежьегорск калаларын басып ала. Нәтиҗәдә дивизиянең чигенү юллары ябыла. Әмма дивизия сугышчылары Повенецк култыгы буйлап 8 декабрьдә камалыштан чыга.

1942 елның августында полковник Алиевны 314нче укчы дивизия командиры итеп үстерәләр. Волхов фронтының 2нче Удар армиясе составына кертелгән дивизия Синявин һөҗүм операциясендә һәм 1943 елның гыйнвар-март айларында Ленинград блокадасын өзү максаты куелган «Искра» операциясендә катнаша. Әлеге һөҗүм барышында Алиев яугирләре фронтның удар төркеме флангын саклыйлар. Бераздан Алиев дивизиясе 2нче Удар һәм 67нче армияләр составында Мга, Красносельск-Ропшинск, Ленинград-Новгород операцияләрендә сынала. Кингисепп каласын азат иткәндәге батырлыклары өчен 314нче дивизия «Кингисепп» исеменә, ә аның командиры Иван Алиев Кызыл Байрак орденына лаек була. 1944 елның октябреннән генерал-майор Алиев — 124нче укчы корпус командиры. Корпус сугышчылары Балтыйк буе һәм Көнчыгыш-Пруссия һөҗүм операцияләре барышында үзләрен данга күмә. Хәрби хәрәкәтләрне яхшы аңлап тормышка ашырганы һәм оста

командалык иткәне, шулай ук батырлык һәм кыюлык үрнәкләре күрсәткәне өчен милләттәшебез II дәрәҗә Кутузов ордены белән бүләкләнә.

Сугыш тәмамланганнан соң, генерал-майор Иван Михайлович Алиев Дон хәрби округында пехота офицерларының белемен күтәрү курслары башлыгы итеп билгеләнә, 1946 елның февраленнән — Львов урман техниклары институтында хәрби кафедра башлыгы. Шул елның июненнән — отставкада. 1964 елның 11 февралендә Волгоград каласында вафат була. Дүрт Кызыл Байрак, II дәрәҗә Суворов, II дәрәҗә Кутузов орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән.

**Татар милләтенә мәгълүм булмаган тагын бер корпус командиры гвардия генерал-майоры (15.07.1941. №1865) Кирзимов Александр Ильич 1897 елның 12 декабрендә Верный каласында (хәзерге Казакъстанның Алматы каласы) туа.** 1910 елда шәһәр училищесында 2 классны тәмамлый һәм хезмәт юлын кулакларга ялланып эшләүдән башлый. 1913-1915 елларда — Алматының тәмәке фабрикасы эшчесе. 1915 елда Рус император армиясенә чакырыла. Әүвәл Екатеринбургтагы 120нче запастагы пехота батальонында хезмәт итә. Аннары — Көнбатыш фронтта хәрби хәрәкәтләрдә катнашучы 18нче Влодак полкында рядовой һәм унтер-офицер. 1916 елда яраланып Сызраньда дәваланганнан соң, 1917 елның ноябренә кадәр — Ташкенттагы Себер (кайбер чыганакларда — Сембер) пехота полкында кече унтер-офицер. 1917-1922 елларда Гражданнар сугышында катнаша. Октябрь революциясеннән соң ук Ташкенттагы Ирекле кызылгвардия отрядына кушыла. Чины — кызылгвардеец. 1918 елның гыйнвар-февраль айларында Ташкенттагы 1нче Совет полкында взвод командиры. 1918 елның февраленнән Төркестан фронты карамагындагы 1нче Совет полкының кавалерия разведкасы башлыгы, август аеннан 5нче кавалерия полкында эскадрон командиры ярдәмчесе һәм 1920 елның февраленнән эскадронның хәрби комиссары. 1919 елда яралана. 1920 елның июленнән Кирзимов — Төркестан фронтының 4нче кавалерия полкында эскадрон хәрби комиссары һәм 1921 елның гыйнварыннан — эскадрон командиры.

1921 елның декабрендә Кирзимовны ВЧКның Термиздагы 36нчы чик саклау бригадасының 34нче эскадронына командир итеп күчерәләр. 1922 елның мартыннан — ВЧК отрядларының Көнчыгыш Бохара экспедициясе башлыгы, 1923 елның февраленнән — ОГПУ гаскәрләренең аерым чик саклау эскадроны командиры. 1924 елның май аеннан борынгы Керки каласында (1999 елдан бәйсез Төрекмәнстанның беренче президенты С.Ниязовның әтисе Атамурат исемен йөртә) урнашкан ОГПУ гаскәрләренең 7нче һәм 47нче Үзбәк чик саклау отрядлары коменданты ярдәмчесе. Басмачыларга каршы җәелдерелгән сугышларда катнаша. 1925 елдан — Төньяк Кавказда: Грозныйдагы ОГПУ гаскәрләренең 53нче Чечен дивизионы командиры ярдәмчесе. 1926 елның гыйнварында шундый ук вазифа йөкләнеп, ОГПУ гаскәрләренең Орджоникидзе каласындагы 46нчы дивизионына күчерелә. Әлеге хәрби берләшмәләргә куелган төп бурыч — Төньяк Кавказдагы законнан тыш дип игълан ителгән һәм азатлык көрәшенә күтәрелгән формированиеләргә каршы сугышу. 1927 елның апреленнән ОГПУ гаскәрләренең Махсус максатлардагы Грозный дивизионы командиры (Грозный каласында). 1929-1930 елларда Кирзимов РККАның командирлар составының белемнәрен күтәрүне максат итеп куйган кавалерия курсларында укый. 1931 елның октябреннән ОГПУ гаскәрләренең Нальчик каласындагы Аерым Төньяк Кавказ милли кавалерия дивизионы командирының ярдәмчесе һәм ОГПУ гаскәрләренең Махачкаладагы 48нче Дагыстан дивизионы командиры. Тагын бер елдан ОГПУ гаскәрләренең Пятигорскида урнашкан 81нче кавалерия полкы командиры вазифаларын башкара башлый. 1934-1936 елларда М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академия тыңлаучысы. Академияне тәмамлаганнан соң, НКВД гаскәрләренең 16нчы кавалерия полкы командиры итеп билгеләнә. Полк 1939 елда Украинаның Львов өлкәсенә керүче Броды каласы тирәсенә күчерелә һәм 1940 елда НКВД чик буе гаскәрләре Баш идарәсенең 16нчы аерым мотоукчылар полкы итеп үзгәртелә. Полк 1941 елның февраленнән НКВДның оператив гаскәрләре карамагында.

Бөек Ватан сугышы башланганда, полковник Александр Кирзимовның полкы

Көньяк-Көнбатыш фронтның флангын саклап, Стыр елгасы буйлап заслонда тора. 26 июнь көнне полк командиры яралана, әмма алгы сызыкны калдырмый — вазифасын үтәүне дәвам итә. Өч көннән НКВДдан чакыру ала һәм полкын Тернопольдә калдырып, Мәскәүгә оча. Аны НКВД тарафыннан оештырылучы 15 укчы дивизиянең берсенә — 265нче дивизиягә командир итеп билгелиләр. Тулысынча оешып бетмәгән дивизияне — 11 мең 200 кешедән торырга тиешле дивизия нибары 5539 кешедән тора — Ленинград фронтына озаталар. Генерал-майор Кирзимов яугирләре август башында Выборг янында сугышка керә. Авыр сугышлар барышында дивизиянең калдыкларын алгы линиядән чыгаралар, ә Александр Ильичны, «ышанычны акламу» сылтавы белән 1941 елның 24 августында вазифасыннан азат итәләр һәм Ленинград фронтының шул көнне дөнья күргән боерыгына (№00103) ярашлы рәвештә, Хәрби совет карамагына җибәрәләр.

Генерал-майор Александр Ильич Кирзимов 1941 елның 14 сентябреннән 6нчы аерым укчы бригада командиры итеп билгеләнә. 1941 елның 28 декабреннән кабат Оборона халык комиссариаты карамагында. 1942 ел башыннан Урта Азия хәрби округында: гыйнвардан — 102нче, апрельдән — 105нче кавалерия дивизияләре командиры. 1942 елның 2 августыннан Мәскәү хәрби округында 6нчы һава-десант корпусы командиры. Корпус сугыш хәрәкәтләрендә катнашмый, хәрби әзерлек белән шөгыльләнә. Декабрь аеннан үз корпусы базасында оешкан Югары Башкомандование Ставкасы резервындагы 6нчы гвардия һава-десант дивизиясенә командалык итә. Оборона Халык Комиссариаты боерыгы нигезендә (№0283) дивизия 1943 елның февралендә Төньяк-Көнбатыш фронт составына бирелә. Кирзимовка исә кабат башка вазифа йөкләнә: март аеннан ул — Ставка резервындагы 380нче укчы дивизия командиры. Бу вазифада ул нигездә частьлар оештыру һәм аларны фронтка озату белән шөгыльләнә. Апрель аенда генерал Кирзимов командалык иткән 380нче укчы дивизия Брянск фронтының 3нче армиясе составына кертелә. Июль аеннан милләттәшебез — Касыйм каласындагы пулемётчылар училищесы башлыгы. Мәскәү хәрби округы командующие генерал-полковник Павел Артемьевич Артемьевның Кирзимовка биргән характеристикасыннан бер өземтә: «Ул — дисциплиналы, эшен намус белән башкаручы генерал, әмма вузларда эшләү тәҗрибәсе житенкерәми».

Гвардия генерал-майоры Александр Ильич Кирзимов сугыш тәмамланганнан соң да шул вазифасында кала. Тик 1945 елның июлендә авырып госпитальгә эләгә һәм 1946 елның маенда, сәламәтлеге начараю сәбәпле, отставкага чыга. 1955 елның 7 маенда Мәскәүдә вафат була. Ленин (1945 елның феврале), ике Кызыл Байрак (1936 һәм 1944), I дәрәҗә Ватан Сугышы, Бохара Республикасының Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән.

**69нчы укчы корпус командиры полковник (1940) Нәҗип Шәнгәрәй улы Хәмитов 1898 елның 5 декабрендә (яңа стиль белән — 18 декабрь) Уфа губернасының Уфа өязенә керүче, мишәрләр һәм йомышлы татарлар нигез салган Олыкүл авылында (хәзерге Башкортстанның Кырмыскалы районы) туа.** Беренче бөтендөнья, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша.

1917-1918 елларда патша армиясендә: бу чорда Нәҗип Хәмитов Идел буе хәрби округының Вольскидагы 245нче запастагы полкның укыту командасын тәмамлый һәм Уфадагы Мөселман пехота полкында кече унтер-офицер званиесендә хезмәт итә башлый. 1918 елның июнендә демобилизацияләнә, әмма июль аенда гомуми мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырыла һәм адмирал А.В.Колчакның 3нче аклар армиясе составындагы 16нчы Татар полкының сапёрлар командасына рядовой итеп алына. Анда ул фельдшерлар әзерләү курсларын тәмамлый һәм армиянең Томск губернасының Тайга станциясендә урнашкан җыелма госпиталендә хезмәт итә. Кызыл Армиягә каршы үткәрелгән хәрби хәрәкәтләрдә катнашмый. 1919 елның декабрь ахырларында кызылларның уңышлы һөҗүмнәре нәтиҗәсендә аклар Томск, Новониколаевск калаларын һәм Тайга станциясен калдырырга мәҗбүр булалар. Нәҗип Хәмитов исә үз теләге белән 5нче Кызыл Армия сафларына баса һәм Томскидагы хәрби госпитальгә нәзир итеп билгеләнә. 1920 елның августында Кызыл Армиянең каладагы Хәрби-пехота курсларын тәмамлый һәм взвод

командиры вазифасында Казандагы Татар милли полкына күчерелә. Декабрь аеннан — РККАның 6нчы запас полкында.

1921 елда Нәжип Хәмитов Идел буе хәрби округының Казандагы Югары хәрби мәктәбендә укый. Аны тәмамлауга, авырып госпитальгә эләгә һәм тиешле ялын алганнан соң, Одесса губернасының ЧКсы карамагына җибәрелә. Биредә ул партиянең хәрби отрядларыннан саналган Одессада урнашкан Махсус максаттагы ЧОН (махсус максаттагы частьлар) аерым бригадасының 6нчы батальонында рота командиры һәм батальон командирының ярдәмчесе вазифаларын башкара. Аннары — Берёзовка каласындагы 2нче аерым ЧОН батальонында взвод командиры. 1924 елның җәендә батальон таратылганнан соң, Хәмитов Ананьев каласындагы Украина хәрби округына керүче 95нче укчы дивизиянең 283нче укчы полкында рота командиры ярдәмчесе, взвод һәм рота командирлары булып хезмәт итә. 1930 елның май-август айларында рота командиры вазифасында 95нче артиллерия полкында стажировка үтә. Кабат 283нче укчы полкка әйләнеп кайта: рота командиры, батальон штабы башлыгы, полк штабы башлыгы ярдәмчесе. 1930 елның 5 ноябреннән 1931 елның 3 июленә кадәр Нәжип Шәнгәрәев РККАның «Выстрел» комсоставның белемнәрен күтәрү курсларында укый. 1934 елның маеннан Казанда урнашкан 71нче укчы дивизиянең — 212нче, ә аннары Алабугадагы 213нче (сонрак 3нче укчы полк итеп үзгәртелә) укчы полкларында штаб башлыгы. Сентябрь аеннан Идел буе хәрби округына керүче 86нчы укчы дивизиянең 258нче укчы полкында штаб башлыгы. 1939 елның сентябреннән шул ук округтагы — 209нчы запастагы укчы, 1940 елның гыйнварыннан 18нче запастагы укчы дивизиянең — 90нчы запастагы укчы һәм ноябрь аеннан 18нче запастагы укчы бригаданың 578нче запастагы укчы полкларына командалык итә.

Бөек Ватан сугышы башланганда, полковник Нәжип Хәмитов — Идел буе хәрби округының 422нче укчы дивизиясендә штаб башлыгы, октябрь аеннан исә 72нче запастагы укчы полк командиры. 1942 елның февраленнән Төньяк фронтка керүче 1нче удар армиянең 397нче укчы дивизиясендә штаб башлыгы. Демянск һөҗүм операциясендә катнаша. Декабрь аеннан — К.Е.Ворошилов исемендәге Югары хәрби академия тыңлаучысы. Әлеге абруйлы академияне тәмамлауга, полковник Хәмитов 1943 елның маенда 69нчы укчы корпусның штаб башлыгы итеп тәгаенләнә. 1943 елның 1-30 июль көннәрендә Мәскәү өлкәсенең Люберцы каласында оештырылучы шул корпусның командиры вазифасын башкара. Август аенда Ставка карамагындагы 21нче армия составына керүче корпусны Көнбатыш фронтка озаталар. 69нчы укчы корпус армия частьлары белән берлектә Смоленск һөҗүм операциясендә катнаша. Шул сугышлар барышында, 5 сентябрь көнне, полковник Хәмитов һәлак була.

Геройны бүләкләү кәгазеннән өземтә: «Һөҗүмнәр вакытында Хәмитов барлык штаб хезмәтләренең югары хәрби әзерлеген тәэмин итте, вазгыятькә тирәнтен һәм һәрьяклы анализ ясады. <...> Үзенә буйсынган гаскәрләр һәм берләшмәләр, шулай ук дәрәҗә буенча өстенрәк торучы штаблар белән даими элемтә булдыруга иреште. <...> Ул вазгыятьнең үзгәрүенә карап, тиз арада үзгәрешләр кертә алу сәләтенә ия».

Полковник Хәмитов Ленин, Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән.

**Рәис ЗАРИПОВ**

***Редакциядән:***

*Авторыбыз киң мәгълүмат биргән корпус командирлары арасына тагын бер милләттәшебез кертелергә тиеш түгелме икән? Түбәндәге хатта аның турында беребез дә белмәгән фактлар китерелә шикелле. Шундый хәрби җитәкчебез булганны документаль төстә раслый алмассыз микән, Рәис әфәнде?*

# МИЛЛИ КАҺАРМАН ГЕНЕРАЛ ХӘСӘН САЛИХОВ

1895 елның 10 апрелендә туган ул, Татарстанның Нурлат районында булса кирәк. Авылы билгеле түгел. Сәбәбе — чит илләрдә яшәүче әсирләрне совет агентлары аулап йөриләр иде. Без, Илдәге туганнарыбызга зарар килмәсен диеп, чын исем-фамилияләребезне яшереп йөри идек.

Мин генерал Хәсән ага белән сугыш туктагач, 1945 елны Германиянең Мюнхен шәһәрендә Фраймандагы SS казармасында таныштым. Бу казармада бераз торганнан соң, безне Германиянең Обер Байерен өлкәсендәге Миттенвальд шәһәренә күчерделәр...

Без Песнер казармасында тордык. Бу лагерьда төрле милләт әсирләре булса да, без аны «Төрек лагере» диеп атадык. Мин инде бу лагерьда генерал Салихов ага белән якыннанрак таныштым. Сугыштан соң Германиядә 8 миллион чит ил кешесе бар иде. Гитлер аларның күбесен эшкә, коллыкка алып килгән булган. Алар әкренләп төрле илләргә китә башладылар. Лагерьдагы Русия мөселманнары да урыннарыннан кузгалдылар. Төркия дәүләте дә Германиядәге мөселманнарны үзенә ала башлады. Минем күп дусларым, генерал Хәсән ага Салихов та, Төркиягә китте. Мин Германиянең Ной Ульм шәһәренә барып урынлаштым. Анда эшкә кереп, үз көнемне үзем күрә башладым. Генерал Салихов ага, Төркиягә китсә дә, мине онытмады...

Генерал Салихов ага сугышта каһарманлык күрсәткән татар генералларыннан булган. Берничә мәртәбә җәрәхәтләнгән. Соңгы вакытта корпус (4 дивизия) белән командалык иткән. Ул үзенең корпусы белән немецларның көчле армиясен (100 мең кеше) тар-мар иткән, каһарманлыгы өчен берничә орден алган. Армиядә үзен солдат-офицерлар да бик сөйгәннәр. Татар солдатлары исә «Хәсән ага» диеп йөргәннәр. Мина Салихов аганың корпусында булган кешеләр белән сугыштан соң очрашырга туры килде. Бу кешеләрнең берсе — Кырым татары, ә инде икенчесе хәзер Австралиянең Брисбанн исемле шәһәрендә торучы Хәбиб Фәйзуллин, алар Салиховның каһарманлыгы турында исләре китеп сөйләделәр...

Салихов ага Аллаһка ышанган олуг галим иде. Ул Төркиягә киткән Төркия Хәрби академиясе генералы профессор Мәҗит Сакмар ага белән Төркиядә «Идел — Урал» журналын чыгарды. Төркиянең башка күп газета-журналларында татар халкы турында төрле исем-псевдонимнар астында бихисап мәкаләләр язды. «Без татарларга нәрсә кирәк?» — дигән китап бастырып чыгарды. Германиядә чыгучы, рус телендәге «Освобождение» газетасында да күп мәкаләләр бастырды. Гарәп телен яхшы белүе сәбәпле, гарәпчә газета-журналларда катнашты. Аның мәкаләләрен Нью-Йоркта чыга торган «Новое русское слово» газетасында да еш күреп була торган иде.

Салихов ага күп яза иде. Ул үлгәнче милли азатлык фронтында көчен кызганмый эшләп килде. Мин аны энциклопедик белемле кеше дим. Мин үзем дә гарәп хәрефләре белән яхшы язам, ләкин генерал Салихов агага җитә алмыйм. Бернинди язу машинасы да аның кебек матур яза алмас иде. Ул миңа атнасына иң кимендә 3-4 дәфтәр калынлыгында хат язып торды. Аның хатларын мин «энциклопедик сүзлек» дияр идем...

Салихов ага карт кеше түгел иде әле. Җиң сызганып, милли фронтта эшләп йөргән көннәренең берсендә сукыр эчәк белән хастаханәгә керде. Шул операциядән котыла алмады, вафат булды. Минем фикеремчә, аны халкыбызның дошманнары үтергән булуы мөмкин. Аның үлеме милләтен сөйгән барча кешеләр өчен зур югалту булды.

**Минһаҗ Хаҗи Исмәгыйли (Измайлов Минач).**

***

Мөхтәрәм Укучым!

1993 елда фәкыйрегез Ибраһимга әлеге Сина тәкъдим ителгән язма авторы Минһаҗ ага Исмәгыйли белән очрашып, озак кына әңгәмә кору бәхете насыйп булды.

Шул очрашудан соң ул мина ике хат юллады.

Беренче хатында ул татар халкының даһи юлбашчысы Гаяз Исхакый белән үзенең

очрашулары турында, Җәлил һәм җәлилчеләр турында кыйммәтле мәгълүматлар да кертеп, тәфсилле хикәят язган иде. Ул хатны, «кайнар» чагында ук, мин Ижауда чыга башлаган «Янарыш» газетасы редакциясенә тапшырдым. Ләкин, ни сәбәптәндер, хат озак ятып, басылмады һәм гомумән юкка чыкты. Кыйммәтле тарихи документ югалды! Копиясен генә биргән булсам икән... Авыз пешкәч, икенче хатны бирергә ашыкмадым. Тик, кызганыч ки, очрашуыбыздан соң икеме еллап вакыт үтүгә, Минһаҗ ага мәңгелек дөньяга китеп тә барган... Инде, Кадерле Укучым, аның бу хаты, соңга калып булса да, Сиңа ирешсә иде! Бәлки, генерал каһарманыбызның нәсел кардәшләре дә табылыр иде...

Автор турында кыска гына булса да белешмә бирмәсәм, аның якты рухын рәнҗетү булыр иде.

Минһаҗ ага Чуашстанның Шыгырдан авылында туып үскән. Туган елы 1909 булса кирәк. Ул 1928 елда Касыйм татар педучилищесын тәмамлаган һәм туган авылында балалар укыткан. 1933 елда Казан университетының география факультетында белемен күтәрә башлаган, «халык дошманнарын» эзләү кампаниясе башлангач, Шыгырданнан ераграк китеп югалырга карар иткән — Үзбәкстанның Маргелан шәһәренә килеп урнашкан. Монда ул мәктәптә укыткан, бер үк вакытта, Ташкент университетында белем алуын дәвам иткән. Диплом казангач, мәктәп директорлыгына тәгаенләнгән. Биредә ул, үзе кебек, тыныч почмак эзләп килгән шагыйребез Зыя Ярмәки (балалар яратып җырлый торган «Ак каен» авторы) белән танышып, дуслашып яшәгән. Тормышының чәчәк ату чоры була бу. Тиңдәше Фатыймага өйләнеп, нәни улын һәм кызын сөю бәхетенә ирешә. Ләкин бәхете озакка бармый...

Явыз язмыш дулкыннары аны хәсрәт диңгезенә чумдырып кына калмый, газап океанына да ыргыта.

М.Исмәгыйли 1941 елның сентябрендә фронтка алына. Күп орышларда катнаша, Курск–Орёл дугасындагы бәрелешләрдә өлкән политрук Минһаҗ Измайлов, яраланып, әсирлеккә эләгә. Мең газаплы тормыш башлана...

Ниһаять, көрәш фашизмны тар-мар итү белән тәмамланса да, ярты үлеккә әверелгән Минһаҗ тагын да биш ел буе үлем белән яшәү арасында җәфалана, хастаханәләрдә ауный. 1951-1970 елларда автозаводта кара эшче булып хезмәт итә (немецлар читләргә яхшы эш бирмиләр), сәламәтлеге какшап, пенсиягә чыга...

Әсир язмышыннан гарык Минһаҗ үз ватанын өзелеп сагынган, туган иленә кайтырга талпынган, әмма, утызынчы еллардагы рәхимсез террорны исендә тотканлыктан, Сталин режимының хәрби әсирләргә карашын яхшы белгәнлектән, кайтырга батырчылык итмәгән. Йөрәк парәләренең иминлеге хакына ул үзенең исәнлеген, кайдалыгын хәбәр итүдән дә ваз кичкән.

*Сандугачлар сайрый, әй, тагын да*
*Илкәемнең матур таңында.*
*Шулар моңы китми җанымнан,*
*Узган гомерем кайный аңымда...*
*Ватанымны уйлыйм иртән-кичен,*
*Алып синнән илһам җимешен,*

— дип өзгәләнгән Минһаҗ.

Озак еллар узгач кына, нарасыйларының сугыш елларында ачтан үлүен, хатынының нахакка гаепләнеп Себергә озатылуын ишетә ул. СССР территориясенә беренче кат 1982 елда гына аяк баса ала. Үләренә 2-3 ел калгач кына туган туфрагына бөтенләй кайта...

Бик тә югары милли рухлы кеше иде Минһаҗ абый. Урыны җәннәттә булсын!

**Ибраһим БИЕКТАУЛЫ**

***Редакциядән:***

*Мәшһүр язучыбыз Тәүфикъ Әйди «Казан утлары»нда (1992 ел, № 11) «Йөртә безне язмышлар» дигән зур язма чыгарды. Аның «Кайтып булмый тиз генә» дигән бүлеге Минһаҗ Исмәгыйлигә багышланган.*



1946 ел.



1975 ел.

*Госман Бакир (1896-1982) — балалар язучысы. Гражданнар сугышында (1918) һәм Бөек Ватан сугышында Украинадагы Тернополь шәһәрен ике мәртәбә азат итүдә катнашкан шәхес. Тарихта андый хәл бардырмы, әйтүе кыен.*



*Офицер Габдрахман Әпсәләмов. 1943 ел.*



*Язучы Габдрахман Әпсәләмов. 1960 ел.*



*Фронтовиклар очрашкач.*
*Язучы Әнәс Галиев (сулда),*
*шагыйрь Нури Арсланов. 1989 ел.*



*Татар шагыйрьләре Венада.*
*Мөхәммәт Садри (сулда)*
*һәм Гали Хуҗи. 1945 ел.*



*Брест каһарманы*
*Пётр Гаврилов (уңда) һәм*
*язучы Самат Шакир.*
*Үткән гасырның*
*60нчы еллары.*

# ЙӨРӘК ХӘТЕРЕ



Мин, әлеге язманың авторы, үзем дә сугыш чоры баласы, ул чактагы вакыйгаларның бер шаһиты. Фашистлар Германиясен һәм милитаристик Японияне җиңүнең 70 еллыгы көннәрендә ул авыр елларны, сугышта катнашучылар һәм тыл батырлары белән очрашуларны хәтеремдә кабат яңартам. Күпмилләтле халкыбыз каһарманлыгы турында уйлаганда, үз әсәрләремдә Бөек Җиңүгә ир-атлар керткән өлешне күбрәк яктыртам икән дигән нәтиҗәгә килдәм. Ләкин сугышта һәм аннан соңгы чорда хатын-кызларның роле дә бәяләп бетергесез бит. Иҗатымның шушы ягын тигезли барып, бу документаль язмамны, кадерле укучыларым, гаҗәеп язмышлы Нәкыя Мөхәммәтфатыйх кызы Сәфәровага (кыз чагындагы фамилиясе — Фатыйхова) багышлыйм. Ул соңгы чирек гасырда Казанда, улы — мәгълүм дәүләт эшлеклесе Әсгать Әхмәт улы Сәфәров гаиләсендә яши.

Бөек Ватан сугышында катнашкан Нәкыя Фатыйх кызына 2015 елның 20 июнендә 92 яшь тула. Күз генә тимәсен, ул әле бүген дә терекөмеш кебек, бик актив, хәтере үткен, эзлекле. Менә без аларның Баровое Матюшинодагы йортларында утырабыз һәм ул миңа үткән көннәрдәге вакыйгаларны тәфсилләп сөйли. Әңгәмәдәшемне тыңлап, ул күрсәткән документларны карап, бу чын мәгънәсендә олы кеше язмышындагы хәлләргә гаҗәпләнүдән тәннәрем чымырдый. Аның турында хикәяләр, повесть-романнар язу гына түгел, кинофильмнар төшерергә кирәк, канлы егерменче гасырда халкыбызның күргәннәре, аның язмышы, батырлык-чыдамлыгы хакында моннан да яхшы, дөрес әсәр булмас иде.

Барысын да тәртипләп бәян итик. Хезмәт сөюгә һәм моңга бай Сарман ягындагы Карашай Саклау авылында таза тормышлы мөселман дине әһеле Мөхәммәтфатыйх хәзрәт Хәертдинов һәм игелекле Мәсрурә абыстай яши. Йорт-җирләре ныклы була — сыер-сарык, атлар асрарга да урын җитәрлек, мунча һәм башка корылмалар да бар. Шунда тәгәрәшеп, инде кул астына кереп, өч бала: 1921 елгы Мәхәсим, 1923 елгы Нәкыя һәм 1927 елда туган Мәгариф үсә.

Бу якларда да Совет власте урнаштыру буенча революция давыллары булып уза. Утызынчы елларда тырышып эшләгән халык иркенрәк яши башлый. Күп терлек асраган, сөрү җирләре, печәнлекләре булган Хәертдиновлар гаиләсе дә шундыйларга керә.

Күмәкләштерү шаукымы 1932 елда Карашай Саклау авылына да килеп җитә. Нәкъ шул елларда Татарстанда, Советлар Союзы дип аталган иксез-чиксез илдәге кебек үк, «канэчкеч кулакларга» һәм «дин ялчылары» — хәзрәт-муллаларга, поп һәм башкаларга моңарчы күрелмәгән басым башлана. Югарыдагы большевистик хакимият күрсәтмәләрен үтәп, җирле коммунарлар «кулак» Мөхәммәтфатыйх хәзрәтне, хәләле Мәсрурә абыстай һәм 11 яшьлек Мәхәсим, 9 яшьлек Нәкыя һәм 5 яшьлек Мәгариф белән бергә, үз йортыннан куып чыгаралар. Хезмәт сөюче гаиләнең барлык терлек-туарын тартып алып, авыл читендәге ташландык алачыкка күчерәләр.

Шул ук елның җәй ахырында, әлеге түбәнсетүләрне һәм тормыш ачысын күтәрә алмыйча, изге Ураза бәйрәме көнендә Мөхәммәтфатыйх хәзрәтнең йөрәге тибүдән туктый. Ул әле нибары 51нче яшендә генә була.

Ятим гаилә яшәү өчен яраксыз шушы алачыкта ике ел буе көн күрә. Карашай Саклау авылының һиммәт иясе — 49 яшьлек Мәсрурә абыстай кышкы суыкларда да, көзге-язгы баткаклыкта да тишек чабатасын киеп теләнеп йөрергә мәҗбүр була. Ачлыктан интегүче балаларын ничек тә туендыру өчен, ул Сарман ягы авылларын кат-кат әйләнә. Тишек-ертык кием-салымнан җил-салкыннарда болай йөрү эзсез үтми, әлбәттә. Мәсрурә абыстай үпкә чиренә дучар була һәм аяктан кала. Түшәктә

яткaндa дa ул, беренче чиратта, балаларын кайгырта. «Әй, йөрәк параләрем, — ди ул, — соңгы көннәрем җитә. Әтиегез мине үз янына алыр, ахры. Әмма сез бик бетеренмәгез. Минзәләдә ятим балалар йорты ачылган дип ишеткән идем. Әгәр мин әтиегез янына бөтенләйгә китеп барсам, шул балалар йортына урнашырга тырышыгыз. Анда сезне ачка үтермәсләр, шәт...»

Чыннан да, Мөхәммәтфатыйх хәзрәт вафатыннан соң ике ел дигәндә Мәсрурә абыстай да, балигъ булмаган өч баласын Ходай Тәгалә хөкеменә калдырып, якты дөньядан китеп бара.

Бу 1934 елның җәе ахырында була. Әниләрен соңгы юлга озатканнан соң, аның әйткәннәрен тыңлап, яланаяклы өч бала Минзәләгә таба кузгала. Ин өлкәннәре Мәхәсимгә унөч яшь, Нәкыяга — унбер, энеләре Мәгарифкә нибары җиде яшьләр була. Хәер сораша-сораша, кич кундыруларын үтенеп, авыллар аша узалар. Үч иткәндәй, ник бер ат-арбалы кеше очрасын. Нәни энеләре бик нык арыгач, абыйсы һәм апасы аны чиратлашып күтәреп баралар. Шулай илле чакрымлап юл үтеп, хәлдән тайгач, балалар Минзәлә балалар йорты капка төбенә килеп егылалар.

Бәхетләренә, аларны бик тиз табып, эчкә алып керәләр. Юындыралар, өс киеме дә, аяк киеме дә бирәләр. Туйганчы ашатып, йокларга яткыралар. Балаларын әлеге йортта какмаячакларын әйткән Мәсрурә апа хаклы булып чыга. Чит-ят казна йортында, әлбәттә, бәхет турында сүз бармый, ләкин алар ач-ялангач түгел. Уку елы башлангач, балаларның өчесе дә мәктәпкә бара. Шулай итеп, тук тормышның ике елы узып та китә. Абыйлары Мәхәсимне ФЗӨ — фабрика-завод өйрәтүләре училищесына укырга алып китәләр. Аның соңрак заводта эшләвен, ә 1939 елда фин сугышында катнашып, Советлар иле чикләрен саклаганда һәлак булуын Нәкыя белән Мәгариф байтак еллардан соң гына беләләр.

Алгарак узып шуны әйтим: Сарман ягының «кулак» ятимнәре — Мәхәсим, Нәкыя һәм Мәгариф — өчесе дә дәһшәтле сугышларда катнаша.

Мөхәммәтфатыйх хәзрәт белән Мәсрурә абыстайның кече кыз-уллары Минзәлә балалар йортында биш ел яши. 1939 елның ноябрендә фин-совет сугышы башлангач, балалар йортының матди хәле кискен начарлана. Кече яшьтәге ятимнәрне Минзәлә һәм аның тирәсендәге башка район авылларының житешлерәк гаиләләренә тараталар. Мәгарифне дә каядыр алып китәләр. Нәкыя аның язмышы турында күп еллар буе бернәрсә дә белми. Бактың исә, Мәгариф ят гаиләләрдә армиягә чакыру яшенә җиткәнче тәрбияләнгән икән. 18 яшьләрендә аны Ватаныбызга бәреп кергән Гитлер илбасарларына каршы сугышка алалар. Ул туган якларына кайткач, Нәкыя апасын эзләп таба.

Нәкыя исә 1938 елда Минзәлә балалар йортында җиденче классны «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый һәм үзе кебек бер кыз белән Казанга, Болак буенда урнашкан педагогик училищега укырга җибәрелә. Кызлар тулай торакта яши. Стипендияләре ачка үлмәскә җитәрлек була. Минзәлә балалар йортында тәрбияләнгән кызлар монда да сынатмый — гел «бишле» билгеләренә укыйлар.

Дәһшәтле сугыш алды елларында Казан педучилищесын ябалар һәм анда хәрби госпиталь ясыйлар, ә укучыларны башка уку йортларына тараталар. Кайберәүләр Минзәлә педучилищесына эләгә, ә Нәкыя Фатыйхованы, Бөек Ватан сугышы башланырга бер ай кала, Спас педучилищесына билгелиләр.

Тик Казанда педучилище ябылыр алдыннан өлкән курс студентларын республикабызның мәгариф министры Кантюков үз янына җыя һәм быелгы чыгарылыш укучыларының күбесе Байкал буена, Бурят-Монгол автоном республикасындагы татар авылларында балалар укытырга җибәреләсен әйтә. Өлкәннәр хәтерлиләр: ул елларда Россия составындагы Бурятия Республикасы шулай дип атала иде.

Шул рәвешле, яшь-яшь укытучылар төркеме 1941 елның 20 июнендә ерактагы таныш булмаган республикага килеп төшә. Бер-ике көн үтүгә, Гитлер баскынчылары белән зур сугыш башлану турында игълан ителә. Яна килгән укытучылардан егетләрне шунда ук фронтка җибәрү өчен хәрби комиссариатка чакыралар. Дус кызлары Рәйсә һәм Мәүлия белән бергә Нәкыяне, шулай ук башка кызларны да Транссебер тимер юлы буендагы татар авыллары мәктәпләренә урнаштыралар. Ә монда мәҗбүри күмәкләштерү елларында ук «кадерле» Иосиф Сталин тарафыннан Арча, Дөбъяз, Апас һәм Әтнә районнарыннан сөрелгән татарлар яшәп ята икән. (Төбәк исемнәренең

алфавит башында урнашуларына игътибар итегез. Мөгаен, Советлар Союзының башка өлкәләренә алфавит буенча башка районнарның кумәкләшергә теләмәгән крестьяннары эләккәндер). Байкал буендагы татар авылларында хәерчелек хөкем сөрә. Мәктәпләрдә дәреслекләр дә, дәфтәрләр дә юк. Яшь укытучылар сирәк кенә булса да төрле киңәшмәләрдә, конференцияләрдә очрашып зарланышалар. Үзара киңәшкәннән соң, алар Себердән качарга карар кылалар.

Беренче булып Татарстан ягына юл тоткан поездда Мәүлия китеп бара. Ә Рәйсә бер якташыбызга кияүгә чыга. Нәкыя дә кая, ничек китү турында уйлана. Татарстанда туганнары һәм якыннарыннан берәү дә юк бит. Әмма бу ач Селендум авылында Себер патриоты булып яшәүдә дә мәгънә юк.

Әлегә монда калган якташ кызлар белән бергәләп Нәкыя дә тимер юл вокзалына килгәли, монда нинди поездлар тукталуын күзәтәләр. Совет солдатлары төялгән күпчелек составлар Көнчыгышка юнәлә. Алар, уйнап-көлеп, кызларны үзләре белән китәргә чакыралар. 1945 елның гыйнвар көннәренең берсендә кызларның түземе төкәнә, алар Көнчыгышка баручы хәрби эшелонга утыралар. Солдатлар аларны кыерсытмый, киресенчә, туйганчы ашаталар. Ә бер старшина даими азык-төлек белән тәэмин итүгә язып куя.

Эчке Монголияне үтеп, совет гаскәрләре төялгән эшелон Кытай чигендә үк урнашкан Баян-Тумен шәһәрчегендә туктала. Монда исә япон басып алучыларына каршы сугыш бара. Шулай итеп, Сарман районының Карашай Саклау авылында туган яшь укытучы Нәкыя Фатыйхова Кытай чигендәге Совет хәрби гарнизонында авиация часте хәрби хезмәткәре булып китә. Авиатор формасын киеп, ул Ватаныбызның Ерак Көнчыгыш чикләрен саклый башлый. Бер төркем кызларга бик авыр һәм хәтәр эш йөклиләр — бомбардировщикларга япон гаскәрләренә атарга әзерләнгән йөкне төяп торалар.

9 майда гитлерчылар белән сугышта җиңү турында шатлыклы хәбәрне Нәкыя Фатыйхова хәрби аэродромда башкалардан да алданрак ишетә. Ерак Көнчыгыштагы хәрби хезмәт айлары да сизелмичә үтеп китә. 1945 елның сентябре башында япон хөкүмәте тулы капитуляция турында белдерә. Ә шул ук елның 20 декабрендә Баян-Тумен аэродромы хезмәткәрләрен демобилизацияләү турында фәрман чыга. Кичәге укытучы татар кызларын мәйданга тезеп, берләттән икешәр медаль: «Германияне җиңгән өчен» һәм «Японияне җиңгән өчен» медальләре, бик яхшы хезмәт иткән өчен бүләкләү документлары тапшыралар. Хәтта Кытай ефәгеннән, йон тукымадан тегелгән күлмәкләр, башка киемнәр, матур итекләр салынган чемоданнар да өләшәләр. Кызларга атап бик күп матур сүзләр әйтелә, командование туган якларына кадәр хәерле юл теләп кала.

Иптәш кызлары кайсы-кая тарала башлый. Демобилизацияләнгән Нәкыя Фатыйхова, сугыштан соңгы матавыклар белән, Новосибирск һәм башка зур станцияләрдә күчеп утыра-утыра, ниһаять, Казанга кайтып житә. Туган яклар тарта икән шул.

Казанда ул Саклык кассасына керә һәм хәрби запасын — монгол тугрикларын совет рубльләренә алмаштыра. Күзгә күренмәс көч аны Уфага баручы поездга утырта һәм Бөгелмә станциясендә төшеп калырга мәҗбүр итә. Аннан җәяүләп, нининдер авылларда куна-куна, район үзәге Сарманга барып житә. Авылдашларында кунып, икенче көнне караңгы төшкәндә, туган авылы Карашай Саклауга кайтып житә. Авыл башында инде ут алынган йортларның тәрәзәләренә карап тора, ә керергә беркеме дә юк. «Исәнме, туган авылым! Исәнме, Карашай Саклау, мин, ятимә кыз, абый-энем белән сине тугыз яшьлек чагымда ташлап, Минзәлә балалар йортына дип киткән идем...»

Чыннан да, кичәге солдат кызны 1946 елның караңгы гыйнвар кичендә туган урамына тартып кайтарган көч каян килә соң? Кыз шуларны уйлап, озак тора. Кинәт кенә бер йорттан көянтә-чиләкләрен асып хатын-кыз чыга һәм коега таба юнәлә. Солдат киемендәге кызны күреп, анын янына килә һәм кызны уй-фикерләреннән аралый:

— Син кем сон, кая барасың?

— Мин Мөхәммәтфатыйх хәзрәт һәм Мәсрурә абыстай кызы... — дип кенә әйтә ала Нәкыя.

— Әй, Алла! — дип, хатын көянтә-чиләкләрен төшереп җибәрә һәм урам буйлап йөгереп китә.

Аннан соң аңлашылганча, ул Мөхәммәтфатыйх хәзрәтнең туганнарына чапкан икән. Берничә минуттан Нәкыяне туганнары чолгап ала һәм өйләренә алып китә. Әлеге йортта ирләре Бөек Ватан сугышыннан кайтмаган өч гаилә яши икән (чыннан да, сугыш һәм аннан соңгы елларда авылда байтак гаиләләр өйдәш булып тора, болай салкын кышларны үткәрү җиңелрәк булгандыр).

Бу йортта Мөхәммәтфатыйх хәзрәт туганнарыннан өч гаилә яши икән. Нәкыя әлеге зур бер гаиләгә унөченче кеше булып кушыла. Ике көн узгач, авылга Сарманнан Нәкыя әнисенең иптәш кызы Кифая Аксакова кунакка килгәнлеге мәгълүм була. Ул район мәгариф бүлегендә эшли икән. Мәсрурә абыстай кызы Нәкыянең авылга кайтканын ишеткәч, ул аның янына килә. Барысы турында да сорашкач, кичәге укытучы кыз, бүгенге хәрби сафлардан җибәрелгән Нәкыягә РОНОга килергә куша.

Икенче көнне үк Нәкыя район үзәге Сарманга юл тота. Беренче эш итеп хәрби комиссариатта исәпкә керә, сугышчан медальләрен саклауга тапшыра һәм район мәгариф бүлегенә юнәлә. Аны РОНО мөдире үзе кабул итә. Бик җылы әңгәмәдән соң, Карашай Саклау авылы мәктәбенә рус теле укытучысы итеп тәгаенләнгән юллама бирә. Шулай итеп, кичәге солдат, әтисенең туганнарында торган хәлдә, авыл балаларын рус теленә өйрәтә башлый.

Автор буларак, мин бу урында әлеге гаиләнең фаҗигале язмышы турында хикәяләвемне туктатып торам һәм гаҗәеп бер хис белән: «Барысы да Аллаһы Тәгалә кулында шул! Без барыбыз да бер Ходай коллары, Аның ихтыярында йөрибез!» — дим.

Язмышның шундый авыр борылышларыннан соң туган җиренә исән-имин кайта алырмын дип уйлады микән Нәкыя Фатыйховна?! Ул бүген дә, биш намазын калдырмыйча, һәрдаим кабатлый: «Мин бөтен күңелем белән Ходай Тәгаләмә рәхмәтлемен. Мин — бик бәхетле кеше, гомерем бәхет эчендә уза. Моңа ничек шөкер итмисең?!»

Бик күпне күргән акыллы-зирәк, киң күңелле, кешеләргә карата саф ярату Аллаһы тарафыннан бирелгән кеше генә шулай фикер йөртә ала.

Туган авылында Нәкыя ел ярым укыта. Аны авылдашлары да, укучы балалары һәм мәктәпнең башка укытучылары да ихтирамлы карашы өчен яраталар. Ул хезмәт хакы алып эшли, туганнарына торак урыны һәм туклану өчен өлеш чыгарырга онытмый.

Киләчәк язмышларын алдан белгәндәй, педучилище тәмамлаганда дипломнарын кулга бирмәгән булалар. Сарман мәгариф бүлеге уку йортына шуны сорап хат юллый. Озак та үтми, Фатыйхова Нәкыя Мөхәммәтфатыйх кызы исеменә диплом килә.

1947-1948 уку елы башында Нәкыяне Сарман РОНОсына чакырып, болай диләр: «Без сезнең эштән канәгать. Әле яшь чагыгыз, квалификациягезне күтәрергә кирәк. Сезне Алабуга укытучылар институтына укырга җибәрәбез».

Бу тәкъдим яшь укытучы өчен Ходай бүләге сыман була. Озак та үтми, ул бик яратып, ике еллык укытучылар институтында укый башлый. Башка студентлар кебек үк тулай торакта яши, стипендия ала.

Студент чаклар — ул бит йөгерек чишмә кебек, вакыт бик тиз ага. Алабугада укуларын тәмамлап, 1949 елда югары белем турында диплом тапшырганда: «Эшкә кая бармакчы буласың?» — дип сорыйлар аннан. Нәкыя Әтнә районында әнисе ягыннан туганнары Фәйзулла хәзрәт Таҗетдин Ялчыгол нәселе яшәвен исенә төшерә. Шулай итеп, Әтнә районы мәгариф бүлегенә юллама ала һәм Татарстанның төньяк-көнбатыш ягына китеп бара. Инде бик күпне күрсә дә, аңа 26 яшь кенә була.

Әтнә РОНОсы аны Түбән Көек авылы җидееллык мәктәбенә рус теле укытучысы итеп җибәрә. Ул шунда Гөлкамал апа һәм Гарифулла ага Шәйдуллиннарда торып, дистә елдан артык балалар укыта. Авылда Нәкыяне тик яхшы яктан гына беләләр. Тирә-күрше белән аралашканда да, мәктәптәге хезмәттәшләре дә аны бик хөрмәт итәләр. Ә йорт хуҗалары Гөлкамал апа белән Гарифулла ага өчен ул үз кызлары сыман була.

1960 елның башында Нәкыя Фатыйховнаның шәхси тормышында зур үзгәреш була. — СССР Югары Советына сайлаулар көнендә колхоз рәисе, тол ир, Бөек Ватан сугышы инвалиды Әхмәт Сәфәровка кияүгә чыга. Нәкыядән унбер яшькә өлкәнрәк кызылармияче Сәфәров Сталинградны саклауда катнашкан, сугыш

ахырында каты яраланып, демобилизацияләнгән. Аның сугышчан батырлыклары дәүләт бүләкләренә лаек булган.

Монда кайбер озын телләр: «Яшь килен бик яшь тә булмаган икән...» — диярга мөмкин. Бу бик гади аңлатылса да, төптән уйлаганда, «сере» аяныч. Нәкыяның 1920–1925 елгы чордашлары Бөек Ватан сугышы юлларында ятып кала. Каһәр суккан сугыш бигрәк тә 1923-1924 елгы яшь егетләрне бөтенләй диярлек кырып бетерә. Сугыштан берән-сәрән инвалидлар гына кайта. Минем күз алдымда никадәр яшь, чибәр кызлар ир рәхәте татымыйча, бала табу бәхетенә ирешә алмыйча картайды. Жинел булмаган ялгыз тормыштан алар гасырлар бусагасында берәм-берәм китә бардылар...

...Сәфәровлар гаиләсе 150 йортлы Күлле Киме авылына күченә, монда инде урта мәктәп тә була. Сүз арасыннан, халык шагыйре Сибгат Хәким дә бу авылда туган, хәзер биредә аның музее бар.

Күлле Кимедә Әхмәт ага Сәфәров яңа йорт житкерә. Нәкыя Фатыйховна жирле урта мәктәптә укытуын дәвам итә. 1961 елның 20 октябрендә уллары Әсгать туа. Ике елдан соң кызлары Әнисә дә дөньяга аваз сала. Сәфәровларның ныклы һәм тату гаиләсе егерме елга якын шулай матур яши. Тик еллар үткән саен, Әхмәт аганың фронтта алган яралары көчлерәк сиздерә. Ул 1978 елда, 65 яшендә якты дөнья белән хушлаша. Нәкыя ханым ул чакта 55нче яше белән бара.

Туган авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Әсгать Казан дәүләт университетының юридик факультетына укырга керә һәм башкалабызга китеп бара.

Шулай итеп, Нәкыя Фатыйховна терлек-туарлы зур йортта үзе генә кала. Каникулларда, кайчакта ял көннәрендә дә улы һәм кызы кайтып йөри. Күлле Киме авылында Бөек Ватан сугышы ветераны, Татарстанның атказанган укытучысы Нәкыя Фатыйх кызы Сәфәрова ун елдан артык шулай үзе генә яши.

Әсгать өйләнә, эшли башлый һәм тиздән унайлы фатир да ала. Яшьләр әниләрен Казанга, үзләрендә яшәргә чакыралар. Нәкыя ханым гел суза килә, Әхмәт ага белән тырышып жыйган хужалыкны калдырып китү жиңел булмый. Шулай да 1990 елда, инде 67 яшендә ул Казанга килә, улы Әсгать һәм килене Луиза гаиләсендә яши башлый.

Башкаладагы фатир бик унайлы. Килене һәм оныгы белән жылы мөнәсәбәтләр урнаша. Ләкин Нәкыя Фатыйховна авылны, андагы йорт-жирен сагына, хезмәттәш укытучыларны юксына. Баштагы чорда шәһәр тормышына авыр ияләшә, урамга чыкса да, һава житми кебек. Ходай туры китергәндер инде, кисәк кенә Галимнәр йортына йөри башлый. Анда фикердәшләрен очрата, төрле секцияләр эшендә катнаша башлый. Анардан билгеле бер темаларга чыгыш ясавын сорыйлар. Шулай итеп, Галимнәр йорты эшчәнлегенә тартыла һәм ун еллап монда бик теләп шөгыльләнә. Хәзер дә ул вакытларны жылы хисләр белән искә ала Нәкыя Фатыйховна.

Балалары һәм оныклары, шулай ук якыннары — 80, аннан соң 90 яшьлек юбилеен да зурлап, жылы итеп уздырдылар.

Чал чәчле бу ханым белән аралашканда, аның хәтеренә гажәпләнәм. Бу яшендә барысын да шулай яхшы хәтерләп, жентекләп сөйләргә кирәк бит! Күз тидерүдән куркам хәтта.

Соңгы күрешүебездә Нәкыя Фатыйховна миңа тагын бер кат болай диде:

– Мин — иң бәхетле хатыннардан. Мондый бәхетне миңа Аллаһы Тәгалә ихлас күңелдән иман китерүем һәм инануым өчен биргәндер. Ходайга болай тирәнтен ышануым әти ягыннан да, әни ягыннан да зур дин әһелләре булган әби-бабайларымнан ук килә. Иң каты атеизм елларында да мин һәрвакыт күңелемдә Ана ышандым, эчемнән дә, телем белән дә бер Аллаһыма ялвара идем. Изге Коръәннең байтак аять-сүрәләрен яттан өйрәндем, биш вакыт намазымны калдырганым юк...

Мин, бу язманың авторы, Коръәни Кәрим турында китап язучы, тулы хаж кылган кеше, шулай ук мәгълүм хәзрәтләр нәселе дәвамчысы, гажәеп язмышлы Нәкыя Мөхәммәтфатыйх кызы Сәфәрованың бу фикерләре белән тулысынча килешәм, аңа исәнлек-саулык, хәерле озын гомер телим.

**Ягъсуф ШӘФЫЙКОВ**

# ШИГЪРИ МӘЙДАН НИ СӨЙЛИ?

## 2014 ЕЛДА «КАЗАН УТЛАРЫ»НДА БАСЫЛГАН ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘРГӘ КҮЗӘТҮ

2014 елда журналда дөньяга чыккан татар шигъри әсәрләрен укыгач, шәхсән үзем өчен күзгә иң ташланганнары түбәндәгеләр булды: беренчесе – милләт-халык язмышы турында уйлану-сызланулар, аның өчен чыгу юллары эзләү; икенчесе – җәмгыятьнең бүгенге халәте турында фикер йөртүләр – ана аек бәяләмә бирергә омтылу, унай йогынты ясарга алгысу; өченчесе – Тәкъдир, Вакыт турында сүз алып бару, фатализм моменты, яшәү вә үлем фәлсәфәсе, олы юатылу табарга теләү-өметләнү; дүртенчесе – яшәү-хәят мәгънәсе эзләү; бишенчесе – мәңгелек темалардан даимиләренең тагын берсе – Сөю-Мәхәббәт темасы...

Милләт, халык темасы ул соңгы дистә елларда «Казан утлары» битләрендә ин күзгә ташланган актуаль темаларның берсе булып кала килә. Илебездә үзгәрешләр башланганнан бирле инде утыз еллап татар кавеме якты үзгәрешләр көтеп, кайчакларда аларга ирешеп тә яисә бераз артка чигенә төшеп тә яши бирә. Бу табигый дә. Кайсы гына ул-кыз үз халкына, Ватанына хөр, матур яшәеш теләмәс иде, аның хокукларының аз (!) яклануына борчылмас иде икән.

Тик бу юл шактый катмарлы да, анда кайчак уңышлар очраса да, киртәләр дә аз түгел. Әмма татар халкының олы максаты билгеле вә ачык: ул – дөнья халыклары арасында үзенә лаеклы урын алу.

Шул рәвешле, милли гамь шагыйрьләрнең әсәрләрендә даими борчылу, сызлану булып җан итә. Үз исән-иминлеген (тел, дин, милли рух һ.б.) турында кайгыртмау халкыннын сәламәт булмавы, милләтләрнең олуг галактикасында аның йолдыз-кояшы батып баруы турында гына сөйләр иде.

Әнә нәрсә ди шагыйрә Нәҗибә Сафина «Өмет тирәге» әсәрендә: *Җилгә сибеп кайгы-сагышларны, / Яфрак ярыр өмет тирәге дим, / Булсам иде газиз милләтемә / Якты өмет нуры, тирәге мин!*

Шагыйрәнең якты хыялы аңлашыладыр да, билгеле... Татар шагыйрәсенең туган телдә – ана телендә иҗат итүе, алар белән укучыларны даими таныштыра баруы, дин-кыйблага тугрылыклы калуы шул өмет нурының бер өлеше була аладыр да инде.

*Ирекккә тугрылык – Ватанга тугрылык! – / Юл яру киләме көченнән? / Мәйданда: «Ирек!!!» – дип / Тилмергән көннәрнең / Минуты чыкмады исемнән («Чиксезлек»),* – дип яза шагыйрәбез Флёра Гыйззәтуллина да. Бу юлларны укыганда, шиксез, ирек, азатлык даулаган 1990 еллар башындагы Ирек мәйданы хәтергә килә.

*Тарихлардан алган сабак, / Йөрәк тибә сулык-сулык. / Мененче кат кабатлыймын: / Бергә булыйк, бердәм булыйк!* – дип яза Таһир Шәмсуаров «Бергә булыйк, бердәм булыйк» шигырендә, милли бердәмлеккә дәшеп, үткәннәребездән гыйбрәт алырга чакырып...

*Соң түгелме җанны уятырга, / Телсез калып, яшәп арыгач? / Дәшми калу дөрес булырмы соң, / Илем-телем диеп яшәгәч? («Тел язмышын уйлап»).* Бусы – Роберт Сәлахиевнын моңсурак тавышы. Дәшми калу мөмкин түгел, билгеле. Галәмнәр Раббысы – Аллаһ сиңа – кешегә тел нигъмәт биргән түгелме?!. Шиксез, һәр халык гаиләдә үз түбәсе астында яшәргә омтыла; җиһанда, йолдызлар астында үз йортын торгызырга тели. Башка гаилә белән бүлмәдәшлек бик күңелсез булыр иде ул.

Илдә, җәмгыятьтә социаль тигезсезлек барлыкка килде. Тормышта акча, мал-байлык, сату-алу белән бәйле өр-яңа сынаулар туды.

Бу яктан карасаң, татар шагыйрьләренең милли мәсьәләләргә иҗтимагый проблемалар яссылыгында игътибар итүләре искә алып китәргә лаеклы. Мәсәлән, татар авылы язмышы... Татар тәкъдире турында уйлаганда, аның чишмә башын урап узып булмый. Ул инде «ярымурыслашкан» кала түгел, тышкы кыяфәте, күккә омтылган мәчет манаралары белән үк «мин – татар авылы» дип кычкырып тора.

Рәниф Шәриповның «Биш алма» поэмасы бу яктан үзенчәлекле уйлануларга этәрергә, бәлки, аерым бер мизгелне «сискәндереп куярга да» сәләтле. Поэма иҗат әһелен соклandырган, аңа тәэсир ясаган вакыйга белән башлана: яшь кыз авылдан китеп баручы шагыйрьгә йөгереп килеп биш алма бүләк итә. Ошбу нәни генә вакыйга шагыйрь күңеленә нык тәэсир итә, ул аның күңелендә кайта-кайта төрле уйланулар, ассоциацияләр тудыра, социаль катаклизмнарга эләккән татар авылының үткәне-бүгенгесе-киләчәге турында йөрәгендә борчулы фикерләр барлыкка китерә, татар җәмгыятенең, милләтенең бүгенге халәте турында күпмедер каршылыклы уйларга да этәрә.

Шагыйрь, сызланып, болай ди: *Күпме алар, сукыр тәрәзәле, / Жансыз, ямьсез, үле авыллар! / Урамнары, зиратлары белән / Тормыш кала, күпме эш кала. / Соңгы сулышымы авылымның / Мәктәптәге шушы өч бала? («Биш алма»).*

Чыннан да, авылларның бетүе татар өчен аеруча борчулы темаларның берсе булып кала бүген. (Билгеле, гөрләп яшәп яткан татар авыллары да аз түгел.) Милләтебезнең шәһәрдә сакланып калуы шактый сораулар уятырга мөмкин. Поэма татар авылларының проблемалары турында уйланырга этәрә алуы белән кыйммәтле.

Бу яктан Рәниф Шәрипов ялгыз түгел. Мәсәлән, Чыңгыз Мусинның «Зур югалту хисе» шигыре татар авылы язмышы турындагы борчылу-сызланулар белән тулы. Анда түбәндәге юллар бар: *Авыл тирән түгә / Сукыр бер тиен хакка. / Илдә кайсы түрә / Уйлый шушы хакта? / Үксез калган авыл, / Нурсыз иртә-кичә. / Утсыз яна жанда / Зур югалту хисе.* Шуңа күрә, бәлки, татар халкының генофондын саклап калуда иң беренче катнашучылар – туган якларына хәерхаһлы кешеләрдер?!.

*Минем чабу туган жирдә, / Йолкып алып китеп кара...* – дип яза Таһир Шәмсуаров «Китеп кара» шигырендә. Гомер-гомергә нинди дер кысылулар да күрә килгән татар авылы язмышы бүген, бәлки, яхшырак якка алышына алыр?!. Моны Аллаһ кына белә.

Әйе, факт факт булып кала: татарлар башта авыллардан китеп, аннан Ватанны да калдырып, җиһан буенча кая гына сибелмәгәннәр. Шагыйребез Айдар Хәлим, мәсәлән, «Туган илгә йөгерәсе килә» исемле шигырьләр көлтәсенә кергән «Нью-Йорк сабан туенда» әсәрендә дөнья буйлап сибелергә мәҗбүр татар мөһаҗирләре язмышына кагылып, түбәндәгечә уйга кала: *Уйлап кына жыр тумый. Хис кирәк! / Ул моң булып бармый башкага. / Нью-Йорк сабан туе күздән / Югалган моң эзләп башлана.*

Чит җирләрдә, күктерәр өйләрдән торган мегаполисларда гомер итәргә дучар татар кешесе кардәшләре белән очрашулардан нәкъ менә милли рухны эзләмимени?!. Үзе дә, бәлки, ахыргача сизеп-аңлап бетермичә, Идел-Йортны, Уралларны, Хаҗитарханнарны, Әни суын, Байкүлләрне һ.б. якларны искә төшерүче милли хисләргә тирән сусау кичермиме икән ул вакыт-вакыт?!.

Дөнья буйлап таралган, сибелгән татар халкын берләштереп-җыеп торган биниһая зур байлык икән ул гасырлар аша безгә килеп ирешкән кыйммәтләр – Моң, Сабантуй, халык иҗаты, җырлар, риваятьләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, әкиятләр... Алар, шагыйрь әйткәнчә, безгә кайчак үлемнән котылырга, яхшының – яманны, акның караны җиңүенә ышанырга ярдәм итмиләрме икән? Шагыйрьләр кайчак милләт өчен чыгу юллары эзләп әкиятләргә, мифларга (аларны күпмедер яшерелгән хакыйкать тә диләр) мөрәҗәгать итәләр. Шагыйрь Газинур Морат, мәсәлән, милли тормышыбызның – вакыйгалар агышының аерым бер мизгелендә ризасызлык белдереп, болай ди: *Әкиятне башлыйк янабаштан, / Ак бүренең кайтсын әфсене.*

*/ Кабат тораташка әйләнмәсен / Ашинаның асыл нәселе. («Әкиятне башлыйк янабаштан...»)*

Бүгенге яшәеш үзәннәренә күз ташлаган шагыйрь гаҗәпләнә: әкиятнең бит ахыры яхшы бетәргә тиеш! (Бу – аксиома, хакыйкать!) Югыйсә, бу нинди сәер әкият булып чыга соң?! Нишләп әкияттә кара көчләр дә җинә бара? Ни өчен асыл нәсел әфсенләнеп (ә сихер чыннан да бар, ди Ислам) тораташка әйләнгән дә сәламәт халәткә кайта алмыйча җәфа чигә? Нинди догаларга мохтаҗ икән ул? Кайда аны коткарыр батырлар? Нинди төгәлсезлек килеп чыккан ошбу әкияттә?!.

Билгесез бер фәйләсүф әйткәнчә: «Бар да яхшы бетәргә тиеш. Әгәр начар беткән икән, димәк, әле бар да бетмәгән...» Яшь иҗатчылар да, гаделлек эзләп, яхшылыкның яманлыкны җинә алуына ышанып, фольклорга мөрәҗәгать итә. Рүзәл Мөхәммәтшинның «Ак бүре» либреттосы (татар халык әкиятләренә нигезләнеп язылган), мәсәлән, бу яктан игътибарга лаек.

Беренче чиратта, ул ак һәм караның мәңгелек көрәшен янә искә төшерә, һәм татар фольклорының әдәби әсәрләр өчен шактый бай чыганак булуын янә бер кат искәртә.

Күп кенә татар әкиятләренә хас булганча, монда да инсанның Дию пәрие белән аяусыз көрәше сурәтләнә: хан уллары аналары Ханбикә өчен батырлык кылалар һәм ахыр чиктә җиңәләр. Бу җиңүдә каһарманнарга ярдәм итүче хәлиткеч көч ул – Ак бүре, дөресрәге, ыруның Ак бүре рухына тугрылыгы булып чыга: ягъни аның күңелендә яшәгән бүрегә хас бәйсезлек ярату, кыюлык һ.б. сыйфатлар хан улларының кечесе – Тәгингә башта – Юханы (зинаны, фәхешлекне), аннан Дию пәриен (халыкның, Ил-Ватанның, гаиләнең имин тормышын бозучы кара көчне) җиңүгә илтә.

Яшь шагыйрь монда хайваннар дөньясының бер вәкиле булган бүрегә табынырга чакырмый (югыйсә бу мәгънәсез бер нәрсә – мәҗүсилек яки иң зур гөнаһ – мөшриклек булыр иде. Билгеле, кешене барлык авырлыклардан, җәфалардан фәкать Аллаһы Тәгалә генә коткара ала, башка беркем дә түгел), әмма, мөгаен, гаиләнә, Ватанына куркыныч килгәндә, бәйсезлек, кыюлык, түземлелек кебек сыйфатларга да ия булырга чакыра төсле. Гасырлар чоңгылында без үзебезнең кайбер (безне данлы, шанлы иткән) сыйфатларыбызны югалтмадык микән дип тә сорый кебек ул. Шул ук вакытта ул «Дию пәрие» безнең күңелләребездә яшәгән гөнаһлы уйлар, кимчелекләр белән дә тукланмый микән, дип фикер йөртә, күпмедер рухи үсеш турында да искә төшерә автор.

Әйе, аерым авырлыкларга эләккән кешеләр чыгу юлларын, яклауны кайдан гына эзләмәгәннәрдер?!.. Хакыйкатьне әйтә алмаганда (асылда, бу халәткә төшү кешеләрнең, кавемнәрнең гөнаһлары аркасында буладыр), алар Эзоп телен сайлаган.

Сүз дә юк, узган гасырларда, ерак түгел үткәндә дә халык иҗаты белән бергә аерым шәхесләргә бәйле сәхифәләр дә аз түгел безнең... Халкыбыз әнә шулардан нур-җылы алып яшидер дә, бәлки. Шагыйрь вә шагыйрәләребез бу турыда искә төшерүне дә лазем санныйлар. Сания Әхмәтҗанованың «Арча поезды» циклы шундыйлардан.

Әлеге хыялый поезд Татарстан тимер юллары буйлап кына хәрәкәт итеп калмый, ә галиҗәнап Тарих сәхифәләре буенча да юл ала... *Мин сәфәргә чыгам, Хәтер буйлап, / Рәшәләрдә – йолдыз тузаны...*

Һәм менә милли офыклар артындагы милли чакрымнарны тоташтырган гүзәл тукталышлар булып бер-бер артлы Арча, Әтнә якларын дөньяга таныткан олы шәхесләр турында цикллар тезелеп китә: «Мәрҗани», «Тукай хакыйкате», «Камал», «Бәшир – баш ир», «Безнең Сибгат», «Гариф», «Мәһдинамә»... Нәрсә турында сөйли ала калебләребезгә ошбу таныш вә кадерле исемнәр?.. Әлбәттә, безнең милли асылыбыз турында.

Татар зыялыларын хәтергә алу ягыннан шулай ук Фарис Фәсхинең «Җанны пакьли торган яктылык» исемле шигырьләр көлтәсенә игътибар итәргә кирәк. Татар шагыйре, сынчы-рәссамы кадерләре, бәлки, үз вакытында бик белеп тә

бетерелмәгән татар зыялыларының барельеф-портретларын ясап кына калмаган, ә шигырьләрендә аларны (Р.Әхмәтҗан, М.Әгъләм һ.б.) иҗат әһелләре буларак үзгә дөньяларында үзенчә ачарга омтылган...

Шагыйрьләребез бүген милләтнең үткәне вә киләчәге турындагы каршылыклы уйлар белән җан итәләр, болгар-татар күгендәге «догалы моннар»га да еш колак салалар, милләт язмышына кагылышлы рәвештә калеб түреннән килгән сораулар куялар һәм җавап та эзлиләр. Үткәннәребез, бигрәк тә ерак үткәннәребез... – бәйсез дәүләт-йортлар төзеп яшәгән чакларыбыз шанлы булып, данлы булып искә төшә, ә бүгенгебез бездә (бәлки, кайбер ирешелгән уңышларыбыз булса да) еш кына канәгатьләнү хисләре тудырмаска мөмкин... Аннары, шагыйрьләр күпмедер дәрәҗәдә үткәннәрне идеаллаштырырга да хаклы.

Мәсәлән, шагыйрь Марсель Галиев еш кына татарның азат, бәйсез, шанлы-данлы, гаярь чакларын сагынып яза (чыннан да, моннан әле берничә гасыр элек кенә, урта гасырларда гына татар кавеме урыс, француз, инглизләр кебек дөньяның төп халыкларыннан саналган түгелмени?!.): *Балбаллары ауган япан далаларда / Әрнеп үскән әрем – хәлләребез... / (...) / Кайтавазлар инри юашланып: / Бүгеннән без, бәлки... бөгелмәбез... («Чыдам тау да, үзән дә без...»)*

Нишләргә соң? Кем, ни безне дөньяда коткара алыр икән? Нишләп безнең халык дөнья тарихын язуда бүген әллә ни катнашмый?!. Милләтебез язмышы, киләчәге белән нинди рәк көчләр идарә итә?.. Халкыбыз өчен бердәнбер котылу юлы, мөгаен, Аллаһы Тәгалә юлыдыр.

Шагыйрьләребез ошбу дөреслекләр турында кайта-кайта, еш уйланалар. Марат Кәримов, мәсәлән, «Хатирәләр – учак көле алар» шигъри гөләндәменә кергән «Булабыз» шигырендә, уйга калып, болай ди: *Кайда булган икән безнең / Холкыбыз, йолабыз? / Шулай яшәп кем булабыз? / Монафикъ булабыз.* Шагыйрь безне монафикъ, ягъни, икейөзле булмаска чакыра. (Коръәндә монафикълар җәһәннәмнең иң түбән катламында булачак диелә.)

Билгеле, рухи-дини юл милли проблемалардан гына түгел, ә җәмгыятьтәге проблемалардан да чыгу юлы булып каладыр... Югыйсә, аларның бер-берсенә шактый ук тыгыз бәйләнгәннәре ачык күренә түгелме?!.

Шагыйрь Рим Идиятуллин «Таулар хакында ике шигыр»ендә, мәсәлән, төрле еллар кимәленнән карап болай ди: *Алданыпмы шайтан коткысына, / Әләм иттек гөнаһ, бозыкны; / «Ярлыка!» дип тәүбә кылмагачтын, / Ходай безне тәмам онытты.*

Кайсыдыр бер мизгелдә шагыйрь, «сискәнеп киткәндәй», әле күптән түгел генә булып узган Чибәркүл вакыйгасын да искә төшерүне лазем саный. Нишләп безнең – XXI гасыр кешеләренең башына күктән ташлар, кометалар ява икән?.. Пәйгамбәребезнең: «Кешеләрнең аз гына гөнаһлары да Галәмдә зур гына катаклизмнар китереп чыгарырга мөмкин», – дигән хәдисе искә килә. Димәк, кешенең Җирдәге нәни генә гамәлләре дә миллионнарча чакрым ераклыктагы зур яктылыклар таратучы йолдызларга тәэсир ясарга мөмкин икән...

Шагыйрь аерым бер мизгелне безне җаннарыбызны чистартырга, пакьләргә сәләтле, керләнгән тормышыбызга яңарыш алып килергә кадыйр булган тәүбә, истигъфар юлларына чакыра вә ахырда болай ди: *Рас яраткан икән Ходай безне / Мен-мен төрле чәчкә төсендә, – / Үрчетик гел иман вә игелек / Үсентесен җирнең өстендә! («Таулар хакында ике шигырь»).* Чыннан да, кеше бу дөньяга бәхетле булыр өчен генә килмәгән. Аның бакый яшәеш алдында бурычлары да бар. Шагыйрьләр бу турыда да еш, кайта-кайта фикер йөртә.

Сүз дә юк, күпмедер адашулар кичергән илебез туры юлга да кайтырга тели кебек. Әмма, җәмгыять соңгы елларда рәхимлерәк, яхшырак якка әверелдеме икән?!. Әллә анда башка, үзгәрәк кыйммәтләр хөкем сөрәме?

Дин-кыйбла, кызганыч, җәмгыятьтә әйдәп баручы көчкә әйләнмәде кебек әле, бу рольне күбрәк акча, матди байлык артыннан куу уйный. Олыраклар хәтерлидер: элек, социализм чорында кешеләр бер-берсенә миһербанлырак, рәхимлерәк түгел идеме? Үзара ярдәмләшү дә шактый көчле иде. Әмма, яңа урнашкан капитализм, базар икътисады үзәккә социаль тигезлекне, иптәшлекне түгел, ә индивидуализмны,

шәхси табыш артыннан кууны куйды. Шуның белән, бәлки, җәмгыять күпмедер метаморфозалар аша да узарга мәҗбүр булды. Ник дин-кыйбла, рәхимлелек, миһербанлылык җәмгыятебезнең йөрәгенә үтеп керә алмады икән?!. Уйлавымча, безгә, мөгаен, җаваплылык җитеп бетмәгәндер.

*Мин тормышны матурларга тудым, / Җавап тотам барсы өчен дә,* — дип яза Фәрит Суфияров «Өлгерергә кирәк» шигырендә.

Әйткәнебезчә, бүгенге татар шагыйрьләре җәмгыять проблемаларына гамьсез калмый. Бәлки, киресенчәдер дә: заман-дәвергә хас мәсьәләләр аларның иҗатында тулысынча чагыла.

Заман, вакыт метаморфозаларына, җәмгыяви контрастларга еш игътибар бирүче, төрле чорларның үз үзенчәлекләре турында уйланган шагыйребез Равил Фәйзуллин, мәсәлән, XXI йөз башында болай дияргә мәҗбүр: *Без яшәгән кыска гына бер гомердә / алмагачлар ничә кабат үсеп корды... / Күпме дуслар, ярлар җан тәслим кылды... / Ничә патша алышынды!.. Үзгәрешсез — / имгәтелгән Иман белән / нәҗесләнгән Җир-Ана калды... («Без яшәгән кыска гына бер гомердә...»)*

Уйлап куясың: нишләп дәверләр алышына тора, ә җәмгыять, кешеләр һаман яхшырмый икән?!. Ни өчен иманыбыз имгәтелгән, ә Җир-Анабыз нәҗесләнгән?.. Ошбу хасият безне тирән фикерләүләргә этәрә вә шушы яшәеш өчен җаваплылыгыбызны янә бер кат искә төшерә. Ирекле еллар рухи мөстәкыйльлеккә, дин-кыйблага гына юллар ачмады, кызганыч, җәмгыятьтә күпмедер зина, фәхешлек тә көчәйде. Алар җәмгыятькә дә, милләткә дә яхшылык булып кайта алмадылар, ә кешеләр тормышына фаҗигаләр генә алып килделәр. Югыйсә, безнең халыкның Ислам белән бәйле үз рухи традициясе дә бар. Башкаларга иярү безнең халык өчен хәвефле икән.

Олы дөреслекләр, рухи-кальби кыйммәтләргә омтылган иҗат әһелләренең җәмгыять белән үзенчәлекле шигъри диалог алып баруы аңлашыла да. Шагыйрә Рухия Ахунҗанова, әйтик, чордашларына түбәндәгечә эндәшә: *Әй, замандаш, синдә нинди / гамь ята соң? / Сиңа дәшәм. Миндә сорау / уятасың... («Замандашка»).* Әмма шагыйрәнең сүзенә колак салырлармы? Тыңларлармы аны? Шагыйрәнең сүзе үтәме бүгенге җәмгыятьтә?

*Шагыйрьне кемнәр таныр соң?!* — ди Салават Рәхмәтулла да үзенең «Сату-сатылу заманы!..» шигырендә, күпмедер ирония белән.

Әйткәнебезчә, капитализмга күчү илдә төрле каршылыклы реалияләр, социаль катаклизмнар да тудырды. Һәр замандагыча, ошбу чорда да кеше сыйфатлары, кеше рухы, кеше кальбе үзенчәлекле сынаулар аша уза икән... Кемнәр ничек уза ала аларны — болары инде Аллаһы Тәгалә кулында.

Фәнәвис Дәүләтбаев, мәсәлән, тормышыбызда, җәмгыятебездә гаделлек җитми дип саный: *Гаделсезлек җирдә тулып ашкан — / Бу тормышка исең китәрлек. («Караңгылыкта»).* Дамир Гарифуллин да робагыйларында XXI йөз башындагы кешеләр җәмгыятенең кимчелекләренә еш игътибар итә: *Дөнья тулы гайбәт, әләк, ялган да, / Бер-берсенә алар оста ялганган. / Хакыйкатькә санап минә шуларны, / Бу тормышта күпме адәм алданган.*

Бу яктан алсаң, аеруча тәэсирле шигырьләрнең берсе, бәлки, Гәрәй Рәхимнең «Гомер буе яна-яна яшә идең!» исемле шигъри гөләндәмендә табыладыр: *Аюдан курыкмый кеше, / Бүредән курыкмый кеше, / Таулардан курыкмый кеше — / Кешедән курка кеше. / Кояшка ышана кеше, / Әкияткә ышана кеше, / Хыялга ышана кеше — / Кешегә ышанмый кеше. («Безнең чор кешесе» (XXI гасыр хакыйкате)).* Кешеләрнең бер-берсенә ышанмавы, бер-берсеннән куркуы җәмгыятьнең бик үк камил булмавы турында сөйли.

Кешенең каршылыклы табигате турында фикер йөртүләр, билгеле, һәрвакыт булган. Мәгълүм ки, Аллаһы Тәгалә инсанны сынап карау өчен бу дөньяга яраткан, аңа иман да, нәфес тә биреп караган. Әлеге сыналу иҗтимагый тормыш яссылыгында да чагыла. Иҗтимагый мәсьәләләргә игътибар итүче шагыйрь Ленар Шәех болай ди: *Күңелләрдә тынычлык юк, / Ышанычы бармы, белмим?.. / Очын-очка ялгаучылар! / Сезне уйлыйм, җәллим... көлмим. («Шәһәр шаулый. Тормыш бара...»)*

Төрле тарихи-социаль борылышлар кичергән ил-җәмгыять, аерым кешеләрнең аларга гына мәгълүм гомер юлы... Шагыйрьләр вә шагыйрәләр вакыт-вакыт бу турыда да фикер йөртә. Шигырьләрендә моң-гамь тулы Фирүзә Җамалетдинова да илнең үткәне вә бүгенгесе турында борчылып яши: *Яхшын күпме, әллә ялганыңмы? – / Туган илем, хәлең җиңел түгел. / Бар аклыгың сине алга этсә, / Каралыгың артка тарта бүген. («Туган илем»).*

Кеше-инсан бүгенге җәмгыятьтә каршылыклы кичерешләр белән яши икән, бу җиһанда көнелләргә якты кичерешләр бирә алган ни-нәрсә кала соң? Шагыйрәләр иҗатына кагылсаң, җавап табыла кебек: бәлки, кешене кеше иткән, аның яшәешен күпмедер аклаган, саф хисләр була алган Мәхәббәт кала, Мәрхәмәт, Шәфкать...

Шигырьләрендә еш кына моңсулык булса да, шагыйрә Илсөяр Иксанова тормышка ышаныч белән күз ата: *Дәрьяларда тулы дулкыннарның / Күпме чоңгыл-упкын юлында. / Ни кичсә дә, барыбер / Һәрбер дулкын / Үз ярына кайтып егыла... («Саумы, диңгез!»)* Мәңгелекнең үзеннән барлыкка килгән яшәешкә булган бу ышаныч мөһимдер дә. Яшь шагыйрә Лениза Вәлиева да киләчәккә, язларга ышанып, яратып карый: *Бу – апрель. / Җанымның тулышкан, / Чайпалып түгелер фасылы. / Бөрешкән күңелне эретер күзләрдә – / Яшәүнең асылы. («Бу – апрель»).*

Кеше үзе үзгәрмичә, дөнья да үзгәрми икән. Без, асылда, кылганнарыбызның әҗерен алып яшибез түгелме?!. Адәм баласы туры юлда булуы белән генә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына өметләнә ала. Аллаһ тирә-юньгә хәерхаһлы кешенең үзенә дә шуны ук кире кайтармый микән соң?!. Гөлнур Корбанованың «Йөрәгемдә сагыш уянганда» шигырьләр көлтәсенә кергән бер шигыре, мәсәлән, шул турыда: *Мин белән: кайларга китсәм дә, / һәрвакыт догада торырлар, / ихластан хәерле юл теләп, / чыршылар, / юкәләр, / тупыллар.*

Җәмгыятьтәге кимчелекләрне, «авырулар»ны күргән шагыйрь вә шагыйрәләр, инде алдан әйтеп үткәнебезчә, чыгу юлын еш кына рухи янарышта эзләргә мәҗбүр. Сәләтле яшь шагыйрәбез Ләйсән Фәтхетдинова, әйтик, нәкъ менә рухи кыйммәтләр турында сүз алып бара. Рухи биеклекләргә юлның җиңел үк булмавын искәртә ул безгә: *Дөньяның малыннан баш тарттым – / Яшәүнең кызыгы калмады... / Акчага кул сузган чакта да / Бер рухи рәхәтлек алмадым. / (...) / Авыру тоймадым тәнемдә – / Кадерен оныттым саулыкның. / Чирләгән иң авыр чагында / Иманым белән мин савыктым. («Мәгънә»).*

Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) шундый бер хәдисе бар: «Житәр шундый заман: Ислам динен тоту утлы күмер тотып йөрү кебек булыр – ташларга да теләмәсләр, кулларын да пешерер». Ләкин бүген андый чор түгел, кешеләргә хакыйкый юлда тугрылык сакларга бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Шулай ук яшь, сәләтле шагыйрә Дания Нәгыймуллинаның шигырьләре рухи эзләнүләргә бай булуы, рухи янарышка эчкерсез чакыруы белән, шиксез, күңелләргә үтеп керә: *Мин гаҗәпкә калмам кебек, әгәр / Җир әйләнеп беркөн туктаса. / Кылган гөнаһларны кичерә алмый, / Язмыш таяклары тукмаса. / (...) / Кара туфрак кардәш-туганнарның / Күп сеңдергән садә каннарын. / «Кичер безне», – диеп әби сала / Мәчетләргә сәдакаләрен. («Гөнаһлы җиһан»).* Яшь шагыйрәнең «Эт тормышы» шигыре шулай ук күпләрне гамьсезлектән, битарафлыктан уятырга вә мәрхәмәт, миһербанлылык (ә бүген бу – кешеләрдән иң соралган сыйфаттыр, бәлки?!.) кылларына кагылырга сәләтле.

Әйе, кеше тәүбәгә килә, андагы кимчелекләрдән баш тартып, туры юлда гына яшәргә тели ала. Шагыйребез Хисам Камал бер әсәрендә түбәндәгечә белдерә: *Яшим фәкать каралама, / Акка гына яши алмыйм һаман. / Тормышымның бар битен дә – / Шатлыклысын, / Кайгылысын – / Төшермичә алга барам. («Гомерем минем – каралама...»)*

Милләт, җәмгыять проблемалары белән бергә шигърияттә соңгы елда күзгә иң бәрелгән темаларның тагын берсе, шиксез, ул – Вакыт, Тәкъдир, Язмыш турында эчкерсез лирик-фәлсәфи уйланулар. Хәер, бу табигыйдер дә. Вакыт, гомер агышында кешенең яшәешкә, тормыш этапларына, циклларына күз ташлавы мантыйкый шуна этәрә. Әлеге шигырьләр үзләренең фаталистик моменты белән аерым вакытларда

XXI гасыр башындагы шигъриятне дә (Дәрдемәндне, Думавины, Гафурины, Сүнчәләйне һ.б.) искә төшерә.

Клара Булатова, мәсәлән, «Гасыр аты шундый тиз чапты» шигъри гөләндәменә кергән «Төш» шигырендә биек кыядан кин дингезгә төшеп югалган таш кыйпылчыгы турында уйлана вә болай ди: *Исәбенә мәнге чыгалмадым, / Юкка чыккан нинди көнемдер? / Ничә көннәр шулай югалгандыр – / Үлчи калсан, тулы бер гомер.* Кыядан ычкынган таш кыйпылчыкларына охшаган көннәр белән тулы бер кеше гомере узып киткән икән... Бу иксез-чиксез мәңгелек дингезенә төшеп югалган бер-берсенә охшамаган көннәр күңел дәрьясында да күпмедер монсулык, сагыш дулкыннары уятырга сәләтле.

Ә шагыйрь Чыңгыз Мусин исә, Вакыт агышына, яшәеш циклларының котылгысыз рәвештә алышынып торуына карап, үзенчәлекле бер эчке гаҗәпләнү, тетрәнү кичерә: *Жилләр, жилләр, жилләр инде, / Жилгә форсат килгән инде. / Жилдән житез чаклар узды, / Без кемнәргә тиннәр инде? / Без хәзер тик кемнәр инде? («Жилләр, жилләр»).* Бу юлларны укыганда, Дәрдемәнднең атаклы шигъри юллары искә төшә: *Исә жилләр, кучә комнар... бетә эз... / Дәрыйгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез! («Без»).*

Әйе, Вакытның котылгысыз агышы, гомер чорларының туктаусыз алышынып торуы бүгенге күп кенә заман шагыйрьләре иҗатына гаҗәпләнү, сагыш, борчылу, соклану, өмет кебек хис-тойгылар алып килә.

Халисә Мөдәррисова, мәсәлән, Вакытның көтелмәгән метаморфоза-әверелешләре турында түбәндәгечә фикер йөртә: *Бирә-ала. Яшь сылу да / Инде бөкре карчык. / Шәлберәйткән баһадирны / Бу аяусыз вакыт. / (...) / Ул тезләнмәс, ул төкәнмәс / Бакыйлыкка шаһит... / ...Бер ХӘТЕР алдында баш ия / Галиҗәнап Вакыт. («Вакыт һәм хәтер»).*

«Бер Хәтер алдында баш июче» Вакыт гаять зур көч (ана кем, ни каршы тора ала соң?) буларак күз алдына баса. Шагыйрьләр Вакытны төрле образлар вә метафоралар белән бәйләп тәкъдим итәләр.

Нур Әхмәдиевнең «Вакыт» шигырендә, Вакыт һәркемне, һәрнәрсәне дә «или алган» үзенчәлекле бер җиһани-хәяти тегермән образында гәүдәләнә: *Вакыт или / Жайдакны да, / Атсызны да; / Затлыны да, / Затсызны да; / Хаклыны да, / Хаксызны да. / (...) / Вакыт белән көрәшүләр / Борынгыдан калган, / Ә кем жинә алган? / Дон Кихотлар дөнья тулы, / – Жиңдем! – дию – / ялган! («Вакыт»).*

Ә Хәнәфи Бәдигый исә үз әсәрләр тупланмасын, гомумән, «Вакытның юк башы, азагы» дип атаган. «Юк» шигырендә болай ди ул: *Бар белән юк булу арасы, / Һәркемгә шул юлдан барасы. / Килгәнне-киткәнне хәтерли / Туган жир һәм адәм баласы.*

Бу, мөгаен, адәм баласы өчен үзенчәлекле бер юатылудыр да. «Килгән-киткәнне» хәтерләүчеләр кала әле: Туган жир вә сине күргән-белгән адәм балалары. Шулай да бер сорау һаман җавапсыз кебек: ә нәрсәдә соң яшәү мәгънәсе? Бармы хәяттә какшамас якты, чын, җанга кадерле маяклар? Яшәү вә үлем арасында нинди гамь ята соң? Без – инсаннар абсурд эчендә яшәргә хөкем ителмәгән микән?!.

Хәят кырларында тукталып уйланырга мәҗбүр булган шагыйрь бер шигырендә болай ди: *Минем өчен Канун – Коръәндәге / Йөз дә үндүрт сүрә. / Алар Ходай сүзе, кануннардан / Өстен шуна күрә. («Тумыштан»).*

Димәк, Вакыт агышына, тормыш циклларының бер-берсен алыштырып торуына артык гаҗәпләнергә дә, сагышланырга да кирәкми икән, ул барыннан элек кеше өчен Галәмнәр Раббысы – Аллаһы Тәгалә биргән Сыналу Кыры булып кала: гыйбадәт кылуда, яхшылыкта-явызлыкта...

Бу фәлсәфи уйланулар, мәңгелек офыкларга багарга омтылу, яшәү мәгънәсен эзләү төрле шагыйрьдә төрлечә чагыла. Яшәү мәгънәсен эзләү, рухи иҗтиһад кылу, мәңгелек кыйммәтләр турында сүз алып барырга адымнар ясау – татар шагыйрьләренә борын-борыннан хас. Әлеге тема да 2014 елда журналда еш очраган темаларның берсе булып кала.

## ҖИҢҮНЕҢ КӨЕНЕЧЛЕ КАТЛАМНАРЫ

**Тынычлык сөюче гадел Советлар иле дөньяны кабахәт Гитлер җитәкләгән фашистлар иленнән саклап калды, дибез бит инде. Ләкин 1939 елның 23 августында нәкъ менә шул Германия белән дуслык-хезмәттәшлек пакты төзелә. Һәм бу ике ил Европаны бүлешә башлыйлар. Советлар Союзы Көнбатыш Украина, Көнбатыш Белоруссия, Латвия, Литва һәм Эстонияне яулап ала. (Финляндиягә көче җитеп бетми.) Менә шундый хәлләрдән соң Америка белән Англиянең СССР ягыннан сугышка керергә бик ашыкмавына гаҗәпләнергә кирәк микән?**

**«Чтобы защитить отечество от врагов, Пётр опустил его больше всякого врага». — Тарихчы В.Ключевский моны Пётр I хакында әйткән. Сталинга карата бигрәк тә мач килә бу. Агентлары иң көчле генералларыбызны (оборона министры урынбасары маршал Тухачевскийга кадәр барып җитеп!) үтереп чыга алса, Гитлер аларга нинди генә бүләкләр бирмәс иде икән?! Ошбу репрессия актлары; бомбага тотарга җайлы булсын дигәндәй, бөтен хәрби техниканы чик буена терәп урнаштыру (сугышның беренче иртәсендә үк меңнән артык самолёт харап ителә!); үз агентларыбызның Германия сугыш башлаячак дигән сигналларына төкереп карау (Рихард Зорге сугыш башлану көне, дивизияләр саны һәм аларның хәрәкәт схемасына кадәр җиткерә!) кебек тупас хаталарны совет халкы, амбразура каплаган солдат кебек, миллионлаган тере тән белән каплап кына төзәтә алды. Ләкин илнең җитәкчеләрен мондый корбаннар куркытты микән?.. Биш миллионлап совет әсиренең концлагерьларда газап чигүендә Гитлер гына түгел, Сталин да гаепле: ул хәрби әсирләр хакындагы Женева конвенциясеннән йөз чөерә. «Хәрби әсирләребез юк, сатлык җаннар гына бар», — ди Сталин. Теге концлагерьлардан исән кайтканнарның да күпмесе совет концлагерьларына олактырыла... Берлинга беренче булып совет гаскәре керә. Америка армиясе командующие Эйзенхауэр: «Сез Берлинны ураган мина кырын ничек шулай тиз чистартып бетерә алдыгыз?» — дип сорагач, Жуков: «Ә без анда пехотаны җибәрдек», — дип җавап бирә.**

**Менә бу җырга колак салыйк әле:**

***Смело мы в бой пойдём***
***За власть Советов.***
***И как один умрём***
***В борьбе за это!..***

**Татарларга килсәк, автономия кысаларында мескен хәлдә гомер кичергән милләтебез сугышта төп дүрт халыкның берсе була. Татар телендә хәтта фронт газеталары да чыга. Сугыш беткәндә исә кирәксезгә әйләнеп, безне дә аздан гына сөрми калалар.**

**Җиңгән солдатлар Европада халыкларның шәп яшәве турында кайтып сөйләгәч, яшьләр арасында мондагы тормыштан ризасызлык туа башлый. Сталин Бериягә яшьләрне куркытып алырга куша. Кулга алуларның яңа сериясе башлана. Бездән студентлар Аяз Гыйләҗев, Мәҗит Рәфыйков, Гурий Тавлин (булачак язучылар) төрмәгә утыртыла.**

**Җиңелсәк, ни булыр иде? Сталин изүеннән күп көчлерәк изү башланыр иде. Яуланган СССР территориясен идарә итү планы төзелә. Анда, мәсәлән, туган телдә укытуны башлангыч мәктәп белән чикләү турындагы пункт та була...**

**Рәфикъ ЮНЫС**

Мәсәлән, шагыйрь Ренат Харисның бу елда дөнья күргән шигырьләре һәрвакыттагыча үзенә хас фәлсәфи хис белән сугарылган.

Уйласаң, һәр инсан да тормышның үз вариантын яза, үз Галәмен төзи. Мәгълүм ки, бу бигрәк тә нечкә күңелле шигърият әһелләренә кагыла. Ренат Харис та, шиксез, моннан чыгарылма түгел. Бәлки, аның шигъриятен «шигырьгә әверелүче тормыш» дип атарга булыр иде. Шагыйрь тормыш-хәяттә ни-нәрсәгә генә кагылса да, ул тора-бара шигърияткә әверелә кебек.

Ренат Харисның «Кара түгәрәк» шигыре безне фәлсәфи уйланулар чоңгылына этәрә. Шагыйрь тәүдә рәссам Малевичның дөньякүләм атаклы «Кара квадрат» картинасын искә төшерә һәм болай ди: *Теләсәң ни күреп була анда! / Теләсә ни була ишетеп! / Әллә нинди дөньяларга ачык / каралыкның якты ишеге... («Кара түгәрәк»).*

Гаҗәп метафора түгелме: «каралыкның якты ишеге...» Малевичның гади генә күренгән рәсеменә карап, дөнья буйлап күпләр төрле каршылыклы, парадоксаль хис-тойгылар кичергәндер вә кичерәләрдер... Һәм, менә, татар шагыйре өчен дә бу хасият ят түгел икән. Аннары ул бөтенләй башка нәрсәне, әйтерсең лә Малевичның картинасына аваздаш булган үзенең төнге халәтен, эчке кичерешләрен дә искә төшереп сурәтли. Шагыйрь, чиксезлек, ди... Ә нәрсә соң ул без белгән чиксезлек? Галәмдәге чиксезлеккә баксак, анда миллионлаган-миллиардлаган йолдызлар күзәтәбез. Йолдызлар артында янә йолдызлар, галактикалар артында яна галактикалар... Чиге бармы аларның? Бармы бездән башка метагалактика? Без моны әле белмибез. Хәер, күкнең жиде каты бар, диләр. Без белгәне – беренче, диләр...

Татар шагыйре өчен мәңгелек хакыйкатькә илтүче фәлсәфи, трансцендентал офыкларга багу гаҗәеп мөһимдер дә. Хаклык белән кызыксыну, димәк, Аллаһ белән кызыксыну кеше йөрәгендә төрле кимәлләрдә вә кинлекләрдә яши һәм ачылып китә ала икән... Гомумән, бу чынбарлыкта һәрнәрсә дә, һәр юнәлеш тә Аллаһы Тәгаләгә генә илтә аладыр. Мәсәлән, оптимист, тормышның унай якларына игътибар итәргә яратучы шагыйрьләребезнең берсе Рашат Низами Галәмнән килгән серле авазларны да тынларга онытмый: «Каләмемнең кипмәс карасы» исеме астында чыккан шигырьләренең берсендә болай ди ул: *Галәмдәге меңәрләгән сорау / Тартып тора безне итәктән... («Астрономия»).*

Шигырьләрдәге фәлсәфилек, сүз дә юк, безне чынбарлыкны тирәнрәк вә киңрәк анларга ярдәм итә алыр иде, күңел офыкларын киңәйтеп җибәрергә сәләтле булыр иде. Поэзия еш кына фанилык һәм бакыйлык арасындагы олы уйланулар тезмәсе булып күз алдына баса.

*Баштан сыйпый серле жиһанның / Мәңгелектән килгән өннәре*, – ди шагыйрь Рәшит Бәшәр дә «Баш очымнан шаулап чор ага» исемле шигъри тупланмасына кергән бер лирик шигырендә.

Сүз дә юк, ахыр чиктә Вакыт, Тәкъдир, Язмыш турындагы фикерләр дә, яшәү мәгънәсен эзләү дә тегеләйме-болаймы дин-кыйбла темасына, Аллаһ юлында яшәү темасына гына илтә аладыр... Чөнки яшәеш бит бакый. Аның дәвамы ничек булуы безнең үзебездән генә тора түгелме?!. Бу – югарыдан иңгән кануннар.

Фәйрүзә Мөслимованың «Мизгелләр елларга биргесез» шигъри тупланмасы рухи эзләнүләргә, рухи янарышка омтылуы белән, шиксез, кыйммәтле. Шагыйрә һәр инсан өчен искиткеч мөһим булган саф тәүбә юллары турында уйлана һәм әйтерсең лә жан-кальбенең үзгеннән үк дәшәргә мәҗбүр: *Аһ, озак сынадың Син мине, / Ташлама, ярлыка, йа Раббым! («Ярлыка!»).*

Әйе, без беләбез: һәр адәм баласы да тәүбәгә, истигъфарга мохтаҗ. Ә менә адашулар ачысын татып тәүбәгә килгән инсанга тискәре мөнәсәбәт күрсәтү берничек тә хуплана алмый.

Шулай итеп, 2014 елда дөнья күргән шигъриятә ачык табылган, калку беленгән дүрт зур тема – милләт турында уйлану-сызлану, җәмгыятьнең бүгенге халәте турында фикер йөртү, тәкъдир-вакыт фәлсәфәсе, яшәү мәгънәсен эзләү – Аллаһ юлында яшәү темасына, дин-кыйбла темасына китерә, аның аша чишелеш таба. Чыннан да, рухи-дини тема соңгы елларда шигъриятебездә көннән-көн зуррак урын

ала бара түгелме икән?!. Шушы тенденция поэзиябезнең рухи-фәлсәфи янарышына да якты өмет уята аладыр, бәлки. Бүген инде маяклар юк, кая таба юл алырга дип өзгәләнү кирәк микән?!. Югыйсә, дин-кыйбла, Аллаһ күрсәткән туры юл ачык табылган, янә беленгән рухи-кальби маягыбыз булып кала. Күрәсең, әлеге тема шигъриятебездә киләчәктә төп темаларның берсе буларак ачылырга бик мөмкин. Шулай ук монда узган ел еш күренгән зур темаларның берсен – яшәешнең үзе кебек үк бакый булган Сөю-Мәхәббәт темасын да әйтеп узарга булыр иде. Ул күп кенә шагыйрьләребездә очрый һәм алар арасында, чыннан да, уңышлылары аз түгел. Әмма без мәкаләдә аларның барысын да искә алып торуны кирәк тапмадык. Шунысы бәхәссез: әлеге тема бигрәк тә яшьләр иҗатында дәвамлы. Һәрхәлдә, арада аңа кагылмаучы күңелләр аз...

Мәсәлән, үзенчәлекле стильдә иҗат итүче яшь шагыйрь Эльнар Байназаров Мәхәббәт темасына багышланган шигырендә үз халәтен аңа гына хас булганча фәлсәфи-шигъри драматизм белән сурәтләп бирергә омтыла: *Калтырый шәүләләр, әзерләп миңа дар, / Һәм гади дар түгел – җан дарын. / Беркатлы, берьяклы, беренче сөюем – / Кызганыч, бер җырдан яшәмәссең ары. («Хушлашу җыры»).*

Шагыйрь «беркатлы, беренче сөюе» белән хушлаша... Сөюсез яшәүне ул җан дарына кадаклануга тиңли. Бу күңелдә төрле хис-тойгылар барлыкка китерә. Беренче сөю дигәндә, күңелгә ак карлардай пакь беренче саф хисләр, саф сүзләр килә, һәм өлкән укучыларны яшьлеккә алып кайта.

Гомумән, мәхәббәт темасы сафлык, ихласлык белән бәйле булганда гына игътибарны җәлеп итә ала түгелме икән?!. Башкача булганда (әйтик, зина һәм башка шундый бозыклыклар белән бәйле булганда), ул күңелләргә канат бирә алмыйдыр, кеше күңеленә яктылык алып килергә сәләтсездер һәм аны рухи биеклекләргә дә алып менә алмыйдыр... Гомумән, саф сөю-мәхәббәт темасы кеше күңелен пакьләүдә, сафлауда гомер-гомергә Аллаһ биргән үз миссиясенә ия булып каладыр.

Тәнкыйть йөзеннән, бу урында ике нәрсәне әйтеп узарга мөмкин: беренчесе – шигырьләрдә пессимизмның көчлелеге (монысы шагыйрьнең җәмгыятьтә тоткан ялгызрак урыны белән аңлатыла ала, алшарт булмаса да), шагыйрь, уйлавымча, зарланып кына яшәмәскә, кешеләргә өмет тә бирергә, үз тәҗрибәсенә бәйле чыгу юлларын да күрсәтергә тиешледер, мөгаен; икенчесе – иҗтимагый проблемаларга игътибарның азрак булуы. (Әйтик, татарларда, французларда нинди генә шагыйрьләр булмаган, әмма татар халкы – аның проблемалары белән яшәргә омтылган Тукайны, французлар аның проблемалары белән яшәргә омтылган Гюгоны сайлаганнар.) Безнең шигърияттә академизм көчле (бу да кирәк, билгеле), тик рух очышы, фәлсәфи эзләнүләр, шигъри яңалыкка омтылу азрак сыман.

...Тарихның үзенә тиң шигъри мәйдан батырларны билгеләү белән тәмамланыр. Монда хөкемдар – милләт, халык, галиҗәнап Вакыт. Ул – гадел. Хөкеме – йөз елларга... Әмма күңелләрне куандырганы бүген бөтенләй башкада: шигъри мәйдан уртасындагы пакь биеклеккә ымсынган шигъри колгага менәргә теләүчеләр кимеми, киресенчә, елдан-ел арта гына бара.

**Илшат ВӘЛИУЛЛА**

# «АЛАР БИТ БЕЗНЕ ТАШЛАП КИТТЕЛӘР...»

***

*Мин Ватан сугышын күрмәдем. Һәр язучының үзенә якын, үзе сайлаган һәм гомерлек юлдашы иткән темасы була. Язучы үз чордашлары алдында да, киләчәк буын алдында да мәгълүм бер чор өчен, билгеле бер тема өчен җаваплы. Бер язучы да бөтен дөньяны колачлый алмый ич. Толстой йөз томнар әсәр язган икән, бу әле йөз тема күтәрдең дигән сүз түгел! Толстой ике-өч теманы ала да, шулар тирәсендә, төрле яктан кила-кила, тирәнәйтеп, киңәйтеп һаман үз сүзен үткәрә бара. Мин Толстой белән үземне чагыштырырга һич тә җыенмыйм, әмма мин үземнең т е м а м н ы , ү з у р ы н ы м н ы тапкан кеше дип йөрим. Минем төп әсәрләрем сугыштан соңгы чорга багышланганнар. Сугыш чорындагы авыл һәм аның аннан соңгы еллар өчен татар әдәбиятында мин җавап бирәм. Әгәр мин бу чорны алдагы буыннар аңларлык, бәһаләрлек һәм тетрәнерлек итеп яза алмаганмын икән, монда, заманның күптөрле киртәләреннән тыш, мин дә гаепле.*

*...Мин сугышның үзен күрмәсәм дә, сугышка китеп, башларын салган йөзләрчә кешеләрне күргән. Мин озатып калган иптәшләрем, классташларым: Җәкәү, Үткен Ибаны, Җәпүш, Җаграп дәдәйләр, мин сокланып йөргән егетләр — Кунун Бәчелие, Кайнарларның биш улы, башкалар... Мин соңгы сулышымда да ул кешеләрне оныта алмам. Гүзәл, акыллы кешеләр булганнар — Баграж керәшеннәре! Матур кешеләр...*

*А.Гыйләҗевнең Н.Әсәнбаевка язган хатыннан.*
*31 март, 1975 ел. Казан*

***

«Камыш бармак, көмеш тырнак» (1969-1970) әсәре темасы белән хәрби повестьларга якын тора. Аяз Гыйләҗевнең бу әсәре Бөек Ватан сугышы елларында дөньяның гомуми торышын чагылдыра: кешелекнең фашизм кансызлыгына каршы көрәшен гәүдәләндерә. Билгеле булганча, «Хрущёв җепшеклеге» елларында язучыларда сугыш вакыйгаларын дөрес итеп сурәтләү теләге арта, алар киң даирә укучыларга таныш булмаган сугыш эпизодларын, XX гасыр трагедиясенең яна, гадәти булмаган якларын ачып бирергә телиләр. Җинүче геройлар, батырлар һәм каһарманнар гына түгел, сугышка буйсынып, рухи яктан бетерешкән дезертирлар да игътибар үзәгенә куела.

Беренчеләрдән булып бу темага Чыңгыз Айтматов мөрәҗәгать итә. Күләме белән артык зур булмаса да, гаҗәеп көчле эчтәлекле «Кара-каршы» («Лицом к лицу», 1957)[1] повестенда ул сугышның ерак кыргыз аилына барып җитүе һәм Сәйдә исемле яшь хатынның тормышын тәмугка әйләндерүе турында бәян итә. Аның ире — Исмәгыйль фронттан качып кайткач, гаиләне кара күләгә булып хурлык пәрдәсе каплый[2]. 1958 елда А.Дроздов бу повестьны рус теленә тәрҗемә итә, һәм

[1] Айтматов Ч. Лицом к лицу // Ала-Тоо. — 1957. — №6.
[2] Ч.Айтматовның беренче җитди басмасы укучыларны тетрәндерә, тик әдәби тәнкыйть мәкаләләре ике

ул «Октябрь» журналында басылып чыга[3]. 1980-1990 еллар чигендә Ч.Айтматов, ике фаҗигале сюжетны — коллективизация һәм Бөек Ватан сугышын — берләштереп, повестьны тагын да камилләштерә. Шул рәвешле, «Кара-каршы» әсәренең икенче редакциясе дөнья күрә[4].

Ун ел үткәч, бу тема Мирсәй Әмирне дә кызыксындыра. 1969 елда аның «Җан көеге» повесте языла[5]. Бу әсәрдә язучы халыкның сугыш елларындагы авыр тормышын гәүдәләндерә, тылдагыларның үз-үзләрен аямыйча эшләүләренә, ватанпәрвәрлегенә мәдхия укый. Фронтка барганда, юлда качып киткән Камәретдин образына М.Әмир аерым игътибар бирә. Дезертир үз гаиләсен генә түгел, күршесенең гаиләсен дә хурлык упкынына төшерә, якыннарын җәфаланырга мәҗбүр итә. Заман таләпләренә тугры калып, автор повестьта партия җитәкчеләренең халык массаларын тәрбияләүдәге ролен ассызыклый. Конфликт «дезертир» дип даны чыккан герой Камалетдиннең өенә кайтуы һәм чын дезертир Камәретдиннең хөкем ителүе белән чишелә.

Бөек Җиңү юбилее алдыннан дезертирлык темасына мөрәҗәгать итү язучылардан кыюлык һәм тәвәккәллек сорый. Әдәбият галимнәре бу темага кискен каршы килә, татар халкының намусын саклап калырга тели. Кырым татарларын депортацияләү, Идел буенда яшәүче татарларга адресланган янаулар һәм гаепләүләр, Муса Җәлилнең фаҗигале язмышы — болар барысы да татар зыялыларын уйланырга мәҗбүр итә.

Аяз Гыйләҗевнең 1969-1970 елларда язылган повесте «Совет әдәбияты» журналында басылып чыкмый[6]. Тәнкыйтьчеләр дусларына хыянәт итеп, фронттан качып кайткан куркак дезертир турындагы бу әсәрнең басылырга хокукы юк, дип саный. Алар фикеренчә, бу повесть Бөек Ватан сугышы вакытында батыр уллары фронтта көрәшкән, халкы бөтен ил белән бергә тыл авырлыкларын кичергән татарларның авторитетын төшерә. Язучының хатыны Н.Гыйлежева фикеренчә, нәкъ менә шуна күрә дә әлеге әсәр шундый драматик язмышка дучар була. Бәлки, рецензентлар ике татар язучысының бер үк дезертирлык темасына повесть язуы мөмкин хәл түгел, дип уйлаганнардыр; А.Гыйләҗев Ч.Айтматов әсәрен татар җирлегенә яраклаштырып язган, диючеләр дә табылгандыр.

Бүген, повесть язылуга ярты гасыр үткәннән соң, без А.Гыйләҗевнең «Камыш бармак, көмеш тырнак» повестендагы новаторлыгын, яңалыгын тиешенчә бәяли алабыз. Өч повестька чагыштырма анализ ясаганда исә, алар арасында, чыннан да, охшаш сыйфатлар булганлыгы күзгә ташлана: дезертирлык темасы, сугыш һәм тынычлык хронотопларын бер-берсенә каршы кую, үсеш кичерә яисә тормыш төбенә тәгәри торган характерлар. Ч.Айтматов та, М.Әмир белән А.Гыйләҗев тә «халкыннан башка кеше юк, кеше бары тик халкына бәйле булганда гына көчле, кешелеклелек, мәрхәмәтлелек сыйфатлары бары тик халыктан килә» дигән фикердә тора[7].

Шулай да А.Гыйләҗевнең дезертирлык мәсьәләсенә киңрәк каравы сиземләнә. Язучы конкрет-тарихи фактны иҗтимагый-фәлсәфи гомумиләштерүләр рәтенә күтәрә.

А.Гыйләҗев кешенең гадәти булмаган, катлаулы ситуациядә — сугыш вакытында — нинди үзгәрешләр кичерүен өйрәнә. Сугыш кешеләрне ир-хатын, кеше-җәмгыять

унъеллыктан соң гына языла (Кара: Байрамов Н. Великая личность // Совет алабияты. — 1978. — №12 (на туркм.яз.); Абдуллаева Г. Певец счастья и любви // Кишлок хакикаты. — 1978. — 12 декабря (на узб.яз.); Каттабеков А. На службе высоких идеалов // Сырдарьинская правда. — 1978. — 12 декабря; Укачин Б. Со времён «Джамили» // Звезда Алтая. — 1978. — 23 октября), чөнки «дезертирлык темасы ул чорның идеологик әдәбияты кысаларына сыймый» (Ахматалиев А.А. Творчество Ч.Айтматова в тюркоязычном литературоведении и критике // URL: http://www.turkacadem.kz/ru/vp.php?idd=115 (дата обращения 23.06.2012)). А.Каттабеков, Н.А.Садыкова, Б.Укачин Ч.Айтматовның бу повестьта үзен «психологик портрет остасы, кискен сюжет һәм кешеләрнең төрле характер сыйфатларының бәрелешен оста сурәтләүче язучы» булуын билгеләләр (Каттабеков А. На службе высоких идеалов // Сырдарьинская правда. — 1978. — 12 декабря; Укачин Б. Со времён «Джамили» // Звезда Алтая. — 1978. — 23 октября; Садыкова Н.А.Стилевые особенности повестей Чингиза Айтматова (к проблеме художественного мастерства). — Бишкек. — 2004. — 22 с.).

3 Айтматов Ч. Лицом к лицу // Октябрь. — 1958.

4 Айтматов Ч. Лицом к лицу // Литературный Кыргызстан. — 1990. — №3.

5 Амир М. «Җан көеге»// Амир М. Безнең авыл кешесе: повестьлар. — Казан: Тат.кит.нәшр., 2007. — Т.5. — 89 б.

6 Гыйләҗев А. Камыш бармак, көмеш тырнак // Казан утлары. — 1995. — №7. — 10 б.

7 Шамурзина Р.С. Современная советская повесть. Проблемы историзма // Дис. на соискание уч.степени доктора филол.н.. — Бишкек, 1994. — С.53.

мәсьәләләренә янача карарга өйрәтә. Повестьта сурәтләнгән вакыйгалар 1941-1942 елларда Югары Актай дип аталган кечкенә генә авылда бара. Берәүләр «аннан башка немецны җиңгәнче» өлгерергә тырыша; икенчеләре, Түбән авыл егете Сәйфелмөлек кебек, хатыны артына кача һәм, сугышка бармас өчен, комиссия алдыннан тәмәке суы эчә, һәм, йөрәге «авырту» сәбәпле, фронтка китмичә кала. Гариплар арасында да төрлесе бар: эчеп, кайгырып, эшләрен аннан-моннан башкаручы тәннәре генә түгел, җаннары гариплар дә (яхшы ашлыкны бозалар; ни Аллага, ни муллага эскерт салалар) (Имән урамының беләкәй Хәйбери); бер куллы булып та, үзләрен аямыйча тырышып эшләүчеләр дә (Зәбир Рәхмәтуллин). Ирләренә тугры калган намуслы солдаткалар һәм тол хатыннар да; «туймас тәнле» ятсызлар да, ирләре фронтта чакта, урманчы белән типтерүчеләр дә бар. Сугыш кешеләрне ныклыкка, чыдамлыкка тикшерә, аларны иләк аша уздыра сыман. Мәхәббәт һәм нәфрәт, батырлык һәм куркаклык, яшәү һәм үлем сюжетны хәрәкәткә китерүче көчләр булып аңлашыла. Әсәрдә хыянәтнең иң куркыныч гөнаһ булганлыгы ассызыклана. Иленә хыянәт иткән, бурычын үтәмәгән кешенең җирдә яшәргә хакы юк. «Качак», «Өч аршын җир», «Берәү» повестьларында искә алынган тема бу әсәрдә яна яңгыраш ала. А.Гыйләҗев бөтен көчен хыянәтнең эчке механизмнарын өйрәнүгә юнәлтә. Шуңа күрә дә бу повестьның үзәгендә гади куркак түгел (М.Әмирнең повестендагы герой сыман), ә бик кыен, куркыныч, четерекле вакыйгалар нәтиҗәсендә хыянәтчегә әйләнгән кеше тора. Хыянәт феноменын өйрәнеп, язучы аның нигез сәбәпләрен табарга омтыла. Исламгәрәй тумыштан куркак булмый. Сугыш вакытында ул, камалыштан кораллы килеш үзебезнекеләр ягына чыкканы өчен, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Бөтен бер батальоннан бары сигез кеше исән кала, калганнары сазлыкта һәлак була. Исламгәрәй кыен вакытта да куркып калмый, иптәшләрен ташламый. Үткәннәр турында уйлаган саен, аның күңелен рәнҗү, хәсрәт, көчле ярсу һәм ачу хисләре биләп ала. Рәмзиянең ире: «Барлык бәла-казаларда бары дәүләт гаепле», — дип саный: *«Алар бит безне ташлап киттеләр... Полк! Танклар, пушкалар чигенде...»*[8]; *«Штабыние белән безне сазлык арасында камалышта калдырып киттеләр бит, тәреләр!..»* (25 б.); *«Бөтен ягында кораллы немецлар! Танклар уза, самолётлар үкереп оча... Күктә дә, җир астында сиңа котылмак юк... Коры мылтыгыңны кочаклап, тәбәдәге тычкан кебек, миең түнеп ятасың... Ни ашарга, ни эчәргә... Берни юк... Сине бөтен армия, командирлар, полклар ташлап чигенгәннәр. — Тәүлекләр буе баш калкыта алмый ятасың да ятасың»* (26 б.); Исламгәрәйнең солдатларны язмыш иркенә ташлап киткән дәүләткә ачуы килә. Герой аны хыянәттә һәм икейөзлелектә гаепли: *«Яхшы ата балалары чебен күк кырылып калды...»* (26 б.).

Хәтта бүләк тә аңа канәгатьлек хисе бирми. Рәмзиянең ире сугышта һәлак булып калган иптәшләре алдында үзен гаепле саный: *«Чыккач медаль бирделәр... Капчыкта ул, әнә, калай тартмада... Вагон идәнендә аунаганда, төшемә тагарга оялдым. «Батырлык өчен» дип атала...»* (26 б.).

Үзенең «Үлде» дигән хәбәре язылган кәгазь — похоронканы кулына алгач, ул тантана итә: *«Әһә!.. «Батырларча үлде» дигән... Кая күмелгәне әйтелмәгән. «Батырларча»... Бусы яраган! «үлде» дигән, менә моның белән килешеп булмас!.. Үлми торсын әле Исламгәрәй... Үләргә дураклар да җитәрлек анда...»* (24 б.). Ул үзен һәм иптәшләрен үлемгә дучар итүчеләрнең ниятләрен тормышка ашырырга комачаулаганы өчен, чын күңеленнән шатлана. Исламгәрәй камалыштан бары тик үзенең тырышлыгы аркасында чыга һәм үлемнән кала, дәүләтнең моңа бер катнашы да юк. Бүләк белән унбиш көнлек ял дәүләтнең «батыр баш» Исламгәрәй алдындагы гаебен киметми. Рәнҗү һәм өмете өзелү Исламгәрәйне хыянәткә этәрә дә: *«Халык?.. Миңа мылтык биреп, шушында кал, сакла, диделәр. Немец урап алганда, кайда иде халкың? Кайда иде илен?... Ат тоягы эзеннән эчкән сулар!.. Теш белән чәнечкеле тимер чыбыкны кимерә идек!..»* (28 б.). Гадел ярсу — явыз ачуга, каһәрләүгә әверелә. Ачу, үз чиратында, гомуми нәфрәткә китерә.

Хатыны аны юкка оялтырга тырыша: *«Батыр башың белән ил күзеннән качып ятмассың бит инде...»*, *«Ир башы белән ат башы күрә, дигәннәр...»*, *«Ил бар,*

---

[8] Гыйләҗев А. Камыш бармак, көмеш тырнак // Казан утлары. — 1995. — №7. — Б.24. (Алга таба әлеге әсәрдән алынган өзекләрнең бит саннары текстта җәяләр эчендә күрсәтеләчәк.)

*көн бар! Халык бар!»* (28 б.). Герой, «Өч аршын жир»дәге Мирвәли кебек үк, танымаслык булып үзгәрә: «күзендә елтыраган зәһәр утлар» күренә, алар «әшәке бер ният, усаллык» белән карый. Тәкәбберлеге, мин-минлеге аркасында Исламгәрәй үзен, теләген башкалардан өстен куя. Коллективизация һәм Бөек Ватан сугышы вакыйгалары исә герой холкындагы бозыклыкны көчәйтә генә, геройның тормыш төбенә тәгәрәү процессының катализаторы булып килә.

Халык идеалларына хыянәт иткән шәхеснең рухи таркалуын күрсәтеп, автор әлеге процессны кире кайтарып булмаслыкны ассызыклый; А.Гыйләҗев бу вакытта Ф.М.Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» һәм М.Горькийның «Карамора» әсәрләренә таяна.

Исламгәрәй белән танышуның беренче минутыннан ук укучыда аңа карата җирәнү хисе уяна, бу хис автор тарафыннан да көчәйтелә: *«Исламгәрәй танымаслык үзгәргән иде. Кара-соры таплы-таплы шинеленең итәге чачакланган, шинель астында юкарак кына гимнастёрка, аның да терсәк төпләре кат-кат ямалган, муенына ураганын шарф димәссең, бозау муенчагы кебек шомарып, ялтырап беткән. Гимнастёрка якасын ычкындырганда, күкрәгендәге төк бөртекләре арасында кыймыл-кыймыл килеп йөргән җирән, эре бетләр күренде. Бер мизгелгә җирәнеп күзен йомды Рәмзия, аннан ирен кызганып, башы белән аның күкрәгенә капланды»* (23 б.). Хатын-кыз тышкы кыяфәте танымаслык булып үзгәргән иренә карата ике төрле хис кичерә: бер яктан, ул аннан җирәнә, икенче яктан, кызгана һәм хәленә керергә тырыша.

Куркаклык һәм хыянәт темасы персонажның исемендә үк чагылыш таба. А.Гыйләҗев героена Кырым ханы[9] исемен бирә. Исламгәрәй ханның хәрби биографиясе дә хыянәт белән тапланган: ул хәлиткеч мизгелдә союздашы Богдан Хмельницкийга хыянәт итә. А.Гыйләҗев Исламгәрәе дә туган ил өчен катлаулы булган бу вакытта частена кайта ала. Ләкин төп герой башка юлны сайлый. Ул, фашист гаскәре Мәскәүгә басып кергәндә, Ватанына хыянәт итә. Курку хисе аның бөтен барлыгын биләп ала: Исламгәрәй тагын бер кат язмышын сынарга теләми, аның бу «кан баткаклыгында», «ут эчендә», «тәмугта» каласы, югаласы килми. Ул, үзе дә сизмәстән, сугышчы-*бүредән сукыр тычканга* әйләнә.

Әсәрдә сурәтләнгән сугыш Ватан сугышы төсмерләрен ала. Бар халык туган ил сагына баса: ирләр генә түгел (Зәбир, военкомат тирәсендә җыелып торган ир-егетләр төркеме, югары сыйныф укучылары), хатын-кызлар да (фельдшер Сәкинә, укытучы Зоя Лобкова) фронтка китә. Соңрак Рәмзия иренең эгоизмы, үз-үзен яратуы һәм мин-минлеге аркасында гына дезертирлыкка чыгуын аңлап ала. А.Гыйләҗев герое холкының тупаслануын сурәтли. Ул рухи яктан кире кайтарып булмаслык итеп таркала. Рәмзиянең иренә булган җирәнү хисе көннән-көн арта. Хатынның тормышы тәмугка әверелә: элек ире аны бәйләнү-каныгулары, сукрану-зарлanулары белән рухи яктан җәфалый, аннары, кыйнап, физик яктан да газаплый. Яна ел төнендә Рәмзиягә бөтен дөнья, аның күңеле кебек үк, караңгыга баткандай күренә, Җир белән Күк арасындагы нечкә үтәкүренмәле чик аның аяк астыннан үткән кебек тоела. Хатын үзенең бәхетсезлеге белән халык кайгысы арасында тыгыз бәйләнеш сизә: *«Йөрәген телгәләгән шәхси бәхетсезлеге ил язмышына, халык бәхетсезлегенә үрелгән иде»* (32 б.). Авылга немецларның Мәскәү астында тар-мар ителүе турында хәбәр килгәч тә, Рәмзия бу турыда иренә сөйләми: хәзер инде Исламгәрәй тормышы белән ил тормышы арасында бернинди бәйләнеш юк.

Үзенең гөнаһлы икәнлеген белгән Исламгәрәй башкаларда да тискәре сыйфатлар

[9] Сүз Украина казаклары гетманы Богдан Хмельницкий белән аның полякларга каршы сугышында берләшеп, ярдәм итәргә вәгъдә биргән Кырым ханы Исламгәрәй (1604-1654) хакында бара. Бары тик үз мәнфәгатьләрен кайгырткан ханның хыянәте Украина армиясен Берестечко (1651) и Жванц (1653) астындагы сугышта җиңелү куркынычы астында калдыра. Орышның иң кызган чагында «хан кинәт качып китә, аның артыннан морзалар һәм бәкләр төркеме агыла. Ханның качып китүе татар халкын шулкадәр тетрәндерә ки, алар, балаларын, хатыннарын, зәгыйфь һәм хәтта үлгән якыннарын калдырып, йортларын ташлап качалар. Хмельницкий гаскәр белән идарә итүне Джеджалыкка тапшырып, үзе ханны туктатырга теләп, аның артыннан чаба. Хан сугыш барган җирдән 3 чакрым ераклыкта туктап кала һәм: «Безнең йөрәкләребезне курку хисе биләп алды. Татарлар сугышмас. Минем белән кал, уйлашыйк. Иртәгә мин үземнең сугышчыларымны казакларга ярдәм итәргә җибәрермен», — ди. Ләкин икенче көнне үк Вишневцка юнәлә һәм Хмельницкийны да үзе белән алып китә. Выговский исемле писарь ханның Хмельницскийны җибәрүен үтенә. Тик үзе дә кулга алына. Шулай итеп, гетман белән писарь Кырым ханының тоткыннарына әйләнә», — дип яза Н.Костомаров «История России в жизнеописаниях её главнейших деятелей» (М.: Эксмо, 2009. — 360 с.) китабында.

табарга тырыша. Яраланган Зәбирне ул үз-үзенә атуда, хатынын — хыянәттә, халыкны битарафлыкта гаепли. Беркөнне эштән кайткан Рәмзия иренен өйдә юклыгын күреп куана: хатын Исламгәрәйнен, ялгышын аңлап, фронтка китүенә өметен җуймый әле. Сонрак исә авылда анын шөбһәләрен раслаган вакыйгалар була: мәктәп мылтыгы юкка чыга, Илайлар йорты яндырыла. Март аенда сакал-мыеклары җиткән авыру Исламгәрәй табыла. Автор геройнын деградациясен — түбәнгә тәгәрәвен сурәтли. Исламгәрәй үзен һәм язмышын җәлләп, кызганып утыра. Рәмзия Исламгәрәйгә булышырга теләмәгәч, ир ана яный башлый. Тик хатын анын куркытуларын көлемсерәп тыңлый. Йомшак күнеллелек күрсәтеп, урманга, иренен торган урынын карарга баргач та, ул, нәфрәтләнеп, болай ди: *«Тере килеш кабергә төшеп яткансын икән...», «Сугышта куркыныч, монда куркыныч... Кәтмә!»* (42 б.). Шулвакыт Рәмзия үз каршында чибәр баһадир-ирен түгел, «саргаеп беткән өрәк», «албасты», «сукыр тычкан», «хайван» күрә.

Күршеләренен кече улы — Мәрданнын (Рәмзия аны бик ярата) үлемен сурәтләгән күренеш Исламгәрәй-дезертирга тулы характеристика бирә. Иренен, качкан урынын ачарга куркып, адашкан баланы үлемгә дучар итүе Рәмзия күнелендә Исламгәрәйгә булган кызгану хисенен сонгы тамчыларын юкка чыгара. Бу эпизод Исламгәрәйнен әхлакый түбәнлек чонгылына төшүен, анын рухи үлемен гәүдәләндерә. Баланы корбан итү мотивы А.Гыйләҗевтә Ф.М.Достоевский иҗаты белән аваздашлык тудыра. Рус әдәбиятынын классик язучысы өчен дә сабыйларга, ятимнәргә, гарип-горабага ярдәм итә алу геройнын хаклыгын һәм житлеккәнлеген билгели торган төп сыйфат булып тора.

Геройнын үлеме дә, безненчә, символик мәгънәгә ия. Исламгәрәй, үзенә землянка казыганда, нарат агачынын тамырларын яралый. Шуна күрә дә өермә вакытында нарат бөтен авырлыгы белән анын торган жире өстенә ава. Рәмзия, таныш урынга килеп, иренен жирдән чыгып торган озын тырнаклы сары кәкре кулын һәм күгәреп беткән мылтык көпшәсен күрә. Шул рәвешле, Исламгәрәйнен хыянәтен Рәмзия генә түгел, туган жир, борынгы бабаларыбыз рухы хөкем итә. Язгы чәчүдән сон чыккан бу өермә төньяктан килә; әйтерсен лә ул дөньяны чистартырга, сафландырырга, коточкыч гөнаһ кылган (хыянәт иткән, баланы үтергән) бу кешедән арындырырга тели.

Сюжет үстерелеше белән Исламгәрәй — Зәбир антитезасы көчәя, кискенләнә бара һәм *«үзен югалткан ир» — «үлемгә баручы батыр»* төсен ала. Унай геройнын исеме анын холкын ачып бирә: Зәбир — «ныклы, көчле, куәтле»[10]. Герой холкындагы героик потенциал, яшерен батырлык сыйфатлары турында хәбәр итү өчен, автор анын, сугыш башланганда, кадр хезмәтендә, погранзаставта булуын сурәтли. Илайлар турындагы яман дан тирә-юньгә таралаган була: аларны Сабантуй вакытында да кыйнаш-тартышлар оештырып йөрүче сугыш чукмарлары итеп беләләр.

Фронттан кайткан Зәбир авылдашларын абыйлары кебек шаярып, ду килеп, тырай тибеп йөрәмеве белән гаҗәпләндерә дә, куандыра да: *«абыйлары күк күрше тавыгын урлап, тол хатыннар белән көмешкә чөмереп азапланмады, ерак дәдәсе янына тегермәнгә дә урләмәде, агай-энесе белән тыйнак күрешеп, ил агайларына түбәнчелекле сәлам биреп, бер-ике көн кунак булгандай итте дә, эш сорап, колхоз идарәсенә барып керде»* (15 б.). Зәбир «атлы эш» сорый. Бу вакыйга да анын холкына баһадирлык, батырлык төсмерләре өсти. Яраланган булуына карамастан, ул ял белмичә эшли, үз җилкәләренә тормышнын бөтен авырлыгын салган хатын-кызларга ярдәм итәргә омтыла. Авылдашларынын берише Зәбиргә көнләшеп карый: сугыштан исән кайтуына, әнисен куандыруына кызыга, аны «иблис» дип атый, икенчеләре исә егетне хөрмәт итә, ана теләктәшлек белдерә.

Сугыш авырлыгын инде бер кат татыган Зәбир Рәхмәтуллин да сайлау алдында кала: авыр яралануы аркасында тылда яшеренергәме яисә, Ватанын яклап, фронтка китәргәме? Авылдашларынын усал сүзләре анын күнеленә ук булып кадала: *«Син солдат түгел инде, безнен шикелле үк авыл кабартмасы» (17 б.), «Коры куык... Бик атлыгып торасындыр» (16 б.).* Күрше хатыннарынын *«Сине сугышка янадан алмасалармы икән?»* дигән соравына ул, бер дә шикләнмичә: *«Алсалар, бара беләм. Юлы таныш!»* — дип җавап бирә. Сонрак анын сүзләренен дөреслегенә башкалар да инана: *егет сүзе бер булыр дигәндәй, Зәбир үзе теләп фронтка китеп бара (15 б.).*

[10] Саттаров-Муллиле. Татар исемнәре ни сөйли? — Казан: «Раннур», 1998. — Б.104.

Геройның рухи байлыгы аның күңеленә оялаган саф мәхәббәтендә чагыла. Рәмзиягә булган гыйшык хисе әкренләп гаҗәеп нык рухи бәйләнешкә әйләнә. Бу хиснең иң югары ноктасы Зәбирнең фронтка китәр алдыннан Рәмзиягә мәхәббәт аңлатуында һәм хатында чагыла. Хат: *«Гөл — былбылын, былбыл гөлен / Сагынгандыр, билгеле...»* (37 б.) дигән сүзләр белән тәмамлана.

Повестька аулак өйләрдә еш җырлана торган «Сөнбел» җырын кертү әсәрнең ассоциатив пространствосын тагын да киңәйтә: *Егет — илнең былбылы, / Кызлар — былбылның гөле шул, / Былбыл гөлне, гөл былбылны / Сагынасы билгеле*[11].

Ике баскычлы егет — былбыл, кыз — гөл метафоралары әзерлекле укучы анында шигъри ассоциацияләр тудыра. Фарсы шигъриятендә былбыл — гөл метафоралары шагыйрь һәм аның сөйгән яры образларын ачу өчен кулланыла. Татар халык авыз иҗатында исә әлеге образлар традицион рәвештә туган илгә хезмәт итүне һәм гашыйкларның бер-берсенә тугры булуларын чагылдыра.

Рәмзия, иренә мөрәҗәгать иткәндә: *«Ир башы белән ат башы күрә, дигәннәр...» (27 б.); «Ил бар, көн бар! Халык бар!» (28 б.),* — ди. Зәбирне исә Рәмзия *«үлемгә китеп барган батыр егет»* (34 б.) дип атый. Ул чын күңеленнән егетнең куанып-горурланып, медальләр тагып, сау-сәламәт килеш фронттан кайтуын, һәм Илайлар хакындагы яман даннын мәңгегә юкка чыгуын тели.

Зәбир Рәхмәтуллин Калинин фронтында батырларча һәлак була. 1942 елның июлендә Калинин фронтында булып үткән саклану операциясе — Бөек Ватан сугышындагы иң фаҗигале вакыйгаларның берсе. Озак еллар ул сер булып саклана[12]. Совет тарих гыйлемендә «Зейдлиц» операциясе аерым, хосусый вакыйга буларак өйрәнелсә, алман документларында исә аның вермахт өчен бик мөһим булуы ассызыклана, һәм бу сугышта күпсанлы немец коры җир гаскәрләренең катнашуы билгеләнә. Калинин фронты гаскәрләренең операция барышында «Жирновский калкулыгы» дип аталган чыгынтыны саклап торулары билгеле. Сакланган территория Калинин һәм Смоленск өлкәләре тоташкан җирдә була һәм куе урманнар, торфлы сазлыклардан тора. Бу җирлек 1942 елның гыйнвар-апрель айларында һөҗүм итү операциясе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Нәтиҗәдә Калинин һәм Смоленск өлкәләренең бер өлешендә Совет хакимияте торгезелә, колхозлар төзелә. Бу җирләрдә яшәүче халык совет сугышчыларына бик зур ярдәм күрсәтә: саклану ныгытмалары төзергә булыша, азык-төлек белән тәэмин итә. Шулай ук ташлап калдырылган сугыш кирәк-яраклары һәм техниканы җыеп бара. Гаскәрләр җирле халык һәм партизаннар белән тулыландырыла.

Солдатлар гына түгел, тыныч халык та язмыш иркенә тапшырыла. Чигенү турындагы приказ ике көнгә соңга калып килә. Уннарча мең кеше үлемендә Калинин фронты командирлары, Ставка һәм 1942 елгы Ржев — Вязьма операциясен уйлап табучылар гаепле.

Хәбәрсез югалганнарның гомуми саны — архив документлары буенча 47 мең. Кайсы сугышчының һәлак булганын, кайсысының әсирлеккә төшкәнен яисә партизанлыкка күчкәнен әйтү кыен. Шулай да бу сан немец документларындагы әсирлеккә төшкән рус сугышчыларының гомуми санына (50 мең) бик якын. Немецлар үз донесениеләрендә совет солдатларының батырлыгын һәм фидакярлеген искәртә. 1942 елның 13 июлендә вермахт 30 мең солдатның әсирлеккә алынуы турында хәбәр иткәч, газеталарда «Гитлер командованиесенең ялган хәбәре» дигән мәкалә басыла. Шулай да канкойгыч сугышлар кире кагылмый, 7 мең кешенең һәлак булуы, 5 мең сугышчының хәбәрсез югалуы турында, алардан күпләрнең партизанлыкка китүләре хакында хәбәр ителә. Бүгенге тарих фәне һаман да «Зейдлиц» операциясе югалтуларын киметеп күрсәтергә тырыша: 20 360 кешедән 7 432 сугышчы һәлак булган, 12 928е санитар югалтулар рәтенә кергән, хәбәрсез югалганнарның саны күрсәтелми. Бу плацдармын югалткан Кызыл Армия җитәкчеләренә, күпсанлы хәрби частьларны һәм берләшмәләрне торгызу өчен, резервлар эзләргә кирәк була. Ләкин иң куркынычы — уннарча мең кешене югалту!

[11] «Сөнбел» җыры // URL: http://tatarlarga.ru/tatfolksong/read/soembel2.html

[12] Бу вакыйга турында мәгълүматлар Герасимова С.А. Оборонительная операция Калининского фронта в июле 1942 г. // Военно-исторический архив. — №23. — С.18-56 // URL: http://rshew-42.narod.ru/seydlitz.html (дата обращения 1 марта 2015 г.) мәкаләсеннән алынды.

Аларның барысы да камалышта калу фаҗигасен кичерә, күбесе билгесез җирләрдә һәлак була, меңләгән кеше әсирлеккә төшә.

Калинин фронтының повестьта искә алынуы бер дә очраклы түгел: бу җирләрнең үзенчәлеге булган сазлык образы әсәрдә дәүләтне гәүдәләндерә торган символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Дәүләтнең ялганга һәм үз халкына хыянәт итүгә нигезләнгәнлеге ачыклана. «Батырлык өчен» медале һәм «Кызыл байрак ордены» — илгә кайтып житкән гади, гадәти сугышчыларның батырлыгын һәм ватанпәрвәрлеген бәяләү чарасы. Коточкыч репрессия еллары һәм Бөек Ватан сугышы иң яхшыларның гомерләрен алып китә. А.Гыйләҗев фикеренчә, халыкның рухи яктан зәгыйфьләнүе дә шуның белән аңлатыла: сугыштан соң ил хыянәтчеләр, бар нәрсәгә ераклаша белүчеләр, икейөзлеләр кулында кала... Әсәр ахырындагы детальләр зур әһәмияткә ия: «җир астыннан чыгып торучы таныш кул» һәм «кул янындагы мылтык көпшәсе». Аларны бербөтен итеп караганда, әлеге детальләрнең гаҗәеп тирән мәгънәгә ия булуы аңлашыла. Бу образда прозаик А.Гыйләҗев драматургия алымнарыннан файдалана. А.П.Чехов фикеренчә, беренче актта сәхнәдә эленеп торган мылтык әсәрнең ахырында атарга тиеш. Рус язучысы әсәрләрендәге кебек[13], А.Гыйләҗев деталь символик катламны хасил итә, текстның мәгънәви кырын киңәйтә. Нәтиҗәдә, әдәби текстның күзгә күренеп торган эчтәлегеннән тыш, потенциаль эчтәлеген уку ихтыяҗы килеп баса. Әдәби деталь реалистик катламда түгел, символик катламда урнаша, әсәрнең ассоциатив мөмкинлекләрен киңәйтә. Шул рәвешле, реалистик укылыш чикләрен узган символ А.Гыйләҗевтә мәгънәви катламны оештыра, аны бер үзәккә туплый.

Мәфтуха, дустының кайгысын уртаклашканда, Рәмзиягә мунчада төшеп калган солдат төймәсен бирә: *«Төсе итеп тотарсың... Күзен Зәбирнең керләрен юганда мунчада төшереп калдыргансың...». «Төймә генә калмады, — диде Рәмзия ап-ачык итеп».* Элек киемне эләктереп кую өчен тасма яки бау кисәге тегеп куйганнар. Төймәләү — «төйнәп кую» мәгънәсендә. Атама борынгы төрки телдән килә. Татардагы «Төймә төйдем, төпкә салдым» табышмагы нәрсәне дә булса истә калдыру өчен җепкә яисә кульяулыкка төен ясап куюны аңлата[14]. Төймә татар халык җырларында эләктерүче, берләштерү көчен символлаштыра: *«Төймәсе өзелмәсен. / Миннән башкаларны сөеп / Үзәгең өзелмәсен», «Их, төймә, төймә, төймә, / Төймәләмичә кимә. / Син минеке, мин синеке, / Миннән башканы сөймә («Төймә, төймә»)*[15].

Хыянәтче Исламгәрәй вафат, тик хыянәт, иҗтимагый күренеш буларак, җирдә яшәвен дәвам итә — кешелеккә әле һаман да куркыныч яный. Исламгәрәй нәселе корымаган: Рәмзиянең баласында аның каны ага. Сабыйның октябрьдә, җиргә кырау төшкән вакытта тууы да символик мәгънәгә ия. Балага исем кушу вакыйгасы да ялганга, икейөзлелеккә корыла, ул дәүләтнең яшәү принцибын гәүдәләндерә: *«Малайга Мәрдән дип исем куштылар. Авыл советында «Рәхмәтуллин Мәрдән Зәбир улы, туды 1942 елның 27 октябрь числосында», — дип теркәделәр»* (44 б.). Рәмзиянең ялганына аптырашта калган авылдашлары да кушыла: *«Шушы тиклем охшаса да охшар икән, нәкъ менә Зәбирнең үзе инде, суйган да каплаган, — дип шатлана-шатлана Рәмзиягә кучтәнәчләрен, бүләкләрен тапшырдылар».* Зәбирнең әнисе дә бу матур ялганга ышанырга тели: *«Зәбирнең әнкәсе Миңлезифа карчык... оныгын кулына алгач, озак кына текәлеп торды, тоныкк күзләрен яшь белән юып: — Төпчегем, Зәбирем икән шул! — диде»* (45 б.).

Автор бәясе Миңлезифа карчыкның «тоныкк күзләре» аша бирелә. Дүрт улын фронтта югалткан ана балаларының бу җирдә нәсел, дәвам калдыруын тели.

Баласын явыз язмыштан сакларга теләп, Рәмзия ана «Мәрдән» дигән исем бирә. Фарсы телендә аның шундый мәгънәләре бар: «I. 1) ир-егет, ир, эшлекле; 2) көрәшче, сугышчы; 3) ир, тормыш иптәше; 4) батыр II. Баһадир, батыр, курку белмәс, мәрхәмәтле»[16]. Шул рәвешле, борынгы ышануларга, әхлакый-рухи традицияләргә нигезләнеп, ана баласының тормышын билгеле бер программага салырга тели.

А.Гыйләҗев өчен повестьның исеме бик кадерле була. Моны әдипнең «Современник»

---

[13] Freise M. Die Prosa Anton Cechovs Eine Untersuchung im Ausgang von Einzelanalysen. Amsterdam-Atlanta: Editions Rodopi B.V., 1997. — 330 s.

[14] Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек. — Казан: Мәгариф, 2007. — Б.472.

[15] Татар халык җыры «Төймә, төймә» // URL: http://tatarca-text.narod.ru/jirlar2.html

[16] Саттаров-Муллиле Г. Татар исемнәре ни сөйли? — Казан: «Раннур», 1998.

нәшрияты редакторына язган хаты раслый, бирәдә автор повестьның исеменә аңлатма биреп китә: «Татар телендә повесть «Камыш бармак, көмеш тырнак» дип атала. Егет, сөйгән кызына хат язганда, традицион рәвештә аның бармакларын — камыш, тырнакларын көмеш белән чагыштыра»[17]. Әкърибә хатының[18] эпистоляр формуласы укучыларны кешелек өчен кадерле булган мәңгелек мәхәббәт темасы турында уйларга мәҗбүр итә. Повестьның исеме Г.Кандалыйның «Сәлам улсын сәңа, бәгърем парәсый»[19] шигыре белән аваздаш. В.Ганиев повестьның исемен рус теленә «О мой серебряный камыш» дип тәрҗемә итә, автор бу тәрҗемәне ошатмый. М.Ганинаның «Люблю тебя, моя нежная...» тәрҗемәсе исә язучы күңеленә хуш килә.

Шул ук вакытта «көмеш тырнак» метафорасы укучыларны батырлык турында уйланырга мәҗбүр итә. Төрки эпоста бу портрет детале баһадирның төс-кыяфәтен сурәтләгәндә кулланыла. Кагыйдә буларак, татар халык эпосларында сурәтләнә торган каһарман һәрвакыт матур, зифа буйлы һәм нык була. Аның кашлары кара, чәчләре куе һәм ат кылыдай нык, тырнаклары көмештәй, куллары тимердәй, аяклары төз имәндәй. Батыр һәрвакыт Ватан сагында тора, халкын һәм илен басып алучылардан коткара («Идегәй», «Чура батыр» дастаннары). Татар халык җырларында исә егет күктә оча торган көмеш тырнаклы бөркет белән чагыштырыла. Шул рәвешле, әсәрнең исемендә үк автор повестьның төп темаларына ишарә ясый.

Батырлыкның, каһарманлыкның табигатен өйрәнү юлында язучы милли этник традицияләргә мөрәҗәгать итә. Бу әсәрдә әдәби мифологизм яна баскычка күтәрелә. Ике төп герой — Рәмзия һәм Исламгәрәй образлары белән тыгыз бәйләнгән мифопоэтик структуралар әхлакый-фәлсәфи һәм иҗтимагый проблематикага өстәмә мәгънә бирә, әдәби психологизм үзенчәлекләрен билгели.

Ире кайтыр алдыннан Рәмзия символик мәгънәгә ия булган төш күрә. Бу төштә Борынгы Болгар һәм Казан ханлыгы мәдәниятенең нигезен тәшкил иткән эпик хикәятләрнең (Ибне Фадлан, «Әхмәт ибне Фадланның Иделгә сәяхәте»; Идегәй, Чура батыр турындагы эпос үрнәкләре) төп геройлары алыплар, туган якны саклаучы баһадирлар катнаша. Хатын күңелендә сугыш — тәмуг, Гитлер — тәмуг утында януга хөкем ителгән зат, ә авылдашы (сельпо директоры Мөхәммәтгали) — туган якны саклаучы, гадел хөкемне тормышка ашыручы булып гәүдәләнә.

Күршесе белән сөйләшкәндә, Рәмзия иренең үлеменә ышанмавын белдерә: *«Ничек телең барып «Мәрхүм» дип әйтә аласын?»* (11 б.). Сизгер йөрәге алдамый аны. Бер төндә Исламгәрәй «теге дөньядан» сау-сәламәт килеш кайтып төшә... Бу вакыйга Рәмзиянең тормышына кискен үзгәрешләр кертә.

Исламгәрәй образына бәйле повестьта убырлык мотивы уздырыла. Төрки мифологиядә гульябани дип аталган явыз убырлар образы гәүдәләнә. Алар кешеләр яшәми торган урыннарда йөриләр һәм төнлә ялгыз юлчылар каршына килеп чыгалар, имеш. Әкиятләрдә еш кына бүрегә әверелә ала торган явыз ир образы очрый. Ул патша кызларын урлый, имеш. Бу образларга бәйле Рәмзия белән Исламгәрәй арасындагы диалог кызыклы. *Төнлә ишек шакыган иренә (Рәмзия аның Исламгәрәй икәнлеген белми) ул, ачуланып, элек ачарбак (бирән мәгънәсендә), аннары көчек ( «Ах, яхшыдан яман туган көчек») һәм бүре («Авыл советына явит иткәнне теләден ахры син, бүре?! Тимерчегә барып теленне таптатып килденме? Мин сина тинтәк кәҗә бәтие түгел!»)* (23 б.) дип эндәшә. Бу, бер яктан, авыл мохитендә тәрбияләнгән Рәмзиянең уй-фикерләрен, миф-легендаларга, ырымнарга ышануын күрсәтсә, икенче яктан, *ялган ир, бүре-убыр* мотивын актуальләштерә. «Көчек» дип эндәшү исә кешеләрнең килеп чыгышы хакындагы мифка һәм яңа туган балаларны көчек белән алмаштырып кую турындагы әкиятләргә[20] (мәсәлән, башкортларның «Санай батыр» әкияте) нигезләнә. Төркиләрдә эткә карата ике төрле караш яши. Хатынның иренә «көчек» дип эндәшүендә тирән мәгънә бар. Кешеләрнең килеп чыгышы турындагы борынгы төрки мифта этнең, уңайлы

[17] Язучының архивы: А.Гыйләҗевнең «Современник» нәшриятының редакторына язган хаты. 1972 елның 28 феврале, Казан.
[18] Авхадиева А.И. История изучения эпистолярного стиля в татарском и русском языкознании // Учёные записки Казанского государственного университета, 2007. — Т.149. — Кн.4. — С.32-37.
[19] Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар. — Казан: Тат.кит.нәшр., 1988. — 224 б.
[20] Бисенбаев А.К. Мифы древних тюрок. — Алма-Аты: Ак Арыс, 2008. — 120 с.

тормышка кызыгып (ана жылы тун бирәләр), Тәңрегә биргән вәгъдәсен бозуы турында сөйләнә. Бүрене, тимерче һәм кәҗә бәтиен телгә алу исә «Кәҗә бәтиләре һәм бүре» әкиятен искә төшерә. Исламгәрәйнен батырлыгы, камалыштан чыгуы турындагы хикәясе исә *Ак бүре* турындагы мифка[21] барып тоташа. Төрки эпоста Ак бүре юлдаш вазифасын үти, сугышчан походларда, авыр вакытларда ярдәмгә килә *(Кара: «Угызнамә», «Чыңгызнамә», «Ак бүре» әкияте)*. Билгеле булганча, төркиләрдә бүре сугышчының көчен һәм батырлыгын символлаштыра. Шуңа күрә дә төрки эпосларда юлбашчыларны, гаскәр башлыклары һәм каһарман-баһадирларны гына түгел, тулы бер гаскәрне һәм, гомумән, ир затыннан булган һәркемне «бүре» дип атау кабул ителгән. Куркыныч хәлләрдә югалып калмау, үлемгә бирешмәү аларның барысы өчен дә уртак сыйфат булып тора.

Исламгәрәй корсаклы хатынын кыйный... Шулвакытта Рәмзия, ире суккан саен, тәнендә бер җинеллек сизгәндәй була: *«тәнен басып торган албасты[22] җинелде»* (33 б.).

Әсәр башында Исламгәрәй белән Рәмзияне ир белән хатын, кайгыдан берләшкән ике җан итеп карап булса, соныннан ир образы акрынлап сүнә, тоныклана, һәм авырлыкларга бирешмәс көчле хатын образы калкып чыга. Рәмзия авызыннан автор үзенең яхшылык һәм яманлык, мәхәббәт һәм нәфрәт, яшәү һәм үлем турындагы фикерләрен, уйларын әйттерә.

Гаиләсенә төшкән хурлыктан арыну өчен, Рәмзия колхозда ике кешелек эшли, радистка булып фронтка китәргә җыена. Балага узуын белгәч, үз-үзенә кул салырга уйлый. Тик табигать аңа бу усал ниятен тормышка ашырырга мөмкинлек бирми. Бу эпизод «Өч аршын җир» повестендагы эпизодлар белән аваздаш (Мирвәли авылдан чыгып киткәндә, салкын җил аңа каршы исә; урманда хатынын күмәргә туган җир ирек бирми). Кара кайгыга баткан Рәмзия таудан төшә, батып үләргә теләп, бозга әверелгән елга буйлап бәке эзләп йөри, тик таба алмый. Шунда ул көянтәләр асып, су алырга килгән хатыннарны күреп акылына килә, бигрәк тә хатынның игътибарын тау шуып йөргән балалар: малай һәм кыз җәлеп итә. Рәмзиядә аналык хисләре уяна: хатын уйламыйча кылган гамәлләренең баласына зыян сала алуын аңлый.

«Өч аршын җир» повестендагы кебек үк, бу әсәрдә дә каргыш образына зур урын бирелә. Ирен оялтырга теләп, чын ир-егетнең асыл максатлары турында сөйләгәндә дә, Рәмзия аның күзенә карамаска тырыша: иренә рәнҗеше, каргышы төшүдән курка.

Шул рәвешле, А.Гыйләҗевнең реалистик хикәяләүгә нигезләнгән әсәр тукымасына аерым мифологик мотивлар кертеп җибәрүе конкрет-тарихи образларны универсаль мәгънәләр һәм аналогияләр белән баета. Әхлакый-психологик конфликтның чишелеше фольклор системасына түгел, бәлки авторның катлаулы әдәби мантыйгына нигезләнә. А.Гыйләҗев үзенчәлекле повесть иҗат итә алган. Беренче тапкыр бу әсәр — «Люблю тебя, моя нежная...» — 1973 елда Мәскәүдә «Современник» нәшриятында «Кызлар язган хатлар» («Девичьи письма») җыентыгында дөнья күрә. Татар телендә повесть бары 1995 елда гына нәшер ителә һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан берничек тә бәяләнми[23].

**Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,**

*филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты*

---

[21] Урманче Ф.М. Ак бүре // Урманче Ф.М. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 т. — Т.1. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. — 61-63 б.

[22] Инде К.Насыйри «албасты» сүзенә («әл-кул» һәм «басарга» сүзләреннән: кемнедер кулы белән бастыручы зат; яисә «ал» һәм «басарга» сүзләреннән: тәннең алгы өлешен басып, бастырып торучы зат) билгеләмә биреп китә. Ул — русларның домовое һәм татарларның убыры кебек мифологик зат. Ул кешенe йоклаганда буа һәм аның йөрәгеннән кан эчә, имеш. Күчерелмә мәгънәдә халыкта тырыш кешене «убыр», ялкауларны «албасты» дип атау гадәткә кергән (Насыров К. Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства. — СПб: Типография В. Безобразова и Ко, 1880. — 30 с.

[23] 1977 елда В.Распутинның «Живи и помни» әсәре (1975) дәрәҗәле Дәүләт бүләгенә лаек була.

# С

**САТИРА** (лат. satira — «җыен юк-бар»), көлкенең бер төре, тасвирлау предметына карата авторның тиешле сәнгати чараларның һәм образларның гомуми характерын сайлауга тәэсир итә торган тискәре мөнәсәбәте. Сатирик көлү төрле формаларда тормышка ашырыла (ирония, гипербола, гротеск, фантастика, пародия, инвектива һ.б.), төрле жанрларда файдаланыла (комедия, хикәя, памфлет, карикатура, шарж һ.б.). Татар әдәбиятында С. халыкның көлү культурасы тамырларына барып тоташа: татар йолалары һәм бәйрәмнәре көлке б-н кушылып бара, фольклор әсәрләрендә С. зур урын алып тора (шаян җыр, мәзәк, табышмак). Урта гасыр татар әдәбиятында С. кыйсса, мәсәл, хикәят жанрларына хас күренеш буларак яши. 19 гасырда С. мотивлары Г.Кандалый, Акмулла, Я.Емельянов, К.Насыйри һ.б. әсәрләрендә күзәтелә башлый. 19 гасыр уртасыннан татар һәвәскәр театры үсеш ала, анда күбесенчә комедияләр куела. Г.Ильяси һәм Ф.Халидинең беренче пьесаларында милли патриархаль гаиләнең яшәү рәвеше тәнкыйтьләнә. Татар сәүдәгәрләре һәм байлары тормышын сатирик рәвештә тасвирлаучы мәгърифәтчелек прозасында З.Һади («Яңа әсхабе кәһәф») һәм Ш.Мөхәммәдов («Япун сугышы, яки Доброволец Батыргали агай») сарказм, ирония, гиперболага мөрәҗәгать итәләр.

20 гасыр татар әдәбиятында С. Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Тукай, М.Гафури, Ш.Бабич иҗатларында аеруча көчле чагылыш таба. Мәгърифәтчел идеалларны раслап, Ф.Әмирхан «Фәтхулла хәзрәт» сатирик повестенда феодаль тәртипләрдән көлә. Г.Исхакыйның «Тәгаллемдә — сәгадәт», «Кәләпүшче кыз», «Бай угълы», «Өч хатын берлән тормыш» «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрләрендә мәгърифәтчелек реализмы позициясеннән чыгып әхлакый кимчелекләрне тәнкыйтьләү мыскыллы көлүгә әйләнә.

С. ярдәмендә Г.Тукай үз иҗатында милли янарыш идеалларын раслый, искелеккә, артталыкка каршы көрәшкә өнди («Сорыкортларга», «Государственная думага», «Мөридләр каберстаныннан бер аваз», «Алтынга каршы», «Милләтче», «Золым», «Авыл халкына ни җитми?», «Сайфия», «Көзге җилләр», «Дөньяда торыйммы? — дип кинәшләшкән дустыма», «Ишан», «Ысулы кадимче»); аның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасы милләт язмышын кайгырту хисләре б-н сугарылган. М.Гафуриның мәсәлләрендә, җәмгыятьнең иҗтимагый-сәяси төзелешеннән көлү б-н беррәттән, ш.у. әхлакый-дидактик эчтәлек тә урын алган («Үгез белән бүре», «Сарыкны кем ашаган?», «Эт белән куян»). Самодержавияне, феодаль тәртипләрне, дини фанатизмны тәнкыйтьләү Н.Думавиның беренче әсәрләрендә дә урын алган. Г.Камалның «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Безнең шәһәрнең серләре» пьесаларында төп көлке объекты булып наданлык тора. Бу юнәлеш соңыннан Г.Коләхмәтов, М.Фәйзи, Г.Исхакый иҗатларында үсеш ала.

1920-30 еллар татар әдәбиятында сатирик башлангыч берникадәр сүлпәнәя төшә, үгет-тәрбия янгыраш ала. Драматургия (К.Тинчурин, «Җилкәнсезләр», Н.Исәнбәт, «Һиҗрәт») һәм прозада (Г.Газиз, Г.Толымбайский хикәяләре) ул фаш иткеч пафостан алып хакимлек иткән идеологиянең мифлардан арынуына (Ф.Әмирхан, «Шәфигулла агай»), поэзиядә — үз-үзенә юнәлтелгән иониягә (Һ.Такташ, «Гыйсъян», «Такташ үлде») кадәр үсә-үзгәрә бара. Бу елларда сатирик комедия жанры үсеш ала (К.Тинчурин, «Американ», «Портфель»). 1940-50 еллар С.сын бюрократияне зәһәрле тәнкыйть утына тоткан, икейөзлелек, эчкерлелек, эчүчелекне, җәмгыятьнең башка кимчелекләрен фаш иткән сатирик шигырьләр, хикәя һәм комедияләр билгеләде. Фашизмга каршы юнәлтелгән әсәрләрдә С. яңа сулыш ала, гипербола, гротеск, шарж, күпертүләр ише сәнгати алымнарга иркен мөрәҗәгать итә.

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынан басылып килә.*

1960-80 еллар татар сатирик әдәбияты үсешендә яңа этап булып тора. Язучылар актив рәвештә «яшерелгән көлү» осталыгын үзләштерәләр, С. чаралары белән тормышны эпик киңлектә тасвирлау чикләрен киңәйтәләр (А.Гыйләҗев, Ф.Хөсни, И.Гази, Х.Сарьян). Әхлакый характерлар, замана җимеше булган үзенчәлекле социаль типлар тергезүгә омтылыш күзәтелә башлый (Хәсән Сарьян, «Нокталы өтер», «Бер ананың биш улы», А.Гыйләҗев, «Әтәч менгән читәнгә»). Кеше күңеленең «саегуы» темасын типик яссылыкта Ф.Шәфигуллин ачып бирә. Шигъри С. да үсеш ала. Поэзиядә иҗтимагый-психологик гротеск, фәлсәфи-аналитик башлангыч көчәя (Ә.Исхак, Г.Афзал, Ш.Галиев). С. әдәби барышның үзен анализлауга тартыла, шуның белән пародия һәм эпиграмманы яңартуга этәргеч бирә.

20-21 гасырлар киселешендә үткән совет чоры (язучылар кешенең тоталитар системада яшәве проблемасына мөрәҗәгать итәләр) һәм советтан соңгы вазгыять тәнкыйди тикшерү объектына әйләнә. Проза әсәрләрендә ешрак җәмгыятьтә һәм замандашлар күңелендә тотрыклылык югалу сизелә башлый. Бу күренешләр ирония, сарказм, әдәби үен ярдәмендә тәкъдим ителә (Ф.Садриев, «Бәхетсезләр бәхете»; Т.Галиуллин, «Сәет Сакманов»; Р.Мөхәммәдиев, «Кенәри — читлек кошы»; Г.Ахунов, «Этләр патшасы»). Авторларның сов. идеологиясен мифлардан арындыру, «абсурд» дөнья картинасын булдыру омтылышы С.ны концептуаль дәрәҗәдә файдалану б-н үрелеп бара (прозада — З.Хәким, «Агымсуда ни булмас», М.Кәбиров, «Сары йортлар сере»; драматургиядә — Ф.Бәйрәмова, «Вакыйга җүләрләр йортында бара», Д.Салихов, «Алла каргаган йорт», З.Хәким, «Җүләрләр йорты»). Аталган әсәрләрнең поэтикасын күп очракта әдәби уен ысулы билгели. Т.Миңнуллинның «Минһаҗ маҗаралары» романында пародия-гротеск формасында массалар аңында яшәп килгән мифлар тасвирлана, милли тарихны кабат күздән кичерү омтылышы ясала. Аның драматургиясендә («Әлдермештән Әлмәндәр», «Сөяркә», «Илгизәр+Вера») милләтне саклап калу һәм яңарышка чакыру проблемасы сатирик алымнар һәм чаралар ярдәмендә калкуландырыла. Поэзиядә С. һәм юморның үрелеп баруы күзәтелә, бу, үз чиратында, карикатуралаштыру, җиңелчә көлү, мәгънәви каламбур тудыра (Ш.Галиев, Л.Лерон, Р.Миңнуллин, Л.Шәех). Сынлы сәнгатьтә С. графика һәм плакат жанрларында үсеш ала.

Әдәб.: Ганиева Р.К. Сатирическое творчество Габдуллы Тукая. К., 1964; Ханзафаров Н. Татарская комедия. К., 1996; История татарской литературы нового времени (XIX— начало XX вв.). К., 2003.

**САФИН** Мансур Габдулла улы (11.5.1949, Кемерово ө., Анжеро-Судженск ш.), язучы, тәрҗемәче. Татар һәм рус телләрендә яза. Оренбург зенит-артиллерия уч-щесын (1969), Казан ун-тын (1975), Яр Чаллы патент ин-тын (1992) тәмамлый. 1978 елдан Чаллыда яши: КамАЗда эшли, 1995 елдан «Аргамак» ж-лының баш мөхәррир урынбасары, 1999 елдан Яр Чаллы пед. ин-тында укыта, 2001 елдан «Бизнесс-класс» ж-лының баш мөхәррир урынбасары, 2007 елдан Үзәк китапханәләр системасы методисты. «Мамадыш таңнары» (1992), «Хәерле иртә» (Чаллы, 1994), «Өмет, Ышану һәм Мәхәббәт» («Вера, Надежда и Любовь», Чаллы, 1994), «Ода Мамадышу» («Мамадышка мәдхия», Чаллы, 2007) шигырьләр җыентыклары, балалар өчен «Сербакчага сәяхәт» (1997), «Сыерчык бураны» (2004) җыентыклары, туган төбәкне өйрәнүгә багышланган «Мамадыш — былиналар төбәге» («Край былинный, Мамадышский», 1994), «Гомер хакына — утка» («В огонь — во имя жизни», 1998) китаплар авторы. Рус теленә Э.Касыймов, М.Насыйбуллин, Е.Уткин, Ф.Бәйрәмова, З.Гомәрова, Г.Асанов, В.Казыйханов әсәрләрен, татар теленә М.Цветаева, Б.Пастернак, Н.Рубцов, В.Высоцкий әсәрләрен тәрҗемә итте.

Әдәб.: Прихожан П. Пространство ожидания Добра // Аргамак. 1999. №5; Чупринин С. Новая Россия: мир литературы: Энцикл. словарь-справ. М., 2003. Т.2.

*Б.А.Канеев.*

**САФИН** Фәкил Миңнемөхәммәт улы (әдәби тәхәллүсе Фәкил Әмәк) (2.1.1954, Мөслим р-ны Әмәкәй ав. туа), язучы, филол. фән. канд. (2007), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1981). 1975тән Мөслим р-ны урта мәктәпләрендә укытучы. 1984 тән Чаллы шәһ. яши. 1988 елга кадәр «КамАЗ» ЖБдә мастер. 1991-95тә «Аргамак» ж-лы мөхәррире һәм җаваплы сәркатибе, 1996-99 да «Фән һәм мәктәп» — «Наука и школа», 2001-05тә «Мәйдан. Чаллы» ж-ллары баш мөхәррире. 2005-06да ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары, 2006дан Чаллы шәһ. администрациясе каршындагы рухи мирасны өйрәнү төбәк фәнни-методик үзәген җитәкли. 1970 елларда яза башлый. «Тузга-

нак чәчәге» (Чаллы, 1994), «Сәфәр» (2002) исемле шигырь җыентыкларында татар халкының язмышы турында уйланып язылган әсәрләре урын алган. Шигырьләре аллегорик сурәтләүләргә бай. «Соңгы көз» (Чаллы, 1992) пов.нда тоталитар җәмгыять өчен хас булган иллюзияләрдән кешенең арыну процессы тасвирлана. «Гөлҗиһан» хикәяләр җыентыгы мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек турында. «Биек тауның башларында» (1998) ром. белән С. Чечен Респ-касы белән РФ арасындагы 20 гасыр ахыры конфликтын, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып күрсәтүгә ирешә. Төп геройлары репрессия корбаннарына әверелгән «Саташып аткан таң» (2003) ром.-трилогиясе белән «Шәүлә» (2008) ром. да тарихи чынбарлыкка нигезләнеп иҗат ителгән. С. шулай ук балалар өчен язылган «Ак канатлы йолдызлар» (1997), «Ләлә белән Арыслан» (2005) җыентыклары; К.Сибгатуллин, Зөлфәт, Р.Бәшәр, М.Әгъләмовның тормыш һәм иҗат юлларына багышланган әдәби-тәнкыйть мәкаләләре авторы. ТРның Г.Исхакый исем. Язучылар берлеге премиясенә ия (1999). Медальләр белән бүләкләнгән.

Әд.: Бәйрәмова Г. Шәфкать һәм вәхшәт // Казан утлары. 1999. №5; Заһидуллина Д. Фаҗигале еллар авазы // Яңа дулкында. К., 2006; Аныкы ук. Яңа юллар бәхете // Казан утлары. 2007. №7.

**САФИН** Фәннур Шәйхенур улы (27.6.1948, Минзәлә р-ны Күзкәй ав. — 31.12.1992, Казан), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлагач (1974), ТАССР МС ның телевидение һәм радиотапшырулар к-тында мөхәррир, «Татарстан яшьләре» г-тасы, «Ялкын» һәм «Казан утлары» ж-лларында әдәби хезмәткәр, «Мәгариф» нәшриятында мөхәррир вазифаларын башкара. 1983-87дә ТАССР Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре. Башлангыч чор иҗаты «Беренче карлыгачлар» (1970), «Юл башы» (1972) күмәк җыентыкларында урын алган. «Кеше юлга чыкса» (1976), «Сез кемнәр?» (1980), «Тынлык» (1982), «Күкчәчәк» (1985), «Чәчәк гомере» (1988) исемле шигъри җыентыклар авторы. С. — нигездә лирик шагыйрь. Төп темасы — татар халкы язмышы, буыннар дәвамчанлыгы турында. Шигырьләренә халыкчан тел бизәкләре, беркадәр моңсулык, сагыш белән өртелгән җылылык хас. Балаларга атап язылган шигырьләре («Яңгыр малае», 1993) гади, кызыклы булулары белән аерылып торалар, яшь буынны кыю, гадел, кешелекле булырга өйрәтәләр. С. сүзләренә иҗат ителгән «Хушлашырга ашыкма» (Р.Гатауллин муз.), «Җырымда юатырмын» (Б.Мөлеков муз.), «Моңлану» (Ф.Хатипов муз.) җырлары зур популярлык казанды.

Әсәр.: Тынлык. К., 2008.

Әд.: Лерон Л. Йөрәктә ниләр бар? // Казан утлары. 1987. №5; Гамбәр Н. Авырту булып калды // Казан утлары. 1998. №6; Якупов К. Тынлыкка эндәшү // Мирас. 2002. №12.

**САФИНА** Нәҗибә Әхмәтнур кызы (2.3.1949, Башкортстан Респ-касы Янавыл р-ны Кисәк-Каен ав. туа), шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлагач (1972), башта Кама-Тамагы р-нында, аннары Чистай р-ны урта мәктәпләрендә, Чистай пед. училищесында укытучы булып эшли. 1979-90 елларда Башкортстанда яши: Нефтекамск шәһ. нәшер ителә торган «Вперёд» («Алга») исемле төбәк г-тасының тәрҗемәчесе, бүлек мөдире; 1983тән Нефтекамск шәһ. ндә автосамосвallар з-дында; 1988-90да шәһәрнең китап сөючеләр җәмгыятенә җитәкчелек итә. 1990 елда кабат Казанга кайта. 1992-96да «Шәһри Казан» г-тасында хәбәрче, «Сөембикә» ж-лында бүлек мөхәррире вазифаларын башкара. Беренче шигырьләре көндәлек матбугатта, «Яшь көчләр» (Уфа, 1982), «Кызлар җыры» (1984) күмәк җыентыкларында басыла. Лирик һәм милләт язмышы турында публицистик рухлы шигырьләре «Таң кошы» (1997), «Әгәр дә уйлаганда...» (2002), «Без — шигырь, тормыш — проза» (2004), «Кан хәтере» (2009) исемле җыентыкларда. Аның публицистикасы да милләтне борчыган җитди мәсьәләләрне кыю күтәрүе, принципиаль карашлары белән үзенчәлекле. Балаларга ул мавыктыргыч сюжетлы әкиятләре, шигырьләре тупланган «Кош теле» (1996), «Мәче фәлсәфәсе» (2000), «Аккош күле» (2000), «Камка һәм яфрак капка» (2004), «Чакырып алынган ай» (2009) исемле җыентыклары белән мәгълүм.

Әд.: Гамбәр Н. Таң кошы — таңда йокламый // Казан утлары. 2004. №3.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Сәхифәне* **Рәйсә МУСАБӘКОВА** *алып бара.*

## Ветераннар

Сара Садыйкова көе
Гәрәй Рәхим сүзләре

Картаймагыз әле, ветераннар,
Европаны саклап калган ирләр.
Җиңү бәйрәмнәрен якынайтып
Үттегез сез бик күп, бик күп илләр,
Үттегез сез бик күп, бик күп җирләр,
Үттегез сез, кыю батыр ирләр!
Җиңү бәйрәмнәрен якынайтып
Үттегез сез бик күп, бик күп илләр,
Үттегез сез бик күп, бик күп җирләр,

Җырлагыз сез җиңү көннәрендә,
Яшьлегегез – җиңү көйләренә.
Ветераннар, сез күп түгелләр бит –
Кайталмады күпләр өйләренә.
Кайталмады күпләр илләренә.
Кайталмады туган җирләренә.
Ветераннар, сез күп түгел бит,
Кайталмады күпләр илләренә.
Кайталмады туган өйләренә.

Солдатларча итеп урамнардан
Узыгыз сез, данлы ветераннар.
Картаймагыз, әй, сез, тынмас җаннар,
Сезгә тиеш әле бик күп назлар,
Сезгә тиеш әле бик күп язлар.
Сез күп түгел инде, ветераннар,
Картаймагыз, әй, сез, тынмас җаннар,
Сезгә тиеш әле бик күп назлар,
Сезгә тиеш әле бик күп язлар.

## ВЕТЕРАННАР ГИМНЫ НИЧЕК ТУДЫ

Бөек Ватан сугышында данлы, фаҗигале, көтеп алынган Җиңүгә 70 ел тулу алдыннан күнелдә төрле хатирәләр, җанда төрле хисләр һәм уйлар яңара. Ә бездә, сугыш балаларында бу хисләр аеруча киеренке – безгә, сугыш башланган елны туган яшьтәшләргә дә инде быел 74 яшь тула бит...

Мин үзем 1941 елның 15 июлендә, сугыш башланып, нибары 23 көн үткәч туганмын. Җәйнең иң матур, табигатьнең иң тулып ташкан мәле бу. Шушы гүзәл җәй уртасын (15 июль бит җәйнең кыл уртасы!) тагын да матурайтып дөньяга нәни сабый туу нинди зур шатлык, нинди зур бәйрәм булырга тиеш иде дә бит, тик ил өчен, авылдашлар, туган-тумачалар, әти-әниләр өчен бу көннәр гаять фаҗигале, гаять каһәрле булганнар.



Әтием мин туарга өч көн кала сугышка чыгып киткән. Мин исә әнинең борынына житкән көмәнле корсагында булып калганмын...

Бала чагымдагы җанга тигән ачлык, авыл кешеләренең көн саен диярлек почта белән килгән кара хәбәрләрне – авылдаш ир-атларның сугышта үлеп калулары хакындагы повесткаларны алгач битләрен тырный-тырный сугышка каһәр укулары, үкереп елаулары минем якты дөньяда яшәгән беренче елларымның онытылмас хатирәләре булып калды... Үсә төшеп, беренче шигырьләремне яза башлаганда ук, минем иҗатта сугыш темасы, гомумән сугышларга нәфрәт, бернинди шәхси гаепсез көе сугышта үтерелгән ир-егетләргә карата чиксез хөрмәт темасы үзенчәлекле бер урын алды. Дөрес, сугыш темасына язылган шигырьләрем күп түгел (әдәбиятта гел-гел сугыш турында гына язып тору бу теманы девальвациягә китереп, аны очсызландырган очраклар да аз булмады ич бездә). Һәр китабымда диярлек бер яки ике шигырь шушы темага багышланган иде.

Моннан 30 ел элек, 1974 елда минем «Зирек бөдрәләре» дигән шигырь китабым басылып чыкты. Анда Бөек Ватан сугышыннан исән кайткан якташларыбызга багышлап язылган «Ветераннар» дигән шигырем дә урын алган иде.

Беркөнне Г.Тукай исемендәге Язучылар клубында (клуб ул чакта Бауман урамы, 19нчы йортның бишенче катында урнашкан иде) Язучылар союзының партия җыелышы алдыннан коридорда мине Сара апа Садыйкова туктатты. Гомеренең соңгы елларында Сара ханым язучылар партия оешмасында тора иде.

Туктатты да гадәтенчә дулкынланып сүз башлады:

– Әй, Гәрәй энем, синең «Ветераннар» дигән шигыреңне укыдым. Бик матур сүзләр, яшь булсаң да, ветеран йөрәген аңлый белгәнсең. Минем бу сүзләргә бөтен ветераннарга багышлап җыр, җыр гына да түгел, гимн язасым килә! – дип сүзен тәмамлады ул.

Мина кинәт кыен булып китте. Халкыбызга шулкадәр атаклы җырлар язып бүләк иткән композиторыбыз минем, яшь бер язучының сүзләренә гимн язарга ниятләсен әле!

– Ләкин, – дип сүзен дәвам итте Сара ханым, – җыр текстының үз тәртибе бар, синең шигырь азрак иреклe шигырьгә тартым, аны җыр, нота калыбына саласы булыр.

– Анысын гына эшлибез аның, – дип дәртләнеп җавап бирдем мин.

Сара апа инде бу вакытта халык арасында киң танылган күп җырларга көй иҗат иткән, җыр сөючеләрнең сөекле композиторы иде. Шулай да, Композиторлар союзындагы бик рәсми һәм ясалма сәбәпләргә иярүче, йә булмаса аларны уйлап чыгаручы кайберәүләр Сара апаның иҗади үсешен, иҗади уңышларын тоткарларга тырыштылар. Әйтик, алар Сара Садыйкованың музыка буенча югары белеме юк, ул консерватория бетермәгән дип, шуны төп сәбәп итеп аның Композиторлар союзына әгъза итеп алынуын озак еллар тоткарлап тордылар. Шуңа күрә булса кирәк, Сара апаның иң якын иҗади дуслары язучылар, бигрәк тә шагыйрьләр иде. Аның Язучылар союзының партия оешмасында учётта торуының бер сәбәбе дә шушы булса кирәк.

Сара Садыйкова үзенең иң талантлы, иң саллы, халык тарафыннан югары бәяләнгән, дөньяның татарлар тупланып яши торган бөтен төбәкләрендә яңгырап торган җырларын күренекле татар шагыйрьләре сүзләренә иҗат итте. Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Мостай Кәрим, Нури Арслан, Әхмәт Ерикәй, Мөхәммәт Садри, Гамил Афзал, Мостафа Ногман, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, бигрәк тә Гөлшат Зәйнашева аның якын дуслары булдылар. Ул аларның һәрберсе белән озаклап иҗади әңгәмә кора иде. Аның Сибгат Хәким белән очрашып сөйләшкәннәрен берничә мәртәбә күргәнем бар. Әле дә күз алдымда, Язучылар союзында булган җыелышлардан соң алар Тукай клубында икәү генә калып бик озак сөйләшәләр иде. Бу сөйләшүләрнең һәрберсеннән соң диярлек Сара Садыйкованың Сибгат Хәким сүзләренә язган яңа җыры туа иде. Галим Ким Миңнуллин үзенең «Һәр чорның үз җыры» дигән фәнни китабында *(«Мәгариф» нәшр., 2003)* композитор Сара Садыйкованың шагыйрь Сибгат Хәким сүзләренә 18 җыр язганын билгеләп үтә.

Сара апаның өлкән буын язучылар сүзләренә иҗат иткән «Казан кичләре», «Җидегән чишмә», «Кайтам инде», «Актаныш басмалары», «Көтәм сине», «Туган авыл», «Өченче көн тоташ кар ява», «Дөнья матур, дөнья киң» һәм башка бик күп җырлары әле бүген дә халык арасында өр-яңа җырлар кебек яңгырыйлар.

Сара апа безнең замандашлар булган, ул чактагы яшьрәк буын шагыйрьләр иҗатына да игътибарлы иде. Шагыйрьләр Әхмәт Рәшитов сүзләренә язылган «Беренче мәхәббәт», Роберт Миңнуллинның «Әнкәй» җырлары үзе генә дә ни тора!.. Нәкъ әнә шул чакларда Сара апа минем «Ветераннар» дигән шигыремә дә игътибар иткән. Бу шигырьдә мин, чыннан да, сугыш балаларының берсе буларак, инде сирәкләнеп баручы өлкәнәйгән ветераннарга бер җылы сүз әйтергә теләгән идем.

Тора-бара без Сара ханым белән шигырьне «җыр калыбына» керттек һәм композитор гимнны яза башлады. Шактый вакыт үтте, әледән-әле очрашып торсак та, җыр язмышы турында ни ул әйтми, ни мин сорарга оялам.

Озакламый миңа Мәскәүгә күчеп китәргә туры килде һәм без Сара апа белән турыдан-туры аралаша алмадык. Еллар үтте, мин инде Сара апа бу җырны язарга өлгермәгәндер яки, язылса да, үзен канәгатьләндермәгәндер дә текст өстендә эшләүне туктаткандыр дип уйладым.

Мин Мәскәүдән кайтып, Казанда яши башлагач, Сара апаның кызы Әлфия Айдарская миңа «Ветераннар»ның композитор кулы белән язылган нотасын алып килде. Ул, чыннан да, гимн итеп язылган. Ләкин, Сара апа бу җырны кайсыдыр бер җырчыга яки хорга бирергә өлгермәгән күрәсең, ул композиторның язу өстәлендә ятып калган.

Шулай да «Ветераннар» җыры Татарстанның Мәдәният министрлыгы тарафыннан районнардагы мәдәният йортлары, үзешчән сәнгать түгәрәкләренә таратылган һәм күп кенә районнардагы концертларда башкарылган. Әйтик, Актаныш районы үзешчәннәре аны үзләренең концерт репертуарына кертеп яратып җырлыйлар.

Бөек Җиңүнең 70 еллыгы алдыннан бу гимн белән Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле хоры да кызыксынды һәм аны үз репертуарына алырга булды. Хәзер хор гимнны Бөек Җиңү көннәрендә узачак зур концертларда башкарырга ниятли. Гимнның бәйрәм көннәрендә әлеге атаклы хор тарафыннан башкарылуы, әлбәттә, халкыбызның талантлы кызы, күренекле композитор Сара Садыйкова иҗатына булган мәхәббәтебезне һәм хөрмәтебезне тагын бер мәртәбә ачык чагылдырыр дигән ышаныч бар.

**Гәрәй РӘХИМ,**
*Татарстанның халык язучысы*

# ХАЛКЫБЫЗ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

## ШӘФЫЙКА КОТДУСОВАНЫҢ ТУУЫНА 105 ЕЛ



Тормышта без төрле яссылыктагы кешеләр белән аралашабыз. Берләре үзе яисә якыннары өчен генә матди байлыкка омтылып яши. Дөнья һәм җәмгыять проблемалары аларга байлык туплау яки карьера ягыннан файдалы булу күзлегеннән генә кагылырга мөмкин. Мондый кешеләр гадәттә бай-мул яшиләр, аларда искитмәле купшы төзелгән йорт һәм дачалар, яхшы фатирлар, «текә» машиналар, балалары дәрәҗәле уку йортларында укый... Ә бар шундый кешеләр, тормышның алда әйтелеп киткән яклары аларны бөтенләй дә кызыксындырмый. Дөнья язмышы, ил, халык язмышы, тормышны тагын да яхшыртырга, матуррак итәргә омтылу — аларның яшәү мәгънәсе, яшәү рәвеше. Алар — үзләрен эшкә фанатларча багышлап, җәмгыятьнен чәчәк атуына булышлык итеп, башкаларны да изге шөгыльгә иярткүчеләр, әйдәүчеләр! Бай да түгел, күп очракта тормышка яраксыз кебек, әмма үзләрен бәхетсез хис итмиләр, чөнки алар өчен тормыш ваклыклары юк кебек, бөтен барлыклары белән үз халыкларына фидакарьләрчә хезмәт итәләр, алны-ялны белми эшлиләр, җәмгыять өчен, дөнья үсешенә өлеш кертү максаты белән яшиләр, җәмгыятьне алга алып баручылар, алар ярдәмендә кешелек авырлыкларны һәм каршылыкларны җиңә барып, алга атлый! Кызганыч ки, бигрәк тә безнең җәмгыятьтә, андый затлар азайганнан-азая бара. Кешелек дөньясының үсеш тарихы шатлык һәм кайгылар, изгелек һәм явызлык, вату һәм җимерү, әрсезлек һәм битарафлык һ.б. белән тулы. Әмма кешелек хәтерендә — кешелек җәмгыятен алга этәрүче күренекле Шәхесләр, талантлы язмышлар. Алар исеме халык хәтерендә мәңгелек булып кала!

Татар профессиональ музыка сәнгатебезнең үсеш тарихы зур түгел — бары йөз елдан артык кына. Әмма талантлы татар халкы ничә гасырлар буе чит халык басымы астында яшәргә мәҗбүр булса да, кыска вакыт эчендә үзенең мәшһүр җырчыларын, композиторларын, художникларын, галимнәрен чыгара алды. Җир катламыннан бәреп чыккан чишмә кебек — йөз еллык вакыт эчендә күпме талант туды! Шулай ук һәр нәрсәнең икенче ягы булган кебек, фаҗигале язмышлар да аз түгел талантлар арасында. Даһилык белән золымлык тәңгәл килә алмый билгеле, әмма тормышта залимнәрнең өстенлек алган очраклары да юк түгел. Чөнки Талант — ул иң югары биеклек, ул яклауга мохтаҗ һәм күп вакыт талантлылар тормышка җайлашмаган була...

Без, дан-шөһрәткә ирешкән күп кенә күренекле татар хатын-кызларын беләбез! Аллага шөкер, галимәләребез дә бар. Шундый мәшһүр хатын-кызларыбыз арасыннан Татар Дәүләт опера һәм балет театры солисты, милли опера сәнгатебезнен күтәрелеш чорында үзеннән искиткеч зур өлеш керткән мәшһүр сәхнә йолдызы, опера сәнгатенең музыкаль күгендә якты эз калдырып бик иртә киткән Шәфыйка Котдусованың гыйбрәтле язмышын һәм иҗатын искә аласы иттек...

Шәфыйка Йосыф кызы Котдусова 1910 елның 18 мартында Севастополь (Акъяр) үзәк мәчетенең баш имам-хатибы Йосыф хәзрәт Рәхимовның дүртенче баласы булып дөньяга килә. Бала чагы, яшүсмер чоры шул шәһәрдә уза. Йосыф Исмәгыйль улы фикердәш дусты Исмәгыйль Гаспралының кызы хөрмәтенә кызына Шәфыйка (Шефика) исемен куша (Бөек кырымтатар мәгърифәтчесе Исмәгыйль бәк Гаспралы һәм Идел буе татарларының танылган нәселеннән туган Биби Зөһрә Акчурина кызы — хатын-кызлар өчен беренче «Женский Мир» журналы мөхәррире Шефика-султан Гаспринская-Насипбейли (1886-1975) Гаспралы һәм Рәхимовлар нәселе дустанә мөгамәләдә булалар. Севастопольдә 1913 елда ачылган мәчеттә дә беренче доганы И.Гаспралы укыганлыгы билгеле. Уникенче буын руханилар

нәселеннән булган Йосыф хәзрәтнең әтисе Исмәгыйль хәзрәт тә Сергач ягының иң күренекле татары була. Ул имам булгач, Сембер губернасы Курмыш өязенә кертелгән Яна Мучәләй авылында дәүләт хисабына яши торган дөньяви стационар мәктәп ача, Новочеркасскида мәчет һәм мәктәп бинасы төзеттерә, соныннан Севастополь мөселманнары чакыруы буенча 1885 елда анда күчеп килә. Исмәгыйль хәзрәт имам, мөгаллим, укытучы буларак татарның җәдит мәктәпләренә кадәр үк мәктәп системасын янарта башлаган алдынгы мәгърифәтчеләрнең берсе булган. Севастопольдә беренче башлап ислам үзәге — мәчеткә нигез салучы, ул эшне башлап йөрүче дә шул Исмәгыйль хәзрәт була. Бу турыда Мәсгуд ага Гайнетдиннең «Гасырлар мирасы» китабында «Бер башына өч зур хезмәт» язмасыннан укып белергә була. Исмәгыйль хәзрәт улы Йосыфны да ислам илләре мәдрәсәләрендә укытып мулла итеп урнаштыра. Әтисе хаҗ сәфәрендә вафат булгач, Йосыф хәзрәт аның эшен дәвам итә һәм мәчетне 1913 елда төзеп бетерттерә.

Менә шундый затлы, гыйлемле һәм бик тә музыкаль гаиләдә кәләч йөзле, терекөмештәй житез булып үсә кечкенә Шәфыйка. Биш яшендә инде ул гарәпләрнең борма нәкышле язуын таный, әтисе камил белгән француз телендә иркен аралаша алган. Г.Тукай иҗаты гаиләдә ят булмый — балалар «Кисекбаш»ны, «Шүрәле», «Су анасы»н яттан сөйли, «Туган тел»не җырлый. Алар жыелышып төрле музыка уен коралларында әтиләре Йосыф хәзрәт яраткан «Тукай маршы»н (З.Яруллин) да уйнарга яраталар. Әниләре Фатыйма абыстай «Зиләйлүк», «Гөлжамал», «Зөлхиҗә» кебек озын көйләрне бик оста итеп балаларына тыңлаткан. Балалар гыйлемле булып үсәләр — ике музыкант, бер мәгариф хезмәткәре тәрбияләнә бу гаиләдә: Шәфыйка — җырчы, Камил Рәхимов — Башкортстанның күренекле композиторы, фольклорчы, сеңлесе Нурия — Татарстанның атказанган укытучысы. Шәфыйканың музыка укытучысы, патша хатынының элеккеге фрейлинасы, Смольный затлы кызлар институтын тәмамлаган Елена Остроменская кызга гомумаурупа һәм музыкаль культуралар тәрбиясе бирә. Дүрт ел уку дәверендә Шәфыйка искиткеч уңышларга ирешә: классик әсәрләр фортепианода җинел уйный ала һәм, 15 яшеннән вокал өйрәнә башлап, опера арияләрен дә жырлый ала. Мәскәү консерваториясе профессорлары аның талантына иң югары бәяне бирәләр, кызга зур киләчәк вәгъдә итәләр. Әмма кабул итү комиссиясе мулла кызын консерваториягә алмый.

Ул Севастопольгә кайта һәм, йөрәк ярасын басарга ниятләп, иҗатка тотына. 1927 елны гүзәл Шәфыйканы сәхнәдә күреп, шәһәргә командировкага килгән 24 яшьлек юрист Абдураим Кутдусов гашыйк була. Симферопольдә (Акъмәчет) туып үскән Абдураим Карасубазарда баш прокурор, Шәфыйканың мәгъшукларыннан аермалы буларак, үзенең төпле акыллы-гыйлемлелеге белән кызны үзенә җәлеп итә, гашыйк иттерә. Бу — радикаль эш иткән Йосыф әфәндеңең күнеленә хуш килми, 17 яшьлек кызларын кияүгә бирергә каршы була. Абдураим күп уйламый, ятканының ризалыгы белән аны урлап алып китә.

Язмыш аларны кая гына китерми — яшь гаиләдә беренче уллары Җәвид тугач, Абдураимны Карасубазардан Керчька юллыйлар. Шәфыйка беркайчан да үзен сәнгатькә багышлау уеннан кайтмый, ул зур сәхнә турында хыяллана. Улы Җәвид бераз үскәч, Шәфыйка радиокомитетта эшли башлый. Ул елларда мәдәният традицияләре күпкә югары булып, Кырымның һәр шәһәрендә камера хоры һәм оркестр эшләп тора. Керчьта да радио каршында шундый профессиональ коллектив оештырыла. Шәфыйка шунда пианист-концертмейстер булып урнаша.

Оркестр кыскартылгач, аның тапёр булып эшен дәвам итүен сорыйлар («Дингезчеләр клубы»нда сүзсез киноны музыка белән тулыландыру эше). Билгеле, тулы карангыда пианинода уйнау зур осталык сорый. Бу осталыкка ия Шәфыйка классик әсәрләрне югары дәрәҗәдә башкара һәм заманның популяр көйләрен дә искиткеч осталык белән импровизацияли.

Шул чорларда Абдураим партия сафларыннан чыгарыла, эшеннән азат ителә — «органнар» көтмәгәндә аның «халык дошманы» нәселеннән килеп чыгуын «ачыклыйлар». 1934 елны аларның икенче уллары Эрнст (Эрик) туа. Шәфыйка кичләрен клубта эшләвен дәвам итә, ә көндезен заводта экономист вазифасын үти. Вакыт үтү белән, әнисе килә (әтисе Йосыф хәзрәтне «халык дошманы» дип кулга алалар һәм ул өенә башка кайтмый, атып үтерелгәне соныннан гына билгеле була), Шәфыйкага театр коллективында



*У.Гаджибеков. «Аршин мал-алан» музыкаль комедиясендә Гөлчәһрә ролендә.*

катнашырга мөмкинлек туа. Бу театр күпмедер дәрәҗәдә профессиональлеккә якын булып, Шәфыйка театрның прима артистына әверелә. 1936 елны гаилә Кырым башкаласы Симферопольгә күчә, һәм музыкага профессиональ тартылу көче аны Акмәчет музыка училищесына китерә. Ул ике белгечлек буенча белем алып, вокал һәм фортепиано бүлекләрен параллель рәвештә тәмамлый. Мәскәүдән кайткан Абдураим танылган юристларның берсе булып китә, Симферопольнең адвокатлар коллегиясендә эшен уңышлы дәвам итә. Ә Шәфыйка укуын эш белән аралаштырып, тәмамлагач, Симферопольдә яңа гына оештырылган Кырымтатар җыр һәм бию ансамбленә солист итеп кабул ителә, шул ук вакытта Кырым радиокомитетында пианист-аккомпаниатор булып та эшли.

Сонрак искиткеч матур тембрлы лирик колоратур сопрано тавыш иясе Шәфыйка Котдусова аерым концертлар белән чыгыш ясый башлый. Шул вакыттан ук ул кырымтатар халык һәм татар җырларын да, композиторлар әсәрләрен дә, шулай ук опералардан арияләр, классик романсларны да югары профессиональ биеклектә башкара алган киң репертуарлы җырчы була.

Олы улы Җәвид ул башкарган җитди әсәрләрне зур игътибар белән тыңлап үсә. Музыкаль сәнгатьнең төрле жанрларын күңеленә сеңдереп бара, кечкенәдән музыкага, халык иҗатына мәхәббәт тәрбияләнә Җәвидтә. Соңыннан әнисенең талантын дәвам итеп, профессор дәрәҗәсенә җитә.

1940 елны Кырымга Татар сәнгате декадасына әзерләнү максаты белән опера вокалчыларын тыңлау конкурсын оештыру комиссиясе килеп төшә. Декада Мәскәүдә 1941 елның җәенә тәгаенләнә. Билгеле ки, Шәфыйка берсүзсез сайлап алына һәм декадага әзерләнү өчен Казанга чакырыла. Казанга Ш.Котдусованы әти-әни туфрагы да тарткандыр, татар мәркәзе булган Шәһри Казанга ул пианист-концертмейстер һәм җырчы тәҗрибәсен туплаган талантлы музыкант булып килә. Казанга ул кече улы белән килеп, күп тә үтми, опера һәм балет театрының прима солисты булуга ирешә. Казан опера театрында эшли башлаганда, театр өчен Мәскәүдә махсус студия тәмамлап, инде танылып өлгергән артистлар янында аңа бик нык тырышырга туры килә. Күп көч куеп татар телен, сәхнә хәрәкәтләрен, операда башкару алымнарын өйрәнә һәм, тиз арада ул алар белән бер сафта чыгыш ясый башлый. Казанга килгәч, иң беренче тапкыр тамашачы белән очрашуы Н.Җиһановның М.Җәлил либреттосына «Алтынчәч» операсында Алтынчәч партиясе була. Шәфыйканың Алтынчәче М.Җәлилгә бик ошый, ул аны премьерадан соң котлап, бу партиянең аның тавышы өчен генә язылганын белдерә. Әмма бер айдан соң М.Җәлил фронтка китә.

Шәфыйка Казанга килгәч, аның артыннан ире Абдураим, әнисе Фатыйма абыстай һәм Җәвид тә юлга чыга. Зур тырышлык белән әзерләнгән декада булмый кала — сугыш башлана... Ире Абдураим үз теләге белән фронтка китә һәм батырларча һәлак була, гаиләсе сугыш елларының бөтен авырлыгын, бөтен газабын күтәреп яши. Казан опера театры эшләвен дәвам итә. Артистлар (күпчелек хатын-кызлар) концерт бригадалары төзеп авылларда, госпитальләрдә, фронт сызыкларында чыгышлар ясыйлар. «Концерт эшчәнлегендә, әдәби-музыкаль кичәләрдә иң актив катнашканы Шәфыйка Котдусова булды», — ди замандашлары. 1941 елдан Казан опера театрында эшли башлагач, беренче роле Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсында Алтынчәч, 1942 елда Ж.Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендә Сәрвәр, 1945 тә М.Юдинның «Фәридә»сендә Фәридә партияләре сугыш елларында туа. Авыр сугыш еллары булуга карамастан, ул катнашкан операларда театр залы тамашачы белән тулы була.

Улы Җәвидкә 12 яшь. 1941-1942 елларда коточкыч суык һәм ачлык хөкем сөргән елларда гаилә көч-хәл белән исән кала. Татарстанда урнашкан 176 мең эвакуацияләнгәннәрнең



*Уңнан сулга: М.Җәлил, Ш.Котдусова, Г.Кайбицкая, И.Һилалов М.Җәлил дачасында. 1941 ел.*

яртысы Казанга килә. 70 завод-фабриканы Казанга күчерәләр. Шәһәрдә 50 хәрби госпиталь була. 1942 елдан оборона заводында 13 яшьлек улы Җәвид тә эшли. 12 сәгать эш көненә карточка буенча бирелгән ипи нормасы 800 грамм. Шәфыйка Котдусова — театр эшчесе буларак 400 грамм ипи алып кайта. Соңрак үсмер Җәвид Төньяк флотта юнга мәктәбенә китә. Бөек Җиңүгә үз өлешен кертә.

1941-1953 елларда Шәфыйка ханым спектакльләрдә иң күп җырлаган солист була. Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә куелып килгән татар опера һәм музыкаль спектакльләрнең барысында да, рус һәм чит ил классиклары опера, оперетталарында публиканың яраткан җырчы артистына әверелә һәм төрле образлар иҗат итә. Дж. Вердиның «Риголетта» операсында Джильда, Розина (Дж. Россини, «Севильский цирюльник»), Микаэла һәм Фраскита (Бизе, «Кармен»), Рәйханә («Качкын»), Галиябану (М.Мозаффаров, «Галиябану»), Фәридә (М.Юдин, «Фәридә»), Су-Сылу (Н.Җиһанов, «Түләк»), операсында Карлыгач (Н.Җиһанов, «Намус»), Гөлйөзем (С.Сәйдәшев, «Наемщик»), Шәмсия («Акчарлаклар»), Фәйрүзә («Идел буенда»), Сәрвәр («Башмагым») һ.б. бик күп партияләр... Сәхнәдә ул музыкаль төгәллеге, осталыгы белән тамашачы мәхәббәтен яулый, образларның йөрәк кичерешләрен музыкада, җырда тормышчан, ышандырырлык итеп ачып бирү сәләтенә ия була. Ш.Котдусованың якын дусты, танылган музыка белгече Зәйнәп ханым Хәйруллина: «Шәфыйка, Татарстанның атказанган артисты исеменә лаек булгач, сәхнәдә эшләвен дәвам итте һәм консерваториягә укырга керде, аны 1951 елда (өч елда) тәмамлап, вокал факультетында концертмейстер вазифасына кереште...» дип язды. Зәйнәп ханым кара бөдрә чәчле, кыйгач кашлы, шәфкатьлелек нурлары сибелеп торган зур коңгырт күзле, зифа буйлы ханымга соклана һәм җырчы нинди генә әсәр башкармасын, нечкә музыкаль сиземлелек белән Шәфыйка ханымга гына хас нәфислек, мөлаемлылык белән башкаруын ассызыклый. Күп кенә татар композиторлары әсәрләрен беренче башкаручы да ул. Аның тавышына махсус җырлар языла. Г.Тукай сүзләренә З.Хәбибуллин музыкасына балалар өчен «Кошларга», «Карлыгач» җырларын тыңлагач, аның бу көйгә нинди колоратур төсмерләр кертүенә сокланмый мөмкин түгел. Ш.Котдусованың тавышы — җинел агыла торган житез, йөгерек хәрәкәтчән, төрле колоратур бизәк-мелизматикага табигый итеп күчә алучан тавыш. Төрле жанрдагы әсәрләрне — төрле халык көйләреме — барысын да нечкә музыкальлелек, үзенә генә хас нәфислек белән башкара ул. Үзенең үтә моңлылыгы (музыкальлеге), төгәл-саф эчкерсез ихлас җырлавы белән тамашачыны үзенә җәлеп итә. Образларны тыйнак-нәфис итеп бирүне өстен күрә. Җ.Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендә Сәрвәр — Ш.Котдусованың иң яраткан һәм иң уңышлы рольләренең берсе була. Татарстан радио фондында аның берничә язмасы саклана. Күпме еллар элек язылган язмалар да аның нинди мәшһүр җырчы булганлыгын исбатлый. Кызганыч, күп язмалары, пластинкалары юк ителгән. Җ.Фәйзинең «Башмагым» опереттасы да яздырып алына, «Алтынчәч» операсы аның башкаруында тулысы белән язылган булган, әмма алар юк инде. Видеотасмалар да юкка чыгарылган...

Шәфыйканың Казанга каян килгәнен исләрендә тоткан, танылган артисттан котылырга юл эзләгән, һәркая өлгерүче «органнар» йокламыйлар. Ныклы сәбәп табалмагач, иң мәгънәсез нәрсә уйлап табалар — ТАССРның атказанган артисты (ул заманнарда бу исемнең дәрәҗәсе зур була), тамашачының иң яраткан артисты Шәфыйка Котдусованы иҗатының чәчәк аткан, дан-шөһрәт казанган вакытының

ин югары ноктасында, Кырымда туган татар кызы буларак, репрессиягә дучар итәләр һәм аны профессиональ яктан яраксыз дип яраткан эшеннән алалар. Бу нахак ялганга беренчеләрдән булып театрның баш дирижёры Исаак Шерман кул куя. Артистлар дөньясында интригалар, көнчелек тә табигый күренеш икәне билгеле — көнчелек, хәсетлек тә кушылмый калмагандыр бу эшкә, сәнгать советында саналган кайбер көндәш җырчылар имзасы да була анда. Театрның яна җитәкчесенең башбаштаклыгына танылган сәнгатькәрләр (Ф.Насретдинов, Ф.Садриҗиһанов һ.б.) каршы чыгып, коллегаларын яклап мөрәҗәгать итеп карыйлар, әмма директор НКВДдан (Черек күлдән) күрсәтмә булуы турында белдерә. Шушы сүзне әйткән өчен, директорны да эшеннән азат итәләр. Шундый җан әрнеткеч нахак гаделсезлектән соң ул авырып тавышын югалта. Авыр минутларында аны белгән һәм тиңдәше булмаган талантын бәяләгән коллегалары таяныч-терәк булалар. Тавышы бераз көйләнә башлагач, джаз оркестрын оештыручы күренекле музыкант Олег Лундестрем Шәфыйка Йосыф кызын үзенең коллективына чакыра. Музыка тарихында билгеле булганча, СССРда джаз яңалык буларак тыелган була. 1951 елда оркестрны таркаталар. Шәфыйка ханым, зур конкурс үтеп, Гастрольбюрода (Росконцерт) катнаша. Москонцертта солист буларак ул Зара Долуханова, Иван Козловский кебек танылган җырчылар белән чыгыш ясый, Рәшит Бейбутов белән У.Гаджибековның «Аршин мал-алан» музыкаль комедиясеннән дуэтлар җырлый...

Әмма үткәндә кичерелгән фаҗигаи хәлләр озак көттерми, үзен белдерә — энкеведэшниклар ясаган яра-җәрәхәт, стресслар анның организмын какшата, яндырып көйдерә дисәк тә дөрес булыр. Табиблар җырчының көннәре санаулы икәнен әйтәләр. Куркыныч диагноз, куркыныч хөкем карары кук, 1956 елның апрелендә, 46 яше тулып, бер ай үтүгә, үз эшен эшли. Үләр алдыннан Шәфыйка ханым: «Мин бәхетле, чөнки гомерем заяга узмады. Яраткан сәнгатемә хезмәт иттем, ике искиткеч талантлы ул тудырып үстердем (олы улы Җәвид дирижёр-хормейстер, профессор, 58 ел татар халкының сәнгатенә хезмәт итте һәм гомеренең көзендә туган шәһәре Симферопольгә китеп, Кырым дәүләт индустриаль педагогика университетының музыка белеме бирү факультетында бүгенге Кырымда бердәнбер музыкант-профессор, ә кече улы Эрнст МДУның география факультетын тәмамлаган геолог-морфолог, бик күп китаплар авторы, галим, язучы), яраттым һәм мине дә яраттылар. Мин беркемгә дә ачу тотмыйм!» — ди. Бу сүзләр үзенең гомерен һәм кабатланмас талантын сәнгатькә һәм халкына багышлаган Шәфыйка Котдусова рухының бөеклеген исбатлый, аны васыяте буенча Казанга алып кайтып җирлиләр.

Атылган йолдыз белән тиңлиләр Шәфыйка Котдусованы замандашлары: бик кыска гомер һәм иҗат юлы, ә эзе бик якты кала анның! Чор, тормыш авырлыгы талантлы җырчыны сыный, сыга, ләкин сындыра алмый. Быел анның тууына 105 ел. Татар радио фондында байтак язмалары сакланган. Тормышын, иҗатын чагылдырган ике телдә документаль повесть язылды. Югары музыка уку йортларында анның иҗатына багышланган фәнни конференцияләрдә докладлар укыла. Хәзерге сәясәткә күз салсак, безнең Шәфыйка Котдусова ике төрки халыкның мәдәни рухын берләштерүче шәхес тә булган бит! Менә тиздән анның Татарстандагы һәм дә Кырымдагы иҗат тормышын һәм гыйбрәтле гомер юлын, нәсел-нәсәбен чагылдырган документлар, истәлекләр, мәкаләләр, фотоархив тупланган китап дөнья күрәчәк. Җыентык киң катлау укучыда, урта һәм югары уку йортларында белем алучы студентларда һәм укытучыларында татар музыка тарихы белән кызыксынуларын арттыруга ярдәм итәр, анның җырлау осталыгы киләчәк буын татар монсарларына гыйбрәт-үрнәк булыр, шулай ук шәхесләр язмышына битарафлыкны киметер дигән өмет белән чыгарыла.

Талантлы җырчы, искиткеч соклангыч гүзәл актриса Ш.Котдусованың, шулай ук Татарстанга гына түгел, Башкортстан һәм Кырым музыкаль культурасына да күренеп торган нәтиҗәле зур өлеш керткән Котдусовлар нәселенең язмышлары да никадәр кыйммәтле-әһәмиятле булган кебек, шул кадәр драматик катлаулы да. Татарстан һәм Кырым татарлары җәмәгатьчелеге танылган җырчының олуг бәйрәмен зурлап билгеләп үтәчәк. Бу юбилей — язмышының фаҗигалелегенә карамастан, «Сәнгать — мәңгелек!» дигән хакыйкать, анның иҗатына тиешле бәһа һәм хөрмәт булып яңгырар.

**Филүсә АРСЛАН,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

# ОСТАЗ

## МӘГЪСУМ ХУҖИННЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Аннан шактый яшьрәк булсам да һәм төрле районнарда туып үссәк тә, язучы Мәгъсум абыйның малай чагын әйбәт беләм мин. Теләсәләр, бүтәннәр дә белә ала. Моның өчен әдипнең «Курагай атлары» исемле хикәясен яисә кыскадан-кыска гына «Ялвару»ын аңлап уку да җитә — оста каләменнән төшкән бу әсәрләр каһәрле сугыш чоры балаларының михнәтле яшәешен шактый төгәл итеп күз алдына китерә дә бастыра. Мәгъсум дә шул балалар арасында. Әй, ул сугыш аркасында якты сабыйлыктан, ваемсыз балачактан, иркәләү-назлаудан мәхрүм үскән малайлар! Шуна да байтагының холык-фигыле үзгә, күпләр өчен аңлаешсыз аларның. Сугышта җиңүнең 70 еллыгы белән сугыш балаларының ачы язмышын үзәкләргә үтәрлек хикәяләп калдыра алган әдипнең 85 еллыгы бер үк айга туры килү дә тикмәгә түгелдер.

Менә малайлар бер янгырлы-пычрак көнне Арчадан ат белән «неграин» дигән ягулык алып кайтып киләләр. Сүз уңаеннан шуна да игътибар итик: Мәгъсум Хуҗин хикәяләрендә үз чорының малайлары белән атлары янәшә диярлек куеп сурәтләнә, чөнки тормыш чынлыгы авторга аларны бер-береннән аерып карарга ирек бирми. Хикәядә «хуҗалары» кебек үк ач һәм хәлсез Курагай атларының берсе дә үз йөген Курса тавыннан тартып менә алмый. Берәм-берәм биш арбаны үр өстенә Соры бия менгерә. Үзенең соңгы көче, калган гомере бәрабәренә эшли ул моны. Малайлар соңгы чиктә генә ашарга дип саклаган бар икмәк кисәкләрен җыеп Соры бия хуҗасы Дуслайга бирәләр. Үзләренә берни калдырмыйча! Моны сугыш чоры авылындагы ат хакын да, бала кулындагы ачлык елы икмәгенең ни бәһа торганын да бик күпләрдән яхшырак белгән әдип яза, ышандырып яза. Хикәядән «Соры бия» дип укыйсың, ә күз алдына аның кебек үк соңгы җегәре, алда буласы гомере исәбенә нидер эшләп сугыштагыча шәһит киткән ач үсмерләр, хатын-кызлар, өлкәннәр килеп баса. Ни көенеч, Мәгъсум Хуҗиндай, Мөхәммәт Мәһдиевтәй, Чыңгыз Айтматовтай каләм ияләре генә «күрде» ул балаларны. Ә ил әлегәчә битараф диярлек калды, сугыш чоры михнәтләре вакытсыз алып киткән гомерләрнең исәбен алучы да юк. Урынсыз корбаннарга никадәр күнеккән бу ил!

Шундый вакыйгалар эчендә үскәнгә һәм, өстәвенә, аларны күнеле аша кат-кат үткәреп әсәрләрендә язып килгәнгә, тормышның кадерен белү, шәфкать, миһербан, үзара теләктәшлек кебек, кешене кеше иткән сыйфатларны җанына мул җыйган булгандыр бу әдип. Һәм тагын бер үзенчәлеге — үзеннән байтакка яшьрәк язучы һәм шагыйрьләр арасында шактый еш күреп була иде аны. Яшьләрне — ул, аны яшьләр үз итте. Хикәя китапларына кереш сүзне шагыйрь Зөлфәт, Фаил Шәфигуллин язды, үзе ялга киткәндә, шагыйрь Ләис Зөлкарнәй «Идел» журналындагы эш урынына Мәгъсум абыйсын калдырып тора иде, «Казан утлары»ның баш мөхәррир урынбасары, талантлы Флүс Латыйфи аның белән кызып-кызып үзенең әдәби каһарманнары хакында бәхәсләште, Язучылар берлеге җыелышыннан чыгуына аны фатирына кадәр алып кайту өчен Ләбиб Лерон машинасы көтеп торды, талантлы Фаил Шәфигуллин серле шартларда вафат булгач, Мәгъсум абый үз энесен югалткандай хәсрәтләнде, шагыйрь Газинур Морат аны әле дә иҗаттагы остазым дип саный. Нәкъ шул «Хуҗинлы» елларда «шәкерт» Газинур Морат «Түбә» исемле шигырь китабы өчен көрәшче әдип Гаяз Исхакый исемендәге бүләккә ия булды, Зөлфәткә Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылды, ә аларның уңышына куанучылар уртасында Мәгъсум абыйлары иде. «Күрегез әле, бер елда өч хикәясе басылды, өч яхшы хикәя бит ул!»

– дип, Зиннур Хөсниярны Фатих Хөсни исемендәге бүләккә тырышып тәкъдим итүче дә шул тынгысыз остаз булды. Мондый бүләкнең иң беренчесен бик хаклы рәвештә ана – Мәгъсум Хуҗинга тапшырганнар иде. Хикәя язучыларны бигрәк тә үз итә иде кебек ул. Ркаил Зәйдулланың шигырьдән ныклап хикәя язуга күчә барган чорында радиодан ул: «Хикәяләре шигырьләреннән дә әйбәтрәк», – дип сөйләде. Гүя остаз тиздән Ркаилнең дә «Хөснилеләр сафы»на басачагын, Тукай исемендәге бүләкне дә шигырь һәм проза китаплары өчен алачагын алдан күргән иде. Озак еллар Татарстан Язучылар берлегенең әгъзалыкка кабул итү комиссиясендә эшләве дә Мәгъсум Хуҗинны яшь әдип-шагыйрьләр иҗаты белән якыннан танышып баруга китергәндер. Сонрак комиссиядә анын Газинур Мораттай шәкертләре эшләде.

Карасана, якын аралашкан яшьрәк каләмдәшләре, нигездә, ир-егетләр булган икән бит. Хикәяләрендә дә кыз балаларга караганда малайлар күбрәк анын. Җәмәгате Мәгъфируз апа кызлар гына табу сәбәпле, малай юксынуы аркасында шулай килеп чыккандыр, бәлки. Бик көтеп алынган соңгы балалары Мансур туар-тумастан ук Балтач зиратына кереп ятты. Гомере азагына таба Мәгъсум абый кияве белән, улынын каберен карап, чардуганын янадан буярга Балтачка килгән иде. Үч иткәндәй, ул көнне көн буена янгыр яуды, һәм алар, корырак чакта кабат килербез, дип, кайтып киттеләр. Ләкин ана Балтачка, андагы улы каберенә тагын бер килергә язмаган иде, күрәсең. Вафатыннан сон, калдырган буяулары белән, чардуганны мин буядым.

Мәгъсум абый белән иң беренче тапкыр күрешү-танышуым сәеррәк килеп чыкты. 1964 елнын җәй башлары иде. Мине университетка җәйге сессиягә киткән журналистлар урынына Арчаның «Коммунизмга» газетасына вакытлыча эшләргә чакырып алдылар. Колхозда эшли-эшли, Республика читтән торып уку урта мәктәбен тәмамлап, әле генә аттестат алган елым бу. Беренче эш көнемдә редакциянен партия тормышы бүлеге мөдире Илсур абый Хөсәенов мина унлап хат тоттырды да шуларга күзәтү язарга кушты. «Күзәтү язганың бардыр бит?» – ди үзе.

– Ю-у-к! – дим мин, аптырап.

– Ә-ә, ие бит, – ди Илсур абый, минем колхоз фермасыннан гына килүемне исенә төшереп булса кирәк. – Ярый-ярый, язасың син аны.

Язуын яздым да, ниндирәк баш куярга, дип кенә икеләнеп калдым. «Ярар, Мәгъсум абыең үзе карар, бүлмәсенә кертеп куй», – диде Илсур абый.

Типографиядән бүлмәсенә кереп, өстәлендә минем күзәтүне күргәч, җаваплы секретарь Мәгъсум Хуҗин күршедән кычкыра берзаман:

– Рәфыйк, бу күзәтүеннең башы кайда?

– Баш таба алмаган идем шул, – дидем мин, анын кырыс соравыннан котым чыгып.

– Һе, газетада эшләүнең бөтен тәме дә әнә шул табылмаганнарны эзләп табу бит инде!

Икенче елны Балтач районы кире кайтарылып (ул 1962 елда бетерелгән иде), «Хезмәт» исеме белән янадан торгызылган газетада бергәләп эшли башлагач, Мәгъсум абыйның бу сүзләре һич тә очраклы гына әйтелмәгәненә кат-кат инандым. Журналистларны туктаусыз эзләндерүе, иҗадилыкка өндәп торуы дүрт елга якын Мәгъсум Хуҗин мөхәррирлегендә чыккан «Хезмәт»нен һәр санында диярлек сизелеп тора. Ул чакта безнең хезмәт җимеше республикада иң әйбәт эчтәлекле, иң җанлы-җылы газеталарның берсенә әверелде. Ирекле фикерләүнең, иҗат мөмкинлегенең кысыла барган еллары бит әле, Хрущёв «җепшеклеген» сүгеп, сүз ирегең яна чикләүләр эченә куып маташкан чорыбыз. Кече форматлы район газетасы бигрәк тә каты күзәтү астында, андагы «сәяси хата»ны теләсә кем күреп райкомга җиткерә ала. «Хата» җибәрүебезне сөенә-сөенә көтеп йөрүчеләр райкомның үзендә генә дә дистәләгән кеше. Әмма баш мөхәрриребез безгә эзләнү өчен партия түрәләре бәйләнмәслек темалар таба, анда үзенә шелтә эләксә дә, авыр сүзне безнең өскә аудармый. Районнан чыккан күренекле кешеләр турында мавыгып язуларыбыз шул елларда башланды. Иҗат планкасын югары күтәрдек: очерк-зарисовкаларны Мәгъсум абыйның хикәяләре кебек матур итеп язарга омтылдык. Арчада республиканың матбугат җитәкчеләре уздырган бер зона кинәшмәсендә безнең мәкаләләрне берәм-берәм атап: «Башлары ук җырлап тора, редакторының язучы икәнлеге әллә кайдан күренә», – дип сөйләделәр. Мин

шуларны кайтып әйткәч, мөхәрриребез көлеп җибәрде, чөнки теге мәкалә башларын ул түгел, мин үзем куйган идем инде. Шулай булмыйча, кем шәкерте мин?! Мәгъсум абый районга килгән язучы халкыннан хикәя һәм шигырьләр алып калырга тырышты, алар газетаны нык баета, җылы, укылышлы итә дип ышанды. Шагыйрьләр Нәҗип Мәдияров, Дифгат Сирай һәм яшь Тукай биографиясен ак таплардан тазартып, соңрак Ибраһим Нуруллин белән фәнни хезмәт язган Риф Якупов та биредә эшләгәнлектән, редакциябез язучыларның кечкенә генә башлангыч оешмасын хәтерләтә иде.

Мәгъсум Хуҗин кайсыдыр районда эшләгәнме, бүтән җирдәме, мин ул урынны үзенә бертөрле бәхетле булган, дияр идем. Чөнки, кайда эшләсә дә, ул тирәнең халкын, табигатен, үзенчәлеген хикәяләрендә чагылдырып мәңгеләштергән бит ул. Бөек Тукай турындагы хикәяләре язылуга да («Кеше күңеле – үзе бер кояш», «Инә дә инә карлар») әдипнең Арчада эшләп-яшәп алуы йогынты ясамый калмагандыр. Балтач яныннан агып уза торган Шушма инеше аның хикәяләрендә чынбарлыктагыдан да гүзәлрәк булып, үзенә тартып тора, әрәмәсендәге былбыллары үтә өздереп сайрый («Оҗмах агачы»). Соңрак язылган «Урак өсте болытлары» повестенда да Балтачны гел хәтерләвен сиздереп куя ул. «Бөтен Татарстанда су тегермәне икәү генә калган әнә, Янгулда да Салавычта. Икесе дә Балтач районында. Ә безнең Мишә Шушмадан кимме?» – ди повесть каһарманы Мөсәвир карт. (Ни көенеч, Мәгъсум Хуҗин хөрмәт белән исендә тоткан, Мөхәммәт Мәһдиев матурлап язган су тегермәннәре Шушма өстендә дә юк инде.) Биредә язучының хикәяләренә татарлар белән ингә-ин торып яшәүче удмурт вәкилләре – Любаша, Петрух дәдәй, Гликерия-Гөлчирә дә бик табигый гына кереп китә («Сон», «Алан»). Пермь якларында булуы аның иҗатын анлы-намуслы бер генә язучы да читләтеп үтә алмаслык фаҗигале 37нче еллар темасына алып килгән («Кударада кәлтә уйный», «Мәгарә»). Казакъстанда эшләп алуы аның иҗатына («Урак өсте болытлары») беркадәр дала киңлеге өстәгән.

Хикәяләр остасы Мәгъсум Хәмит улы Хуҗинның күпчелек каһарманнарында туган җир хисе шулкадәр көчле, алар шундый бер моң, нечкә-нәфис тойгылар белән тасвирланган ки, берсен дә тыныч кына укырлык түгел («Урак өсте болытлары», «Кангый илендә» h.б.). «Кангый илендә» хикәясенә филология фәннәре докторы Фәрит Хатипов «Якты җирлектәге һәлакәт» исемле рецензиясендә бик югары бәһа бирде. «Кече күләмле жанрда М.Хуҗин инсан хәятенең бик гыйбрәтле, тирән мәгънәле төбәкләрен, адәм баласы холкының төрле якларын, кәеф-халәтенең күп төсмерләрен сурәтләп күрсәтте. Аның әсәрләрендә без җанны назлый торган, нурланып балкыган күренешләр, мөнәсәбәтләр җылылыгы белән дә, кискен драматизм, сагыш, күңел китеклеге, бәндә рухының ярлылана, тупаслана, коргаксый төшүе белән дә очрашабыз. Әмма, ни генә тасвирланмасын, аның хикәяләрендә тоташ моң агыла. Еллар үткән саен бу моң яктыра, тирәнәя, нәфисләнә бара», – дип язды әдәбият галиме, әдипнең тулаем иҗатына кагылып («Казан утлары», 2000 ел, 3нче сан).


Иҗаты чорында иң матур мәхәббәт хикәяләре язып калдыра алуы белән дә бәхетле ул Мәгъсум Хуҗин («Исәнме, Раушания!», «Пшыяцулка»). Ләкин «Пшыяцулка»ны нилектәндер соңгы ике җыентыгына кертмәгән ул. Фатих Хөсни исемендәге бүләкне нәкъ шул хикәясеннән соң биргәннәр иде, югыйсә. Бәлки татар егетенең бер Панига мәхәббәтен кат-кат афишаламаска булгандыр? Алай дисәң, паннар әнә үз илләрендә татар сугышчысына һәйкәл дә салып куйдылар. Президентларында да азмы-күпме татарлык бар икән! Мөнәсәбәтләрнең шуңа таба барачагын «Пшыяцулка» авторы алданрак та күргән булып чыга әле монда. Ә әдипнең алдан күрүчәнлеге – күкләргә якынлык билгеседер, мөгаен.

Хактан әйткәндә, бу әдип бүләкнең зуррагына да лаек булган үзе. Талантын һәм иҗатын Тукай исемендәге бүләкне «эләктергән» кайбер каләмдәшләренеке белән чагыштырып караганда, бу бигрәк тә ачык күренә. Ләкин Мәгъсум Хуҗин тагын шуның кадәр язса да, үзенә Тукай бүләге даулап йөрмәячәк, моңа аның тыйнаклыгы, күпне күргән сугыш чоры баласы булуы юл куймаячак иде. Зөлфәт кебек, Мөдәррис, Ркаил, Газинур кебек зур талантлы яшьрәк каләмдәшләренең иҗатын күрсәләр һәм бәяләсәләр, шуңа да риза-канәгать иде ул.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**



*Геннадий Паушкин — солдат. 1941 ел.*



*Геннадий Паушкин — язучы. 1983 ел.*



*Мәҗит Рәфыйков — фронтовик-студент. 1946 ел.*



*Мәҗит Рәфыйков – язучы. 1978 ел.*



*Сугыш ветераннары – татар әдәбиятының аксакал әдипләре. Сулдан уңга – Риза Ишморат, Сибгат Хәким (утырган), Әмирхан Еники. 1980 ел.*



*Җәлил варислары. Шагыйрьгә багышланган митингтан соң төшерелгән фоторәсем. Үткән гасырның 70 нче еллары.*



*Бер төркем фронтовик язучылар. Сулдан уңга – Тихон Журавлёв, Мәхмүт Хәсәен, Рәйсә Ишморатова, Юрий Белостоцкий, Мирсәй Әмир, Нәби Дәүли. 1975 ел.*

# СЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ СУГЫШ УТЫ БЕЛӘН ҮРЕЛГӘН

## АФЗАЛ ШАМОВ

*(ШАМОВ АФЗАЛ ШИҺАБЕТДИН УЛЫ)*

*(1901–1990)*



Язучы, публицист, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе. 1901 елның 4 мартында хәзерге Татарстан Республикасының Яшел Үзән районы Татар Танае авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.

1919 елның декабрендә А.Шамов үз ирке белән Кызыл Армия сафына баса. Башта ул татар кызылармиячеләрен укырга-язарга өйрәтә, ә 1920-1921 елларда Украинада ақгвардияче Врангель гаскәрләренә һәм Махно фетнәчеләренә каршы барган Гражданнар сугышында катнаша. Армия хезмәтендә ул 1922 елның августына кадәр була.

1922-1925 елларда А.Шамов Казан дәүләт университеты рабфагында укый, бер үк вакытта ике ел ятим балалар йортында клуб мөдире һәм бер ел Татарстан Мәгариф комиссариаты каршындагы зурлар мәктәбендә укытучы булып эшли.

1926-1930 елларда А.Шамов Беренче Мәскәү университетының әдәбият һәм сәнгать факультетында укый. Мәскәүдән кайткач, А.Шамов 1931 елның мартыннан 1943 елның февраленә кадәр Казанда Татар дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторында җаваплы һәм өлкән мөхәррир булып эшли.

1943 елның февралендә ул янә үзе теләп фронтка китә һәм Бөек Ватан сугышында фронт газеталарының хәрби корреспонденты булып хезмәт итә, фронт матбугатында күпсанлы хәбәрләр, репортажлар, очерклар язып бастыра. Ватан сугышы чорындагы батырлыклары өчен ул Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Сугышчан хезмәтләре өчен», «Кёнигсбергны яулаган өчен», «Германияне җиңгән өчен», «Японияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Армия хезмәтеннән А.Шамов 1946 елның маенда кайта.

1949-1950 елларда А.Шамов «Совет әдәбияты» журналының мөхәррире, 1958-1961 елларда Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе булып эшли. 1962 елдан башлап профессиональ язучы сыйфатында әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә.

Әдәби иҗат өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре өчен А.Шамов Хезмәт Кызыл Байрагы, Октябрь Революциясе орденнары һәм 12 медаль белән бүләкләнә.

Афзал Шамов 1990 елның 19 гыйнварында Казанда вафат була.

### Гази Кашшафка[1]

*Газый дус!*

*Мин синең хатыңа җавап язган идем. Алгансыңдыр инде. Ул хатка кадәр, бәлки, үзем кайтып житәрмен дигән идем, булмады күрәсең. Инде июнь башында кайтырмын дип өметләнеп торам. Өметне тагын да ераккарак сузарга туры килмәсә ярар иде.*

*Орденлы егетләр альбомы алып кайтачагым турында язган идем шикелле. Менә шул альбом эшләнеп һәм начальниклар тарафыннан расланып бетмәгән.*

*Үзегезне бик сагындым, бик күрәсем килә.*

*Менә нәрсә, Газый, Радиокомитетка мин «Нәфрәт көче» исемле 4-5 битле бер материал җибәрдем. Алар файдаланганнан соң журналына алсаң, бик яхшы булыр иде. Бәлки, шушы арада тагын бирәр нәрсә җибәрермен.*

*Монда калган өчен мине бик сүкмиләр микән?*

*Иптәшләргә сәлам, диген. Ә үзенә аерым сәлам!*

*Хөрмәт белән, А.Шамов.*
*18 май, 1943 ел*

ЯММҮ. 100 ф. 3 тасв. 295 эш. 2 бит. Төп нөсхә.

*Газый дус!*

*Минем 3-4 хатымны син бер җавапсыз калдырдың. Ә мин синнән җавап көткән идем. Күрәсең, син дә, башка иптәшләр шикелле, гамьсезләнә башладың.*

*Правлениенең информацион хатын алып укыдык. Искә алуыгызга рәхмәт. Матур әдәбиятка һәм язучыларга шундый зур әһәмият бирелә башлавына без бик шатландык. Иҗат өстендә утыручы иптәшләргә чын күңелдән уңыш телим.*

*Без[2] монда бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Вакыт юк. Менә бу хатымны да әле төнге сәгать 4тә генә язам. Исән кайтып, безгә дә бары әдәбият белән генә шөгыльләнергә насыйп итсен иде.*

*Декада мәсьәләсе ничегрәк тора? Әгәр правление члены итеп декадага чакырсагыз бик яхшы булыр иде. Чакыру булса, мондагы начальниклар җибәрергә риза. Бары телеграмма яисә хат үз вакытында килеп кенә житсен.*

*Утын мәсьәләсендә минем семьяны утыртып калдырдыгыз, ахры? Мондый «дуслыкны» кайсыгыз эшләде? Гайнуллин[3] да алдакчы булып чыкты. Чыннан да, шул дәрәҗәдә ялганлый белергә кирәк бит!*

*Иптәшләрнең барысына да сагынычлы сәламнәремне әйт.*

*Кулыңны кысып, А.Шамов.*

*P.S. Фронттагы егетләрдән хәбәрләр бармы? Ф.Кәрим[4] кайда? Газетада түгелме? Без аны чакырткан идек, җибәрмәделәр, ахры.*

*6 март, 1944 ел*

ЯММҮ. 100 ф. 3 тасв. 295 эш. 5, 5 әйл. бит. Төп нөсхә.

*Газый дус!*

*Бу хатны алып укый башлагач та гаҗәпләнеп торырсың инде. «Менә сиңа кирәк булса! Узган хатын ачуланып, үпкәләп язган иде, ә бусында — дус!» — диярсең. Их Газый, Газый, үпкәләрсең дә, ачуланырсың да. Үзең генә уйлап кара, Казанга язучыларга күпме генә хат язмадым мин. Сиңа 5-6ны яздым, А.Гомәргә[5], Ф.Хөсни[6], Ә.Камалга[7] һәм башкаларга хат артыннан хат яздым. Ник берсе җавап бирсен. Нәкъ 5 ай дигәндә синнән беренче хат алдым. Алдым һәм күңелем җылынып китте. Менә бит ничек ул солдат! Аңа бер кечкенә генә хат кисәге дә җитә кала. Шуның белән шатланып, яшь баладай канатланып йөрим. Белмим, иптәшләрдән хат алуның күңеллелеген, аның шатлыгын аңлый алырсың микән син?!*

*Менә шул, дускай!*

*Синең отчёт хатыңа вакытында җавап язган идем. Хатыңа караганда, син аны алмаган шикелле күренәсең. Бәлки соныннан алгансыңдыр да инде. Мин ул хатымда да әдәбият өлкәсендәге соңгы хезмәтләрегез өчен барыгызга да (бигрәк тә сиңа) бик зур рәхмәтемне әйткән идем. Шул ук рәхмәтемне мин бу хатымда да кабатлыйм. Язучыларга һәм аларның хезмәт шартларына шундый зур игътибарның башлануына чын күңелдән шатланам. Бу игътибарның озакламый нәтиҗәләре күренә башлавына да ышанам.*

*Язучы — язучы булып кына хезмәт итәргә тиеш! Бу турыда без никадәрле сүз сөйләгән, никадәрле «кан койган» һәм никадәрле хыялланган идек. Ахырда ул теләккә ирештек, күрәсең. Хәерлегә генә булсын. Төкле аяклы булсын!*

*Бу матур хыялның практик ягы ничек бетте соң? Гонорар мәсьәләләре?*

*Син «кешеләр юк» дип зарланасың. Бик яхшы аңлыйм. Барыгыз да анда йөк атлары шикелле эшләгәнегезне беләм. Нишлисең бит, Газый, еллар шундый бит хәзер.*

*Обком үтенече барып чыкмаган икән. Мине исәпкә алмаганда, башкаларны кайтарырга яраган булыр иде. Рус иптәшләр бу турыда бик иркен эшлиләр. Киләләр дә, китәләр дә. Еш кына аларның өйдәме, әллә армиядәме торганын белмисең. Ә без, бер урында утырып иҗат итүдән бигрәк, хәбәрче, корреспондент ролен башкарабыз.*

*Әгәр теләгегез бар икән, мине безнең политуправление аша соратырга була. Алар өчен бу эшне башкару һич тә авыр булмаячак. Тик моны авторитетлырак оешма аша сорарга кирәк. Әгәр Динмөхәммәтов[8] яисә Шәрәфиев һәм Обкомнан да берәр кеше кул куйса, бу эшнең барып чыгуы бик мөмкин. Политуправление начальнигы — генерал-майор Дребеднев. Адресы: 21475-К.*

*Журналга мин шактый гына очерклар һәм ике хикәя кисәге дә калдырган идем. Нинди хәлдә алар? Нигә җавап бирмисез? Очеркларым, хикәяләрем чыккан журналларны, зинһар, җибәрегез әле. Кем соң ул журналда? Сораучыга җавап бирү — бик элементар кагыйдә бит инде ул! Аңларга кирәк иде шуны. Зинһар, ул таш маңгайларның колакларын бор әле. Бераз кеше кебек булсыннар иде.*

*Таттосиздаттагы «Нәфрәт көче»нең торышы турында язып җибәрә алмассыңмы? Таттосиздатка — Гайнуллинга, Махиянга[9], А.Гомәргә яза-яза да кыйммәтле вакытымны әрәм иттем. Алар, үлек җаннардай, җавап бирмиләр. Ах, шундый игътибарсыз була да алырга кирәк бит!*

*Семьям турында кайгыртуыгыз өчен бик рәхмәт. Чын күңелемнән әйтәм. Бәлки инде ул утынны китертә дә алгансыз. (Көз көне, башкаларга китерткән вакытта, ничек китертә алмый калдыгыз соң?) Әгәр китертергә ярдәм итмәсәгез, ул ордер ордер хәлендә генә калачак.*

*Маннур[10] адресын сорагансың. Белмибез. Ни өчендер безгә белдерәсе килми аның.*

*Үзем һаман шул ук Афзал. Өстемдә дә шул ук шинель. Һич тә үзгәргәнем юк. Әгәр беркадәр үпкәле төшеп хат язганмын икән, бик табигый. Моны син үзең дә аңларга тиеш. Әгәр син минем урында булсаң, дәһшәтле таягыңны селкер идең әле. Менә шулай, дускай.*

*Әгәр вакытың булса (хәтта булмаса да!), хат яз әле. Электәге шикелле үк дус бул әле. Без монда Казаннан килгән һәрбер кәгазь кисәгенә балалар шикелле чын мәгънәсендә куанабыз.*

*Язучыларның барсына да, барсына да минем кайнар сәламемне тапшыр.*

*Кулыңны кысып, исәнлек теләп, А.Шамов.*

*5 апрель, 1944 ел*

ЯММҮ. 100 ф. 3 тасв. 295 эш. 7, 7 әйл., 29, 29 әйл. бит. Төп нөсхә.

*Газый дус!*

*Хатымны элекке гадәт буенча шулай башлап китик әле. Ләкин алгы кырыйдан арып-талып, пычранып кайтып кергәндә, өстәл өстендә дустымның 12 сүздән генә торган бер открыткасы ята иде. Унике сүзнең унбере сиңа хас булмаган зәһәрлек белән тулган открытка иде ул. Әле ярый хатларны сагынып кайткан вакытка туры килде, булмаса, мин дә зәһәрләнеп укыган булыр идем.*

*Шулай да открыткаң өчен рәхмәт. Узган елдан бирле бу синең икенче хатың. Дистәгә якын хатка җитәрлек җавап. Менә шул дистәгә якын хатка бик сагындырып җавап алу аркасында «үпкәләшеп» алдык та без.*

*Сезнең бик тырышып эшләп ятуыгызга без монда барыбыз да бик шатланабыз һәм чын күңелдән уңыш телибез. Кайчакларында, кайтып, сезнең гөрләшеп эшләп ятуыгызны күз кырые белән генә булса да күреп китәсе килә. Инде сугышның очы күренә. Бәлки быел, быел булмаса, «киләсе ярминкәләргә» әйләнеп кайтып җитәрбез. Безнең әле монда бик күп кенә йортларның капкаларын җимерәсебез бар. Эш күп һәм бик авыр эш. Еш кына без туктаусыз алга баручы иптәшләргә чамасыз кызыгып карыйбыз.*

*Маннур адресын сораган идең. Аны күптән түгел генә күрдем. Сиңа хат язган икән. Шунда адресын да язгандыр. Хәзер минем янымда аның адресы булмаганга, аны яза алмыйм (мин моны чит урында язам).*

*Маннурның хәле мактарлык түгел. Әгәр мөмкин булса, аны кайтарырга тырышырга кирәк. Төрле хәлнең булып куюы мөмкин. Шуннан үзең аңларсың дип уйлыйм.*

*Гимн нишли соң? Раслануы белән ук безгә җибәртергә карагыз әле. Монда сорап аптыратып бетерәләр.*

*Шуның белән хатымны бетерәм. Мине сорашкан иптәшләргә сәлам диген.*

*Кулыңны кысып, сәлам белән, А.Шамов.*

*P.S. Язучыларга хатлар язган идек. Нигә җавап бирмиләр? Мирсәйдән*[11] *башка берсе дә җавап бирмәде әле.*

*4 май, 1944 ел*

ЯММҮ. 100 ф. 3 тасв. 295 эш. 9, 9 әйл. бит. Төп нөсхә.

*Газый дус!*

*Бу хатымны өйдән*[12] *язам. Әле хәзер генә кайтып кердем. Әле кулларым да жылынып бетмәгән, ләкин күңелем жылы, хәтта чамасыз жылы. Бер кочак материал, барысы да татар егетләре турында, ә алган тойгыларны инде һич тә кочакка гына сыйдырып бетерерлек түгел. Егетләр сугыша беләләр. Алай гына да түгел, барлык авырлыкны баһадирларча, йөзләрен дә сытмый күтәрә беләләр. Һәм кирәк икән, солдатча батыр итеп, дошманның өстенә егылып үлә дә беләләр.*

*Мин шундый егетләргә карыйм да таңга калам һәм үземнең шулар арасында булуыма шатланам да, горурланам да. «Их, вакыт булсын иде дә, — дим мин, — «К.Татарстан» өчен яисә радио өчен нәрсә булса да язасы иде», — дим.*

*Шушы хатым белән мин сиңа журнал өчен кечкенә генә бер хикәя җибәрәм. Зинһар, алуың турында хәбәр ит әле. Март аендамы, әллә февральдә үкме, «Куаклар арасында» дигән бер нәрсә җибәргән идем [журнал адресы белән]. Шушы көнгә кадәр чыкканын да күрмим, берничә мәртәбә редакциягә хат язуыма карамастан, җавап бирүче юк. Әйт әле, зинһар, кем җавап бирми, нигә язарга авырыксыналар? Әгәр моны аңлы рәвештә эшлиләр икән, тиешле чарасын күр. Моны ничек эшләргә икәнен син миннән яхшырак беләсең. Моны мин үзем өчен язмыйм, әгәр кирәк икән, тиешле җавапны мин таш астыннан да ала алырмын.*

*Редакциягә хат белән мөрәҗәгать итә торып һәм җавап ала алмый торган йөзләрчә егетләр өчен язам мин моны.*

*Шатлыгымны кая куярга мөмкин булмаган сәгатьләрнең берсендә, барыгызга җыеп, бер хат язган идем, бәлки, алгансыз. Яңа билет алу өчен [ә минем искесе дә юк], Мирсәй ниндидер анкета сораулары җибәргән иде, хәзер аның ул кәгазе кул астында юк. Аны табып, шушы көннәрдә аерым хат язармын.*

*Сагынычлы сәлам белән, кулыңны кысып, Афзал.*

*P.S. Мине сорашкан иптәшләрнең барына да дусларча сәламемне тапшыр! Һаҗәргә*[13] *дә бик зур сәлам диген! Аның белән ике кәлимә сүз сөйләшмәгән булсам да, акыллы ана һәм чын, идеаль хатын, йөрәкле кеше булып сакланып калган ул минем күңелдә. Балаларың нихәл? Исәннәрме? Ә үзеңнең исәнлегең? Яңадан кискенләшүеннән саклан, дускай! Әгәр мөмкин булса, хикәяне радиога да тапшырт әле!*

*29 ноябрь, 1944 ел*

ТР МА. Р-7083 ф. 1 тасв. 176 эш. 46 бит. Төп нөсхә.

*Газый дус!*

*25 ноябрьдә язган хатыңны өйдән чыгып китәр алдыннан гына алдым. Искә төшерүең өчен бик рәхмәт.*

*Хатыңдагы җылы сүзләреңнең тәэсире күңелемә генә түгел, тәнемә дә булды, ахры. Көн шактый гына җилле һәм салкын булуга карамастан, туңмадым дип әйтерлек. Машинадан машинага күчә-күчә, 70-80 километр җирне үткәнне сизми дә калдым. Алга якынлашкач, инде җылынырга урыны да һәм җылынырлык хәрәкәтләре дә була.*

*Монда килеп житкән көнне үк хат язмакчы идем. Туры килмәде. Көндезе эш белән уздым, ә төнлә урыны да, яктысы да булмады.*



5*

*Менә хәзер кечкенә генә бер «өстәл» янында, кеше үтеп киткән саен сүнәргә талпына торган «шәм» яктысында сине искә төшерә-төшерә хат язам. Тирә-юнемдә, ялкау гына яна торган тимер мич янында, егетләр утыралар. Алар әле бүген генә кызу сугышны үткәннәр, үлем белән күзгә-күз берничә мәртәбә очрашканнар. Анда аларның кайбер дуслары да ятып калган. Әллә шуңа, әллә башкага, алар авыз эченнән генә моңаеп нәрсәдер җырлыйлар. Мин аларның нәрсә җырлауларына колак салмыйм, ә моңнарын гына тыңлыйм. Матур моң, күңел кылларын тибрәтерлек көй. Алар белән бергә минем дә моңаясым килә. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, минем көем юк. Көйсез кеше булдым мин.*

*Бу егетләрне мин моңа кадәр бер генә мәртәбә дә күргәнем юк. Ләкин аларны мин шушы берничә минут эчендә инде дус күреп, якын күреп өлгердем. Хәтта артык нәрсә сөйләшмәдек тә без. Житмәсә, татарлар да түгел әле алар. Шулай да без бер-беребезне дус итеп хис итәбез.*

*Алар миңа барсы да хөрмәт күрсәтәләр. Беләм мин аларны, алар минем фикерләремне чуалтмас өчен шулай әкрен генә сөйләшәләр, әкрен генә җырлыйлар. Мин дә аларга шундый ук хөрмәт белән җавап бирәм. Ә бераздан без барыбыз бергә аркага-арка куеп, тәмле йокыга талырбыз. Их, тормыш, тормыш, синең юлларың кая гына алып бармый, кемнәр белән генә табындаш итми һәм салам түшәкләрне кемнәр белән генә уртаклаштырмый! Уйлыйм да, гаҗәпкә калам. Кемнәр белән генә мин бер котелоктан ашамадым, кемнәр белән генә мин төннәр үткәрмәдем шушы ике елда. Кая гына барсам да, нинди генә землянканың ишеген каксам да, үземнең дусларымны табам мин. Алар мине һәр юлы үзләренең сугышчан иптәшләре итеп каршы алалар.*

*Бераздан йокларга ятабыз, дидем. Әйе, ятабыз. Безне йокыга да туп, миномёт һәм пулемёт тавышлары озатачак, әгәр төн тыныч үтсә, без шул тавышлар астында тәмле йокыга китәчәкбез һәм шул ук тавышлар астында уяначакбыз да. Өсне салмыйча, чишенмичә йоклыйбыз инде без. Син безгә, дускай, тәмле һәм тыныч йокы телә. Төн буе безнең тимер мичебез янып торсын, ә ишек төбендәге часовойның күзенә бер генә секундка да йокы әсәре кермәсен һәм ул үзенең сизгерлеген киметмәсен.*

*Ут карангыланганнан караңгылана бара. Мин язып бетерергә ашыгам. Хатны язучы һәм укучы өчен дә бердәй күңелсез темага күчәргә телим. Нишлисең бит, монда булу, кайтып, үзең эшли алмау хат аша язарга, хәтта сорарга да мәҗбүр итә.*

*«Куаклар арасында» дигән нәрсәне (хикәя дисәң, кәефе китүе мөмкин) 6/III та Альменов[14] артыннан җибәргән идем. Аны ул «С.Ә.»на илтеп биргән булса кирәк. «С.Ә.»ннан алып, радиода укыганнар дип ишеттем. Таба яисә таптыра алмассыңмы икән син аны.*

*Инде утын турында сүз башлыйк. Үткән ел өйдән хат ала алмавым аркасында, синнән берничә мәртәбә сорарга, хәтта сине үпкәләтергә туры килгән иде. Быел фронтовик семьяларына утын мәсьәләсе ничек тора? Минекеләр әле узган елгыны да китертә алмаганнар дип ишетәм. Әгәр безнең кебекләргә бирә торган булсагыз, истән чыгармасагыз яхшы булыр иде.*

*Хикәя язарга һич тә вакыт юк дисәм, ышанмассың инде син. Әллә кайчан башлаган ике хикәям бар. Ләкин һич тә кул тими. Исән кайтсак, ничек тә бер талпынып карарбыз инде.*

*Котлавың өчен рәхмәт. Аны акларлык хезмәт күрсәтергә кирәк әле. Тагу гына житми бит ул.*

*Өйдән чыкканда гына Разинның да хатын алган идем. Аңа инде икенче бер унай китереп язармын.*

*Дусларча кулыңны кысып, сагынычлы сәлам белән, Афзал.*

*Фронттагы язучыларның күбесе бүләкләнгәндер инде. Алар турында язсаң, яхшы булыр иде. Кызыксынуыбыз кечкенә түгел.*

*Танысаң гына ярар иде инде бу хатны!*

*20 декабрь, 1944 ел*

ТР ММ. КППи 120056-1. 1-2 бит. Төп нөсхә.

**Язучыларга**

*Иптәшләр!*

*Бу хатымны кемгә язарга да белмим. Язучыларга җибәргән барлык хатларым җавапсыз калып киләләр. Шуның өчен дә берәүгә дә атамыйча гына язам.*

*Шушы хат кисәге белән бергә «Куаклар арасында» исемле бик кечкенә генә хикәя җибәрәм. Алуыгыз турында хәбәр итүегезне үтенәм.*

*Минем очерклар чыккан журналларны берәр данә җибәрсәгез, бик яхшы булыр иде.*

*«Өзелгән кыллар» дигән хикәя җибәргән идем. Алдыгызмы?*

*Сәлам белән, А.Шамов.*
*6 март, 1944 ел*

ЯММҮ. 100 ф. 3 тасв. 295 эш. 4 бит. Төп нөсхә.

*Кадерле иптәшләр! Газый, Гомәр, Мирсәй, Кавый[15], М.Гали[16], Тажи[17], Фатих, А.Гомәр һәм башка иптәшләр! Бу хатымны мин Сезгә Германиядән, кабахәт, ләгънәтле илдән язам. Менә мин икенче көн инде, һөҗүм итеп баручы бер батальон белән бергә, Германия җире буйлап барам. Безнең ил чиге инде шактый артта калды. Ул һаман ераклашканнан ераклаша. Ул никадәр генә ерак калмасын, без аны барыбыз да бөтен җаныбыз-тәнебез белән сизәбез. Ул безнең артта, ул безгә көч һәм дәрт бирә, үзенең нуры белән безне җылытып тора.*

*Фашизмны тудырган бу ләгънәтле ил җиренә аяк басуның беренче минутларын күрсәтәсе иде сезгә, дуслар! Безнең сугышчыларның батырлыгына, куркуны белмәүләренә һәм алга ашкынуларына исегез китәр иде! Мондый ашкынуны әле минем бервакытта да күргәнем юк иде.*

*Немецлар качалар. Без аларның үлекләрен таптап, кирпеч түбәле хуторлар, агачлар арасына утырган авыллар, кечерәк шәһәрләр аша үтәбез. Бөтен әйберләрен, җиһазларын, хәтта ашый торган ашларын да ташлап качканнар. Урамнарда, кырларда сыерлар, сарыклар һәм тынгысыз дуңгызлар йөри. Аларны куып алып китәргә өлгермәгәннәр. Төрле җирдә трофей кораллар аунап ята.*

*Кешеләр юк. Һәркайда да бушлык. Немец халкы качуны артык санаган. «Юк, качып котыла алмаслар. Без инде хәзер ерткычның үз оясында. Без аны шунда кыйнап үтерәчәкбез!» — диләр сугышчылар.*

*Без гадел хөкем, алынырга тиеш булган хаклы үч алып барабыз. Гадел хөкем аларны кайда гына булса да куып җитәчәк.*

*Иптәшләр, сез кинәт миннән барыгызга бер хат алуыгызга гаҗәпләнмәгез. Мин сезгә, һәркайсыгызга да, вакытында аерым-аерым хатлар яздым. Ә җавапка саранлыгыгызны сез инде һәркайсыгыз да бик яхшы беләсез. Бу хатымны исә мин җавап алу өчен түгел, ә шатлыгымны уртаклашу өчен язам. Без Германиядә! Бу сүзгә карт солдатның күпме шатлыгы, күпме горурлыгы һәм барыннан да бигрәк тәмам җиңү сәгатенең ничек якынаюын тою салынганын сез бик яхшы аңлыйсыз инде.*

*Барыгызга да исәнлек теләп, һәркайсыгызның кулларын кысып калам.*

*Афзал.*

*P.S. Бу хатымны мин бик күп мәртәбәләр бүленеп яздым. Мин аны 21 октябрьдә кырда, бер агачлык арасында башлаган идем. Шуннан соң мин аны бәрхетле диван өстендә дә, подвал идәнендә дә яздым. Ахыры менә 22 октябрьнең иртәсендә, кояш чыгып килгәндә, бер йорт буена ышыкланып тәмамладым. Әле бик иртә. Кояш күтәрелеп кенә чыгып килә. Кояш бит, егетләр, безнең яктан, Москва ягыннан чыга!*

*А.Ш.*
*21 октябрь, 1944 ел*

ТР ММ. КППи-120056-1. 21, 21 әйл. бит. Төп нөсхә.

**Хәмит Ярмигә[18]**

*Ярми туган!*

*Тар гына кәгазьгә киң өметләр белән язылган хатыңны алдым. Мондый кәгазьгә, чыннан да, фольклор материалларын язарга кирәк. Җырлар язуны гына сорап тора торган кәгазь.*

*Бу хатың белән син мине ничектер уятып җибәргәндәй булдың. Без фольклор җыю эшенә монда бертөрле дә әһәмият бирмәгәнбез. Тынгысыз частьлар буйлап, ашыгыч эшләр артыннан йөгерә-йөгерә, шундый әһәмиятле нәрсәне онытканбыз. Дөрес, минем бу турыда уйлаштыргалаганым бар, ләкин һәрьюлы аны икенче, хәтта иң арткы планга куйгаларга туры килде. Шулай итеп, бүген минем биштәрле капчыгымда ике генә юл да материал юк. Хәзер мин сиңа бернәрсә дә җибәрә алмыйм, дус кеше. «Ах, бу бәндәне!» — диярсең инде син ачынып. Нишлисең бит, бәндә гөнаһтан хали түгел (шулай диләр шикелле, онытыла да төшкән).*

*Кызың институтта, улың хәрби мәктәптә укый торган булгач, бик зур карт булгансың икән инде син. Балаларыңа бәхет телим, ә үзеңә тыныч «картлык»! Ах, гомер, гомер, уза да уза! Чынлап картаябыз, Ярми. Артыбызга әйләнеп карасак, озын, тар сукмак. Гомер сукмагы. Анда безнең ялангач аякларыбызның эзеннән башка бернәрсә дә юк. Коры эзләр генә.*

*Сез миңа Тукай томын җибәрткәнсез, дип ишеткән идем. (Шушы урында ручкамның карасы бетте. Каһәр төшкән немец ручкасы! Караны аз ала. Хәзер инде гади ручка кебек итеп манып кына язам. Кул астында андый кара юк. Бу хатымны өйдән чыгып киткән җирдә язам.) Искә төшереп, китап җибәрүең өчен шушы көнгә кадәр сиңа да һәм Агишка[19] да рәхмәт әйтергә туры килгәне юк иде. Бу хатым белән бергә минем чын күңелдән әйтелгән рәхмәтемне дә алыгыз!*

*Яңа эшеңдә уңыш телим! Материаллар табылу белән үк җибәрә барырмын.*

*Сәлам белән, А.Шамов.*
*6 февраль, 1945 ел*

Бу хатның күчермәсе Халидә Гатина тарафыннан Республика традицион мәдәният үзәгенә тапшырылган. Төп нөсхә ЯММҮдә 90 тасфирланмаган фондта саклана.

Искәрмәләр

1 Гази Кашшаф (1907-1975), әдәбият галиме, тәнкыйтьче.
2 Язучылар Абдулла Әхмәт (1905-1976) һәм Афзал Шамов.
3 Мөхәммәт Гайнуллин (1903-1985), ул чакта Таттосиздат директоры.
4 Фатих Кәрим (1909-1945), шагыйрь.
5 Абдулла Гомәр (1906-1974), тәрҗемәче, журналист.
6 Фатих Хөсни (1908-1996), язучы.
7 Әнәс Камал (1908-1978), язучы.
8 Гали Динмөхәммәтов (1892-1951), ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе.
9 Фатих Махиянов (1900-1987), ул чакта Таттосиздатның баш мөхәррире.
10 Шәйхи Маннур (1905-1980), язучы.
11 Мирсәй Әмир (1907-1980), язучы.
12 Өйдән — фронт редакциясеннән.
13 Һаҗәр — Гази Кашшафның тормыш иптәше.
14 Байназар Альменов (1909-1976), рәссам, график. 1944 елда ике айдан артыграк «Алга, дошман өстенә» исемле Беренче Балтыйк буе фронт газетасы редакциясендә иҗади командировкада була.
15 Кави Нәҗми (1901-1957), язучы.
16 Мөхәммәт Гали (1893-1952), язучы, әдәбият галиме.
17 Таҗи Гыйззәт (1895-1955), язучы.
18 Хәмит Ярми (1904-1981), фольклорчы галим.
19 Якуб Агишев (1899-1972), әдәбият белгече, текстолог.

## Афзал Шамовның Кытайдан язган хатлары

*Гомәр!*

*Язмыш җиле безне дөньяның бер читеннән икенче читенә ташлады. Хәзер без Кытайда. Куе кытай чәе эчәбез, аларның тозсыз пешерелгән мантыйларын ашыйбыз. Син тагын манто дигәч тә, өскә кия торган мантоларны ашый башлаганнар икән бу җүләр солдатлар, дип уйлый күрмә! Һич тә андый нәрсә түгел. Ул бары кабартма шикелле ашамлык кына.*

*Кытайларның ашын ашагач, тормышларын күргәч, мин ирексездән: «Йә раббым, йә раббым, туган илемнең өтек чыпчыгы да мондагы сандугачлардан матур!» — дияргә мәҗбүр булам.*

*Гомәр, синең редакциядәге китап чыккандыр инде. Миңа тиешле бер данәсен*

*минем өйгә җибәрсәң һәм, мәрхәмәтең килеп, берсен безнең редакциягә җибәрсәң, бик тә яхшы булыр иде.*

*«С.Ә.»нда кем хәзер? Бик күрәсе килә шул журналны. Гаҗәп сагындырды.*

*Теләнә башлагач, теләнеп бетерим инде. Анда «Батырлар китабы»н алырга мөмкинлек юкмы? Әгәр шундый мөмкинлек булса, минем семьяга хәбәр иттер әле! Алар, акчасын түләп, килеп алырлар.*

*Сәлам белән, А.Шамов.*
*П.п. 74232-П.*
*2 сентябрь, 1945 ел.*
*Кытай*

ТР МА: Р-6529 ф. 1 тасв. 128 эш. 11, 11 әйл., 12 бит. Төп нөсхә.

*Ерикәй!*

*Мин сиңа «Соры мәче» исемле бер хикәя җибәрәм. Зинһар, аны үз кулың белән «С.Ә.» журналына тапшыр әле! Анда хәзер кемнең редактор икәнен белмим. Редакциягә генә җибәреп, югалуы ихтимал. Шулай исемсез җибәреп, бер хикәям югалган иде инде.*

*Мин сиңа берничә хат язган идем. Барып җитмәделәр, күрәсең. Монда килгәннән соң, Казандагы иптәшләрнең берсеннән дә хат алганым юк. Язучылар тормышын бик беләсем килә.*

*Тиз кайтып булмас, ахры. Очы күренми.*

*Сәлам белән,*
*А.Шамов.*
*2 октябрь, 1945 ел.*
*Кытай*

ТР МА. Р-7083 ф. 1 тасв. 176 эш. 38 бит. Төп нөсхә.

*Газый дус!*

*Бу хатымны мин ерактан, Кытай җиреннән язам. Хәзер төн. Тышта күзгә төртсәң дә, күренмәслек караңгы. Кайдадыр якында гына патефонда кытай һәм япон көйләрен уйнагалар. Вакыты-вакыты белән кайбер көйләр нәкъ безнең көй — татар көе шикелле булып яңгырыйлар. Моңнарыбызда ниндидер охшату моментлары бар. Хәзер генә мин тышта озак кына тыңлап тордым.*

*Үзең беләсең, мин музыка өлкәсендә бик надан кеше. Шулай да, минем колаклар монда Сәйдәш иҗат иткән моңнарның охшаш аһәңнәрен тотып алгалый.*

*Тышта шулай тыңланып утыру, безнең көйләргә охшаган моментлары булган музыка тыңлау, Казанны, семьяны, дусларны аеруча сагындырып җибәрде. Шундый сагынулы минутларның берсендә сиңа үземнең дусларча сәламемне җибәрәсем килде. Шулай ук хәлеңне, исәнлегеңне дә беләсем килде.*

*Әгәр вакыт таба алсаң, үзеңнең хәлең һәм тормышың турында, кыска гына булса да, сызгалап җибәр. Сәламәтлегеңне бик-бик беләсем килә.*

*Монда без сине бик еш кына сагынып искә төшерәбез. Егетләр анда кайта башлаганнар икән инде. Монда әле безгә андый җил исми.*

*Һаҗәргә һәм балаларыңа минем сәламемне тапшыр! Ә үзеңә аерым сәлам!*

*Афзал.*
*8 октябрь, 1945 ел.*
*Кытай*

ЯММҮ. 100 ф. 3 тасв. 295 эш. 11, 11 әйл., 12 бит. Төп нөсхә.

*Гомәр!*

*Синең хатыңны алдым. Рәхмәт! Хинган таулары зурлыгындагы рәхмәт!*

*24 сентябрьдә язылган беренче хатың үзе белән бераз борчу да алып килде. Хатыңның тонына һәм андагы сүзләргә караганда, мин сине үземнең хатым белән үпкәләткән булсам кирәк. Нәрсә белән үпкәләтүемне һич тә хәтергә төшерә алмыйча берничә көн борчылып, пошынып йөрдем. Җавап язар өчен кулыма каләм дә ала алмадым. Бары икенче хатың гына тынычлык бирде. Җылы һәм дусларча язылган хат булып чыкты анысы.*

*Дөрестән дә, 2 сентябрьдә җибәргән хатымны миңа коры гына һәм бик ашыгыч кына язарга туры килде. Ул көнне мин командировкага чыгып китәргә хәзерләнә идем. Хатымны шул командировкага чыгып китәр алдыннан гына сызгалап ташлаган идем. Күрәсең, ул тупас һәм күңелне кырырлык булып чыккан булса кирәк. Син мине андый тупаслыгым өчен гафу ит, дус кеше! Исән булып, кайтсам, кайчан да булса бер утырып, хәят шәрабе белән (әйе, хәят шәрабе белән!) урынсыз үпкәләрнең табын бик ныклап юарбыз. Ибрай Газый әйтмешли, долой кызыл аракылар, яшәсен рус әчесе! (Нәрсә әйтсәң дә, фронтовиклар шул!)*

*Әгәр сез безнең монда Казандагы иптәшләргә нинди зур хөрмәт саклаганны белсәгез иде, андый үпкәләрнең исен дә чыгармас идегез. Киткәнгә шактый булды шул, озакламый өч ел тула. Егетләр безне оныта башлаганнардыр. Сугыш, фронт мәшәкатьләре белән күмелеп, кулга тотарлык рәтле нәрсә дә иҗат иткән юк. Анда халыклар, күрәсең, безгә инде әдәби балласт, төшеп калмаган эч пошыргыч йөк дип карый башлаганнар булса кирәк. Нишлисең, алар да хаклы. Без еракта. Күренмибез һәм нишләп ятуыбыз да мәгълүм түгел.*

*Син тагын моны, зинһар, үз хисабыңа алма. Бу һич тә сиңа карата әйтелгән түгел. Син — фронт, сугыш авырлыгын үзең татыган кеше. Аллага шөкер, ертык ботинка киеп, винтовка күтәреп, 20 яшьлек малай чагында Украина даласын таптап үткән һәм 42 нче елда Старая Русса сазлыкларында аяк чолгауларын гына түгел, тезләреңне һәм түшләреңне дә чылаткан кеше. Бу тормышның прозасы да һәм поэзиясе дә сиңа таныш. Син аңлый аласың аны.*

*Син журналлар һәм китаплар җибәртермен, дигән идең. Көтәбез. «Совет әдәбияты»ның 3, 4, 5, 6, 7нче номерларын күргән юк. 8нче номер килде. Килде генә түгел, кинәт бер «олау» килеп төште. Әллә инде журналлар исергәннәр, әллә инде аларны безгә җибәрүче кеше исерек булган — анысын белмим. Ләкин Әпсәләмгә, Эль-Габидка 4 һәм башкаларга дигән журналлар безгә килеп төште. Тик шунысы кызганыч: барысы да 8 нче номер. Житмәсә, тагын безнең адрес та дөрес язылмаган. Безнең адрес: 74232-П. Ә журналга «П» хәрефе куелмаган. Журналлар шул 74232 адресы буенча барганнар. Анда, бәхеткә каршы, мине белгән кеше бар икән, ул аларны миңа җибәргән. Кайчандыр миңа дигән журналлар Г.Бакиров һәм башкалар адресы белән икенче фронтларда алынганлыгын вакытында миңа язганнар иде. Мондый «шаяру»ны бетереп булмыймы анда? Бәлки, бу эшне Ф.Хәсни үз кулына алыр. Ул — аккуратный һәм намуслы егет.*

*Әгәр син 3, 4, 5, 6 һәм 7нче номерларын да җибәрә алсаң, бик яхшы булыр иде. Билгеле, синең хикәяне башлап укып чыгар идек. Мин «Дустым кабере янында» дигән бер хикәя кебек нәрсә калдырган идем, басылдымы ул, юкмы? Бу әле син редактор чагында иде. Шуңа күрә синнән сорыйм.*

*«Ник кайтмыйсың?» дип сорыйсың син. Чынлапмы бу, әллә шаярып кынамы? Әгәр СПдан нинди дә булса чакыру булса, аз гына вакытка булса да кайтып китәр идем. Кайтасының ничек килүе турында язып тормыйм инде. Балаларны һәм семьямны сагыну һәркемгә дә таныш, аның ачы шәрабен татымаган кеше юктыр. Моннан җибәрергә уйламыйлар. Доброволь булып килдең, мәҗбүри кал, диләр. Менә әкәмәт, доброволь итеп кайтармыйлар бит. Анда Ерикәй кызулатса ярар иде. Каләмебез тупаслана, барлы-юклы әдәби көче кими, хәтта сүнеп бара. Вак хәбәрләр, мәкаләләр, зәвыксыз очерклар язган буласың. Ә алар тычкан кебек әдәби хәзинәне кимерәләр. Тутыкканлыгымны бөтен җаным-тәнем белән сизәм.*

*Шушы көннәрдә генә «Агач башмаклы кыз» исемле бер хикәя язып бетердем. Кыска гына. Шушы көннәрдә җибәрәм.*

*Безгә берәр нәрсә яз әле! Мәсәлән, бүгенге Казан яисә бер мәктәп турында, булмаса, юл өстендәге берәр артельгә йә фабрикага кереп, яшьләр һәм кызлар турында. Гомумән, теләсә нинди темага 200-250 юллык нәрсә. Ул кадәр читен эш түгел бит инде. Ачуымны китерсәң, синең исемнән монда үзем язам. Дүрт айга нәкъ 4 номер «К.Т.» газетасы алдык. (Чынлап 4 номер гына!) Шул номерлардагы мисалларны алам да язам.*

*Иптәшләргә сәлам диген! Кашшафны күрсәң, минем исемнән кулын кыс һәм терелүен телә.*

*Хатларың өчен рәхмәт! Ачулы булса да, хат, ичмасам. Тагын бер кат рәхмәт!*

*Утыртыйнскийдан (ай, дөрес тә әйткәнсең, каян уйлап таптың), Гыймадидән, Ахмеровтан да сәлам!*

*Кулыңны кысып, исәнлек һәм иҗат уңышы теләп, Афзал.*

*P.S. Хатың кыска дигән идең. Мә, ындыр табагы буе хат. Мантоның аның шундый тел бистәсенә әверелә торган гадәте бар. Милли бәрәнге кәлҗемәсе түгел ул!*

*30 октябрь, 1945 ел.*
*Кытай*

ТР МА: Р-6529 ф. 1 тасв. 128 эш. 13, 13 әйл., 14, 14 әйл. бит. Төп нөсхә.

*Гомәр!*

*45 ел артта калды. Аның көннәре, сафка тезелгән солдатлардай нык басып, кайгы һәм шатлык аралашкан гомер юлы буенча узып киттеләр. Без вакыты белән кайгы касәсендәге шәрабен дә, шатлык касәсендәге шәрабен дә тамчысын да калдырмыйча эчтек. Инде безнең алдыбызда тыныч көннәр җәелеп ята. Сугыш көннәрендәге кайгыларны, өзлексез борчуларны татымыйбыз инде, ләкин күңелләребездәге сагыну хисләре электәгечә яши. Хәтта электәгедән дә көчлерәк дисәм, дөрес булыр. Элек тә безнең алда зур һәм билгеле максат бар иде. Без, авыр еллар аша үтеп, ул максатка барып җиттек. Җиңүгә ирештек. Бу омтылыш, безнең сагыну хисләре безне томалап тора иде, хәзер инде алар бәреп, ташып чыктылар.*

*Билгеле, без үзебезнең семьяны гына түгел, Казанны да, матбугат йортын да, әдәби эшне дә һәм каләмдәш иптәшләребезне дә сагынабыз. Үзебезнең эшкә кайтырга бик вакыт инде. Бу турыда андагы иптәшләр дә теләктәшлек белән тулган хатлар җибәрәләр. Бик рәхмәт аларга!*

*Күрәсең, язучыларны кайтару мәсьәләсе Москвада уңайлы рәвештә хәл ителгән булса кирәк. Моннан инде рус язучылары кайтып беттеләр. Зур язучылар түгел, өлкә күләмендәге язучылар гына. Ә безнең беребезгә дә чакыру килгәне юк. Нәрсә, әллә безнекеләрне кайтармаска ясаганнармы? Ни өчен кайтармаска ясадылар икән? Миңа шушы нәрсә мине бик гаҗәпләндерә. Казаннан бу турыда берәүдән дә хәбәр ала алмыйм. Син шушы турыда ачыграк язып җибәрә алмыйсыңмы?*

*Дөрес, мин бу турыда Ерикәйгә дә яздым. Бәлки, ул да җавап бирер. Ләкин ул бераз соңгарак калып җавап бирергә ярата. Әгәр уңай хәбәр булса, телеграмма белән хәбәр итсәң дә ярар иде.*

*Журналның бары №8 генә алдык. Шуңа кадәр һәм шуннан соңгы номерларны да күргәнебез юк. Әллә инде исереп, дөнья гизеп йөриләр.*

*Матбугат дөньясында нәрсәләр бар? Үзеннең әсәреңне бетердеңме? Без монда газета битенә сыярлык нәрсәләр белән генә шөгыльләнәбез. «К.Татарстан»дагы Гариф абзый булып калмасак кына ярый инде, дип куркам.*

*Кара әле, үзеңә генә әйтим әле: безнең турыда кайгыртучылар бармы анда, юкмы? Әллә болай да кайтырлар дип көтәләрме? Болай гына булмый. Бер төрле дә өмет юк. Болай гына китәргә генә мөмкин иде, ә кайтырга — юк. Мин Ватаныбыз өчен иң авыр көннәрдә үзем теләп киткән идем, хәзер инде каләмемне әдәбият өчен йөртәсем килә.*

*Минем сүзләрдән син, бәлки, күләрсең дә. Шулай да дусларча аңлый белерсең.*

*Сәлам белән, А.Шамов.*
*Адресым: Хабаровск, ул.Карла Маркса, 16.*
*2 гыйнвар, 1946 ел*

ТР МА: Р-6529 ф. 1 тасв. 128 эш. 15,1 5 әйл., 16, 16 әйл. бит. Төп нөсхә.

*Гомәр, Акком асты егете!*

*Миңа шулай була ул: кеше сиңа яхшылык эшли, бу эшкә ул үзенең иң яхшы хисләрен, изге ниятләрен сала, ә син, аның тагын изгерәк эш эшләвен көтеп, аңа рәхмәтеңне әйтмичә тукталып торасың. Минем белән дә шундый ук хәл булды. Син миңа Хабаровск адресы белән берничә хатыңны җибәрдең, мин икенче хатыңны көттем.*

*Икенче хатынны алгач, Ерикәй Москвадан кайткач биреләчәк телеграмманны көттем. Телеграмма бирерлек күнелле хәбәр булмады, ахры. Чөнки телеграммалар ташучы почтальонның әле һаман да безнең ишекне килеп шакылдатканы юк. Ә без шундый шатлыклы шакылдатуны һәр көнне, хәтта һәр сәгать көтәбез. Кайчакларында шундый көтү хисләре белән йокыга китәбез һәм шул хисләр белән урыныбыздан да торабыз.*

*Әгәр дә бу хисләрне мина, мин Казанда яшәгән вакытта, минем шикелле бер карт солдат язган булса, мин солдат йөрәгендә мондый акылсыз, хәтта җүләр дип әйтерлек йөгәнсез хисләрнең яшәвенә гаҗәпләнер идем. Аннары ана, дилбегә озынлыгы итеп, тозлап-борычлап, шул ук вакыт вәгазь-нәсыйхәтне һич тә кызганмыйча хат язар идем. Оялтыр идем мин ул егетне. Менә югарыдагы юлларны язганда, мин синең дә шундый сүзләрне күнелең белән язарга ашкыначагынны сизгәндәй булдым. Язма син аны, дус кеше, кирәкми! Кирәкми! Андый сүзләренне очрагач, кайткач, аб ал-хәят кәсәләрен күтәргән вакытта әйтерсең. Андый минутларда әйтүе дә һәм тыңлавы да җиңел булачак. (Минем якын дусларымнан берсе — ак аракыны сугышка кадәр татып та карамаган бер әдәпле егет − күптән түгел генә бер хатын: «Долой кызыл шәрабләр, яшәсен Мәскәү ачысы!» — дип бетергән иде. Миңа да ул фикеремне шундый сүзләр белән очларга туры килер, ахры. Сугыш безне ачы кайгыны гына түгел, ачы хәмерне дә эчәргә өйрәтте.)*

*Тукта, язган хатларың һәм минем турыдагы барлык кайгыртуларың өчен рәхмәт әйтеп үтим. Тиз җавап бирмәвем белән бер әдәпсезлек күрсәттем, инде рәхмәт әйтмичә торып, бу әдәпсезлегемне тагын да дәвам итмим, дим.*

*Без һаман да әле Амур суын эчәбез, тимер дагалы итекләребез белән көнчыгыштагы кала урамнарын таптыйбыз. Сугыш беткәннән соң да инде икенче пар итекне туздырабыз, ул көннән соң инде шулкадәр күп вакыт узды, хәтта А.Әхмәткә инде яна тешләр дә чыга башлады.*

*Без синнән монда очерклар көтеп ятабыз, ә син анда хәтта мыегыңны да бөтереп карамыйсың. Шушы көннәрдә сиңа 80 сум акча барып җитәр, ул сиңа кайтарылып алынмый торган «аванс». Берәр очерк көтәбез.*

*Син хатыңда: «Сезне кем җибәрә ала?» — дип сораган идең. Безне бары Москва гына, Шикин гына җибәрә ала. Аннары син анда капчык авызын каты итеп бәйләү турында да язган идең. Нәкъ шуны инкяр иткән кебек, синең хатны алган көннәрдә бер казах егете, бер бурят егете китте дә барды. Барсы да безнең шикелле штаттагы халыклар. Рус иптәшләр шундый ук штаттагы халыклар иде.*

*Тастымалның (Ибрай шулай атый) тукталуы турында сүз юк әле.*

*Ерикәй Москвадан нинди хәбәрләр алып кайткан? Казанда нәрсәләр бар? Тукай көннәре ничек үтте? Барысын да яз әле.*

*Мине искә төшергәннәр булса, сәлам диген аларга.*

*Сәлам белән, А.Шамов.*

*P.S. А.Әхмәтнең теше турында яздым, хәтта анын дагалы итеген дә искә алдым, ә аннан сәлам язарга онытканмын. Безнең заман Хуҗа Насретдиненең дә сәламын кабул күреп ал инде син!*

*«С.Ә.»ның №7дә Әдип Маликовның 5 поэмасы бар. Нинди егет ул? Нигәдер ул Х.Т.ны бик хәтерләтә. Ул түгелме икән дигән фикер дә килә кай минутларда. Чынлап та.*

*3 апрель, 1946 ел*

ТР МА: Р-6529 ф. 1 тасв. 128 эш. 17-19, 19 бит. Төп нөсхә.

*Хатларны һәм искәрмәләрне* **Әлфия ШАМОВА** *әзерләде.*

Әнәс
Хәсәнов



# БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ

ИСТӘЛЕКЛӘР

### Мин янә Мәрзияле

Хәтеремнән Валя ерагайганнан-ерагая бара. Хәдияне дә исемә төшермим. Ә Мәрзия сагындыра. Аңла инде шуннан соң бу адәм баласын!

Өч хатмның берсен төзәтергә вакыт. Мәрзия белән хыялланып, үземә-үзем биргән вәгъдәмне үтәп, аңарга хат яздым. Эчә торган коена төкермә дигәннәре шулдыр инде. Җавабы да озак көттермәде. «Мин сине элеккечә яратам, зинһар, ышан!» — дигән җөмләсен укыгач, җаным эреп киткәндәй булды. Һәм күземне яшь басты. Болай булгач, нигә рәхәтләнеп бергә яшәмәскә ди әле? Фатирны карап, аш-су пешереп, миңа якын иптәш булыр. Үземне инде тыйнаграк тотар вакыт. Хатын-кызларны картайткан да, яшәрткән дә ирләр ди бит. Хәзерге урыслашкан татар балалары халкыбызның андый акыл хәзинәләрен юньләп белмиләр. Аңлы рәвештә телебезгә хыянәт итеп, үзләрен-үзләре талаган булып чыгалар... Аһ, нәрсәләрдән, нинди гәүһәрләрдән үзебезне-үзебез мәхрүм итәбез! Кызганырлык та, үкенерлек тә. Нишләргә белмәгән чакларда халкыбыз иҗаты менә дигән киңәшче була ала ич! Халкыбызның тәүге саф инешләрен янә барлап, файдаланырлык вакыт түгелме?

Инде ни күрсәм дә күрермен, чакырам никахлашкан Мәрзиямне! Әлегә язмышыбызның калган өлеше үз кулыбызда ич. Уйладым да тәвәккәлләп ташка уйдым. Ерак гарнизон тормышы ямьсыз киткәндәй булды. Тылсымлы мәхәббәт бар нәрсәгә ямь бирә, сүрелгән җаннарга өмет очкынын өрә. Бик күп нәрсәләргә сәләтле ул мәхәббәт дигән могҗиза!.. Мәрзиянең шул хаты килүгә, хәрбиләр кассасыннан бушлай билет алу кәгазьләрен конвертка салып юлладым да түземсезлек белән өлешемә төшкән көмешемне көтә башладым. Ара якын түгел, хатлар озак йөриләр. Көтәргә туры килә. Нишләп йөри икән ул анда? Һаман шул «Светлана» фирмасы эшендәдер инде. Акчасының очын-очка ялгап кына яшидер... Теге хатын минекен алуга ук язган, ахры. «Ышан, зинһар» дигән сүзләре исемә төшә дә елмаям.

Ике атнадан артык вакыт үтүгә, Мәрзиянең телеграммасы килде: «Юлга чыктым, каршыла!» — диелгән. Ә кайчан каршыларга икәне әйтелмәгән...

Поезды Белогорск аша Хабаровскига төн уртасында уза. Бер тәүлектән соң баш инженер подполковник Мураловтан кечкенә автобусыбызны сорап, Белогорскига элдердем. Көтәм. Поезд килеп туктады — Мәрзия юк! Икенче

төнне тагы барам. Поезд килеп туктый, үч иткәндәй, Мәрзия юк! Менә тамаша! Тиле баш аякларга тынгылык бирми шул.

Оятсызланып өченче тапкыр автобусны сорарга базмадым. Кичтән Белогорск автобусына утырып тагы киттем. Поездны арлы-бирле йөренеп көтәм. Менә ул ерактан ыжгырып һәм давыл куптарып, прожекторы белән карангылыкны бораулап килә. Әкренәя һәм теләр-теләмәс кенә, көпчәкләрен шыгырдатып туктый. Унөченче, хәрбиләр вагоны янына йөгерәм. Бер кеше төшә, икенчесе... Аллага шөкер, менә Мәрзия дә ишектән күренде. Башында ак калфак. Татар баласы ич! Ул, берни булмагандай, тулган ай кебек елмая. «Көттерден!» — дим. Чемоданын тотып, автобус тукталышына юнәләбез. Вокзал ябык. Имансызлар кыш уртасында ремонт ясарга керешкәннәр! Үтә суык төндә иртәнге бишкә хәтле кылка автобусларын көтәсе. Кар ява башлады. Көтәбез. Мәрзиянең аякларында йон оекбашлар һәм «румынкалар», ә минекеләрендә — чолгавычлар һәм күн итекләр... Бармаклар туна...

Кыш бабай биетә генә — тыпырдашабыз. Менә кечкенә автобус килеп туктады. Халык бер-берсен сыта-сыта эченә ыргыла. Каян җыелганнар диген! Без дә кешеләр араларына кысыла-кысыла кереп урын алабыз. Бусы булды! Утыруга, Мәрзиянең румынкаларын салдырып, аякларын җылытырга бот араларыма кыстырып, шинель итәкләре белән каплыйм. Возжаевкага килеп төшәрәк аякларга җан керде һәм алар кызып ук киттеләр. Ярый әле өшетмәдек! Югыйсә бармакларым өшегәне бар инде. Тиеннәрне кызганмый, телеграмманы белеп бирергә кирәк аны! Җылы бүлмәгә керүгә, чәй кайнатырга куйдым. Ризыкны өстәлгә алдан ук аныклап, каплап куйган идем. Ашый һәм эчә торгач, тәмам җылындык. Менә шуннан соң, Мисыр күгәрченнәре булмасак та, гөрләшеп яши башладык. Янарып киткән сөю кавыштыра икән ул. Ирексездән исемә Төхфәтуллин төште дә, елмаеп җибәрдем. Кодрәтле партия вәкиленең кулыннан килмәгәнне язмыш үзе булдырды. Инде без бергә, Хак Тәгалә бәхетебездән генә аера күрмәсен! Тузга язылмаган «парлык кануны» («закон парности») буенча бу «Happi end»ның параллель нәтиҗәсе дә була. Бераздан: «Хәдия казакъ егетенә тормышка чыккан!» — дигән хәбәр ишеттем. Бер кыз бала да тапкан, имеш. Менә шулай ул да үзенең оясын корып, көн күрә башлаган. Ник куанмаска ди?

Берничә көннән соң Мәрзиянең зур фанер тартмасы белән багажы килде. Анда байтак кирәкле әйберләре һәм өшегән әфлисуннар бар иде. Тагы да күңеллерәк булып китте. Өйдә йорт эшләрен башкарып, җылы ризык хәстәрләп, сине көтеп утыручы булгач, шәп инде. Мәрзия эшләмәсә дә, әтиләргә җибәрсәк тә, акчабыз көн күрергә җитә, чөнки казна фатир күпкә арзанга төшә. Аннары хезмәт хакы да бераз артты. Кибеткә үзе йөри, мунчага һәм клубка — бергә инде.

Гарнизон бер тату гаилә кебек яши. Хезмәттә һәм ялда барыбыз да бергә диярлек. Клубка полк командиры Барабанщиков (булачак генерал), штаб начальнигы Орёл хатыннары һәм замполитлары белән бәйрәм тамашасына чыккан сыман йөриләр. Өйләрендә сәрхушләнеп утыручылар сирәк. Частьларыбыз биредә вакытлыча гына. Бөтен плитәле юллар, ракета комплекслары, «ГЧ»лар технологик залы, бүтән корал, ягулыклар, кием-салым, азык-төлек складлары вә казармалар яшерен рәвештә тайга эчендә көн-төн төзелә. Ә офицерларның торасы шәһәрчеге («унынчы объект») — йортлары, кунакханәләре, ашханә-кафелары, кибетләре, клублары, мәктәп-балалар бакчалары Ледяная ярымстанциядән ун чакрым читтәрәк корыла. Башкаларга бу бигрәк зур төзелешне «прикрытие риваяте» буенча «йортлар комбинаты» салына дип кенә аңлаталар.

Ярымстанциянең исеме мәңгелек туң җирдә булганлыктан килә. Бераз җирне тирәнрәк казысалар, җәй уртасында да эреми торган бозланып каткан җиргә

(дөресрәге калын боз линзасына) төртеләләр. Мондый галәмәт Сковородино станциясеннән башлана һәм бирегә тикле житә. Бу — узган бозлык дәверенең эзе, жәйге жылы көннәрдә жирнең шактый өлеше сазлыкка әверелә. Менә шунда, ЦК күзәтүе астында Оборона министрлыгы эшләре кызу, удар рәвештә алып барыла да инде. Мәскәүдән махсус комиссияләр гел килеп кенә торалар. Янәсе, АКШ империалистлары без мыштырдаганны көтеп тормаслар!

Сугыш чыгаруларыннан бик шикләнәләр. Хисапсыз стройбатлар, туктаусыз диярлек, тоткыннар кебек эшлиләр. Эшләре дә, тормышлары да үтә авыр, һич кызыгырлык түгел. Тайга уртасында, бозлавык вә сазлыклар өстендә шундый авыр олы эшләрне башкарып кара әле!.. Чирләүчеләр күп, фажигаләр дә гел булып тора. Тынгысыз юлларда машиналар бер-берсенә бәреләләр, бензовозлар янгалый. Зур төзелешләр андый бәла-казаларсыз булмыйлардыр да. Мондый ашыгыч «салкын сугыш» хәрәкәте бөтен ил кинлегендә диярлек алып барыла. Стратегик ракета частьларын акылга сыймаслык, яшәргә унайсыз, кулланырга яраксыз диярлек жирләргә урнаштыралар. Күбесенчә цивилизация учак-үзәкләреннән ерак жирләрдә. Менә шул чакта уйлап чыгарыла да инде бер табышмак. «Таулар араларында, чүл-тайгаларда, чәнечкеле тимер чыбык божралары эчендә яшиләр. Киптерелгән ризык белән тукланалар. Кемнәр ул?» — дип сорауга, — «Ракетачылар!» — диргә кирәк...

Берничә елдан соң, Стратегик ракета гаскәрләре аякларына баскач, тормыш яклары жайланды. Бөтен шартлар диярлек шәһәр тормышына якынлашты. Ләкин мәдәният үзәкләреннән ераклык һәм шәһәрчекләрнең ябык-йомыклыгы, пропуск режимы тормышыбызны колонияләргә тинләштерә иде.

Йортларыбыз төзелеп бетсә, без дә шунда, урман эченә кереп урнашырга әзерләнәбез. Әлегә офицерларыбыз берәр атнага командировкага барып, үзебезгә тиешле бина-корылмаларны күзәтеп-тикшереп йөриләр. Сафка керә барган берсен актлап үз кармакларына алалар. Бераздан халкыбыз анда күбәя башлагач һәм хәрбиләребез кизү тора башлагач, мина да шунда барып йөрергә туры килә. Язга чыкканчы частьның төп өлеше һәм гаиләләребез Возжаевка шәһәрчегендә яшиләр. Әлегә тормышыбыз ярыйсы болай. Итне военторг атнасына бер китерә. Виктория жиләгеннән пешерелгән болгар конфитюрлары вә Кытай-Япун алмалары белән тәэмин итә. Конфитюр килолы калай кәнсир савытларында. Алмалары егермешәр килолы, дөге кибәкле әржәләрдә. Вакланып тормыйбыз инде. Конфитюрын да, икешәр әржә алмасын да чанага салып алып кайтабыз.

Хезмәтем, әйтмәгәнем булсын, авыр түгел. Киләчәк сынаулар алда әле. Тик шунысы бар: үзебезне «олы жирдән» аерылган нәүмизләр күк хис итәбез. Лазаретыбыздан каты авыруларны Белогорск госпиталенә озатабыз. Барган саен каладан яна медицина китапларын да алабыз. Тик алар монда сирәк килә. Лазаретның табиблары, барысы да диярлек, әле яшь, тәжрибәсезрәк белгечләр.

Начальнигы капитан Панкратов һәм рентгенологы капитан Якименко — миннән бер ел элек академиябезне тәмамлаган офицерлар. 1960 елны урынга билгеләүләр безнекенә караганда әйбәтрәк булган икән шул. Үзебезнең «академикларны» очратсаң, агай-эненне очраткан кебек була икән! Панкратов хәйләкәррәк һәм эш дип артык борчылмый торган кеше. Күбрәк үз мәнфәгатьләре белән мәшгуль. Колхоз председателе улы, Ульян өлкәсеннән. Хатынын гел көнли. Ул — анын икенче ире, шулай булса да, урлап китмәгәйләре дип шөбһәләнә. Беркөнне хәтта фатирларында бикләп калдырган! Тиздән аны, булдыра алмагач, Братаненко эпидемиолог эшенә күчерде һәм укырга юллады. Анын урынына Уссурийскидан майор Муравчикны утырттылар. Без аны үзара «буравчик» дип атый башладык. Тулы медицина белемен күптән онытып бетергән, ләкин кеше кулын һәм эш урынын бик шәп куллана белә. — Бу карт

яһүд төлкесе мина: «Хасанчик!» — дип эндәшкән була. Ул да — хатынының икенче ире. Күсе тешле, үсеп килгән ике кызлары бар.

Якименко — гадел, тырыш, эшчән һәм җайлы хохол заты. Игезәк малайларын үстерә. Спортчы — спорт йөрүе белән мавыга. Ике елдан соң аны Мәскәү янындагы Красногорск хәрби госпиталенә алдылар. Шулай кирәк ул! Эш сөя торган адәмнәрне гел түргә уздырырга кирәк!

Хирург өлкән лейтенант Росщункин да Сарытауның мед.факультетын һәм хирургия курсын күптән түгел генә тәмамлаган кеше. «Үгез сөтен» чөмерергә ярата. Бирегә хезмәткә алынганда, ул бик көлке хәлгә калган булган. Белогорскига килүгә ин әүвәле ресторанга юнәлә. Анда бер өстәл артында ялгыз, яшьрәк кыяфәтле полковник ашап утыруын күреп, бу да янына килеп, рөхсәт алып утыра. Заказ бирүгә берне тондырып та җибәрә һәм, кызып, полковник белән әңгәмәгә керергә тотына. Тапкан үзенә тиңне! «Дөрес микән, иптәш полковник, мондагы дивизия командиры Горбунов эт икән диләр?»

Теге ашап бетергәч, дәшми генә чыгып китә. Янәшә өстәл артындагы офицерлар пырхылдап көлеп җибәрәләр. Чыгып киткән полковник үзе үк Горбунов икән бит! Теленә тилчә чыккан Росщункинның чираттагы партконференциядә тетмәсен тетәләр... Ялкау иде ул. Берәр зуррак операция күздә тотылса, андый авыруны кичекми Белогорскига озата иде. Менә шуның белән Мәрзиягә аппендицит операциясен ясарга туры килде. Болай булды бу. Беркөнне Мәрзия кинәт, эчем авырта дип, чирләп китте. Чире аппендицитка охшаган. Тукта әле, Росщункин һәм гинеколог булып кыланган Быкова да карасыннар, дим. Болар да минем белән килештеләр. Юлы начар, утыз чакрым булса да, госпитальга илтим, дим. Мәрзия исә: «Авыртуга чыдый алмам!» — ди. Әйе, юлы сикәлтәле шул, бик авырга киләчәк. Менә шулай операцияне лазаретта ясарга туры килде. Ярый әле шома гына үтте. Аппендиксы әз үзгәргән иде. Гаеп бөерендә яки аналыгында булган, ахры. Бу өч әгъза янәшәдә булганга күрә, чирләп китүләре бер-берсенә охшашлы, башта, өстәмә махсус тикшерүләр, рентген-анализлар ясамый, аеруы кыен. Ахырда, тора-бара Мәрзиянең бөер вә аналык трубкасының чирләре дә ачыкланды.

Ул Быкова надан һәм бер тырбык нәмәстә булып чыкты. Ире татар, РТБ офицеры, фамилиясе дә Хәсәнов иде. Озакламый аерылдылар.

Операциядән соң терелгәч, Мәрзия туганнарына хат язган. Энесе Зәки операциягә катнашуымны белгәч: «Унмаса, мин аны судка биргән булыр идем!» — дип шапырынган. Ә ул аппендицит операциясен кайберәүләр авырмаганда да ясаталар, җайсыз чакта чирләп китмәгәе дип. Эквадор армиясендә исә аны мәҗбүри бөтен солдатларга да ясаталар дип укыганым бар. Шулай итеп Зәки җизнәсен судка бирми калды. Ахмак! Авыруларга махсус рәвештә зарар китерүче табиблар, гомумән, бар микән ул? Булса, алар «СС» гаскәрләрендә вә Берия КГБсында гына булгандыр. Табиблыкка укыган һәм Гиппократ антын биргән кешеләр җәлладлар түгел. Кешегә операцияләрне ясарга белем, акыл, батырлык һәм көч кирәк. Мәрхәмәтле булуым да, зарури батырлыгым һәм белемем һәрвакыт житсә дә, мина кан чәчрәтеп, тере тәнне кисү кыен иде. Шуңа күрә хирург буласым килмәде минем. Ә инде операциянең зарары тия калса, моның объектив сәбәпләре була ала. Һәм — субъектив сәбәпләр дә. Әйтик, ялгышу, маһирлык, тәҗрибә җитмәү.

Әле шунысы бар: операцияләрне җансыз машина ясамый бит, ә, киресенчә, шундый ук булмаса да, адәм ясый! Моны онытмыйк. Мәрзиягә кагылганда, анарга кайчан да, шиксез, ул аппендицит операциясен ясарга туры килер иде. Чөнки уң ягындагы бөеренә таш утырып, пиелонефрит булды һәм хатын-кыз чирләре белән интекте. Мондый очракта аппендикс та ялкынсыныр иде!

Росщункинга килгәндә, хәрби медицинабыз унмады аңардан. Без аннан киткәч, тора-бара ул эчүгә сабышып, тәмам сәрхушкә әверелгән. Ахырда, хатыны да баласы белән ташлап киткән дип ишеттем...

Яңа ел бәйрәмен уздырганнан соң, Мәскәүдән телеграмма килде: «капитан» булуым белән котладылар. Бик вакытлы, акчаны мулрак тотарга була. Ракета гаскәрендә званиеләрне тоткарламаска тырышалар иде.

Күчәсе урынга командировкага поезд белән Поздеевка, Серышево, Свободный аша мина да йөрергә чират житте. Яңа урында байтак корылмалар эшләнеп беткән инде. Безнең «ГЧ» склады янына тимер юл тармагы салынган (тупик). Шул юлда өр-яңа пассажир вагоннары тезелеп тора, рестораны да бар. Бүлмәле вагоннарда офицерларыбыз яшиләр, ә плацкартлыларында — солдат-сержантлар. Бер бүлмәдә медпункт ачтым, янәшәсендә — дүрт урынлы вакытлыча изолятор. Биредә саф һава, жирне ап-пак кар мамыгы каплаган. Урман эчендә тынлык. Шәрә агачлар һәм акка төренгәләгән чыршылар араларында борчулы күкшәләр ыгы-зыгы килә. Эчтәрәк тукран тукылдап азаплана. Тырышмый гына тамак туйдырып булмый шул. Менә шушы гажәп тынлыкта без олы сугыш буласын көтеп, бик ашыгыч рәвештә коралланып маташабыз. Биредә эшем артык күп түгел. Ашханәбезне (вагон-ресторанны) тәртиптә тоту, авыруларны кабул итү (алар да күп түгел). Аннары көн дә бер төркем солдатларны санитар машинага утыртып, стройбат поликлиникасына (жиде чакрым) рентгенга, теш табибына һәм, кирәкләре чыкса, башкаларына да күрсәтергә алып йөрим. Атнага бер офицерларга һәм солдатларга ВМП дәресләрен бирәм. Күмәк хәрби коллективны таза тотар өчен мәшәкате күп. Әйтик, солдатларны мунчага кертер алдыннан анда мунчала-ләгәннәренә хәтле дезинфекция ясарга кирәк. Чишендергәндә тиреләре таза булмаганнарны аерып дәвалыйсың, аларны башкалардан соңрак юындырасың. Санинструктор, мунча кергәннән соң тырнакларын кистерә, кирәк исә, суелган жирләре, бетчә-мазарларын йод белән сөртеп бәйли. Солдатларны үз балаларыңны караган күк тәрбияләргә туры килә, кирәкле киңәшләр бирәсең. Шуна күрә, әйтмәгәнем булсын, йогышлы чирләр юк, грипп, ОРЗ белән авыручылар да аз. Орёл һәм офицерлар белән мөнәсәбәтләр яхшы, мине ихтирам итәләр. Солдатларыбыз тәртипле, Петропавловск-Камчатка һәм Уссурийскидан. Үз иткәнемне сизәләр. Елан жылыга ияләшкән кебек, мина гел: «Иптәш капитан!» — дип кенә торалар. Аларга монда минем белән тынычрак. Монда да военторг кибет ачты. Мәрзия янына өчәр көнгә кайтып йөрим. Ысланган эре симез кета түшкәләрен һәм башка кирәк-яракларны алып кайтам. Күз тимәгәе, тормыш бер жайлангач гөрли генә. Частебез һаман ике өлешкә аерылган әле. Шулай ике арада арлы-бирле хезмәт итеп йөри торгач, кыш та үтте. Язга чыктык. Гөрләвекләр акканда, бер мәлне су үткәргечтә сулары бозылды. Кайберәүләрнең эчләре китkәләде. Быелтыр үзем дә бер атна Белогорск госпиталендә ятып чыккан идем. Шәһәрчекнең суүткәргече искергән шул. Өстәмә чаралар күрергә туры килә.

Мәскәүдән яңа урыныбызга комиссияләр килеп тора. Ә инде хәрби галимнәр, проектчылар, ракета белгечләре һәм Кораллы көчләрнең җаваплы вәкилләре ракета комплексларында даими рәвештә кысылып яшиләр. Хезмәт итүчеләргә алар барысы да авырга төшә. Алар бит кеше җилкәсенә атланып, кеше куллары белән эшләргә күнеккәннәр — күрсәтмәләр һәм боерыклар бирергә остарып беткәннәр. Үзләре моны «булышу» диләр. Житмәсә, үзләрен балаларны караган кебек карап торырга кирәк. Ә кайберләре ике яклы пычак булып, Мәскәүләренә кайткач, әләкләүдән дә тартынмыйлар!..

Тайга эчендә күп тармаклы, төзелеп бетмәгән юлларны әзмәвердәй көчле КРАЗ-МАЗ-Урал-ЧТЗлар тәмам баткаклыкка әверелдергәннәр. Юллар шулай

өзелеп торганда, бер төркем дәрәҗәле партия вә совет җитәкчеләре һәм генераллар белән Политбюро әгъзасы Козлов килде. Кара «Волга»лар кәрваны әллә кайларга сузылды. Юлның ике ягында эшләүче стройбат солдатлары, гражданский бригадирлары, офицерлар авызларын ачып, гаҗәпсенеп карап торалар. Әйтерсең, күктән ят галәм вәкилләре иңгән! Машиналар боламыкланган пычракка бата-бата, түшләре белән көчкә шуалар. Ахырда алдагы машина үкерә-үкерә, пычрак сиптереп, көпчәкләре белән күмелеп батты. Кәрван туктады. Арттагы машиналардан шинель итәкләрен күтәреп, генераллар һәм полковниклар чыгып, тездән батып, тегене этәргә тотындылар. Машинаның арткы урындыгында эшләпәле, тулы янаклы юантыгырак кеше бүлтәеп утыра. Шайтаннарга охшаган, пычранып-өтелеп беткән стройбат солдатлары исләре китеп карап торалар. Аларга полковнигың ни дә генералың ни! Үзләренең җитәкчеләренә дә көчкә буйсыналар. Шунда берсе читтәрәк басып торган генералдан: «Иптәш генерал, нигә соң әле генераллар машиналарыннан төшеп, этәреп маташканда, теге эшләпә машинасында утыра бирә?» — дип сорый. Генерал исә: «Ә синең, улым, политдәресләрдә Ленин бүлмәсендә булганың, кулыңа гәҗитләр тотканың, Политбюро әгъзаларының сурәтләрен күргәнең юкмыни? Яхшырак кара әле, бәлки, танырсың?» — ди. Солдат: «Без монда ата-аналарыбызны да оныта яздык, ә политдәресләр уку комбинатында гына булгалады!» — ди. «Бу бит иптәш Хрущёвның уң кулы — Козлов!» «Ә-ә, безгә барыбер!..» Әңгәмә тәгәлләнә.

Менә шулай, Рәсәй бу, агай-энеләр, алдынгы илләрдәге кебек төзелешләрне юллардан башламыйлар! Башта җирне казып-актарып утыралар да, «төзедек» дип рапорт биргәннән соң, еллар буе канау-баткакларга бата-чума йөриләр! Үзләре дә: «Дуңгыз пычраксыз тора алмый!» — диләр.

Козловның килүе ни белән тәмамланганын төгәл әйтә алмыйм. Әлбәттә, өлкән хәрби һәм җирле граждан җитәкчеләре белән, «кыйммәтле» күрсәтмәләр биреп, киңәшмә уздыргандыр да төзелешне тизләтү һәм хәрби әзерлекне төрле яктан тулысынча тәэмин итүгә файдасы тими калмагандыр. Җир шарының ташкүмер кебек кызган чагы иде. АКШ белән кискен рәвештә ачыктан-ачык ярышу бара. Ике як та коралллы көчләрен үстерә-ныгыталар. Кем куәтлерәк булыр? Мондый очракта артка калу — харап булу дигән сүз.

Тагы шундыйрак кызык вакыйга Возжаевкада булып алды. Ракета гаскәренең (РГ) Яңа Главкомы — Советлар Союзы маршалы Москаленконы көтәбез. Бу урынга ул 1960 елның 23 октябрендә Тюратамда һәлак булган артиллериянең баш маршалы М.Неделиннан соң билгеләнә. Москаленко — Н.Хрущёвның якын, ышанычлы кешесе. Аны усал телләр «сарай маршалы» дип тә атадылар. Ул Бөек Ватан сугышына актив катнашуы һәм канэчкеч Берияне атып үтергәнче Мәскәү гауптвахтасында сакта тотуы белән мәгълүм. Аның турында Мәскәүдә хезмәт итүчеләр: «Ул, нindидер чире булу сәбәпле, бик туңучан» — диләр иде. Перхушководагы штаб кабинетында йомшак урындыгын һәм өстәл астын электр җылыткычлары белән җиһазлаганнар. Мәскәүдәге кабинетыннан яки фатирыннан чыгар алдыннан, адъютанты Перхушково штабына шалтырата икән, шуннан соң кабинет вә урындык җылылыгын 22 градуска тикле җиткерә башлыйлар икән! Мәскәүдәге кабинетыннан Ракета гаскәре штабына атнага ике-өч тапкыр килеп рапорт алып, мөһимрәк кәгазь-приказларга кул куеп, тиешле күрсәтмәләр биреп, бер-ике сәгать утырганнан соң кайтып китә икән. Билгеле, ул ошбу гаскәр белгече түгел, чөнки махсус белеме юк. Менә шул шәхесне командирларыбыз дер калтырап көтәләр. Менә Белогорскидан чыгуы турында безгә шалтыраталар. Портупеясен буган капкорсаклы, бурлат йөзле Орёл юл белән штаб арасындагы чирәмгә офицерларын алдан ук тезеп куйды. Моны армиядә

«ефрейторский зазор» диләр. Кулындагы рапортын ятлый. Формам сезнекеннән үзгә дип, сафтан чыгып, капка янында арттанрак карап торам. Руслар әйтәләр бит: «Патшалардан ераграк тор — башың исән калыр!» — дип.

Менә кара җинел машина, аның артыннан комдив Горбунов машинасы да килеп арырак туктадылар. Алдагы машинаны йөртүче старшина тиз генә сикереп чыкты, кулында ал бәрхет кисәге. Ул машинаның безнең яктагы ишеген ачты. Машина баскычына эчтән күн итекле аяк чыгып басты. Старшина җәһәт кенә бәрхет белән аны ялтыратып алды. Баскычка икенче итек басты. Старшина аны да ялтыратты да читкәрәк тайпылып үрә басты. Ниһаять, зур фуражкалы, ялтыравыклы маршал билгеләре белән бизәлгән киемнән кечерәк итекләр иясе үзе төшеп басты һәм саф янына юнәлде. Орёл сафны үрә катырып, маршал каршына йөгереп, аннары строевой адымга күчеп шып туктады һәм бүртенеп рапорт бирде. Маршал саф белән исәнләште. Саф, гау-гау килеп, сәламен кайтарды. Маршал: «Хәлләр ничек, сораулар бармы?» — дип сорады. Буламы соң, алдан ук кисәтеп куелгач! Шуннан соң ул уңышлар теләп һәм тагы нидер әйтеп, машинасына юнәлде. Горбунов та артыннан калмый. Орёл бераз озатып барырга рөхсәт сорады. Шуннан машиналар кузгалып киттеләр. Итеген саф алдында холуеннан ялтыраттыруы сафны хөрмәтләве булды микән?

Солдатларга старшиналар: «Саф — ул изге урын!» — дип тукып торалар иде. Миндә бу хәл авыр хис калдырды. Алар киттеләр, ә сөйләшүләр исә байтакка сузылды. Тере маршалны көн дә күрмисең бит! Хәтеремдә шул итекләре вә тугралы, зур йолдызлы чигелгән маршал погоннары уелып калды. Кораллы Көчләребезнең яна, бик мөһим тармагы — Стратегик ракета гаскәре белән идарә итүчеләрнең төрлесе булды. Мисал өчен генә булса да әйтим, гаскәр РВ штабының РТБлар бүлеге начальнигы карт генерал-полковник Балядко иде. Ул байтак еллар кавалериядә хезмәт иткән һәм андагы гадәтләр канына сеңгән. Безнең технологик залга килеп керүгә, ни эшләргә белмәвеннән, атом төшле «ГЧ»ларны, самавырларын, чисталыкларын тикшергән кебек, кульяулыгы белән сөртеп маташты! Хәер, аны озакламый лаеклы ялга озаттылар. Ә андыйлар бездә әз булмады.

## Ракета гаскәре яшь әле

Яңа барлыкка килеп, аягына баса башлаган РГда гади генә мәсьәләләр хакында югарыда җитди бәхәсләр барганын ишетә идек. Башта көн кадагына мондый мәсьәлә эленгән: РВ хәрбиләрен нинди формага киендерергә? Тәкъдимнәрнең төрлесе булган. Шуларның берсе — Николай Икенче чорындагы атлы казаклар формасы! Ул киемнәр Беренче Бөтендөнья сугышыннан бирле хәрби складларда сакланып яталар, имеш! Ахырда тупчылар формасына киендерергә булалар. Әле мин РГга хезмәт итәргә килгәндә дә полкларда һәм РТБларда мотопехота, очучылар, диңгезчеләр формаларын кигән офицерларны очратырга мөмкин иде. Кайсы-кайда кыскартылган бит!.. Тора-бара әкренләп аларны да тупчылар киеменә киендерделәр. Без медиклар исә үзебезнең яшел төс кертелгән формада җитмешенче елга хәтле кала бирдек. Хәер, безгә дә бер мәлне кара тасмалы тупчылар фуражка-погон-петлицалары кигезеп маташканнар иде. Барып чыкмады. Ә мин аларны алырга өлгермәдем дә.

Тагы бер мәсьәлә турында бәхәс куба: РГ частьларын нинди калып-рәвештә төзергә? АКШ үрнәге буенчамы? Аларда РГ авиациядәгечә бүленгән. Безнекеләр ахырда артиллерия гаскәре төзелешен — батарея, дивизион, полк — калып итеп алалар.

Соңрак башка мәсьәләләр дә барлыкка килде. Әйтик, РТБларга байрак

биру мәсьәләсе. Алар монарчы байраксыз хәрби частьлар иде. Әлемсез нинди мөстәкыйль хәрби часть булсын ди? Ә байраклы булгач, начальнигы да папахалы, ягъни полковник булырга тиеш. Аннары, армиянең сәяси житәкчелек өлешен нык кыскан оборона министры Г.Жуков 1957 елны министрлыктан сөрелгәч, политурынбасарларның саны арттырылды һәм 50-75 кешеле аерым хәрби оешмаларга берәр политхезмәткәр офицер өстәлде. Бу инде чамадан тыш узыну булды, чөнки тәртип мона карап кына ныгымады. Мин гомеремдә чын мәгънәсендәге эшчән, кеше күңеленә үтеп керерлек политхезмәткәрләрне сирәк очраттым. Аларның күбесенә мөгаллимлек һәм психолог сәләте житмәде. Күбесенең махсус белеме дә юк иде. Байтакларында тиешле кешелеклелек сыйфатлары да булмады. Элек поплардан көлгән кебек, тикмәгә генә алар турында мәзәкләр сөйләмиләр иде. Орёлның политурынбасары майор Туркинның исеме жисеменә искитәрлек туры килә иде. Бер мәнсез, «затурканный» әрәмтамак иде шунда. Артыннан көлми калмаган офицер булмагандыр.

Яшь офицерларны ялга командирлар һәм штаб начальниклары һәр елны кара көз вә кыш айларында озатырга тырыштылар. Бу хакта бер мәзәк сөйләми булмас. Штаб начальнигы офицерларның киләчәк ял планын төзергә җыена. Командир, офицерларын сафка тезеп, мондый сорау биреп боера: «Кемнәр жылынган сыра һәм тиргә батып йөргән хатын-кызларны сөйми, бер адым алга!» Берни сизмәгән яшь әтәчләр алга атлыйлар. Янәсе, андый түбән зәвыклы мәхлуклар түгел! Командир, көлемсерәп: «Әһә, штаб начальнигы, болар берсе дә жылы сыра һәм тирләгән хатын-кызларны яратмыйлар икән. Ялга кыш айларында озатыгыз!» — ди. Мин пионерларча вазифамны үтәп, офицерларны график буенча ял йортларына һәм шифаханәләргә жибәрергә тырышам. Юлламаларга бер чакта да мохтажлык булмады, бигрәк тә бу яклардагы «Океанский» (Владивостоктан 19 чакрым арырак), «Шмаковка», «Кульдур», «Драсун» кебек шифаханәләргә. Юлламалар хәтта Камчаткадагы Тын океан хәрби флотының «Паратунка»сына да була иде. Анда кыш уртасында вулкан таулары яннарында «40 градуслы» геотермаль бассейннарында коену бигрәк тә кызык һәм шифалы! Шулай булса да, кызыксынучылар юк диярлек. Офицерлар шифаханәләргә ялга барырга атлыгып тормыйлар иде. Хәзер генә ул шифаханәләргә путёвкалар сорап аптыраталар. Димәк, тәмен белеп алганнар!

1962 елда без берни булмагандай бәйрәмле май аен шактый күтәренке күңел белән уздырдык. Ә 1-2 июнь көннәрендә Новочеркасск каласында эшчеләрнең митинг-демонстрациясен канга батырып таратканнар! Чираттагы эш хакын төшереп, эш күләмен арттырудан соң, ачлыкка дучар ителгән эшчеләр һәм кала халкы дулап урамга чыкканнар икән. Илдә ризык кытлыгы үзен нык сиздерә башлаган иде ул чакта. КГБчы Шелепинның мөридләре халыкка ата башлаганнар һәм Советлар Союзы каһарманы генерал-полковник Исса Плиевнең гаскәрен бастырырга керткәннәр. Урамнарга танклар ыргылган. Күп еллар узгач кына белдек: 25 кешене үтергәннәр, 122 кешене кулга алганнар һәм 7сен атканнар! «Ирекле» илдә, үзләрен «халык хезмәтчеләре» дип атаган ил хуҗаларының чираттагы канлы гамәлләре бу! Билгеле, гәҗитләрдә әлеге ерткычлык турында бер генә сүз дә күренмәде. Бу «канлы июнь» фажигасе турында ул чакта мина майор Туркин: «Новочеркасскта Совет строена каршы демонстрация булган, әмма Плиев аны бастырган!» — диде пышылдап. Бездә гел шулай булды. Берәр нәрсәгә карыша башласаң: «Син нәрсә, совет строена каршымы?» — дип, авызны томаларга иләшкәннәр иде.

Шуннан соң, безнең гаскәрләрне Кубага керткәч, Плиевне Микоян белән Фидель Кастро янына ярдәм итәргә жибәрәләр. Соныннан, лаеклы ялга чыккач, аны гадәттән тыш Генераль инспекция төркеменә кертәләр һәм аңарга «армия

генералы» дәрәҗәсен бирәләр. Ул Генераль инспекция төркеменә отставкадагы маршаллар гына керәләр иде. Эш кабинетлары һәм окладлары тулысынча үзләренә кала иде. Шуна күрә ул төркемне «райская группа» дип атыйлар иде.

Ләкин олы дәрәҗә-мәртәбәләр Плиевнең данлы исеменнән эшчеләрнең кан тапларын юып бетермәде. Плиевнең «батырлыгын» М.Горбачёв чорында – 1989 елда Тбилисида генерал-полковник Родионов кабатлады.

Чирәм жирләрдә шау-шу куптарып-шапырынып иген чәчүгә карамастан, шул елларда икмәк бетте диярлек. Кибетләрдә кукуруза, солы һәм соя оннарын кушып пешергән кара икмәк сата башладылар. Аны да чират торучыларга тиз арада сатып бетерәләр. Солдатларга да шул кайрак кебек икмәкне ашата башладылар. Билгеле инде, без дә шуны ашадык. Ул ипи тиз искерүчән иде. Чиләбедә авыру әти белән әни ак ипине, сөт һәм манный ярмасын табиб таныклыгы белән өлешләп кенә ала башлаганнар. Без дә дөге вә карабодай посылкаларын җибәргән идек. «51нче»гә хезмәт итәргә күчкәч, политурынбасар майор Тимофеев, Округның партактивыннан кайткач: «Илдә азык-төлек мәсьәләсе авырайган!» — диде. Хабаровск краеның беренче секретаре Шитиков: «Әле генә диярлек Канада бодае хакына караб белән 740 тонна алтын илттек!» — дип әйткән.

Менә шул чакта Черчиль: «Бөтен илләргә ашлык сатучы Рәсәйне Хрущёвның «зирәклеге» генә икмәксез калдыра алды!» — дигән.

Шул чорда кечерәк ыгы-зыгылар бүтән өлкәләрдә дә булганнары мәгълүм. Әйтик, Свердловск каласында, Н.Хрущёв килә дип, кала агайлары шәһәрне чистарта-тәртипкә китерә башлыйлар. Иң зур «Уралмаш» заводы җирләрендә бөтен кәгазь кортларын, алабута-әрем-билчәннәрне йолкырга өч көн куялар. Йолкып бетерә алмаганнарын солярка сибеп яндыралар. Менә билгеләнгән көнне завод идарәсе каршына кара лаклы машиналар килеп туктый. Эшчеләр өере яшенле кара болыт булып көтеп тора. Менә Хрущёв, түшен-корсагын киереп, гадәттәгечә елмаеп, машинасыннан чыгып боларга таба юнәлә. Әйтерсең, эшчеләрнең сөекле атасы!

Азык кытлыгыннан гарык булган, көч-хәл белән генә көн күрүче эшчеләр кинәт, стихия рәвешле ярсып, күз ачып йомганчы Хрущёвны урап алалар һәм пинжәгенә ябышып: «Йә, әйт әле, «халык хезмәтчесе», ничек безне мондый хәлгә төшердең?» — дип сорыйлар. Агарып, чырае качкан Хрущёвны тән сакчылары көчкә аерып, машинасына өстерәп китереп тыгалар һәм бу кара машиналар шунда ук ычкыналар! Бу вакыйга турында үз күзләре белән күргән кешеләрдән ишеткәнем бар.

Мин Ленинградта укыганда да Хрущёв заводларга килгәли иде. Бер килүендә, расценкалар турында сүз чыккач, эшчеләргә болай дигән: «Беләм мин сезне, эшлисе урынына тәмәке тартып, Хрущёв турында мәзәкләр сөйләп утырасыз!» Дөрес, аның турында мәзәкләр байтак иде.

Ленинградның «Киров» заводында эшчеләр жыенында мөнәсәбәтләр куерып кыза башлагач, ул Мәдәният сараеның арт ишегеннән чыгып тайган! Аракыга бәя күтәрелгәч, усал ирләр кибеткә кереп: «Дай Никитку!» — дип кенә сорыйлар иде. Илдә тормыш хәлләре катлауланганнан-катлауланып барса да, үзен бик эшчән рәвештә тотып, унай чыккан саен акыл сата иде Хрущёв. Кыланмаганы калмады!

Ярар, инде үзебезнең хәлләргә күчәргә дә вакыт. Үтә үзенчәлекле ракета гаскәрендә безгә, бүтән төп вазифалардан тыш, гаять мөһим бурыч йөкләнгән иде — хәрби серләрне саклау бурычы. Безгә дүртенче сыйныфта ук махсус бүлек аша «ике нульле» яшерен эшләргә Ленинград хәрби округы хокуклар юллаган иде. Мина да, махсус бүлек тикшерүе иләгеннән үткәч, андый хокук

кәгазе (допуск) бирелде һәм ул «Шәхси эшемә» («Личное дело») теркәлде. Анын номерын яттан белергә кирәк иде. Мәскәү штабына яки уку үзәгенә командировкага җибәргәндә, аны юлламага ук язалар иде.

Ярый әле минем нәсел тамырымны тикшергән чакларда Атабай авылы советында мәрхүм Хәсән бабамның бертуганының улы рәис булып утырган. Запросларга җавапны башкарып җибәргән (ул зыян салмаслык итеп)... Рәхмәт инде!

Моның белән генә эш тәгәлләнми әле. Хәрби серләрне чишмәскә дигән кәгазьгә дә кул куйдырттылар. Ул кәгазьдә җинаять кодексы статьясы да күрсәтелгән! Сер тотмасаң, ни буласын белеп тор янәсе. Ел саен диярлек махсус анкеталар тутырталар иде. Анда һәр туганыңның кайда яшәгәнен яки эшләгәнен күрсәтү таләп ителә. Хәтта Әдһәм энемнең кайда һәм ничәнче зират бүлегендә җирләнгәнен дә язарга тиеш идем!..

Ә инде конкрет хәрби оешмада хезмәт иткәндә, сурәтле пропусксыз беркая да йөреп булмады. Пропускта нинди бүлекләргә керергә рөхсәт ителүе махсус тамгалар белән билгеләнә иде. Яшермим, мин анда керергә атлыгып тормадым. Анда эшләүчеләрнең дә нурланулары житкән! Алар да «кыямәт яки тәмуг утыннары» янына үз теләкләре белән кермәгәннәрдер. Болай да зарарлы матдәләр җитәрлек иде. Тупикларга тимер юл цистерналары белән ракета ягулык-окислительләрен кертә башладылар. Противогазсыз яннарына килерлек түгел...

Ә инде урман эчендәге яңа корылган ябык шәһәрчеккә күченгәч, без генә түгел, хәтта гаилә әгъзаларыбыз да пропусксыз керә дә, чыга да алмады. КПП аша автобустан төшеп, берәмтекләп үтәргә кирәк иде. Берәр туганыңны кунакка чакырасың килсә, бер айга алдан гариза язарга кирәк булды. Алманнарның «СС» үрнәгеннән алынган пропуск кагыйдәләре бигрәк кырыс һәм алжытып бетерәләр иде. Шәһәрчеккә кергән юл өсләрендә шлагбаумнар һәм сакчылар. Тирә-юнь чәнечкеле тимер чыбык белән кат-кат уралган, ә ракета комплекслары өстәмә электр чилтәре белән дә чорналган. Кагылсаң — беттең! Ул гына да түгел, кайбер җирләрдә яшерен миналар күмелгән. Йөрергә билгеләнгән юллардан гына барырга туры килә. Ләкин бетон саклыкларга да карамастан, серләр ачыла, тарала, хәтта АКШка кадәре барып җитә! Стройбатлар башкарган мондый олы эшләрне яшерүе бик кыен. Мөмкин дә түгелдер. Йөзәр эшелон, төзү әйберләре — бетон, ком, вакташ, махсус корыч конструкция-арматуралар, торбалар, трансформатор-вентиляторлар һәм озын, түбәләре генә ачыла торган вагоннар төп юлдан аерылып, монарчы бер адәм дә яшәмәгән тайга эченә көн-төн кереп торсыннар әле! Дөрес, бу төзелеш турында ялган риваять (легенда прикрытия) тараталар-таратуын, ләкин аларга ышаналармы икән?

Аннары, ракета гаскәрләре корылмаларын бөтен ил төзи диярлек. Ә хәрбиләрнең саннары даими рәвештә үрчеп торуын, төрле комиссияләрнең килеп-китеп йөрүләрен ничек аңлатырга?

Көнбатыш илләрнең шымчыларын да токтарлыйлар әле, дипломатларын да, бу якка сәбәпсез килүләрен күреп, борып кайтаралар. Шул чакта биредә элек чит илгә качып киткән бер картайган графиня пәйда була. Аннары, беренче стратегик ракетаны әзерләп стартка бастыргач, аның махсус очу борт программасы Мәскәүдән китергәндә юлда югалган дип ишеттем. Энә түгел бит инде ул. Аны кораллы офицерлар аерым купеда саклап килгәннәр. Ә бәлки, дошманнарны алдар өчен, юри урлатканнардыр? «Дезинформация» була инде ягъни. Андый яшерен уеннар да оештырылалар бит! Соңрак бер искитәрлек вакыйга булды. Беренче ракетабыз сугышчан әзерлеккә стартта кукраеп баскач,

Окиновадан АКШ радио тавышы полк командиры Тинчуринны (булачак генерал) шул унайдан тәбрикләгән диделәр!

Возжаевкада һәм тайгада ятканда, офицерлар яшертен генә Окиновадан япон «Момура ханым» радиотапшыруларын тыңлыйлар иде. Ул тапшырулар кыска дулкында махсус көнчыгыш совет гакәрләре өчен оештырылган иде. Анда шәп музыка, совет җырлары яна оранжировкада башкарыла һәм төрле хәбәрләр житкерелә. Хәтта кайбер офицерларны туган көннәре һәм балалары туу белән дә котлыйлар иде әле! Һәрбер тапшыру ягымлы хатын-кыз тавышы — «Момура сөйли!» сүзләреннән башланып китә. «Момура» «Р» хәрефен японча сакаурак әйтә иде. Байтак кына яңалыкларны шуннан ишетәләр иде. Шул кадәресен каян белгәннәр диген! Әле дә гаҗәпләнәм һәм әллә бу үзебезнең тапшыруларыбыз булды микән дип шикләнеп куям. «Ят тавышларны» тыңларга ул елларда катгый тыела иде ләбаса. Сизсәләр, ышанычларын югалтасың. Ул ят тавышларны махсус басалар да иде бит. Аларны даими басып торыр өчен тулаем Днепрогэс энергиясе сарыф ителә иде! Бәлки, ят тавышларны тыңлатмас өчен, юри «Момура» булып кыланганнардыр? Анысы да булырга мөмкин дигән нәмәстәләре бигрәк зәһәр иде шул... Без дошманнарның яшерен эшләрен белеп торгач, алар да безнең турыда белгән инде. Безнең ил өстеннән аларның берничә шымчы иярченнәре даими рәвештә күзәтеп йөри иде ич. Тыңлыйлар да әле! Аларның берьюлы дүртәве очып тора, икесе — ил буйлап, икесе — аркылы. Штабларыбызда аларның графиклары бар. Безнең турыдан үткән мәлдә бөтен хәрәкәтләр — тукталырга, сугышчылар һәм техника яшерелергә тиеш. Ләкин боларның барысын да төгәл үтәве кыен һәм безнең халыкка хас булган тәртипсезлек тә үзенекен әйттерә бит! Шулай булгач, безне капчыкта яшереп кара!

Җәй көннәрендә миңа командировкага ешрак йөрергә туры килде. Яшәреп янарган мохит куенында, хәрәкәтсез поезд эшелонында яшәүләре күңелле булса да, чебен-черкиләрнең, озынборыннарның куерган кара болытлары күз-авызны ачарга ирек бирмиләр. Үтмәгән җирләре юк. Барысы да кан эчәргә маташа! Диметилорталат белән сөртенеп тә чагуларыннан котылып бетеп булмый. Кич житүгә, урнашкан җиребездә ДДТ шашкаларын кабызып бу канэчкечләрне бераз кыргалый идем. Ләкин бөтен тайга бөҗәкләрен алай ансат кына бетерә алмассың. ДДТ төтененең файдасы беразга гына тия.

Солдатларны эшелон каршында чатырлар кордыртып урнаштырдык. Биредә кыр күгәрченнәре күп. Көне буена чырылдап-уылдап мәш киләләр. Солдатлар аларны: «Жидовские кукушки!» — дип атыйлар. Башта мин дә аларның нинди кошлар икәнен белми идем. Янут этләре дә (енотовидные собаки) очрыйлар. Аларның кызык гадәтләре бар икән: кешедән качып өлгермәсәләр, үлгән булып кыланалар. Берсен шундый мәлдә солдат Ряполов тотып кайта, бәйләп куя да читлек ясап, читлеккә утырта. Чыннан да, кара йонлы кечкенә эткә охшаган. Ул аны ашатып, бауга тагып ияртеп йөрткәләде. Ләкин янут бераздан читлеген кимереп качты. Ирекне һәркем ярата шул. Соңрак кышын бер сверхсрочник сукмакта үле янут гәүдәсен күтәреп кайта, тиресен тунарга дип. Йомшарсын дип ванна астына сала. Бермәлне эшкәртергә дип керсә, янутттан җилләр искән!

Эч чирләре килеп чыкмагае дип, солдатлар белән нык шөгыльләнергә туры килә. Шул араларда ракета гаскәре (РГ) медицина бүлегеннән тикшерү максаты белән баш токсиколог-радиолог полковник Гыйрфанов килде. Ул йомшак фигыльле һәм ихтирамлы мөселман заты иде. Кай яклардан булгандыр, сорашырга базмадым. Әңгәмә корып утырырга туры килмәде. Көне эссе иде. Төш вакыты житеп барган мәл. Сусаганын сизеп, чәй эчәргә тәкъдим иттем. Аш пешерүче солдатка чәй китерергә куштым. Өстәлгә мүк җиләге сыгынтысын

да куйдырттым. Тиздән теге солдат алюмин чәйнеге белән чәй китерде. «Чәйне һәм шикәрне шунда салдым!» — ди.

Тустаганнарга чәй агызабыз. Кипкән иреннәребез белән, өрә-өрә эчә башлыйбыз. Кинәт күзләр акая, чү, нәрсә булды бу? Теге нәмәстә шикәр комы урынына чәйнеккә тоз тондырган! Кәеф тәмам бозылды инде. Нинди сөйләшү ди шуннан соң? Чәйнең яңасын китерттем. Эчү белән абзый китеп барды. Әнинең авылында ярлырак бер ир заты яшәгән. Анарга абруйлы, мөхтәрәм мулла абзыйга чәй эчерергә туры килгән. Шуннан соң, авылдашлары белән бәхәс-фәлән чыга калса: «Сез беләсезме минем кем икәнне? Мин хажи Мусага чәй эчергән егет!» — дип, күкрәген киереп мактана торган булган, бичара. Менә мин дә Гыйрфанов агага тозлы чәй эчергән егет!

Шул вакыйгадан соң, ул пенсиягә чыкканчы, Себердә, Капустин Ярда, Перхушковода гыйльми конференция-җыеннарда аның белән гел очрашкаладык. Аны-моны әйткәне булмады. Ләкин мина күтәрелергә дә булышмады. Байтак вакыттан соң, үзем токсиколог-радиолог булгач, ул минем эше яшь белгечләрне гыйльми конференциягә Перхушковода җыйды. Көннәрнең берендә аннан Мәскәүгә — Склифосовский исемендәге ашыгыч ярдәм институтының клиникасына, ашыгыч ярдәмне ничек оештыруларын һәм агуланган авыруларны карарга бардык. Институтның бер өлеше граф Ширәмәтнең махсус сараенда урнашкан. Шул мәһабәт сарайның гүзәл залыннан озын, бормалы-бормалы, лабиринтка охшаган подвал коридорларыннан берәү чыгып, безгә икенче бинага китәргә кушты да үзе каядыр кереп олакты.

Гыйрфанов, безне ияртеп, шул подвал коридорыннан алып китте дә юл таба алмыйча, ярты сәгать буена лабиринтта йөртте. Ачуыбыз чыкты. Ул да монда беренче тапкыр икән бит... Алланың рәхмәте, каршыбызга килгән бәндә бетәсе түгел ишекләрнең берсенә кертеп җибәрде тагы. Югыйсә, кичкә хәтле йөргән булыр идек! Гыйрфанов РТБдан киткән көннәрдә үк диярлек офицерларны казарма тормышына күчерделәр. Отпускыда булганнарын кире кайтардылар. Бу — бөтен Кораллы көчләрдә башланган хәл. Сәбәбе — Куба — Кариб кризисы. Возжаевкага кайтмыйча, эшелонда яшибез. Барча солдат-офицерларыбыз да биредә. Штабыбыз салынган инде, казармалар төзелеп бетте диярлек. Дивизиянең бер генә полкы сугышка әзер булып кизү торса да, дивизия сафка басты дип игълан ителде. Һәм шуның өчен офицерларга өстәмә акча түли башладылар. Гәҗитләрдә, радио-телевидение аша, политик һәм марксизм-ленинизм дәресләрендә АКШ империалистларын бертуктаусыз диярлек сүгәләр. Әйтерсең, үзебез Кубага тыкшынмаган һәм СССРның йөзе кара түгел! Кубага яшерен рәвештә гаскәрләр һәм ракета частьларын Америка кертмәгән ләбаса. Ул урта ераклыкка оча торган ракеталар АКШның хәрби базаларына төбәп куелган!

Америкалылар, шул сәбәптән СССРны агрессиядә гаепләп, Кубаны диңгез флотлары белән камап та алганнар. Бу инде хәрби блокада дигән сүз! Тәүлегенә утызар совет карабы океан һәм диңгезләрне кичеп, кирәк-ярак ташып йөри. Житәкчеләребез Совет армиясенең җыр вә бию ансамбленнән гайре Кубада бер генә солдатыбыз юк, дип бөтен дөнья алдында ялган тараттылар. Без исә көлештек кенә. Әйтерсең, бөтен дөнья сукыр һәм чукрак! Ахырда АКШнықылар Кубадагы СССР ракеталарының Космостан төшерелгән фотосурәтләрен күрсәтеп, аларны гәҗитләрдә чыгарып, ракета частьларының саннарын игълан итеп, СССРның ялганын фаш итәләр. Шаярырга урын калмый. АКШ чын-чынлап ультиматум куеп, безгә каршы сугыш ачарга җыена башлады. Ә СССРның стратегик ракеталары әле сугышчан әзерлеккә баса гына башлаган. Алар аз да әле. Ә Н.Хрущёвның

шапырынуы буенча исә бездә ул ракеталар конвейердан сарделькалар кебек төшеп кенә тора, имеш.

Дивизия махсус бүлеге полковнигы офицерлар жыенында иярченнәрдән алынган зур фотосурәтләрне күрсәтте. Берсендә Пентагон алдында бихисап жинел машиналар жыелган. Икенчесендә Ак йортлары янында шундый ук хәл. Димәк, хәрби һәм сәяси кинәшмәләр бара! Өченчесендә АКШның Куба утравы тирәсендәге хәрби кораблары күренә. Кайбер сурәтләрдә АКШ күгендә очып барган очкычларының борт номерларына хәтле күренеп тора! Фотоательеларда төшерә белмәгәндә, Галәм күгеннән төшереп үрнәк күрсәтә!

Бераз тарткалашып-карышып маташканнан соң, безнекеләр каракларча яшереп керткән гаскәрләрен һәм ракеталарын, хурга калып, кире кайтарырга мәжбүр булдылар. Д.Кеннеди үзенекендә нык торды. Әйтерсең, дөнья алдында СССРның янагына чәпәде! Нәкъ урыслар үзләре әйткәнчә булды: «Пошли за шерстью — вернулись стрижеными!»

Үпкәләгән һәм СССРга ышанычын жуя башлаган Фидельны тынычландыру һәм үгетләү Микоянга йөкләнә. Ул анда Фидельдан аерылмыйча байтак торды, үлем түшәгендә яткан хатыны янына бәхилләшергә дә кайта алмады, чөнки Куба белән дуслык бозылыр хәлгә житкән иде. Кызык бит, СССРның бөтен дөньяны кочып аласы килә, бөтен дөньяга социализм индермәкче булып маташа, ә үз халкы суган суы суырырга житкән!

Ракета гаскәрен дә бик кызык керткәнбез. Аннан кире кайткан офицерларны төрле частьларга тараттылар һәм аларның мажараларын күбесенең үз авызларыннан ишеттем. Офицерларны һәм солдатларны Одесса һәм Балтыйк буе портларыннан пакгаузларында гражданский киемнәргә киендереп, пароходларга утыртып алып киткәннәр. Андый тәжрибә бар иде инде. 1935-1936 елларда Испаниягә совет гаскәрләре шулай яшерен рәвештә кертелгән.

Солдатларны трюмнарда урнаштыралар. Аларга көндез палубага чыгу катгый тыела. Солдатлар тын алырга саф һавада төнлә генә чыгалар — күлмәкчән генә, чөнки «бүләк» костюмнарын «дембель» көненә саклыйлар! Жыйнаксыз һәм әрсез-әдәпсез солдатлар ризык калдыкларын тегендә-монда түгеп-ташлап вә косып, трюмнарны черетеп, тәмам сасытып бетергәннәр. Үзләре дә тончыга язганнар. Атлантик океанда корабларны АКШ хәрби лачыннары каршы алалар. Тикшереп һәм куркытып, бертуктаусыз үкерә-үкерә, алар мачталарга тияр-тимәс кенә оча башлыйлар.

Ниһаять, безнекеләр аякларыннан язып, авыр хәлгә төшеп, Куба утравына килеп төшәләр. Андый ерак диңгез сәяхәте кемне дә алжытып бетерә. Ракеталарны билгеләнгән жирләргә жайлап бастыра башлыйлар. Солдатлар, каты кисәтүләргә карамастан, Кубаның тропик куак-агачларына ябырылалар. Монарчы күрмәгән-белмәгән орлык-жимешләрне тизрәк авызларына тыга башлыйлар. Нәтиҗәдә, эч китүләр вә дизентерия эпидемиясе башлана. Дөнья күрмәгән солдатлар маймыл рәвешенә бик ансат төшәләр.

Үтә булдыклы, сабыр һәм эшчән капитан В.Щукин белән Новосибирскиның Пашино бистәсендә бергә хезмәт итәргә туры килгән иде. Куба галәмәтен бу яшь хирург та татыган. Килеп төшүгә медицина хезмәткәрләре бушаган өйләрдә, абзарларда һәм чатырларда госпиталь корырга керешкәннәр. Санитар солдатлары белән бергә офицерлар да ярдәм булып, жиһазларны, медукладкаларны ташлап-урнаштырып, көн-төн бөтен кара эшләрне эшлиләр. Моны күреп кубалылар: «Кайчан инде офицер табибларыгыз килә?» — дип сорыйлар икән. «Менә бит без, күптән килдек инде!» — дигәч, — «Шыттырмагыз, табиблар һәм офицерлар кара эшне гади кешеләр кебек эшләмәс!» — дип әйтәләр икән. Кадерсез совет офицерларының борыннары белән жир сөргәннәрен, белмәгәннәр шул алар.

Эшләре беткәч, аруланып ак халатлар кия башлагач кына шаккатып ышанырга мәҗбүр булганнар. Кайберәүләр Куба тутыйларыннан йогышлы җенес чирләре эләктерәләр һәм ул «бүләкләрне» илебезгә дә алдып кайталар. Минем белән укып чыккан урыс егете Колядов та җенес «томавын» эләктереп кайта. Ә соңыннан анарга, тиеш булып та полковник итмәгәнгә үпкәли башлагач, нәкъ шуны исенә төшерәләр. «Совет офицерларына чит ил хатын-кызлары белән алай «аралашырга» катгый тыелган», — диләр. Һәм, минемчә, дөрес иткәннәр. Йә, кыйссамны дәвам итим. «Интернационалистларыбыз» кайтканда инде кыш була, һава сүрелә. Ничек килсәләр — шулай кайтып китәләр. Ни майтарыпмы? Халыкның малын һәм акчасын заяга сарыф итеп! Илебезгә житәрәк дингез дулкыннары өстендә суык булып китә, тозлы-ачы җилләр тәнне өтеп исәләр. Армиядән ата-ана өенә кайтырга әзерләнгән беркатлы солдат-сержантлар пөхтә костюмнарын һаман да кызганып, кими саклыйлар. Кайчан эшләп алачак әле алар андый затлы киемнәрне? Палубага хозурланырга да эчке киемнән генә чыгалар. Ләкин портларыбызга килеп төртелгәч, бичараларны чишендереп, элеккечә тузган шыксыз хаки формаларга киенергә, ә костюмнарын кире кайтарырга кушалар! Солдат-сержантлар тәмам ярсып, интегеп саклап килгән костюмнарын аяк асларына салып таптыйлар! Йә, әйтегез инде, ник шулкадәр дә вакланырга, бүләк итеп үзләренә калдырмаска ди? Мәнсезлек дими, ни дисең инде моны? Фетнә куптарырга әзер «карт» солдатларны озакка сузмый демобилизацияләләр. Рухлары какшаган һәм тәртиптән ычкына башлаган кече офицерларны исә төрле частьларга тараталар. Ләкин анда да күбесенең файдалары булмый диярлек. Инде беләбез, моннан да аянычрак хәлләр Әфган «интернационалистлары» белән дә кабатлана. Кәпрәйгән дәүләт җитәкчеләре халыкны бер бәладән икенче бәлагә тыгарга гына торалар.

Әфганстаннан кайтып, әфган сынауларыннан үткән бәндәләр җәмгыять эшләренә яраксыз булып чыкты. Күбесе эчәргә салышты. Кызганыч инде. Ләкин шулай булмый хәл юк. Чит илне туздырырга барсаң, башсыз калуың да ихтимал. Юкка гына баскынчыларны «интернационалистлар» дип олылаган булдылар. Чит илләрнең хәлләренә тыкшынып йөргәнче, башта үз илеңә хезмәт итү зарурлыдыр. Әнә «демократларны» ашатып, ярты дөнья хөрәсәннәренә булышып, ни майтардык? Бүрене нихәтле ашатма, ул барыбер урманга карый! Моны бервакытта да онытмасак иде! Ярар, алгарак киткәнмен.

Куба мәсьәләсе сүрелә төште. Декабрь азагында Мәрзия янына кайттым. Ул чакта вагоннардан яңа казармаларга күчкән идек инде. Өйгә бер чиләк чамасы күк җиләк (голубика) җыеп кайттым. Тәмле, бик үзенчәлекле җиләк. Безнең казармалардан арырак ул мул үскән иде. Җыйганда, йоклап яткан кыр кәҗәсен куркыттым бугай. Ул кинәт атылып чабып китте. Алар да күп биредә. Төнлә юлга чыгып яталар да машина яктысына эләгеп, машина алдында чабып, кайчакларда көпчәк асларына да эләгәләр. Бай табыш!

Ул күк җиләкне солдатларга җыйдыртып, кышка паёк исәбенә үзләренә варенье да кайнаттырдык әле.

## Ял ләззәте һәм көченүләр

Инде чираттагы ялым җитте. Кайткач, лазаретта белдем: кемдер Кисловодск шифаханәсенең парлы юлламаларыннан баш тарткан. Имеш, Братаненко шунда ял итәргә теләүчеләрне эзли. Юлламаларны кулга төшереп, Мәрзия белән юлга атылып чыгып та киттек! Чиләбе аша узсак та, тукталып керергә вакыт юк, болай да бер тәүлеккә соңга калабыз. Мәскәүгә хәтле туры килгән урынга утырып барсак, аннан махсус бик чиста, урын-җирләре анықланып куелган вагонга

утырып бардык. Мин шунда бәйдән ычкынган эт кебек, ирекkә чыкканыма ышанып житә алмыйча барам. Икебезгә дә рәхәт булып китте. Кисловодскида бик жылы иде әле. Бөтен мохит ямь-яшел. Биек һәм киң ябалдашлы кәстәнә агачларының шома, күркәм көрән чикләвекләре тротуарларга шып итеп төшеп тәгәрәшәләр. Елның бигрәк матур чагына туры килгәнбез. Халык пөхтә җәйге киемнән. Чатларда кара тутлы әрсез алыпсатарлар кибетләрдән алынган кием-салымнарны сатып йөриләр. Аларны тыючылар күренми. Шифаханәдә без беренче тапкыр. Ожмахка кердекмени! Аерым бүлмә бай җиһазландырылган, идәндә келәмнәр, холларда кисмәкле гөлләр, көзге-кәнәфиләр. Хезмәткәрләре ягымлы, ял итүчеләр ачык йөзле. Бина-бүлмәләрдә чиста һәм тыныч. Ризыклары мул, тәмле. Возжаевкада эләкмәгәнне монда ычкындырмыйбыз инде. Ресторанга кереп, берәр бокал шампан шәрабен эчеп, краб, ягъни диңгез кысласы итен авыз итеп чыгабыз. Тансык йөзем тәлгәшләрен алып сыйланабыз. Иркенлек биредә! Буфетка нарзан суын эчәргә йөрибез, нарзан ванналарына керәбез. Шәп! Паркка һәм якындагы тауларга йөрибез. Күңелле. Нинди хозурлык! «Комсомол» исемле ясалма күлләрен карап, коенып кайттык. Көн дә диярлек кино карыйбыз.

Монда көтмәгәндә Прилукидагы ОБАТОның элекке штаб начальнигын — подполковник Скворцовны очраттым. Ул, командиры полковник Кошкин кебек лаеклы ялга чыккан икән. Болай, «сыерчык» белән «мәче» тату хезмәт итәләр иде. Скворцов минем академия бетерүемә гажәпләнде. Биредә онытылмаслык егерме биш тәүлек үткәнен сизми дә калдык. Тагы шул фирменный поезд белән башкалага киттек. Мәскәүдә яңа төзелгән «Спутник» кунакханәсендә тукталып, ун тәүлек яшәдек. Башкалабызга эләккәч, күбрәк күрәсе, кирәкле һәм ошаган әйберләрне аласы килде.

Күршеләр заказлар да биргән иде. Вакытны заяга уздырмаска тырыштык. Ерак Көнчыгышта бу сәяхәтне ел буе көтеп торасың бит! Башта янәшәдәге ВДНХ сарайларын һәм күргәзмәләрен карап чыктык. Аннары Горький проспектын (Тверьская) җәяү, ике ягыннан да кибетләрен тикшереп үттек. «Россия» кинотеатрында Бондарчук куйган «Сугыш һәм тынычлык» дигән төсле киноның премьерасын яратып карадык. Төрле кош ите шулпаларын пешерә торган махсус ресторанда тукланып алдык. Кызыл Мәйданда булдык. «Пассажда» Мәрзиягә яңа гына модага кереп барган кара синтетик тун сатып алдык. Метроны гизеп йөрдек. Икенче көнне Комсомол проспектында яңа ачылган «Синтетика» кибетендә булдык. Бу урамның киңлегендә, турылыгына һәм озынлыгына исең китәр! Кичен «Космос» кинотеатрында яңа кино карадык. Өченче көнне «Националь» ресторанында сыйландык. Дүртенче көнне — «Метропольда», ә аннары «Москва»да. Соңгысының ризыклары ошап бетмәде. Зур театрга билет таба алмадык. Кермәгән кибетләребез калмады. Мәскәү кибетләреннән Марокко сардиналарын, биш литрлы савытлы Венгрия тозлы кыярларын, затлы сыр-колбасалар, тартмалы шоколад, хәлвә, Һинд чәен, маркалы шәраб, ун дистә кукәй, Чех бакарра бокалларын һәм тагы бетәсе түгел затлы һәм тәмле ашамлыклар алдык.

Кисловодскида да кайбер әйберләр алган идек, шул исәптән Мәрзиягә шакмаклы кыска көзге бишмәт, ак ридикюль һәм затлы спортчылар рюкзагы. Хабаровск поездына җыена башлагач, әйберләребез биш урын булды. Минем ике кулыма — авырлары, ә Мәрзиягә җиңелләре тиде. Ел буе җыйган акчабызны сөенә-сөенә пыр туздырдык. Авызына эләккәнен йот дигәндәй, туры килеп торганын алмый үтмәдек инде. Аннары кайдан аласың ди? Военторг ул бит күбесенчә начальствоны гына тәэмин итәргә тырыша!..

Мәскәүдә эт булып арысак та, аякларыбыз өстерәлә башлаганчы йөрсәк тә,

бай тәэсирләр алып, бик канәгатьләнеп кайттык. Мәскәүнең мул, чәчәк аткан чагы иде. Кайтышлый Чиләбегә кагылдык, туганнарыбызны күреп, кунып, юлыбызны дәвам иттек. Барысы да исән-саулар иде.

Омскины узганда Мәрзия туган тиешле яшьтәше Рәзинә белән очрашты. Ул анда индустриаль институтта укый иде. Сөйләшүләре егерме минут кына булды. Алай да бер шешә шампан шешәсен бушатып, Мәскәү конфетларын авыз итеп өлгердек. Рәзинә иптәш кызы белән килгән иде. Шуннан соң саубуллашып сәяхәтебезне дәвам иттек. Кисловодскида эчкән нарзан һәм поездның бертуктаусыз селкетүе үзенекен итте. Мәрзияне бөер өянәге тотып, ташы төшә башлады. Киләсе станциядә аңарга атрорин кадатып, фатирыбызга көчкә кайтып кердек.

Кисловодск, шифаханә һәм Мәскәү истәлекләре байтакка сузылып, күңелләрне күтәреп торды. Йөри алганда йөр икән! Ялдан кайтканнан соң күп тә үтми йөк эшелонын китертеп, безне гаиләләребез белән яңа корылган шәһәрчеккә күчерергә керештеләр. Чегәннәр таборы кузгалдымыни! Биредә кыскартылган Барабанщиков полкы гына кала. Ул да соңрак Иваново тирәсендәге Тейковога күчәчәк...

Лазарет безнең белән күчә. Берәм-берәм алынып килгән йорт әйберләре байтак җыелган икән: панцирьлы сәке, диван, сервант, комод кебек тумбочка, чемоданнар, савыт-саба, кием-салым, азык-төлек. Станциягә йорт җиһазларын офицерлар белән бергәләшеп йөк машиналарына төяп ташыдык. Күмәкләшеп эшләгәндә җиңел һәм күңелле. Солдатлар казарма һәм штаб малларын ташыдылар. Караңгы төшкәч кенә эшләребез бетте һәм эшелонны озаттык. Эшелон артыннан төнге поезд белән үзебез дә киттек һәм Ледяная станциясенә таң атуга килеп төштек. Торган урыныбыз бушап калды. Белогорск, Возжаевкалар белән ара өзелде. Ләкин Кытай белән мөнәсәбәтләр дошманлашуга хәтле барып җиткәч, ул бушаган урыннарны Туладан килеп, танк дивизиясе биләячәк әле!

Яна йорт («Хрущёвка») фатирларының ачкычларын алдык. Миңа йортның башында, икенче катта бер бүлмәлесен («полуторка») бирделәр. Фатирлар жылыткычлар белән җиһазланган, аш бүлмәләрендә плитәле мичләр салынган, бәдрәфләре, канализацияләре бар, ләкин ванналар әле куелмаган һәм жылы кертелмәгән иде. Котельный өлгереп җитмәгән. Әйберләребез өйләдән соң гына килде. Тагы күмәкләшеп ташыдык. Урнаша башладык. Фатирыбыз якты, күркәм. Әле бер дә жылытылмаган салкын бүлмәдә төнне калтыранып көчкә уздырдык. Таң атуга, кар ерып, утын хәстәренә керештек. Мичне ягып җибәргәч һәм аш пешерә башлагач кына тәннәргә жылы керде. Берничә көннән соң йортларга жылы бирә башладылар, язга таба исә ванналарын да китерделәр. Хатыннар, ирләре кайтканны көтмичә, бергә-бергә аларны фатирларына куанышып күтәреп ташый да башладылар. Мин дә, кайтып җитеп, күршеләр ярдәме белән берсен керттем. Бу калын чуен нәмәстәләр бигрәк авыр икән. Аның каравы жылыны озаграк саклыйлар. Шулай тормыш әкренләп тагы тәртәсенә керде. Кибет монда бер генә. Мәрзия анда сәгатьләр буе чират торып, булган ризыкларын ала. Аларны да өлешләп кенә саталар. Сатучылары да тәҗрибәсез, яңа алынган офицер хатыннары. Көчкә кыймылдыйлар. Ризык талымнарга туры килми. Кибеткә ни китерәләр — шуны башың әйләнгәнче чират торып аласың.

Беренче якшәмбе көнендә поезд белән Свободный шәһәренең базарына бардык. Каз түшкәсе йә башка ризык, тозланган кыяр-кәбестә мазар булмасмы дип. Ләкин себеркеләр, балта саплары кебек нәрсәләрдән гайре берни дә юк иде. Кыш биредә үзәккә үтәрлек суык икән. Шулай бермәлне базар

уртасында бармакларым каткан көн итекләр эчендә үкертеп елатырлык итеп сызлый башладылар. Шөкер, Мәрзиянең аягында яна кара киез итек. Ә мин тыпырчынып кая сугылырга белмим. Бәхеткә каршы, шул чакта күземә берсенең кулында киелмәгән соры киез итек чалынды. Сатулашып та тормый алдым. Һәм шунда ук хром итекләремне салып, боларны кидем. Озын кунычлы мул вә йомшак итек киеп алгач, үлем газабыннан котылган кук булдым. Шундый рәхәт булып китте. Белеп әйткәннәр шул җылы җанны саклый дип. Әллә инде бу итекләрне миңа Хозыр галәйһис-сәлам туры китерткән инде?

Свободный шәһәрендә күз төшәрлек бер генә күркәм бина да вә кызык нәмәрсә дә юк. Ресторанына кереп ашадык. Фәкыйрь генә ашханә шунда. Ашларының кызыктырганы — ап-пак, эшләпә хәтле эре, шыгырдап торган, тозланган гөрежделәр! Алар шулхәтле, шөет орлыкларын салып, хасиятләп-килештереп тозланганнар ки, ашаганда телеңне йотарсың! Җайлы гына сөйләшеп сорагач, битоныбызга да тутырып саттылар. Менә бит, Свободныйның берние дә хәтеремдә калмаган, ә бусы һаман истә. Тикмәгә генә Суворов: «Солдатның күңеленә юл ашказаны аша ята!» — димәгәндер. Хәзер Рәсәйнең «Свободный-18», яки «20» дип аталган космодромнары шул элекке безнең ракета комплекслары инде.

Клуб, ашханә, кафе төзелеп бетмәгәннәр әле. Кино карарга мәктәпнең спорт залына йөрибез. Кисловодскида һәм Мәскәүдә булганнарыбыз төштә күргән кебек кенә. Мәскәү һәрчак Мәскәү инде ул. СССРның Мәккәсе. Ул теләсәң нинди кеше зәвыгына хуш килерлек кала. Күңел ачарлык урыннары да, татлы ризыклары да җитәрлек. Исеме дә аның борынгы төрек сүзе диләр — ат тышавын аңлата, имеш. Ул инде хәзер кеше күңелләрен җәлеп итеп, тышаулап тора кебек. Тикмәгә генә регион түрә-генераллары шул Мәскәүгә омтылмыйлардыр. Ләкин Мәскәүнең икенче ягын, аның кемнәр хакына алай иркен яшәгәнен дә беләбез.

Зәмһәрир суыклар узып, яз башлануга, шәһәрчегебезне кар суы басты. Тротуарлар әле салынмаган. Ләкин станциядән полк-дивизионнарга авыр машиналар күтәрерлек калын һәм киң бетон плитәләрдән юл салалар. Менә кайда ул Татарстанга һәм Рәсәйгә эләкми калган юллар!.. Хезмәт һәм тормыш җайланды диярлек. Хатын-кызлар мөмкинлек булган урыннарга эшкә урнаша башладылар. Мәрзия дә янәшәдәге төзүчеләр штабына машинистка эшенә ялланды. Ленинградта бераз стенографистка-машинисткалар курсында укып алган. Үзебезгә хәрби сәүдә кибетеннән бәләкәй язу машинкасы алдык. Кирәге чыкмагае...

Эшли торган урыным җиде чакрымда гына. Үз автобусыбыз белән барып-кайтып йөрибез. Бик җайлы. Бер казармада медпункт һәм изолятор ачтым. Бөтен эшемне махсус кулланмалар һәм уставлар буенча кордым. Командование, офицерлар һәм дивизия табиблары белән яхшы мөнәсәбәттә. Бу яктан борчылырга урын юк. Тик күңелне бераз киләчәк хезмәт мәсьәләсе кыбырсыта. Майор дәрәҗәсен алыр өчен олырак хезмәт урыны кирәк. Бу хакта җаен табып, корпус табибы полковник А.Наугадов белән сөйләшәсе бар. Комиссия белән бергә Хабаровскидан килгәли. Еламаган баланы имезергә ашыкмыйлар бит. Армиядә, кагыйдә буларак, олы начальниклар белән үзеңнең киләчәк хезмәт хакында кайгырта башласаң: «Әле сиңа иртәрәк!» — дип әйтергә яраталар. Ә аннары, вакытың җитеп уза башлагач: «Инде соңга калгансың, яшең үтеп бара!» — диләр. Димәк, башта — иртә, ә аннары соң! Аларны борчыма гына! Ә үзләре исә, этешеп-төртешеп, төрле хәйлә-җайларын табып, кайсын эчереп-сыйлап, кайсына ялагайланып, тәлинкә тотып, аулар оештырып, гел өскә үрмәләргә тырышалар. Андыйларны байтак күргәнем бар. Шундый карьеристлар кеше

таптап түргә үтүдән дә тартынып тормыйлар. Нәкъ менә шулар, түрә булгач, бүтән лаеклыларны үзләреннән алгарак уздырмаска бар көчләрен җигәләр дә инде. Мондый яклары белән Илгә һәм Кораллы көчләребезгә нинди зыян китерүләре хакында язып торуым кирәк микән? Маршал Гречко — хәрбиләр министры, ә Брежнев СССР атасы булганда, кода-кодагыйлык аркасында, ришвәтләр биреп, Лукулл сыйлары оештырып, фәхешлекләр кылып, халык муенына атланучылар аз булмады. Бу барыбызга да мәгълүмдер. Матбугатта язылганы да җитәрлек. Дөньябызны шулар череттеләр дә инде. Үзләре бозык булгач, чирләре эпидемиягә әверелә.

Кызганыч ки, азгынлык чире армиябезне дә читләтеп узмады. Бер илдә бит! Әйтик, Гречко чорында җыен яраксыз кавемдәшләре гаскәр башлыклары булып беткәннәр иде. Кошевой, Третьяк кебекләрне искә төшерү дә җитә, Брежнев, Гречко һәм аларның якыннары үзләрен, назлы кызлар сыман, иркәләтеп, уч төбендә генә сикертеп тоттырырга омтылалар иде. Олуг түрәләрнең йомшак якларыннан файдаланучылар табылып кына торды. Ә гади халык нишләде соң? Барысын да күрде һәм наданлыкка, гафләткә батып, битарафлыкка бирелеп, күнеле кайтып, әкренләп эштән бизә башлады. Сәрхушлеккә, угрылыкка салынды. «Бөек» җитәкчеләр хакимлегенең нәтиҗәсе шул булды. Мондый авыр сырхаудан терелер көн килер микән?

Дивизиябезнең шактый өлеше, ракеталарын торгызып, сугышчан әзерлеккә басты. Болары әле җир астында түгел. Старт өстәлләре җир өстендә. Ләкин коралланунын бу башлангыч адымы гына. Күнекмәләр үткәрәләр. Озын, шәм күк төз ракеталарның атом белән коралланган очлы башлары күкне тишеп торалар. Әйтерсең, бу кыямәт кисәүләре мәхшәр көне җитә дип кисәтәләр! Ләкин аларны галәм күге аша дошман иленә яудырыр өчен башта байтак вакытны сарыф итеп, эчләренә махсус цистерналардан саулыкка үтә зарарлы күп кенә «гептил» шифрлы (несимметричный диметилгидразин) ягулыкны һәм шулай ук үтә агрессив оксидлаштыручы «АК-27 А» сыекчасын (концентрированная азотная кислота в окислах азота) тутырганчы йөгертергә кирәк. Ягулыкны һәм оксидлаштыручы сыекчаны кирәгенчә тутыргач, ракеталарны җибәрер өчен, боерык алганнан соң ике минут чамасы вакыт кирәк. Бу МБРларга алмашка полигоннарда төгәлрәкләре һәм әзерлеклерәкләре сынала һәм аларга шахталар да казыла. Свободныйдан бүтән полкыбыз да бирегә, урман эченә күчеп, төп вазифасына тотынырга җыена. Анда өлкән табиб булып капитан Клименко хезмәт итә. Ул миннән бер ел алдан укып чыккан иде.

Дивизия командирыбыз Горбунов генерал дәрәҗәсенә иреште. Үзе бер төпчек кенә инде. Братаненко, ялагайланып, аңарга махсус санинструкторны беркетеп куйды. Янәсе, олы шәхес кинәт чирләп китмәгәе дә, аны инфаркт сукмагае! Генерал кая гына бармасын, санинструктор, букчасын тотып, артыннан ияреп, йомышларын үтәп йөри. Әлегә кадәр мондый хәлне авиациядә хезмәт иткәндә генә күргәнем бар иде. Авиация маршалы Руденко Прилукига махсус табибын иярә килгән иде. Офицерлар җыенында чыгыш ясаганда, аның кыза башлавын күреп, табибы шунда ук әкрен генә ымлап-эндәшеп, тынычландырырга тырыша иде.

Кирәкләре булганда шулкадәр дә кадерләп карыйлар бу түрәләрне, кирәкләре беткәч исә — мәтәлдерәләр! Горбунов кебек кечерәкләре, күрәсең, олыракларыннан үрнәк аладыр. Урыслар мондый очракларда: «Что крестьяне — то и обезьяны!» — диләр.

Җәй башында гаскәрнең сәләтләрен тикшерергә һәм тормыш якларын күрергә яңа главкомыбыз — Советлар Союзы маршалы Крылов килде. Элек ул Ерак Көнчыгыш хәрби округында хезмәт иткән. Урта буйлы, юантыграк,

түгәрәк битле, тукмак борынлы адәм. Йөзе бераз калмыкка да охшаш диимме... Болай шау-шу куптарганы ишетелмәде. Кайбер карт, сәнәктән көрәк булган генераллар кычкыручан, тынгысыз булалар. Андыйларын да очратырга туры килде. Андыйлар хакында офицерлар арасында байтак ләтыйфәләр (мәзәкләр) сөйләнелә. Берсе мондый. Картаеп барган генералның хатыны бала таба, имеш. Бу, куанып, хатынның хәлен белергә адъютантын юллый. Теге әйләнеп кайткач, генерал түземсезлек белән: «Йә, күрденме, нинди?» — дип сорый Адъютант: «Нәкъ үзегез кебек, иптәш генерал!» — ди. Генерал: «Кит инде!..» Адъютант: «Әйе, үзе пеләш, үзе чөгендер кебек кып-кызыл, үзе яман акыра!» Безнең главком андый түгел. Тыныч кешегә охшый. Стройбат клубында офицерларны җыйдыртып «киңәшмә» үткәрде. Каравылларны мөмкин кадәре киметергә, алар урынына тиешле җирләрдә электр чөлтәрен тарттырып куярга һәм мина кырларын, төрле сигнализация әсбапларын булдырырга кушты. Әгәр дә берәр җирдә сигнал була калса, кизү торучы укчыларны җинел машина яки вертолёт белән шунда җибәрергә. Акыллы карар! Тәрәккыят заманында нигә искегә ябышып ятарга һәм хәрбиләр санын арттырырга ди әле? Тәнәфестә, ул ял итеп утырганда, без, берничә яшь офицер, янына ук килеп бастык. Маршалны көн дә күрмисең бит! Ул, безне аңлагандай, аны-моны әйтмәде, елмайды гына. Тужуркасының алтын йөгертелгән тугралы төймәләрен, Генштаб академия ромбигын һәм маршал тамгалары чигелгән укалы погоннарын җентекләп карадык. Крылов хакында мондый сүз йөри иде. Имеш, хәрби министр — Советлар Союзы маршалы Малиновский аның элекке аттестатына болай дип язган: «Академии не окончивал и в оных не нуждается!» Соңрак барыбер ничек булса да Генштаб академиясен тәмамлаган күрәсең.

Шәһәрчегебездә кунакханә төзелмәгән иде әле. Маршал килүгә, бер подъездның өч бүлмәле фатирында анарга кунакханә булдырдылар. Пинчук хатыны һәм башка командирларның хатыннары, келәмнәр, пианино, кәнәфиләр һәм пәрдәләр алып кереп, чәчәкләр җыеп кертеп, аны шәп кенә җиһазладылар. Һәм маршалны шунда ашатып-эчертеп йөрделәр. Маршал белән Перхушководан ЛОР белгече килгән иде. Аның тагылып йөрүенең сере мондый икән. Ватан сугышында булачак маршал дошман снаряды шартлаганда контузияләнгән. Шул мәлне аның колак пәрдәләре ертылып канаганнар. Яралардан соң колак пәрдәләрендә җөйләр барлыкка килә, алар исә саңгыраулаталар. ЛОР белгече исә, шул колак пәрдәләрен кокаин белән майлап, көн дә колакларына пневмомассаж («по Воячеку») ясый икән. Маршал кокаинга ияләшкән булса кирәк...

Шул киңәшмәдә гарнизон һәм стройбат командирлары маршалга: «Безгә ДВО (Ерак Көнчыгыш хәрби округы) командующие бер дә булышмый!» — дип белдергәннәр. Маршал киткәннән соң, көннәрнен берендә бирердәге тормыш хәл-әхвәлләре белән танышырга дип хәрби округ командующие генерал-полковник Крейзер килде. Килми хәле юк, чөнки Крылов — хәрби министрның урынбасары һәм Югары Совет депутаты! Крейзер кара тутлы гына бер яһүд шунда. Аның махсус пассажир вагонын тупикка кертеп куйдылар. Ул үзенең пешекчесе, табибы, адъютанты һәм сакчылары белән йөри икән. Аның белән бер төркем өлкән офицерлар да килгән иде. Янәсе, сезгә нинди ярдәм кирәк соң? Дивизия округ җирендә булгач, аның иминлеге өчен округ штабы да җаваплы...

Җәй көннәрендә Мәрзия белән тирә-юньдәге урманга һәм бәләкәй генә тайга инеше буена сафланырга чыккаладык. Черкиләр һәм озынборыннар тынгылык бирсәләр икән!

Көз җитүгә Мәрзия хатын-кызлар белән машинага утырып ике мәртәбә

гөреждә жыярга барды. Икесендә дә зур чиләкләрен тутырып кайтты. Чистартып юдык һәм ваннада тәүлек буена жебеткәннән соң тозладык. Бик тәмле булдылар. Гөмбәләрне жыярга һәм хасиятләрен китереп хәстәрләргә икебез дә яратабыз. Гөмбәләренә карап, тозларга да, маринад белән пешерергә дә, табада кыздырырга да, ашын пешерергә һәм тозланган гөмбә уылдыгын анысларга да була. Иренмичә дөрес эшкәртеп әзерләсәң, менә дигән файдалы ризык. Бу гөмбәдә рак чиренә каршы торырлык нindидер матдәләр дә бар диләр.

Март азагында, юлламасын кулга төшереп, Одесса хәрби округының шифаханәсенә дәртләнеп ялга киттек. Чиләбедә тукталып, бер атна чамасы әти өендә кунак булып, аның алтмыш еллыгын уздырдык. Мәрзиянен туганнарына да барып, хәлләрен белеп килдек. Алар безгә юлга тозланган каз түшкәсен пешереп бирделәр. Ите бик тәмле иде. Чиләбедә ул чакта әле ачы жил бозланган урам карларын себерә, күз яшьләрен сыга һәм борын-колакларны чеметеп ала. Суыкка карамастан, шөкер, барысы да исән-имин иде...

Поезд көнбатышка барган саен, яз кыяфәте артканнан артты. Таныш Урал тукталышларын, Уфаны, укыган мәктәп бинасын дулкынланып карап уздым. Монда да эзләрем калган... Инде вагон баскычына асылынып түгел, ә жиһазланган йомшак купеда утырып барам һәм биредә кичергәннәремне, каешлануларымны исемә төшереп, йөрәк әрнүен көчкә тыям. Минем дә мондый көннәргә ирешәсем бар икән! Берәр танышым, бергә укыган дусларым күрсәләр иде хәерче рәвешендә монда укып йөргән ач татар малаен! Танырлар микән медицина капитанын? Юк шул, берсе дә күренмәде. Тормыш барысын да күптән тараткан инде...

Украина жирләренә кергәндә, кар караеп эри башлаган иде. Юл буе саесканнар очрый. Менә юлыбыз тәмамлана. Одессада карның эзе дә юк. Олы, мәшһүр көньяк шәһәренең ошаганын әйтеп торасы да түгел. Көн жылы, кояш нурларына күмелгән. Халык жәйге киемнән йөри. Гүзәл биналар һәм матур һәйкәлләр... Күңел үсеп китте. Биредә һава торышы Амур өлкәсенекеннән нык аерыла икән шул. Шифаханәнең Уналтынчы Фонтан бинасында урнаштырдылар. Икебезгә ике агач сәкеле аерым бүлмә бирделәр. Балконы һәм тәрәзәсе диңгезгә карап тора. Боз бистәсеннән соң бу урынны ожмах дисән дә хак булырсын. Янәшәдә Кара диңгез. Аны Мәрзия беренче мәртәбә күрә һәм шатланып елмая. Төкле аягың белән! Коену сезоны әле башланмаган. Ләкин яр буенда халык кызына инде. Трамвайга утырып, Тугызынчы Фонтан аша үзәк урамнарга йөрибез. «Фонтан» исемле булсалар да, анда бернинди фонтан юк һәм беркайчан булмаган да. Элек атлар белән мичкәләп халыкка су китерә торган урыннар булган. Кайберләрендә китергән суны тотарга таш «коелар» да ясаганнар. Менә шуннан бирле «не фонтан» әйтеме телгә керә дә инде. Берәр нәрсә килешмәсә, Одессада: «Не фонтан!» — дип кенә жибәрәләр.

Кала кибетләрендә азык-төлек мул. Каһарман вә курорт кала бу! Импорт шәраб-сыралары тезелеп тора. Без кызыгып, кургаш башлы, озын шешәле «Сенатор» исемле кара «бәрхет» сыраны тартмасы белән (12 шешә) авыз итәргә алдык. Бераз исәләшкәч, диңгез янына кызынырга йөри башладык, ахырда батыраеп суга кереп, чумгалый да башладык. Чыдарлык. Пляжда әле халык әз, иркен һәм рәхәт. Шунда фотосурәткә дә төштек. Бер истәлек булып калды. Хәзер шул сурәткә гажәпләнеп карыйм һәм яшьлегебезнең булганлыгына ышанып бетмим. Булды микән соң ул? Әллә төшемдә генә күренде микән? Гомер ничек тиз уза! Башта бетмәс-төкәнмәс кебек иде кана...

Өйләдән соң шәһәргә, киноларга чыгабыз. Безгә трамвайларда утырып йөрүе дә тансык. Дерибасов урамында сокланып йөрибез. Данлы опера театры бинасы, Дюк Ришелье һәм Пушкин һәйкәлләре, Куприн тасвирлаган «Гамбринус»

шәраб подвалы, Потёмкин баскычы, кәстәнәле (каштанлы) француз бульвары, ботаника бакчасы һәм Шевченко исемендәге парк — барысы да кызык безгә. Граф Потоцкий сараенда булдык. Анда — картиналар музее. Сарайның җир асты юлы дингезгә чыга. Анда шәраб подвалы һәм шәраб фонтаны булган. Шунда кунак паннар күңел ачып-эчеп утырганнар. Кайберләрен үтереп дингезгә дә агызалар. Хәзер дингез юлын тимер рәшәткә белән томалап япканнар инде.

Дингез портындагы зур-зур теплоходлар: «Моннан да күркәм, тылсымлырак илләр бар!» — дип искәртәләр. Бәлки, кайчан булса да безгә дә берсенә утырырга насыйп булыр әле!.. Дингез буйлап пароходлар артыннан туктаусыз кычкырышып акчарлаклар оча. Бөтенләй бүтән дөнья бу! Без акчарлаклар түгел шул, теләгән җирләргә оча алмыйбыз, канатларыбыз киселгән...

Аннары автобус белән экскурсиягә «кояшлы» Молдавияга киттек. Молдавиянең элекке мәркәзе Тираспольда мамалыга ашап (кукуруз ярмасы боткасы), тамак ялгап алганнан соң, Кишинёвка юнәлдек. Молдавия башкаласының урамнарын, кибетләрен карап, базарына кереп, үзәк ресторанында ашап, универмагта Мәрзиягә җәйге күлмәк алып, кичке ашка шифаханәгә кайтып киттек. Бик күңелле булды. Кишинёв безгә үзенчәлекле яклары белән бик ошады. Бөтен җирләрендә бар нәрсә дә ике телдә язылган. Татарстанга үрнәк! Бу юлы да Кишинёв һәм Одесса универмагында, данлы «Привоз»ларында затлы кием-салымнар, әйберләр алдык, хәтта модага керә генә башлаган торшерга хәтле!

Ялыбыз бик файдалы узды һәм күңелебездә тирән тәэсирен калдырды. Егерме дүрт тәүлектән соң, бирегә тагы да килергә күңел куеп, тазарып, үзебезнең оябызга кайттык. Ярый әле ял йортлары вә шифаханәләре бар безнең ише ябык шәһәрчекләрдә, башка дөньядан аерылып гомер кичерүчеләргә!

## Мин — өлкән табиб

Шул елда полковник Наугадовны очратып, зуррак урынга күчерүен сорадым. Мондагы хезмәтнең әһәмияте беткән иде инде. Байтак тәҗрибә туплагач, олырак эшләр башкарасы килә. Сәләтемне тоеп торам. Аннары званиемне дә үстерәсе бар бит әле. Начальник миңа: «Хабаровскиның арьягында, «51нче километрда» өлкән табиб урыны бушый. Шунда тәртипле хезмәт оештыра алсаң, килештек дигән сүз!» — диде. Менә ул, башта ук үземә билгеләнгән урын, насыйп булгач, үзеңә кире кайта! Наугадов: «Власовны беләсеңме, ул синең сыйныфташың бугай?» — дип сорады. Белмәскә, ул бермәлне сыйныф партоешмасын да җитәкләп алган иде. Яхшы укыды. Тыныч фигыльле, болай булдыклы күк тә күренә иде. Менә шуның лазаретында ятучы ике солдат, төнлә аптекасын талап, эчеп, агуланганнар икән. Тикшерү башлана, тиешле чараларын күрмәгәне һәм җавапсызлыгы өчен Министр приказына эләгә һәм эшеннән түбәнрәк төшерелә Власов. Җитмәсә әле: «Миндә америка частенең штаты булса, алай булмас иде!» — дип тә акланган икән. Бу сүзләре тикшерүчегә аеруча ошамаган. Үз эшенне оештыра алмаганда, дошман армиясенә ишарәләү ни пычагыма кирәк булган инде!

Наугадов әйтүенчә, 51енчедә яшь медицина офицерлары эшләре турында аз уйлыйлар, күбрәк Хабаровскига барып күңел ачып йөрергә яраталар икән... Анысын һәм башкасын да ничек тәртәләренә кертеп, җайга салу әмәлләрен беләм мин. Менә шулай, язмышым мине тагы шул якка тарта. Фатир мәсьәләсен белештем. Анда инде берничә биш катлы йорт салынган икән. Шулай булгач, тәвәккәлләп ризалыгымны бирдем. Ник дисәгез, ул якның табигате, ел фасыллары бу җирнекенә караганда күпкә әйбәтрәк — йомшак. Анда Яна

елга хәтле диярлек озын, коры вә җылы көз. Тайгада кыргый йөземгә, кедр чикләвегенә хәтле үсә. Хабаровск базарының Свободныйныкыннан аермасы бик зур. Азык-төлек белән тәэмин итүләре дә мулрак. Олы шәһәр тирәсендә тормыш шәбрәк җайга салынган була. Кирәк икән, барып кайтырга да мөмкин ич. Аннары иң мөһиме, вакыты житүгә, майор да булып куясың. «Майор» латинчада «зур, олы» дигән сүз. Өлкән офицер разрядына керә. Майорның хезмәт халәте һәм айлык акчасы бөтенләй бүтән. Мәрзияне дә истән чыгарырга ярамый. Яшәгән җиребездән аның күнеле тәмам бизгән иде инде.

Наугадов киткәннән соң, командующийның яңа урынга билгеләү боерыгын байтак көтәргә туры килде. Наугадов кеше мәнфәгатьләрен юлларга ашыкмый иде. Җиде тапкыр үлчәп, бер кисә. Үшәнрәк тә иде. Мәгълүм ки, көткән кешегә һәрчакта озак тоела. Беренче кар явып, ката башлаган җиргә ята башлагач кына, ниһаять, кирәкле боерык килде!

Хәбәр алуга куанышып, әйберләребезне җыеп, күчү эшенә керештек. Безнең илдә гади кешегә унай шартлар буламы соң? Станциябез янәшәдә генә булуга карамастан, контейнерлар бүтән — Бузули станциясендә — егерме чакрым арырак. Әйберләребезне йөк машинасына төяп, шунда киттем. Бузули әле ул ярымстанция генә. Элек анарга карауны да булмагандыр. Арырак, урман эчендә ниндидер бәләкәй ял йорты сыман нәрсә бар. Әллә инде түрәләрнең ау йортлары? Малыбызны контейнерга бушатып, әйләнеп кайттым да, кирәкле әйберләребезне алып, Мәскәүдән Хабаровскига узып барган поездга утыргач кына тынычландык. Менә йөк вагоннары белән тулган, щебёнка өемнәре белән күмелгән Ледянаяны калдырып, Свободный — Серышево — Поздеевка — Возжаевка һәм Белогорскка да уздык. Поезд төн карангылыгына кереп бара. Арып беткән гәүдәләрне йокы басты. Таң атканда без инде Хабаровскига килеп життек. Ашыкмый гына төштек. Ашыгунын кирәге юк. Иялэшергә кирәк. Камыт бераз көтеп торса да, беркая китмәс. Мәрзиягә каланы күрсәтергә кирәк. Рестораннарда сыйланасы бар. Андый бәхет сирәк очрый. Такси яллап, кунакханәгә илтергә куштык. Ярыйсы гына кунакханәгә урнашканнан соң, тамак ялгарга һәм каланы карарга чыгып киттек. Биредә җылы иде әле. Чаганнардан яфраклар да коелып бетмәгән. Кәеф күтәрелде. Табигатьнең тәэсире зур шул.

Гомеремнең тагы яңа сәхифәсе ачылырга тора. Мин ул ак тормыш битен пычратмый гына язып тутырачакмын!.. «Ерак көнчыгыш» исемле ресторанда иң татлы ризыкларын алып ашадык. Шулар арасында маринадлы трепанг салаты аеруча тәмле иде. Ул ак гөмбә яки тозланган гөрәждә сыман ашамлык, «диңгез кыярларыннан» хәстәрләнгән нәрсә. Үзе женьшень тамыры кебек шифалы. Инде менә нихәтле вакыт узуына карамастан, тәме һаман исемдә. Кибетләрдә эре Амур балыклары, башка тәм-томнар. Халык урамнарны тутырып киноларга, стадионга, базарга, Амур ярына агыла. Укучы шәкертләр вә интуристлар байтак. Менә кайда халык яши икән ичмасам! Без дә шәһәрне кызыксынып карап йөрдек. Киң, мәгърур Амур буена бардык. Таш белән ныгытылган яр буенда озак сокланып карап тордык. Арырак, югарыда — крайком кунакханәсе. Аргы якка кечерәк теплоход йөри. Биредә нихәтле ял йортлары, күнел ачарлык корылмалар төзергә мөмкин. Рейн буйларыише генә булмас иде! Куллана белмиләр шул. Үзләренә житкәч ярый инде...

Биредә язучы, ау остасы В.Арсеньев яшәгән, край китапханәсендә мемориал тактасы бар. Аның «Дерсу Узала»сын укымаган кешеләр әздер дип беләм. Япон Акира Куросава төсле киносын да төшергән иде. Бу якларда Иван Арамилев та булган. Аның «Солёная падь» хикәясен бик яратып «Новый мир» журналында укыган идем.

Без шундый инде: үзебезнекеләрне юньләп белмәсәк тә, ятларны ярыйсы гына беләбез.

Монда байтак кызык кешеләр яшәгәннәр һәм яшиләр.

Хәтта атаман Семёновның якын дусты язучы Васильевның да гөнаһларын кичереп кайтардылар!.. Харбинда яшәгән булган. Ә ул «Харбин» дигәннәре хәрбиләр сүзенә килә бугай...

Возжаевкадан һәм Ледянаядан соң әкияти дөньяга кергәнбез кук тоелды. Бузули — «боз иле» түгел инде. Сулуларыбыз иркенәеп китте. Шәһәр безгә ошады. Монда яшәргә була! Ләкин безнең яна торыр урыныбыз арырак, урман эчендә, чебен-черкиләр дөньясында. Ул дөньяда — Коры Этәдә яшәгәнем бар, күнегәсе түгел... Әлегә канатланып, читлектән ычкынып котылган кошлар сыман, берничә көн булса да, рәхәтләнеп ирекле кешеләр арасында яшибез. шулай, кайчакта дөнья безгә дә елмаеп куя. Күңелләребез гел юньле калада яшәргә омтыла. Шәйләгәнегезчә, замана чиреннән икебез дә азат түгел. Кайчан булса да бәлки теләкләребезгә ирешербез әле. Өметебезне өзмик. Өметсез — шайтан, диләр.

Берничә тәүлектән соң, телефон аша хезмәт итәсе урыннан машина чакырттым. Ике сәгатьтән «УАЗ-450» белән полк медпункты начальнигы капитан Гарновский безне алырга килеп житте. Таныштык һәм утырып шәһәрдән, вокзал янымнан борылып чыгып киттек. «Тугызынчы чакрым»нан (элемтә полкы урнашкан жир), Кара елганы, Волконканы (сөрелгән декабрист утары) һәм Апастасьевка авылын узып, «51нче чакрым»га килеп төштек. Калкулык сыртында селикат кирпечтән генә биш катлы дүрт йорт салынган, астарак бишенчесе төзелеп ята. Фатир житмәгәнлектән, байтак офицерларның гаиләләре әле Хабаровск кырыендагы бер баракта яши. Инешнең аръягында — стройбат шәһәрчеге. Салына башлаган йорттан түбәнрәк бер чакрым узсаң, округның элемтәчеләр ротасы, алардан арырак шактый зур күл һәм аннан да арырак Амурның борылышы. Анда балыкчы нанайларның авылы. Тирә-юньдә урманлы калкулыклар. Ул калкулыкларны монда «сопкалар» диләр. Вакытлыча урнашырга дип бишенче катта бер бүлмәле фатир тәкъдим иттеләр.

Беренче каттагы ике бүлмәле фатирдан майор Сёмин топчан менгезде. Анда гаиләләр өчен медпункт кебек нәрсә һәм шунда хатыны — табибә эшли икән. Алар икесе дә — дивизия штатыннан. Дивизия штабыбыз Биробиджанда урнашкан. Ире монда дивизия ОКС бүлегенең махсус күзәтүчесе, стройбатка тиешле биналар эшләтә. Санинструкторлар урындыклар һәм утын керттеләр. Фатир — мичле, ә ванна бүлмәсендә су жылытырга титан куелган. Аны да ягып жылытасы. Мәрзия беренче катта, ике бүлмәле фатирда урнашкан кибеткә азык алырга керде. Ә мине Гарновский командир һәм табиблар белән танышырга алып китте. Ул Ленинградның Беренче мед.институтта хәрби факультет тәмамлаган, Тын океан флотында хезмәт иткән, минем яшьтәге жор белорус. Ике кызы бар. Сугышчан әзерлектә торучы дивизионнарыбыз арырак, урман эчендә — сопкалар арасында. Казармалар, дивизион медпунктлары, ракета ангарлары һәм аларның жибәрү өстәлләре дә шунда. Полк штабы вакытлыча беренче дивизионда, ә аның КПсы бирерәк. КП яртылаш жиргә күмелгән бетон бункер булып чыкты. Өстән кәзләр белән капланган. Командир бункерда иде. Кагыйдә буенча, рапорт биреп таныштым.

Командир — подполковник Пунков. Ул да монда яңа кеше. Юаная башлаган тыгыз бәдәнле, сөйләшергә жайлы урыс. Пунков элек мотопехотада комбат булган. Соңыннан Мәскәүнең Фрунзе исемендәге командирлар академиясен тәмамлаганнан соң, ГДР армиясендә киңәшче вазифасын үтәгән. Бирегә килгәнче Галициядә урта ракеталар полкында командир урынбасары булып та өлгергән.

Шактый тәҗрибәле, хезмәтчән кеше. Теге бишенче йортка, подъездның икенче катына урнашканнан соң, гаиләләребез белән дуслашып та киттек. Ике укучы кызлары бар иде. Үзе авыл малае, Вятка ягыннан бугай. Сугышта да бераз катнашкан. Анардан кайбер кызык мәгълүматлар ишетергә туры килде.

Үзе сөйләгәнчә, Мәскәүдә укыганда, аңарга маршал Будённый белән бер очрашуда булырга туры килгән. Академия тыңлаучыларын һәм курсантларны ул чакларда мәҗбүри рәвештә «очраштыру» гадәте бар иде. Шул очрашуда Будённыйның «Үткән юл» китабының икенче томы чыгу уңаеннан, укучылар белән фикер алышу уздырылган икән. Шунда карт маршал, кызып китеп: «Мин боларны да кылыч белән чабып, тегеләрне дә тураклап тар-мар иттем!» — дип сөйләгәндә, залдан бер казак сугышчысының тавышы ишетелә: — «Сэмэн, син берүзең генә тураклаганда, без кайда булдык соң?» Маршал мин-минлеккә бирелеп арттырып җибәргәнен абайлап тынып кала. Аңарга сораулар бирә башлыйлар. Залда тагы картайган, отставкадагы өлкән офицер торып: «Семён Михайлович, әйтегез әле, зинһар, 37нче елда сез безне ни өчен утырттыгыз?» — дип сораган. Будённый, дорфаланып: «Ни өчен утыртканны мин шәп беләм, ә менә нигә чыгарганнарын әле дә аңлый алмыйм!» — дигән. Ул байтак нәрсәләрне аңламый калган, ахры. «Ә маршал Тухачевскийны нигә аттырдыгыз?» — дип сорау бирүчегә дә: — «Тапкансыз, ниткән маршал булсын ди ак пирчәткә киеп йөрүче һәм скрипкада уйнаучы адәм?» — дип җавап кайтара.

Күрәсең, фикерләре белән Бериядан артык аерылып тормаган ул. Ә без сабый чакларыбызда «Пионерская правда»ны укып, Ворошилов һәм Будённый белән горурлана идек. Алар турында матур җырлар җырлый идек. Ә алар исә бик күп кенә күренекле хәрбиләрнең башларын сатканнар! Бермәлне ракета гаскәреннән егерме алдынгы солдат-сержантларны җыеп, хезмәтләрен хуплап, Будённый белән очрашырга дачасына алып баралар. Ул аларны аталарча кабул итеп, байтак сөйләшә, атына атланып, кылычын да айкап ала. Атсыз яшәми икән! Солдатларга тәэсире көчле була: частьларга кайтып, очрашулары турында башкаларга да сөйлиләр. Андый тамашалар хәрбиләрне патриотик тәрбияләү максатыннан оештырыла да инде. Шул ук чорда РВ гарнизоннары буенча Главпурдан махсус лектор вазифасын үтәп, үз вакытында бик данлы Соколов-Соколёнок фамилияле генерал йөри иде. Ул — Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары каһарманы. Ниләр белән генә бүләкләнмәгән! Батырлыгы өчен яшь вакытында ук «Соколёнок» кушаматын такканнар...

Пунковка мин ошадым булса кирәк, моны беренче минутлардан ук сиздем. Соңыннан да ул мина ышанып, һәрчак ихтирамлы булды, бер ниятемне дә кире какмады. Командир белән бердәмлектә хезмәт итү бик мөһим нәрсә. Моны башкалар да күреп, «мыекларына чорныйлар». Хәзер инде Пунков — отставкадагы генерал. Ракета гаскәре илгә күп кенә генералларны үстереп бирде.

Полкыбызда ике дивизион. Өченчесен оештырмаска булганнар. Дивизионда урта ракеталар белән коралланган өч батарея. Алар АКШның Окинаводагы хәрби базаларына төбәлгән. Билгеле, бу бик зур серне кайбер офицерлар гына беләләр һәм ул хакта сүз йөртмиләр. Дивизионның штабы, клубы, казармалары, вакытлы медпункты стройбатлардан калган җыелма агач щитлардан корылган. Ашханә — кирпечтән. Медпункт һәм ялгыз офицерларга ике катлы тулай торак салына башлаган. Әлегә полк медпункты да дивизионныкы белән бергә. Штат белән шунда таныштым. Икенче дивизионның табибы — минем сыйныфташым лейтенант Александров, ә беренчесенеке — лейтенант Стецюк, кече табиб — лейтенант Глятман, РТБ табибы — капитан Бескоровайный. Ике фельдшерыбыз, аптека начальнигы, шәфкать туташлары, лаборантка һәм

санинструкторыбыз бар. Теш табибының урыны буш. Менә кемнәр белән идарә итеп хезмәт итәсе.

Полк штабы, складлары, автопарк, полк медпункты (ПМБ), клуб, кунакханәсе, балалар бакчасы салына башлаган. Сигезьеллык мәктәп әзер. Болар барысы да шәһәрчегебез кырыенда. Унайлы.

Стецюк академиябезне яна гына бетергән хохол, нииндидер совпартократлар улы. Бескоровайный Куйбышев мединститутының хәрби факультетын тәмамлаган. Глятман — Махачкаладан. Хәрби хезмәттә яна кеше. Бескоровайный монарчы Сахалин утравында — Корсаковода, мотопехотада хезмәт иткән. «Бездә кызыл балыкны этләр дә ашамый иде!» — дип сөйләде. Аны невхлар кышка киптерәләр һәм «юккола» дип атыйлар икән. Стецюк аның белән дуслашкан, авызына гына карап тора. Гарновский белән килеп кергәндә, алар гына түгел, машина йөртүче солдатларга хәтле мине күтәп утыралар иде инде һәм барысы да бердәй сынаулы күзләрен мина текәделәр.

Халык байтак икән. Бескоровайныйның санитар машинасыннан гайре берние юк. Ул да полк медпункты муенында. РТБ солдатлары дивизионнарда. Аларны дивизион медпунктлары тәэмин итә. Шулай булгач, ул минем карамакка керә. Ни уйлаганнарын сизенәм. Кызыксыналар, шикләнәләр. Начальниклары бит! «Ярый, эшебез уртак, бер-беребезне анлашып, йөкләнгән бурычларыбызны төгәл үтәп, яхшырак хезмәт итәргә тырышыйк!» — дим. Шулай дими, ни дисен? Болар белән берләшеп, җиннәрне сызганып җигеләсе генә кала. Хәзер мин алар өчен дә җаваплы кеше.

Танышып, сүзне кыска тотканнан сон, җыенны тараттым. Александров санитар машинасына утырып, ун чакрым арырак урнашкан дивизионына китте. Аннан да арырак округ штабының яшерен запас КПсы гына.

Полкның халәте анлашыла башлады. Биредә майтарасы эшләр чамасыз күп икән. Казык кагудан башлыйсы дисән дә ярый. Хәрби медикларның беренче планда күпкырлы профилактика мәсьәләсе тора. Офицерлар һәм солдатларның саулыкларын тикшереп, тиешенчә тазарту чараларын күрәсе, гаилә әгъзаларына да ярдәм итүне үз өстебезгә аласы бар, чөнки гади генә инъекция-процедураларга 65 чакрым йөрмәсләр ич инде! Ин мөһиме, йогышлы чир эпидемияләреннән саклану. Кизү торучы частьны эпидемия аягыннан екса, Алла сакласын. Аннары, мондый частьларда зарарлы һәм хәтәр эшләр байтак. Аларны үткәргәндә, ул-бу булмагае дип даими күз-колак булып торырга кирәк. Барча бина-объектларны безгә стройбат төзи. Өйрәнчек солдатлары кайбер эшләрен миннән киткәнче, иясенә җиткәнче дигәндәй аннан-моннан гына әтмәллиләр. Медпунктларыбызның ничек төзелүләрен дә даими күзәтеп торырга туры килә. Авыз ачып калсаң, аннары иза чигүең ихтимал. Билгеләнгән көнгә тапшырасы эшләре төгәлләнмәсәләр дә, актларына кул куйдыртмакчы булып маташалар: «Аннары бетерербез!» — дип. Бетерерләр, көт! Нык торырга туры килә. Өч яна медпунктка округ медокладыннан тиешле җиһазлар, прибор-аппаратлар яздырып аласы бар. Ашханәләрнен, казармаларның, өч шәһәрчекнен арулыкларын кайгыртып тикшереп торасы бар. Өлкән табиб үз өлкәсендә ул милиционер да, прокурор да, эпидемиолог та, эшләрне оештыручы җитәкче дә! Бөтен башкарасы эшләрне күз алдына китерәм дә хезмәттәшләрем белән башкарып чыга алуыма нык ышанам. Ниятләрем пакь, белемем һәм тәҗрибәм җитәрлек. Зиһенемне җыеп, көчемне туплап, сынатмаска кирәк дим. Хәерле сәгатьтә!

Яна кешене күтәп кенә торган сыман, эшлисе эшләре бигрәк күп җыелган. Элекке өлкән табиб Ушаков (флот медицинасы офицеры) бүгенгесен һәм иртәгесен кайгыртып баш ватып маташмаган. Моннан ычкыну ягын гына

караган. Әйтерсең, бүтән җирдә эшләргә кирәкми! Ахырда, җаен табып тайган. Җитәкчеләренә карап, башка медофицерлар да юлдан язып беткән диярлек. «Солдат йоклый — хезмәт бара!» — дигән яраксыз әйтемгә буйсынып. Үзләрен ялыктырмый-борчымый яшәргә тырышканнар.

Кичке алты җитүгә, беркемнән дә рөхсәт алмыйча, Александров, санитар машинасына утырып, хатыны янына Хабаровскига, ә аның артыннан өйләнмәгән Стецюк трай типтерергә элдерәләр! Гаиләсе монда булса да, Бескоровайный да алардан калышмый. Дивизионнары һәм РТБ табибларсыз кала. Ул-бу килеп чыкса, аларны эзләп табып кара! Икенче көнне арып-талып, еш кына махмырдан да арынып бетмичә, сәгать тугызга-унга дивизионнарына көчкә килеп җитәләр һәм ял итеп алу форсатын эзли башлыйлар. Ә инде якшәмбе ялына шимбәнең төшке ашын ашагач ук ычкыналар. Бу инде калганнарның җилкәләренә салыну дигән сүз. Катлаулы медицина вазифалары фельдшерларына һәм санинструкторларына кала. Ә алар инде чамалы белемнәре җиткәнче генә булдыралар һәм еш кына миңа шалтыратырга мәҗбүр булалар, чөнки фатир телефоны миндә генә. Гарновскийның һәм Глятманның телефоннары юк. Миңа артыгыннан көчкә килә. Төнлә дә тынгылык юк. Бескоровайный исә, хезмәткә китәсе никрут егет кебек мутланып, кунак рәвешендә яши. Аның РТБ солдат-офицерлары безнең әзер ашханә, медпунктларга беркетелгән. Аларны тәэмин итү дә безнең җилкәләрдә. Жора Бескоровайный байтак вакытын Стецюк белән беренче дивизионда үткәрә һәм эш вакыты дип тормый, аракы чөмергәли. Стецюкны да шул тәмам аздыра язган. Кызурак Гарновский боларны җиргә алмый аптырап йөри. Әчелешле буласы да килми. Кушканын кече табиб Глятман гына карышмый эшли. Анысы да инициативасыз. Наугадов: «Аларны «кулга» ала алырсыңмы?» — дип тикмәгә генә сорамаган икән. Өч «УАЗ» (РТБныкы белән) һәм бер «ГАЗ» санитар машиналарының бер генә көпчәгендә дә шомарып тузмаган покрышка юк! Машиналарны аяусыз үз мәнфәгатьләренә арлы-бирле йөгертә-йөгертә, еллык лимитларын ярымзаяга сарыф итеп, тәмам җимерелер хәлгә җиткергәннәр. Автобус йөрүенә карамастан, үзләренең шәхси машиналары урынына кулланалар. Кинәт каты чирләп киткәннәргә ашыгыч ярдәм күрсәтү хезмәте тәртипкә салынмаган. Санинструкторлар шундый мәлләрдә табибларын эзләп интегәләр. Гаилә әгъзалары — олысы да, кечесе дә, бер Семён карамагына калдырылганнар. Теш табибына һәм башка белгечләргә күрсәтер өчен авыруларны көн дә икешәр машинага утыртып Хабаровскига — хәрбиләр поликлиникасына, ямщиклар хәленә төшеп илтәләр. Анда барып кайтырга теләүчеләр чиратка языла. Чират кыскармый. Хатын-кызларны гинекологка күрсәтергә дә, бала табарга да калага илтәләр. Биредә мондый эшләрне җайга салыр өчен бернинди чара табылмаган. Шулай булырга тиеш тә дип уйлыйлар. Рентген, ЭКГ, гаиләләр өчен аптека һәм балалар бакчасы — берсе дә юк. Боларны барысын да башымнан вә күңелемнән үткәреп, авыр шартларны җиңеләйтер, эшләребезне җайга салыр, унай чаралар тудыру әмәлләрен эзли башладым. Бер атна үтүгә, барысына да төшендем. Нидән башларга соң? Әлбәттә, тәртиптән! Корыч тәртип урнаштырмасаң, берни дә майтарып булмас!

Шундый карарга килгәч, беренчедән, берсен дә рөхсәтсез Хабаровскига чыгармаска булдым. Берәр ракеталары, йә ягулыклары шартлап китүе, йә сугыш башлануы бар, ә алар урынсыз бәйдән ычкынган айгырлар күк калада иһаһайлап чабып йөрсеннәр! Кашык ашаганда кирәк була ул. Частьлары монда булгач, алар да биргә булырга тиеш түгелме? Бу ниятемне катгый рәвештә шунда ук гамәлгә ашырдым. «Яна себерке»нең себерүе кайберәүләргә ошамаса да, нишләмәк кирәк? Безне монда, акча түләп, уен уйнар өчен җыймаганнар бит!

Александров рөхсәтсез санитар машинага утырып Хабаровскига китеп

карады-каравын. Ләкин финанс бүлеге аша машина һәм бензин өчен акчасын каертып алганнан вә шелтә биргәннән соң шып тынды. Бу бүтәннәргә дә шәп сабак булды. Нигә әле житлеккән кешеләрне нәни балаларны үгетләгән күк төчеләнеп йөрергә ди? Алар бит рәсми урыннар белән торалар һәм нинди вазифа йөкләнгәнен беләләр. Икенчедән, санитар машиналарны, шул исәптән РТБныкын да, турыдан-туры үз карамагыма алдым. Аларның табиблары белән кизү тору графикларын төзеп, командирга кул куйдырдым. Шуның белән моннан ары тәүлек буена автопарктан машиналарның берсен генә чыгарырга рөхсәт ителде... Яна тәртип урнаштыргач, РТБ командиры полковник Наумов: «Безнең УАЗ ватылган, график буенча кизү торырга бирә алмыйбыз!» — дигән булган иде. Ләкин мин, бер дә исем китмичә: «Ярар, алайса, авыруларыгызны ашыгыч рәвештә госпитальгә илтергә үзегезнең жинел машинагызны бирерсез!» — дигәч, алмашка урын-урынбасарларының машинасын бирергә һәм УАЗны кичекми автозаводка төзәтергә озатырга мәжбүр булды. Шунда Бескоровайныйны үз санитар машинасына хужа була белмәве өчен сүктем. Өченчедән, икенче дивизион машинасын төзәтергә жибәрүен, яна УАЗга вә покрышкаларга заявкалар юллавын сорадым. Кешенең гомере кыл өстендә булганда, машинаң ватылып, юлда тукталса нишләрсең? Адәм гомере белән шаярырга ярамый бит! Дивизиядән покрышкаларны төрле сылтаулар табып бирмәскә маташканнар иде. Алар анда яналарын ялагайланып начальствоның «газик»ларына куярга тырышалар, вакытлары чыкмаса да.

Хәрби округның «Суворовский натиск» (без аны «суворовский нажим» дип атый идек. Редакторы яһүд Шапа иде) гәжитенә усал мәкалә язгач, Биробиджаннан дивизиянең авто-трактор бүлеге начальнигы көпчәк резиннарын машинага төяп үзе китермәсенме!

Дүртенчедән, моңарчы биредә булмаган хәлне — табибларның тәүлекләп график буенча кизү торуларын гамәлгә керттем. Анысын да Пупков хуплады. Үземнән башлап, һәр офицер (алты кеше) башта беренче дивизион медпунктында, ә соныннан ПМБда тәүлекләп кизү тора башладык. Берең кизү торганда, калган бишебез төнлә тыныч йоклый. Йөкле хатыннарны бала табаргамы, берәрсенә ашыгыч операция ясатыргамы, кизү торучы табиб, карап, калага илтә. Мондый хәлләр язылмаган кагыйдә буенча, күбесенчә төнлә булалар. Кайбер төнне округ госпиталенә (60 чакрым) икешәр мәртәбә барырга туры килә. Шул сикәлтәле юлдан мина башка йомышлар белән дә күп мәртәбә, буыннарымны какшатып бетергәнче йөрергә туры килде. Ә өлкән табибның йомышлары күп була. Госпиталь юлын да таптыйсың, округның мед.бүлегендә дә, корпус штабына Науганов янына да, крайздравотделына да барасың. Әле мин килгәндә, полкыбызның бер өлеше елдан артык Князе Волконскоеда аерым хужалык булып яшәде. Аларга да байтак күз-колак булып йөрдем. Князе-Волконское белән полк арасының юлын жәй вакытында мина берничә мәртәбә командир аша грейдер белән тигезләтергә, ә кышын көртләрен кырдыртырга туры килде. Ул юлның газабын байтак күрдем. Бермәлне, кыш уртасында Князе-Волконскоега житәрәк, бер бичара хатынга, кендек әбие булып, бала табарга булыштым. Төн уртасында беренче йортның ишеген кагып, баланы сөртеп-биләп, анасына тазартып, чәй эчереп, юлыбызны дәвам иттек. Андый очракларга машинабызда аерым сандыкта бөтен кирәкле әйберләребез анык иде. Кышын һәр санитар машинага хәтта берәр бәйләм коры утын да салдырта идем! Юл хәлен алдан шәйләргә кирәк ич!

Әлегә һаман бишенче катта яшибез. Багажыбыз да озак көттермәде. Әкренләп гарнизонда медицина эшләребез жайланды. Моны сизми калмаган кеше булмагандыр. Табиблар үзләре дә канәгать иделәр. Заводтан озатылган

машиналарыбыз да яңарып кайтты, беренче дивизионга янасын да бирделәр. Тәртип булганда, барысы да үз нәүбәтләрендә эшләнә ул!

Бишенче мәсьәләне дә хәл итәргә керештем. Офицерларны һәм солдатларны — елына ике, гаилә әгъзаларын бер мәртәбә рентген аша үткәрергә кирәк. Бу эшне башкарыр өчен округның ПРКсын (подвижный рентгенткабинет) сорап китерттем. Ләкин ул елына бер тапкыр гына килә ала. Анда да сиңа кирәгенчә торып эшләми. Округта бер без генә түгел бит! Бүтән чара табарга — үзебезнең рентгенкабинетны булдырырга кирәк, дим. Ничек инде хәзерге заманда рентгенсыз яшисең ди? Аның бик кирәк чаклары була. Планнарым зур, вакыт һәм саулык кына житсә иде!

Округ госпиталенең житәкчеләре белән сөйләшеп, кече табиб Глятманны рентгенолог һөнәрен өйрәнергә өч айга рентген кабинетына юлладым. Арон моңа бик риза иде. Яһүдләргә укырга гына булсын! Пупков белән киңәшеп, рентген кабинетының хәстәренә керештем. Үзем урнашкан йортның башында, беренче катта ике бүлмәле фатир бирде. Йортта яшәүчеләргә «х» нурларының зарары тимәсен өчен, фатирның түшәм-диварларын барит измәсе белән сылап акларга кирәк, ә анысы бирәдә юк. Кыйммәт нәрсә. Барит измәсен сорап, РВ штабына яздык. Шакыган кешегә ишекне ачалар. Бер ай чамасы узганнан соң, ул измә белән кечкенә контейнер килде. Аны шунда ук сыладык. Бусы булды. Инде хәзер округ медскладыннан, безгә штат язуы тиеш булмаса да, рентген аппаратын һәм тиешле бөтен җиһазларын баш рентгенолог аша юллап аласы калды. ВМО начмеды һәм баш рентгенолог белән сөйләшкәч, аларны да яздырдым. Гарновский бөтенесен йөк машинабызга төяп алып кайтты. Медтехникадан белгечне чакыртып, аны тоташтырып, җайлап эшкә аныклап та куйдык. Шулай, мәшәкате күп булды. Глятман якшәмбе көннәрендә кайтып, кызыксынып йөрде. Эш урыны анык инде. Ул укудан кайтуга, Стецюкны ЭКГ серләренә төшенергә ун көнгә дип шул ук госпитальгә, ЭКГ кабинетына юлладым. Медпунктларыбыз да төзелеп бетеп бара. Күңелем үсә. Эш артыннан эш. Ә эш бит ул эшләүчене сөя.

Хәзер хатын-кызларны тикшерергә лаборанткасы белән округ гинекологын шәһәрчеккә инәлеп чакырдым. Ул чакта округның хәрби гинекологы кыскартылмаган иде әле. Аңарга бездә хатыннарны ике көн буе карарга туры килде. Авыруларның исемлекләрен төзеп, дәваланырга юлламалар бирдек. Шулай итеп, бик мөһим эш башкардык. Бу байтак хатыннарның исендәдер.

Декабрь башында кулыма «Океанск» шифаханәсенә хатын-кызлар юлламасы эләкте. Теләп баручылар булмагач, Мәрзияне озаттым. Тагы бер дәваланып кайтсын әле ятим үскән бала, дим. Башкаларны гына дәваларга димәгәндер!

Гарнизоныбызда гражданский поликлиникага булмагач, хатын-кызларга алтмыш чакрым юл үтеп Хабаровскига барырга кирәк. Балаларын калдырып, автобуска утырып дәваланып йөрүләре читен. Бигрәк тә кышкы якта. Бу мине дә борчый, уйландыра башлады. Үзем гинекология фәнен академиядә яхшы гына өйрәнгән идем. Бескоровайный хирургия курсында укыган, ә Сёмина эчке чирләр белгече. Шулай булгач, үзебезнең төп эшләребездән тыш, икешәр сәгать һәркайсыбыз хатын-кызларны медпунктта кабул итеп, дәвалый алабыз. Шулай иттек тә. Үз өстемә гинеколог вазифасын һәм горздрав бүлегеннән бер шәфкать туташы штатын юллап алдым. Аңарга аптека базасыннан дарулар китереп сату вазифасын да йөкләдем. Шулай итеп, аптекалы да булдык (аптечный пукнт второго порядка). Ул урынга бер офицерның элек акушерка булып эшләгән хатынын алдым. Шуннан соң беренче тапкыр, хатыннарны кабул итәргә килдем. Ләкин башта алар миңа күренергә оялдылар.

Ишек төбендә җыелып, керергә базмыйча озак кына бер-берсен кыстап

тордылар. Тик бүтән чара юк бит. Ахырда Кустовның хатыны: «Әй, кызлар, безнең ишеләрне күрмәгәнмени ул, ни булса да булыр!» — дип, ишекне киереп ачты. Карадым моны һәм шунда ук шәфкать туташына ни эшлисен күрсәтеп бирдем. Әрсез Кустовадан соң хатыннар бер-бер артлы кызарып, башларын күтәрми генә күренергә керә һәм махсус өстәлгә җәелеп утыра башладылар. Диагнозларын һәм ниләр эшлисен шәфкать туташы яза торды. Кулымнан килгәннәрен дәваларга монда калдырдым, ә калганнарын Хабаровскига юлладым. Бескоровайный да үз сәгатьләрендә кабул итә башлады. Менә шулай шәһәрчегебезнең тормыш хәлләрен шактый җиңеләйттек.

Мәрзия шифаханәдән кайтканчы, яңа гына төзелеп беткән йортның икенче катыннан ике бүлмәле фатир алдым. Фатир бик күркәм. Тәрәзәләре ике якка. Солдатларыбыз белән әйберләрне ташыдым. Күченгәндә йорт әйберләре күп булып күренәләр, эт булып арыдым. Күченгәнче идәннәрен янадан буяткан идем. Фатирның батареялары бар, суык су кертелгән, канализация үткәрелгән. Котельня җылыта башлады. Аш бүлмәсендә плитәле мич. Ванна бүлмәсендә суны титан белән җылытасы. Бәдрәф янәшәдә. Тагы нәрсә кирәк? Рәхәтләнеп яшәргә була. Ишек аша гына Пунков гаиләсе урнашты. Димәк, безнең белән аралашып яшисе килгән! Бу подъездга башкаларны да сайлап кына керткән. Дүртенче катта Горновскийлар, ә бишенчесендә лаборанткабыз Есько ире һәм кызы белән. Бездән түбәнрәк тагы бер йорт салына. Анысы төзелүгә Хабаровскидан бөтен офицерларыбыз күчеп бетәчәк. Сигез сыйныфлы мәктәп беренче сентябрьдән үк эшли. Анда роно аша медпункт ачарга булыштым. ПМП аптекасыннан үлчәү-мазар, бикс, шприц-стерилизаторлар һәм башка кирәкле әйберләр бирдерттем. Анда да шәфкать туташы эшли башлады. Димәк, гарнизонның тормышы бу яктан да җайланды. Клуб, кунакханә, балалар бакчасы, кибет (клубтан гайре барысы да бер бинада) анык диярлек. Шәһәрчегебез күз алдында үсеп матурлана бара. Офицерлар гаиләләре белән танышып, дуслашып киттеләр, бер-берсенә кунакка йөрешә башладылар. Яңа ел бәйрәмен җыелып, Горновскийларда уздырдык. Мәрзия бишенче гыйнварда гына кайтты. Анарга яңа фатирга кайтып керүе күңелле булды. Бераз дөнья күреп, кәефе күтәрелеп кайтты. Керогазыбыз көйләнгән, керосин һәм утын анык. Су җылытып, ваннада юынып кинәнәбез. Искечә Яңа елны каршыларга Владивосток күчтәнәчләре — эре криветка кәнсирләребез бар. Менә дигән салат ясарга була!

Сирәк булса да, якын-тирәдәге балыкчылар яңа гына тотылган балыкларын китереп саткалыйлар. Мәрзия бик теләп ала. Балыкчылар бистәсеннән көздән берничә пыяла савыт тозланган кызыл балык уылдыгын сатып алдык. Ул елларда уылдыкны һәм кызыл балыкны кулдан иркен алып була иде әле. Кибеттә дә какланган һәм тозланган горбуша-кеталарны саталар иде.

Октябрь аенда елгалар шул балыклар белән кайныйлар иде. Көзге путина. Шул чакта балыкны һәм уылдыкны кышка хәстәрләргә бөтен халык диярлек керешә. Шуның белән дан тота да инде бу як. Бескоровайный әйтүенчә, Сахалинда, имеш, кызыл балыкны этләр дә ашамыйлар! Хәзер анда да хәлләр хөртиләнгән дип ишеттем. Үзебезнең хәлгә килгәндә, тозланган гөреҗдә һәм шампиньоннар үзебезнеке. Бәрәңге, кәбестә, помидорлар вә суган — Хабаровск базарыннан. Тик менә кечкенә кибетебездә китергән һәрбер нәрсәләренә чират торырга туры килә. Анысы Мәрзия эше. Чиратларсыз тормышыбызны күз алдына да китерергә мөмкин түгел. Чиратлар — Советлар иленең визиткалары.

Гыйнвар аенда гаиләләребез вә полк җитәкчеләре белән бергә күңел ачарга Хабаровскига Мәскәүдән килгән «Диксилент» концертына бардык. Аның ише эстрада ансамбльләре оешып үрчи башлаган чак. Күңелле булды. Дәртләнеп,

автобусны янгыратып юл буе җырлап кайттык. Сирәк булса да, андый күңел ачтыруларны гарнизоннарда замполитлар оештыргалый иде. Соңыннан, югары командованиенең таләбенә колак салып, мәдәният министры Е.Фурцева әмере буенча, Мәскәү артистлары шактый еш килә башлады. Байтакларын күреп ишетергә насыйп булды. Андый тамашаларны аулак һәм ябык гарнизоннарда хезмәт итүче гаскәриләрнең рухларын күтәрер өчен махсус оештыралар. Үзәк мәдәният сулышын берникадәр тоеп торырга мөмкинлек бирәләр. Тик татар ансамбльләре генә килә алмады. Югыйсә татар яшәмәгән җир юк. Бездә дә манкорт Дамир Белов һәм ГСМ начальнигы Кадыйров хезмәт итәләр иде. Ял көннәрендә, гадәттән тыш берәр хәл булмаса, атнасына бер тансык йокыны туйдырып, шәһәрчек тирәләрендәге урман аланнарына һавага чыгабыз. Зур кала корым-сөремнәреннән ерак булганга күрә, биредә һава саф, сулап туйгысыз, кар чиста, ак төсен югалтмый. Сирәгәеп калган сыман шәрә ялангач урман, төш күрепме, үлеп йоклый, язга яңа хәл җыя. Аның каты йокысын кышларга калган сирәк кошлар да уятмаска тырышалар кебек. Тавышсыз гына агачтан-агачка, куактан-куакка җим эзләп очып йөриләр. Бер генә карлыгач язны китерми дигән кеби, болар да урманны әлләни җанландыра алмыйлар. Йөрәк тибешен ишетерлек тынлык. Җан тынычлыгы, мәңгелекнең агышы... Җирана балаларына гыйбрәтле үрнәк күрсәтеп, борчылып телгәләнгән җаннарын тынычландыра, дәвалый...

Кайтышлый биредә мул үскән сазанак (багульник) куакларының берничә ботак-тармакларын сындырып алып кайтабыз. Суга утыртсаң, өй җылысына алданып, алар берничә тәүлектән соң язны хәтерләтеп һәм бүлмәгә ямь биреп, озынча яшел яфракларын сузалар. Бигрәк гүзәл һәм талымсыз үсемлек. Яз башлануга ук сазанак куаклары барысыннан да алданрак, дөньяга ямь кертеп һәм безне куандырып, зәңгәрсу-алсу чәчәкләрен ата башлыйлар. Әле яфраклары да ул чакта юньләп күренми... Сазанакны мин беренче мәртәбә бу якларда гына күрдем һәм гаҗәпләнеп, аның хакында, сизмәстән тулган күңелемне бушатып, истәлек шигырен дә русча язып куйдым. Укучым гафу итсен инде. Нишләмәк кирәк, барча СССР милләтләренең балаларына урысча тел ачтыра башлагач, ихтыярсыз диярлек урысча уйларга да, язарга да мәҗбүр буласың. «Кемнең арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың!» — диләр бит. Әлбәттә, бу мәкаль белән ансат кына акланып булмас. Манкортларга яраклаша башладык! Ләкин анысы да бушка бугай, чөнки манкортлар русча да юньләп укымыйлар. Маргиналларга бер милләт психологиясе — миллилеге якын түгел. Урыслар үзләре: «Бүреләр өерендә бүречә уларга туры килә!» — дисәләр дә, әйтик, Татарстанда туып-үсеп, татарча сөйләшергә җыенмыйлар. Димәк, ялган интернационализм пәрдәсенә төренеп, урыслар үзләренекен нык саклыйлар. Башкаларны эретеп йоту максатлары аларның геннарына сеңгән. Шул ялган интернационализм хисенә һәм ятлар гореф-гадәтләренә нык бирелүчән татарлар акылга тиз генә утыра алмаслар, ахры.

Кырыкка ярылырга җитешеп йөргәндә, февраль аенда булса кирәк, өйдән тагы бер шомлы хәбәр килде. Унике илле эчәгесеннән каны саркып, атам хастаханәгә эләккән. Хирурглар операция ясарга кыстыйлар икән. Очып кына янына кайтасы иде дә, ләкин мин, монда көттереп яңа килгән кеше буларак, сорап кайта алмадым. Үз ихтыярымда түгел бит. Аннары кайтып нишләтәсең? Ул анда миннән дә тәҗрибәлерәк табиблар кулында. Чиләбенең мединститут клиникасында ята, танылган профессор Вайнштейн һәм мәшһүр доцент Тарасов күзәтүе астында, аны мәрхәмәтле табиб Колонтаев дәвалый... Мөмкинлегем булганча, посылка юнәтеп җибәрдем һәм операция ясатырга ризалыгын бирмәскә куштым. Сонрак янарак чыккан Һинд даруын — викалинны һәм

искергән фарингитын дәваларга шәфталу маен да юлладым. Алланың рәхмәте, озак кына ятып, әти үлем тырнагыннан котылды. Бик авыраеп киткән чагында да: «Үләсең бит, әйдә, операция ясыйк», — дисәләр дә, тартышып ризалыгын бирмәгән һәм, Ходайга шөкер, кан һәм виталинлы сыекчалар салдыра-салдыра бер айдан соң көчкә аягына баса башлаган. Күрәсең, әҗәле житмәгәндер. Табиблар да ул чакларда тиеннәр хисабына эшләсәләр дә, бик миһербанлы иде әле. Бәхетсезлеккә юлыккан бәндәнең кесә-янчык якларын чамалап маташмыйлар иде. Соңгы елларда гына котырына башлады андый гадәт. Ә бүгенге көннәрнең авырлыкларын исәпкә алып, Аллаһы Тәгалә сырхауларга сабырлык бирә күрсен дияргә генә кала!

Әтинең чирләп киткән көннәрендә борчылып беттем, жан тынычлыгымны тәмам җуйдым. Шуннан бирле әтинең һәм әнинең кинәт үлеп китүләреннән куркып яши башладым. Телеграммаларын алудан һәм шалтыратуларыннан өрки идем. Нервыларым шулхәтле какшады ки, өйдә телефон кыңгыравы шалтыравыннан сискәнеп китәм. Шундый «бетле йөрәк» булгач нишләмәк кирәк? Ә ул өлкән табибның хәерсез телефоннары эштә һәм өйдә дә йөдәтеп бетерәләр иде. Халкың шөбһәләнүчән булгач, үзенне үзгәртүе һәм авызлыклап кулда тыеп тотуы кыен шул. Шуның өстенә бихисап хезмәт борчулары да өстәлә ич. Вакуумда яшәмибез ләбаса!..

Монда да, гадәтләнгәнчә, офицерлар үтә кызыксынып, кыска дулкыннарда Япониядән рус телендәге радиотапшыруларны тыңлыйлар. Япония моннан тагы да якынрак. Японияненң радиотапшырулары безнең өчен эшебездән соң, кичке якта була иде. Тапшыруларны һаман да шул Момура ханым алып бара (псевдонимы булды микән?). Бераз гүзәл музыка яңгыратып алганнан соң, ул көр, матур вә ягымлы тавышы белән, «р» хәрефен бераз японнарча сакаурак әйтеп: «Говорит Момура!» — дип, күңелне күтәреп җибәрә. Булыр икән игътибарыңны җәлеп итә торган шундый да сөйкемле тавыш! Бер ишетүгә үк яратып куясың. Иляләшә дә башлыйсың. Бездәге хәлләрне шактый шәп белүләре гаҗәпләндерә. Хәбәрләр аралаш йә илаһи музыка, йә үзәкне өздерерлек җыр агыла. Тапшырулар булса, менә шундый булсын икән! Сонрак, СССР хәлләре турында хак мәгълүматларны ишеттермәс вә безне «дошман пропагандасына» бирелдермәс өчен шушы тапшыруны «Америка тавышын», «Биби-Си», «Азатлык», «Европа» тавышларын томалый башладылар.

Аларның дулкыннарына, колакларны тондырып, илледән артык томалаткыч эләргә керештеләр. «Кеше авызын томалап булмый!» дигән булалар да бит. Авызларны гына түгел, колакларны да томалап кыландылар. Ул хәтле томалаткычны эшләтергә нихәтле акча һәм тулаем «Днепрогэс» энергиясе — 850 млрд квт сарыф ителә торды. Бу хакта бер әйткән идем инде. Без хәерчелеккә төшми, кем төшсен!

Ә менә безнең өчен оештырылган Кытай тапшыруларын һич тыңлыйсы килмәде. Алар бигрәк примитив иде. Хәзер ничектер, ишеткәнем юк.

Франкларның узган гасыр язучысы Лессаж саңгыраурак булган. Тыңларга көмеш колак бурәнкәсе йөрткән. Кызык түгел кешене тыңлыйсы килмәсә, бурәнкәсен колагыннан алып кесәсенә салган. Менә шулай, тыңламау үз ихтыярында булырга тиеш ул. Элек лыгырдык Н.Хрущёвны һәм авызында коры ботка пешерә башлаган Л.Брежневны соңгы елларында тыңлатсалар да, тыңламый башлаган идек. Кем ничектер, ә мин ялганчы Б.Ельцинга да игътибар итмәдем. Сүздә бер, ә гамәле икенче иде. Әйтерсең, икейөзле Янус! Без бит нәни балалар түгел ялганны чынлыктан аермаска. Хәзер исә кечкенә «ахырзаман» балаларын да алдый алмассын!..

Яна клуб салынып беткәч, кичләрне һәм кайчакларда бәйрәмнәрне дә

шунда уздыра торган булдык. Эчемлекле мәҗлесләр ул чакларда ничектер тыелмый иде. Үзешчән концертларга да катнашкаладык. Кабатланмас яшьлек галәмәтләре...

Илебезнең ышанычлы вә тотрыклы имән баганасына, ә Ракеталы көчләребезнең төп көч-куәтенә әверелгән ракета гаскәре үсеп, бөтен өлкәләргә диярлек тамырларын җәйгәндә, аңа солдатлар җитми башлады! Мәгълүм ки, сугыш елларында һәм нужалы сугыштан соң балалар, бигрәк тә ир балалар әз тудылар. Хәзер менә шуның нәтиҗәсе үзен нык сиздерде. Яшьләрне житлегеп бетмәстән — унсигез яшьтә армиягә алырга дип карар чыгарсалар да, барыбер хәтсез үсә башлаган Ракеталы Көчләрнең ошбу тармагы тишекләрен алар гына каплый алмады. Менә шуны исәпкә алып, телефончы-телеграфист, хисапчы, санинструктор һәм бүтән шундыйрак урыннарга кызларны алырга мәҗбүр булдылар. Яз көннәрендә безнең полкка да сиксәннән артык кыз алынды. Гаҗәпләнергә туры килми, Израильдә күптәннән бирле ирләр белән бер сафта хатын-кызлар берәр ел хезмәт итәләр бит. Башка илләрдә дә, әйтик, АКШта, андый үрнәк бар. СССРда да сугыш вакытында бик күп хатын-кызлар хезмәт итте... Күбесе гарипләнеп вә бала табып кайттылар. Турысын әйткәндә, армия алар урыны түгел инде.

Юбкалы солдатларны полкның Волконкадагы мунчасына автобуслар белән китерделәр. Бу кызлар Рәсәйдән, Себердән, Хабаровск өлкәсеннән иде. Араларында азып-тузып йөргәннәре, хәтта бала тапканнары да бар. Күпләр хезмәт хакына кызыгып һәм иргә чыгу нияте белән ялланганнар. Кешене шул тамак газабы йөртә. Чырылдашып, шау-шу киләләр. Тәртип дигән нәрсәне белмиләр, оялу хисе юк. Аларның тән тазалыкларын тикшереп, юындырып-дезинфекцияләп, үлчәп, медкенәгәләрен яздырып, хәрби киемнәргә киендерергә кирәк. Бу җаваплы эшләр әйберләр белән тәэмин итү бүлегенә һәм медицина хезмәткәрләренә кагыла. Боларны мунчада башкаруны ышанычлы шәфкать туташы Марья Ивановнага һәм үзебезнең инженер-майор Шевченко хатынына йөкләдем. Кызларны, дим, оялдырмый хатын кеше тикшереп, пакьләндереп, үлчәп баксын... Ул алар белән көне буе шөгыльләнде. Аннары байтакларының шакшылыгына, әдәпсезлегенә хәйран калып сөйләде.«Коса яздым!» — диде. Булыр икән! Солдат кызларны махсус җиһазланмаган булса да, аерым казармага урнаштырдык. Карантиннан соң аларны дивизионнарга һәм полк штабына бүлделәр. Сынаганыбызча, файдалары әз, ә мәшәкатьләре чамасыз булды. Солдатлар һәм кайбер офицерлар гел алар тирәсендә бөтерелеп йөрделәр. Мондый шартларда, гыйшык-мыйшык белән мавыкканда, хезмәт кайгысымы соң! Гинекологка күрсәтеп, күремнәре килгәндә, хезмәтләреннән вакытлыча азат итеп, мамык белән тәэмин итеп интегеп беттек. Хатын-кызлар армиядә зур проблема ул. Аларга махсус юыныр бүлмә вә тастымалчыклар булырга тиеш. Урнашуларының бүтән үзенчәлекләре дә бар. Алар кайбер оялчанрак офицерларны дәрес үткәргәндә кызартып, тиргә батыралар иде. Ике ел дәвамында солдат-офицерлар белән чуалып, декрет елларына һәм кайберләре тормышка чыгып, демобилизацияләнеп таралып беттеләр. Шул тискәре тәҗрибәдән соң аларны армиягә сирәк, теләр-теләмәс кенә алгаладылар. Ни әйтсәләр дә, хәрби хезмәт һәм казармалар хатын-кызлар өчен түгел инде!

Кайбер усал телләр: «Хатын-кыз затыннан булган солдат бер генә — «ят» дигән боерыкны гына шәп үти!» — диләр иде. Мондый фикердә бераз хаклык булса да, бөтен хатын-кызларга күләгә төшерергә ярамас. Аларның төрлесе бар. Ирләрнең дә күбесе әүлия түгел ич.

Шул елларда хатын-кызларның байтагы чит илләрдәге гаскәрләребезгә бик теләп ялланалар иде. Әйтик, ГСВГга, Венгриягә. Күп түлиләр, кием-салым анда

мул, баеп кайтырга була... Чүпрәк-чапрак дигәндә, безнекеләрнең ач күзләре тәмам шарлана торган иде инде!

Ниһаять, шул тылсымлы Европага чыккан Дунька-Маруськалар белән кызык хәлләр дә булгалаган. Шундыйларның берсе турында болай сөйләгәннәр иде. Беренче тапкыр хезмәт хакын алуга, яна килгән авыл кызлары өс-башларын карый башлыйлар, ә ГДР кибетләрендә алырлык әйберләр була. Менә ял көнендә болар хәрби киемнәрен алмаштырып, киенешеп чыгалар. Алманнар аларны күреп шаккаталар. Баксалар, өсләрендә берсеннән-берсе матуррак челтәрле эчке киемнәр икән! Дөнья күрмәгән колхоз кызына барыбер түгелмени! Комбатлары бу тузга язылмаган манзараны күреп, хурлануыннан зәңгәрләнеп-бүртенеп: «Күздән югалыгыз, сасыткычлар (вонючки), бу эчке күлмәкләр бит!» — дип, йодрыгын болгап кычкырганын сизми дә кала. Шулай була ул «тимер пәрдә» артында посып, акны-караны күрмичә, бездә «социализм җәннәте» дип яшәгәндә!..

Ярый, сүземнең төп эзенә төшим. Биредә дә дивизионнарның чикләре чәнечкеле тимер чыбыклар, аннары сигнал чыбыклары һәм ахырда югары вольтлы электр челтәрләре белән уратылып алынган. Шиклерәк җирләрдә яшерен миналар да күмелгән. Дошманның шымчылары — диверсантларыннан сакланалар. Ул тирәләрдә бары махсус белгечләр генә тикшереп йөри ала. Электрлы челтәрләргә еш кына төрле киек-җәнлекләр, куян-бурсыклар, фазаннар һәм кыр кәҗәләре эләгеп һәлак була. Күбесенчә караңгы төндә. Бу бит тайга! Аларның табигый мохитләре. Монда эре җәнлекләрдән боланнарга хәтле бар. Алар мәкерле адәмнәрнең мондый хәтәр, харап итәрлек эшләрен белмиләр! Ияләшкән җирләрендә яшиләр. Тикшереп йөрүчеләр шул бичараларның көйгән түшкәләрен тәүлегенә бер челтәрдән җыеп чыгалар. Бу саклык челтәре табигатькә нихәтле зыян китергәнен чамалыйсыздыр. Мондый тиген ит турында солдатлар да белеп ала. Андый нәрсәләргә солдат халкы бик сизгер ул. Тамаклары тук булса да, нәфесләрен сузып һаман эзләнәләр. Хәер, солдатны тулысынча туйдыруы кыен. Аларның гел ашыйсылары килеп торадыр. Чыныгып үскән чаклары бит.

Менә шуларның бер «зирәгрәк» төркеме «отбойдан» соң яшеренеп, тимер чыбыкларның эчке якларыннан табыш эзләргә чыга икән. Электр челтәрендә куяннымы, кыр кәҗәсенме күрүгә, болар чәнечкеле тимер чыбыклар асларын казып, җиргә тияр-тимәс кенә тартылган электр челтәрен таяклар белән күтәртеп, түшләре белән шуып чыгып, чокырда учак ягып, тегене кыздырып, бүреләр урынына ашарга ияләшкәннәр!

Май чүлмәгенең дә чатнап ватылган соңгы мәле була. Менә караңгы төшүгә ит сөючеләр, гадәтләренә кергәнчә, яшеренеп-посып, чираттагы табышны шыпырт кына барларга чыгалар. Менә көйгән җәнлек түшкәсе!

Корсак колларының теләгән ризыклары бу! Чәнечкеле тимер чыбык астын казыйлар. Берсе аунап яткан агач ботагы белән электр челтәрен каерып күтәрә. Икенчесе түше белән аның астына җәнлекне алырга шуыша. Ләкин бу юлы кыек эшләре барып чыкмый. Ин хәтәр мәлдә ботак чыдамый — чыртлап сына һәм электр челтәре астындагы сержантның гәүдәсенә дөп итеп төшә! Ахыры мәгълүм. Сержантның киеме шунда ук көлгә әверелә. Үзе дә кара янып, гомере белән хушлаша. Мондый фаҗигане яшереп булмый инде. ЧП! Ата-анасына: «Шәхси тәртипсезлеге аркасында!» — дип хәбәр итәргә туры килә. Аны-моны абайламыйча, формаль рәвештә тикшереп йөрүчеләргә тиешенчә кирәкләрен бирәләр! Чәнечкеле тимер чыбыкларны астан үтмәслек итеп ныгыталар. Электр челтәрен күтәрмәслек итеп тарттыралар. Сигнал элемтәсен көчәйтәләр. Тирәләрен чыбык-ботаклардан әрчиләр. Бездә гел шулай: берәр фаҗига булып узгач кына ашыгыч рәвештә саклык чараларын күрә башлыйлар.

Рәсәйнең тәртипсезлеге, җыйнаксызлыгы барча илләргә мәгълүм бугай. Җанын ваемсызлык вә битарафлык баскан аның.

Бу күнелсез вакыйга бик күп ит яратучыларга үтемле гыйбрәт булды. Кайчакларда кеше әнә шулай үз тозагына үзе эләгә!

Андый бәла-казалар байтак булгаладылар. Хәтеремдә, ике лейтенант — Плужников вә Костин якшәмбе көне бер матайга атланып, беренче дивизионнан калага, кәеф-сафа корырга дип чыгып китәләр. Плужников, матай хуҗасы, КПны җинел генә узмакчы була. Утырып барган килеш, башын иеп шлагбаум астына чума, ә артта утыручы Костин авызын ачып, маңгае белән шлагбаумга бәрелеп мәтәлә! Аңын югалткан Костинны Стецюк медпунктына күтәреп китерәләр. ЧП! Каушап киткән Стецюк Бескоровайныйга чаптырта һәм миңа хәбәр итәләр. Мин килгәндә, икесе дә Костин янында тулганалар иде. «Әлләни зурдан түгел лә!» — дигән булалар. Карасам, бичараның маңгай тиресе колакларына хәтле ярылган! Тире ярылгач, сөяк чыдамый инде. Пенцетлар белән скальпын каерып карасам, баш чүмече дә ярылып кузгалган! Моны күреп, икесенең дә исләре китте. Шок халәтендәге Костинны, Пупков аша ашыгыч рәвештә корпус вертолётын чакыртып, округ госпиталенә — нейрохирургия бүлегенә озатырга туры килде. Шул гына аны үлемнән коткарды да инде. Без килеп төшкәндә, анда Науганов та килеп өлгергән иде. «Анас, ни булды, һәр фаҗигането кыйпылчыклары минем өстемә дә очалар!» — дип зарланды ул. Аны командующий белешергә дип җибәргән икән. «Безнең гаебебез юк монда, нигә хафаланырга, киресенчә, рәхмәт әйтсеннәр!» — дидем. Терелгәч, авыруны демобилизацияләделәр. Костин миңа рәхмәтен дә әйтә белмәде!

Аның ише фаҗигаләр икенче дивизионда да булгалады. Һаман шул тәртипсезлек һәм башбаштаклык аркасында. Бермәлне солдатлар ял көннәрендә станокта ярты метрдан озынрак һәм беләктән юанрак уенчык ракета ясыйлар да, эченә сабын савытларын ваклап һәм ширпы башларын тутыралар да ут төртәләр. Тирәсендә авызларын ачып карап торучылар байтак була. Ракетаның «ягулыгы» кабынып китә һәм ул урыныннан кубып һавага очар урынына, берсенең нәкъ каеш буган җиреннән корсагын аркылы тишеп тоткарлана һәм яна бирә! Телефон аша безне чакырырга чабалар. Мин Бескоровайный белән килгәндә, бичараның корсагындагы тимер ракета кызу иде әле, ә солдат шок халәтендә хәрәкәтсез ята! Ракетаның очы һәм койрыгы корсакның ике ягыннан күренеп торалар. Эфир сибеп аны суыттык. Эчәгеләре шиксез пешкәннәрдер... Зур операциясез ракетаны тартып алырга ярамый. Корсагын бәйләп, дарулар кадап, тагы вертолёт чакыртып, округ госпиталенә илттек. Анда пешкән эч маен вә метр ярымлап эчәгеләрен кисеп алалар да терелгәч демобилизациялиләр. Уен — муенга тиючән ул.

Безнең дивизион автопаркларында кышын машиналарның радиаторларында су урынына — антифриз, һәр машинаның радиаторына «Антифриз, яд!» — дип, язу эленә. Шуңа да карамастан, каравылда торучыларның берсе «агу» икәненә ышанмыйча авыз итә. Антифриз, бер йотым гына эчелсә дә, бөерләргә бәрә. Алар эшләми башлыйлар һәм кешенең канын бәвел баса да, атна эчендә үлемгә китерә! Бу очракта да шулай була.

Шул ук дивизионда рекламация буенча яңа килгән ракетаны төзәтергә заводтан белгечләрен чакырталар. Ул ракеталарның люк-трубалары заводта эретелгән резина кебек нәрсәләр белән ябыштырылган була. Белгечләр аларны ниндидер сыекча белән шприцлап эретеп алалар да кирәкле эшләрен үткәрәләр. Киткәндә берсе кунакханәдә шул сыекчаны нәни шешәсе белән онытып калдыра. Җыештыручы солдат иснәп карый. Исе тәмле булгач, йотып та җибәрә! Моның белән дә шул ук хәл була! Эзләнгән бәндә үз әҗәлен таба ул!

Тәртипсезлек вә мәнсезлек беркайчан да юньлегә илтми. Бездә тревогалар еш була. Аларны, кагыйдә буларак, гел төнлә үткәрәләр. Бөтен часть корал-машиналары белән хәрәкәткә килә. Расчётлар сугышчан постларына ыргылалар. Һәм шунда чираттагы боерыкны көтәләр. Шундый тынып торган мәлдә бер солдат машина артына тумкаеп черем итә. Бераздан машина чигенә һәм моны сытып үтерә! Хәер, мондый очраклар бөтен армиядә дә булгалыйлар. Танк асларында үлүчеләр дә була...

Минем алда тагы бер җитди мәсьәлә калкып чыкты. «ГЧ»лар белән шөгыльләнүчеләрне, ракеталарның зарарлы ягулыгы һәм зәһәр оксидлаштыручы сыекчасы белән эшләүчеләрне ел саен махсус медкомиссия аша саулыкларын тикшереп уздырасы һәм сәламәтләргә хезмәтләрен дәвам итәргә фатиха бирәсе бар. Ләкин андый комиссияләр Хабаровскида һәм аннан да ераграк Ледяная госпиталендә генә эшли. Шулхәтле ишле халыкны эшләреннән аерып, ничек инде атнасына бер кабул итә торган комиссиягә юллап бетерәсең ди? Алай иткәндә, частьның сугышчан әзерлеге бозыла. Командование исә беренче нәүбәттә шул үтә җитди мәсьәләне генә кайгырта бит! Ә юл чыгымнарын исәпләгәндә, комиссия мәсьәләсе тагы да кискенләшә. Әле ул комиссияләре дә сине колач җәеп көтеп тормыйлар. Артык эш кемгә хаҗәт ди? Менә шуларны барысын да исәпкә алып, андый комиссияне үзебездә булдырырга кирәк дигән уйга килдем. Без дә тегеләрдәге ише дипломлы табиблар ич, авыруны тазадан аера беләбез. Тәҗрибә дигән нәрсә эшли һәм даими рәвештә өйрәнә торгач кына туплана бит. Телефон аша Науганов белән сөйләштем. «Мина комиссия турында фикереӊ ошый. Аның исемлеген төзе дә генерал Архиповка расларга, рәсмиләштерергә җибәр!» — диде. Монарчы башыма кергән уйдан чигенгәнем юк иде әле. Табибларым белән киңәшкәннән соң, үземне — комиссия рәисе, Бескоровайныйны — хирург, Стецюкны — күз, Александровны — ЛОР, Глятманны — эчке чирләр һәм рентгенолог белгечләре, Еськоны лаборант дип теркәдем дә, ике нөсхәсенә Пунковка кул куйдырып, исемлекләрне Перхушковога юлладым. Комиссиядә һәркем күңеле тарткан һәм яхшырак белгән фән белгече вазифасын сайлап алды. Тик Горновскийга, теләмәсә дә, дерматолог вазифасын йөкләдем. Белеме бу өлкәдә анын чамалы иде. Чуаннан гайре башка тире чирләре турында: «Бу ни, диагнозын ничек язарга?» — дип, атлаган саен диярлек миннән сорап торды. Күзгә күренеп торган тире чирләрен минамы белмәскә?

Мин аларны фельдшерлыгымнан бирле яхшы таный идем. Еллар үтүгә, әлеге табибларыбыз шул мин юраган белгечләр булдылар да.

Ике атнадан исемлекнең Архипов раслаган нөсхәсе килде. Ышанып бетмәгән хезмәттәшләремнең исләре китте. Хәзер инде эшкә дә керешергә мөмкин, тиешле хәрбиләрне комиссия аша үткәрергә була, дим. Нигә әллә кемнәргә иңәлергә? Без үзебезнең офицер-солдатларыбызны яхшырак беләбез ич! Комиссия эше байтакка сузылды, ләкин ул, үзебезнең гарнизонда башкарылганга күрә, артык мәшәкатьсез узды. Үзебез дә, командованиебез дә бик канәгать идек. Әлбәттә, саклык чараларын үтәп эшләгәндә, ике-өч ел дәвамында саулык үзгәрешләрен сизеп булмый. Андый тискәре үзгәрешләр байтак еллар буе эшләгәннән соң гына барлыкка килергә һәм үзгәргән геннар аша яңа буыннарга тәэсир итәргә мөмкин. Безнең вазифабыз исә әлегә саулыклары тулы булмаганнарны зарарлы эштән азат итәргә һәм дәваларга. Монысы инде безнең кулдан килә.

Шул чакларда тагы бер мәсьәлә күзгә чалынды. Зарарлы эшләрдә эшләүче офицерлар бик яхшы, хәрби очучыларның бишенче күләменә (нормага) тәңгәл азыкны сатып ала алалар, ә шул ук зарарлы эшкә катнашырга солдат-сержантларга әлегә бары икенче күләм паёгы гына бирелә! Моны солдатларның ике ел гына хезмәт итүләрен истә тотып эшләгәннәр бугай. Янәсе, таушалып

өлгермәсләр! Ләкин яшь организмның зарарлыкларга үтә бирелүчәнлеген уйламыйлар. Ә бу бит генофондның бозылуына китерәчәк...

Бу житди мәсьәләне тирән анлаган хәрби табиблар киңәшмәләрендә көн кадагына куялар. Әлбәттә, без дә читтә калмадык. Зарарлы хезмәттәге солдат-сержантларга махсус паёк кирәклеген таләп итә башладык. Шул паёкка атланмай, бавыр паштеты, сыр, поливитаминнар кертергә, шикәрне һәм балыкны арттырырга кирәк, дидек. Мондый нигъмәтләрне өстәмә рәвештә тик зарарлы эшләр алдыннан ашатырга зарур дигән уйга килдек. Ахырда югарыдагы житәкчеләребез — Архипов вә Гыйрфанов колак салып, главкомыбыз аша бу үтә мөһим мәсьәләне хәрби министрга житкерәләр. Анысы Косыгинга мөрәҗәгать итә. Менә шулай паёк арттыру мәсьәләсе дәүләт кимәлендәге дәүләт башлыгы исә бу эшне хәл итәргә Югары Шурага тапшыра. Анда мәсьәләне тикшерер өчен карт большевиклардан махсус комиссия төзиләр. Тутыгып беткән бюрократик машина шыгырдый-шыгырдый хәрәкәткә килә башлый. Косыгин комиссиягә илдә азык-төлек мәсьәләсенең авырлыгын искәртә. Совет бюрократларының мондый ысуллары һәркемгә мәгълүмдер. Комиссияләрдә теләсән нинди мәсьәләне батырып юкка чыгарырга була. Бер үк фирка түрәләренә буйсынырга һәм үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртырга иялә шкән өстенлекле, картаеп мүкләнгән большевиклар корпорацияне безнекеләрне чакыртып тынлыйлар һәм мондый карарга киләләр: «Халык сезгә хезмәткә сау-сәламәт (?) улларын бирә. Аларның саулыкларын саклау — сезнең бурычыгыз!»

Нәкъ Косыгин ымлаганча, җаваплары алдан ук анықланып куелган булса кирәк!

Һичшиксез, оныклары шундый хәтәр хезмәтләрдә булса, бүтән төрле карар чыгарган булырлар иде! Башкаларның балалары кызганыч түгел шул!..

Хакны әйтмичә булмый: райком секретарьларыннан һәм исполком рәисләреннән башлап, югарыга хәтле бер генә түрәнең дә онык-улын хәтәр эштә күргәнем булмады. Алай гына да түгел әле. Балалары, кагыйдә буларак, ата-аналары яшәгән җирдә хезмәт иттеләр, яки «телефон хокукы» буенча, хәрби хезмәттән бөтенләй азат ителделәр! Балаларының Әфганстанда яки бүтән «кызу» җирләрдә хезмәт итеп һәлак булганнарын ишеткәнегез бармы? Ишетмәссез дә, күрмәссез дә, чөнки военкомнар алар карамагында ич. Бер военкомнар гынамы! Хәзер совпартократлар халыкның бизүенә үпкәләгән булалар тагы! Ә ни көткәннәр соң чамасыз кыланып?..

***Редакциядән.***

*Журналда Әнәс Габдрахман улы Хәсәнов язган истәлекләрдән өзек бирдек. Аларның тулы вариантын күпмедер вакыттан чыгачак китаптан укый алырсыз дип өметләнәбез.*

## Кем син, Хәмит абый?

Алар кичә дә күрше Хәмит абыйлары янында иделәр: анда рәхәт, тик Гөлфиянең бабасы гына ачулана. «Йөрмә аның тирәсендә», — диеп җитәкләп алып кереп китә.

Ә Хәмит абыйлары янында кызык! Ул сугыш вакытында башыннан үткәннәрне сөйләп, балаларны шаккатыра. Менә Гөлфия дә малай булып туган булса, Хәмит абыйсы шикелле атка атланып чабар иде, танкка да утырып, курыкмыйча, утлар-сулар кичәр иде.

Һәр көнне диярлек бура эченә кереп түгәрәкләнеп утыралар да Хәмит абыйларын тынлыйлар. Ул бер ярсып, бер тынычланып сөйли дә сөйли: «Шула-а-ай, күрде инде безнең башлар!» — диеп сузып көн дә яңа кызыклар белән дәвам итә, күз яшьләрен дә сөртеп куя.

«Җәйнең эссе көне, минем «Буян» кушаматлы атым бар иде, шулай командир: «Алга!» — дигән приказ бирде дә, ыргылдым, малай, алга. Буянның корсагына ыңгырчак белән бер генә тибеп куюым була, без уктай атылабыз, як-якта, пулялар тиеп, башкалар егылып кала, ә без гел алгы сызыкта. Шулай чабып барганда, минага эләктек бит, малай. Буян бер якка очты, мин — икенче якка. Аягыма мина кыйпылчыгы тигән, ә атка берни дә юк. Буян мине эзләп табып, яныма килеп ятты, ялыннан тотып алып, бергәләп шуыштык, малай. Шулай итеп, мине ут эченнән алып чыгып, медсанчастька алып кайтты Буяным. Мин ана по гроб жизни бурычлы».

«Ә Буян кайда соң хәзер?» — дип сорап куйды берсе. «Юк инде ул, аны, яхшы ат булгач, генералга бирделәр. Безнең аерылышканны күрсәгез икән сез! Ул елый, мин аның муеныннан кочаклап елыйм, көчкә аердылар».

Кинәт бураның теге ягыннан Гарифулла бабай тавышы ишетелә: «Хәмит, җитәр инде, туктат инде бу баламутыңны». Гөлфия тора да, бабайдан эләккәнче, тизрәк сыза. Бабай Хәмит абый белән сөйләшеп кала. Өйгә кайткач: «Кыз башың белән берүзең малайлар арасында утырасың, Хәмит ни сөйләмәс, йөрмә кабат анда, мә, ичмасам минем куфайкының сәдәбен тагып бир!» — дип Гөлфияне орышып эш куша.

Гарифулла бабай да сугышта булган, тик ул берни дә сөйләми. «Әй, искә төшерсәң, тимер ярчыкларга җан керә бит», — дип сүзен туктата ул. Гөлфия һич аңламый: ничек инде, тимергә җан керсен, сөйлисе килмәгәнгә шулай әйтәдер ул, дип үпкәли генә. Ә менә Хәмит абый бөтен җирдә булган. Берлинның стенасына пәке очы белән кырып үзенең исемен дә язып кайткан. Әйе шул, аның исемендә биш кенә хәреф, тиз язылады, ә бабайның хәрефләре күбрәк: Га-ри-фул-ла.

«Их, сез минем самолётта очканны күрсәгез!?» — диеп кызыктырып сөйләп китте беркөнне Хәмит абый. Самолётны бер кулы белән генә йөрткән ул, икенче кулы белән мылтыктан аткан. Шуны сөйләттереп бетермәде бит Гарифулла бабай, бура авызына килеп башын тыкты да: «Әй, Хәмит, ничек оялмыйсың син? Бу балаларны алдап утырганың өчен Ходай орыр, валлаһи. Без сугышып йөргәндә дүрт ел буе базда яттың бит син. Әниең, бау бәйләп, сиңа ашау төшерә торган булган. Тфү!» — дип лач итеп төкерде дә таягына таянып, аксаклый-аксаклый китеп барды. Бабасы ачуланыр дип Гөлфия аның артыннан йөгерде.

## Бүре

Авыр сугыш еллары... Ачлык, ялангачлык хөкем сөрә. Тамак өчен, җан саклар өчен адәм баласыниләр генә эшләми. Ил белән күргән авырлык беркемне дә читләтеп үтмәгән еллар, шул еллардагы авырлык әнием җилкәсенә дә төшә.

Ач килеш, иптәш кызларына ияреп урманга ризык эзләп чыгып китәләр алар. Урман үзенең үләннәре, гөмбә-җиләкләре, каеры-тузлары белән халыкны ачлык-ялангачлыктан саклап кала.

Көч-хәл белән урманга килеп җиткәч, барысы да юага ябырылганнар, әнием дә юаны (мин аның нинди үлән икәнен белмим) ач тамакка ашый да ашый икән. «Күп ашама, харап буласың», — дигән иптәшләре. Ә ачыгудан тәмам гаҗиз булган әнием ашаган да ашаган шул, өйдә ачлыктан интегүче туганнарына да күп итеп җыйган, инде күтәренеп кайтыр юлга чыккач, бөгелеп төшкән. «Җирләр тырмап елыйм, кире дә чыгара алмыйм, эчем авыртуга түзеп булмый, иптәшләрем дә нәрсә эшләргә белмиләр. Ерак түгел елгадан миңа кушучлап су ташып эчерттеләр, шуннан соң гына бераз авырту басылып, хәл керде», — дип искә ала иде әнием.

«Өй җылытырга утын юк, салам ташып ягып, йокыга китеп, өй эчләре белән янып үлүчеләр дә бик күп булды ул вакытта. Өй җылытырга кирәк, салам беткән, салкыннан туңып ничек төн чыгарга? Җитмәсә, төнгә каршы буран да кузгалырга тора, иптәш кызларым: «Безнең төн чыгарга саламыбыз бар әле», — дип, бармаска булдылар, ә мин берүзем киттем», — дип сөйләвен дәвам итә әнием. Әйтерсең, чын әкият.

Шулай итеп, әнием, кулына озын гына бау тотып, салам эскерте эзләп басуга чыгып китә. Инде караңгы төшкән, юлны чамалап кына, адаша-саташа барганда, әллә кайда еракта ике ут күрә. Машина килә, ахрысы, диеп юлын дәвам итә ул. Бара торгач, бу утлар ике генә түгел, берничәгә әйләнә. Әни пошаманга төшә: «Әллә бүреләр микән?» — дигән уй йөгереп үтә аның башыннан. Ә утлар якынайганнан-якыная бара.

Кулындагы бавын, бияләен салып ташлап, кайтыр юлга таба йөгерә башлый ул. Бик озак йөгереп хәлсезләнгәч, артына борылып караса, бер бүре артыннан ук ияреп бара икән, хәтта әни аның сулыш алуларына кадәр ишетә. Шуннан соң ул, ниндидер бик көчле шартлау тавышыннан куркып, җиргә егыла. Тавыш тагын, тагын яңгыраган, әйтерсең, колак төбендә генә бүреләр нидер шартлаталар кебек тоела аңа. Әллә шартлаудан, әллә бүреләрдән куркып, әнием юл уртасында аңын җуйган.

«Җә, тор инде, тор, ятма, гәүдәнә салкын тияр!» — дигән тавышка аңына килгәч, күрше Гариф абый аңа өйгә кайтырга булышкан. «Тәмәке тартырга чыккан идем, нидер уйлап, капканы ачсам, шәйлим, кемнедер бүреләр куа бит, мәйтәм, бер генә түгел, дүрт-бишенең күзе ялтырый. Туктале, дим, тиз генә өйдән мылтык алып чыктым да һавага атып җибәрдем. Алла рәхмәте белән бүреләр кирегә чапты. Ә теге кеше каядыр юкка чыкты, әллә бүреләр өстерәп йөгерде, әллә җир йотты... Каршы йөгердем, барып җитсәм, куркып киттем, селкенмичә дә аңсыз ятасың, аннан өенә озатып куйдым», — дип, әниемне бүреләр авызыннан ничек алып калганын иртән кереп сөйләгән ул.

«Менә, кызым, сезгә ялган — миңа чын», — дип, күнелендәге хатирәләрен сөйли торган иде әнием.

Авыр туфрагы җиңел булсын!..

**Гөлнур ВАСЫЙЛОВА.**
*Мамадыш*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Һади ТАКТАШ**

## Бердәнбер – «ялгыз»

Актаныш районы Такталачык авылында бер генә ялгыз хуҗалык калган, диләр.

Авылдагы 450 хуҗалык колхозга керүгә карамастан, бер үзе генә керми калган нинди кеше ул?

Элек аның исеме дә, фамилиясе дә булган. Ләкин аны хәзер инде «Заядлый единоличник» дип кенә йөртәләр. Мулла кушкан исеме дә, паспортына язылган фамилиясе дә онытылып бара. Аның кемлеге турында сорау бирә башласаң да, колхозчылар, ни өчендер, елмаюын яшерә алмыйлар:

— Берәү инде шунда... — диләр.

Алтмыш биш-җитмеш яшьләренә җиткән картның колхозга кадәр булган үткәннәре хакында «бер начар сүз дә» сөйләмиләр:

— Урта хәлле крестиян иде, — диләр. — Ләкин... Тавык йомыркаларына кадәр үзе җыя. Хатыны үлгәч, тагын бер хатынга өйләнгән иде... Түзмәде, китте...

— Шул гынамы?

Такталачык авылы колхозчы картлар аны берәм-берәм димләп караганнар:

— Бергә яшәдек, бергә аш ашадык, бездән олагып калма, — дигәннәр. Ләкин ул акыллы картларның сүзен тыңламаган. Хәзер инде аңа ялынмыйлар. Бер карт ярлы колхозчы:

— Аны инде шулай үз көенә кәмит итеп калдырырга кирәк, — ди. — Өстенә карап, борынгы заманны искә төшерербез, — ди.

Һәм ул, дөрестән дә, Такталачык авылында «Таң» колхозы музее өчен бер экспонат булып бара.

Урманга якын кыр читендә, бер ялгызы урак урып йөргән карт, ерактан урманга кереп бара торган карт бүрегә охшый. Урак машиналарының бер күтәрелеп, бер төшеп әйләнгән канатлары, тезелеп урак урып барган колхозчылар гүя ул ялгыз бүрене урманга куып баралар төсле.

Бичара.

*1931*

**Әхмәт ИСХАК**

***

Шундый ил бар – Пакстан,
Халкы кия ак штан.
Ак штан да кия алмас,
Ярдәм алса АКШтан.

Туфан МИҢНУЛЛИН

## Шигырь язарга өйрәтәм...

Мәскәүдә Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларда укыганда, бүлмәмә курсташым шагыйрь Зөлфәт килеп керде. Чәчләре тузган, зәп-зәңгәр күзләре Парнас тавының иң текә кыясына кунган бөркет күзләре сыман яна, ике кулы давылда бәеннән ычкынган тегермәннең канатлары шикелле болгана — димәк, шигырь язган һәм шатлыгын минем белән уртаклашырга тели.

Шулай булып чыкты да. Тотынды укырга шигырен — егерме квадрат метрлы бүлмә тараеп, кечерәеп калды, сыймый шагыйрьнең хисләре бүлмәгә, ана киңлек кирәк, аңа авызлыкларын чәйнәп, иксез-чиксез дала буйлап чабарга кирәк, атмосфера катламын тишеп, галәмгә чыгарга, Сатурнның кыршавына басып Андромеда йолдызлыгына сикерергә, аннан яңадан планетабызга кайтып, Тын океанга чумарга, андагы берәр кашалотны кочаклап үбеп, ярга чыгарга да аяккулларын җирдәге материклар өстенә салып, татлы, илаһи йокыга талырга кирәк.

Шулай эшләде дә Зөлфәт. Укып бетергәч, юашланып ишек янагына сөялде һәм гөнаһсыз күзләрен миңа текәп сүзсез калды.

Мин нишләргә тиеш идем? Әлбәттә, шигырь тәэсиренә бирелеп әсәрләнергә һәм: — Гениально! — дип кычкырырга тиеш идем. Бу моментта шагыйрьнең күңеле шундый сүзгә мохтаҗ иде. Соныннан теләсәң ничек тәнкыйтьлә, ә бу мизгелдә шагыйрь күңеле белән бик сак булырга кирәк. Чөнки мондый чакларда шагыйрь (һәм, гомумән, һәр иҗат кешесенең) йөрәге ачылып шәп-шәрә кала, ул тиз яралана, ул яраны төзәтүе авыр була.

Ходаның биргәненә шөкер, тупаслык бездә җитәрлек инде:

— Аңламадым, — дидем.

Миннән мондый мәгънәсез һәм рәхимсез сүз көтмәгән Зөлфәт аптырап миңа карап торды.

— Шигыреңнең нәрсә турында икәнен аңламадым, — дип кабатладым.

Башын артка чөйде Зөлфәт, уң кулын югарыга ыргытты һәм:

— Шигырь нәрсә турында була аламыни! Поэзия бит ул нәрсә турында була алмый! Шигырь ул — шигырь!.. — дип ишекне ачык калдырып чыгып китте.

Гафу үтендем микән, хәтерләмим. Юк шикелле. Чөнки «шигырь нәрсә турында була аламыни!» дигән сүзе белән ул мине наданлыкта, примитивлыкта гаепләгән сыман тоелды. Мин ул вакытта да, хәзер дә әдәбиятның һәрбер жанры н ә р с ә т у р ы н д а д ы р булырга тиеш дип саныйм.

Берничә көннән бу хакта Зөлфәт белән кара-каршы утырып бәхәсләштек. Ул рәхәтләнеп миннән көлде, мин бирешмәдем. Хәтта мин аны шигырь язарга да өйрәтергә керештем. «Әгәр дә, — дидем, — илһам килеп, шигырь язарга утырсаң, иң элек, язачак шигырендәге фикерне проза белән, ягъни мәсәлән, салкын акыл белән кәгазьгә теркәп куй. Аннан эшкә йөрәгеңне, хисләреңне җик. Менә дигән аңлаешлы шигырь туачак», — дидем.

Идәнгә ятып, тәгәри-тәгәри көлде Зөлфәт. Шигырь турында сүз чыкса, әле дә шул вакыйганы сөйләп көлә. Мин дә аңа кушылып көлгән булам, ләкин күңелемнең кайсыдыр бер җирендә «ә бит мин ул хәтле үк хаксыз түгел» дигән уй ята...

Айдар ХӘЛИМ

## Айдар–Баба һәм мин

Айдар-Баба һәм мин — икебез ике кеше.
Айдар, ай-һай, эшчән — гөрләп бара эше.
— Әнә килә! — дим мин. — Теге Айдар-Баба!
Печәр җирегезне ул барыбер таба!..

## Мунча ташы театры әһелләренә

Тамашагыз гел салмыш, авыз-борыннарыгыз
Чебенле салатта.
Ирләрегез чалыш кирзада, хатыннарыгыз
ертык халатта.
Чокый торгач күзен, төкерә торгач ашар ашына,
Әйләндердегез, и..........тлар, халкыбызны да
мунча ташына.

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Беренче поезд белән

– Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев постыннан төшерелүгә, мин беренче поезд белән Мәскәүдән кайтып төшәчәкмен. Бөтенләйгә! – дигән башкалада яшәп язучы Ринат Мөхәммәдиев.

Берничә елдан сон, Минтимер Шәймиев президентлык постын калдыра. Бу хәбәр яшен тизлегендә таралып өлгерә. Янгыравык исемле дүрт-биш язучы, ашкынып, Казаннын Тимер юл вокзалына төшәләр, Ринат Мөхәммәдиевне каршыларга, мул чәчәк букетлары тотып...

Менә, Мәскәү ягыннан икенче поезд килә, өченче... бишенче... унынчы поезд...
И көтәләр болар, и көтәләр...
Ә беренче поезд һаман килми дә килми икән.

## Сугыш–мазар чыкса...

Шагыйрь Разил Вәлиев үзе кебек үк жор телле энекәше Рәмзил белән Васильевода дача төзи. (1976 ел бу). Алны-ялны белми атна-ун көн эшлиләр болар.

Шулай беркөнне Рәмзил кыбырсый башлый:

— Абый, Казанга кайтып килик.

— Ни калган анда?

— Болай булмый, абый, кайтып килик Казанга.

— Ни житми сина?! Ашарына-эчәренә бар, сандугачлар сайрый, һава әйбәт.

— Атна буе газета укыган юк, радио тынламыйбыз, бер хәбәрсез...

— Башынны ял иттер әзрәк.

— Үкенечкә калмасын, дим, абый. Сугыш-мазар чыккан булса... Бөтен дус-иш түшенә орден-медаль тезеп кайтачак, без, икәү, бернәрсәсез торып калабыз бит...

## Сынмаган

Берничә елдан сон Рәмзил, зур тизлек белән «Жигули»енда барганда, йөк машинасы белән мангайга-мангай бәрелешә. «Жигули»е тәмам жимерелеп, арт тәгәрмәчләре генә исән кала. Үзенә унжиде тапкыр операция ясыйлар.

Айлар буе янында торып саклаган хатыны беркөнне түзми, мышык-мышык елап, үзалдына сөйләнә:

— И-и, ничекләр генә терелерсен инде, бөтен жирен сынып беткән бит...

Тарттырылган, күтәртелгән, беркетелгән, гипска катырылган гәүдә эченнән тавыш килә:

— Кайгырма, хатын, сина кирәк жире сынмаган бит әле...

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# РӨСТӘМ МАҖАРАЛАРЫ

## Югалу

Бу озын хикәядә тасвир ителәчәк искиткеч вакыйгаларның төп каһарманы Рөстәм Асадуллинга 1942 елның язында унөч яшь тә тулмаган иде әле. Аның кинәт югалуы әтисе — химия укытучысы Һашим абыйны да, әнисе — география укытучысы Гайшә апаны да тирән кайгыга төшерде.

Рөстәм, гадәттәгечә, иртә белән дәрескә чыгып китте һәм шул китүеннән кайтмады. Әбисе аны көтеп, аш-су әзерләде. Сәгать арты сәгать узды, ә Рөстәм һаман күренмәде дә күренмәде. Моңарчы, рөхсәт сорамыйча, һичбер кая китеп йөрмәгән акыллы баланың болай озак кайтмый торуы әбине бик тә борчыды. Ул телефон аша улы Һашимга шалтыратты.

— Һашим улым, Рөстәм юк ич, — диде ул.

— Ничек юк?

— Ни дип әйтергә дә белмим инде, улым. Сәгать 4не сукты, ә Рөстәм...

— Юкка борчылма, әнкәй, кайтыр... Берәр түгәрәк утырышында калгандыр...

Һашим абый әнисен әнә шулай тынычландырды. Ләкин үзе шул ук минутта Рөстәм укый торган мәктәпкә шалтыратты. Директор аңа Рөстәмнең бүген дәрестә бөтенләй булмавын әйтте.

— Аңламыйм, — дип карады ата, — аның бит бер генә тапкыр да дәрес калдырганы юк иде...

— Әйе шул, — диде директор, — үзебез дә шуңа гаҗәпләнәбез. Рөстәм Асадуллин безнең иң яхшы, иң тәртипле укучыларыбыздан санала. Сырхаулады, күрәсең, дип уйладык.

Директорның борчулы сүзләр әйтүе Һашим абыйны чын-чынлап пошындырды. Ул, үз-үзен алдарга тырышып, Рөстәм өйдәдер инде дип уйлады. Шулай да өйгә кайтышлый милиция бүлекләренә һәм ашыгыч ярдәм күрсәтү пунктларына керде. Ләкин Рөстәм турында бертөрле дә хәбәр ала алмады. Ашыгыч ярдәм пунктыннан чыгып китәргә торганда гына, кемдер берәү телефон шалтыратты. Телефон трубкасын куйганнан соң, врач шофёрга:

— Трамвай астында бала калган, киттек! — дип кычкырды. Һашим абыйның йөрәге жу итте. Аның күз алдына кан эчендә сыкрап яткан Рөстәм килеп басты.

— Зинһар, мине дә алып барыгыз! — дип, врачка ялварды ул. — Рөстәмдер... Үтенәм!

«Ашыгыч ярдәм» күрсәтү машинасы бик кызу барса да, Һашим абыйга ул акрын бара кебек тоелды. Ниһаять, алар Тукай урамына килеп җиттеләр. Һашим абый, җыелган халык төркемен ера-ера, яраланган бала янына йөгерде. Әмма бер кулы яньчелгән бала Рөстәм булып чыкмады. Һашим абый врачка булышты да, авыр уйларга чумып, өйгә юнәлде.

Бердәнбер улының кинәт юкка чыгуын кич белән Гайшә апа да белде. Ул, күз яшен агызып, күршеләргә йөгерде, мәктәпкә чапты, Рөстәмнең дус-ишләренә барып кайтты, ләкин хәсрәтле ана «юк», «белмим», «күрмәдем» сүзләреннән башка сүз ишетмәде.

Төн тынычсыз узды. Ана, шылт иткән саен, ишеккә йөгерде, улым менә хәзер

кайтыр инде дип, тәрәзәдән күзләрен алмады. Ата, Рөстәм югала торган бала түгел, кайтыр, дип, хатынын һәм әнисен тынычландырырга тырышты. Гайшә апа: «Ни булды минем алтыныма? Үзе кайтып керерме? Әллә, менә улыгыз, дип, аның үле гәүдәсен күтәреп керерләрме? Нишләргә? Кайдан эзләргә үзен?» — дип, төне буе газапланды. Әле ары чапты, әле телефон шалтыратты.

Рөстәм беренче көнне дә, икенче көнне дә кайтмады. Аның югалуы турында газеталарда белдерүләр басылды, радио аша хәбәр бирелде. Рөстәмне табучыларга яки аның кайда икәнлеген әйтүчеләргә кыйммәтле бүләкләр, кайнар рәхмәтләр ышандырылды. Әмма юкка гына: Рөстәм үзе дә, аның турында куанычлы хәбәр алып килүче дә булмады.

Әйтергә генә ансат: күз алдында йөгереп йөргән бала кинәт, көпә-көндез, суга чумгандай юкка чыксын, имеш. Телләре кычыткан гайбәтче хатыннар бу турыда кеше ышанмаслык хәбәрләр дә таратып өлгергәннәр иде инде.

## Серле букча

Бала югалуның өченче көнендә Гайшә апа, эштән кайтып керүгә, өстәлдә Рөстәмнең китаплар букчасын күрде һәм шатлана-шатлана:

— Ул исән! Кайтты! — дип кычкырып җибәрде һәм букчаны күкрәгенә кысты.

— Кайда иде? Үзе нишләп юк соң? — дип, әби аңа сораулар бирде.

Гайшә апа аптырап калды. Аның төсләре үзгәрде, аяк-куллары калтырый башладылар.

— Кайда иде дип, мин үзем синнән сорамакчы идем, әнкәй. Менә сумкасы өстәлдә ята ич...

Гайшә апа букча эчен актарырга кереште һәм:

— Кем китерде? — дип, әбигә эндәште. Әби килененең соравын әллә аңламады, әллә шаярта дип уйлады:

— Берәү дә китермәде, — дип җавап кайтарды.

— Ничек инде «берәү дә»? Һашим кайткан идеме әллә?

— Юк, кызым, кайтмады, — диде әби. — Сумканы мин яңа күрәм. Син керер алдыннан гына өстәл әзерләп йөрдем лабаса, нишләп күрмәдем соң?! Кереп чыккан кеше дә булмады... Үзең алып кайтып, әйтмичә торасыңмы әллә, кызым?

— Шаяртма инде, әнкәй, тизрәк әйт: кая качты? — Рөстәмнең ата-анасын качып каршы ала торган гадәте бар иде. Гайшә апа шуны искә төшерде һәм, бүлмәдән бүлмәгә йөреп, өстәл-караваt асларын, шкаф-комод эчләрен карады, хәтта ишегалдына да чыкты. Килененең: «Улым! Улым! Рөстәм!» — дип кычкырып йөрүен ишеткәч, әби түзмәде — елап җибәрде.

— Нишләп шаяртыйм, кызым! — диде ул. — Кайтса, әйтмичә түзәр идеммени?

— Ә сумка... Сумка кайдан килде соң?

Гайшә апа, бик мөһим әйберне исенә төшергәндәй, өйгә йөгереп керде, өстәл янына килде, букчадан нидер алырга теләп, кулын сузды. Әмма гаҗәп хәл: букча өстәлдә юк иде.

— Әнкәй, сумканы кая куйдың?

— Минем аңа тигәнем юк, кызым. Теге бүлмәгә алып кергәнсеңдер. Хәзер табабыз...

Икәве дә букча эзләргә керештеләр. Байтак вакыт эзләгәннән соң, Гайшә апа үз-үзен тиргәргә тотынды. Бая букчаны карап бетерә алмавына ачуланды. Аның уенча, букчада Рөстәмнең кая киткәнлеген аңлаткан язу булырга тиеш иде.

— Кулымда тотып тордым лабаса... Ни хәл бу?! Кая куйдым соң?..

Гайшә апа шундый сораулар белән борчылып йөргән чакта, өйгә Һашим абый кайтып керде. Ул да букча эзләргә кереште. Эзләп-эзләп тә таба алмагач, хатыны янына килеп утырды, аның йөзенә карады. Гайшә ханым шушы ике-өч көн эчендә аңа гаять ябыккан булып күренде.

— Бу кадәр өзгәләнмәс идең, сөеклем! — диде ул. — Рөстәмнең югалуына күңелем ышанмый. Елама! Интекмә! Нервларың какшаган синең. Рөстәмнең букча күтәреп дәрескә чыгып китүен мин үз күзем белән күрдем. Шул китүеннән ул кайтмады. Димәк, букча аңарда. Ә син, кулыма тотып тордым, күкрәгемә кыстым, дисең... Мөмкинме бу? Гел шуны уйлап йөргәнгә, күзеңә генә күренгәндер...

Һашим абый сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, Гайшә апа диваннан сикереп торды һәм:

— Менә ул! Менә! — дип, өстәлгә ташланды. Гаҗәп хәл: букча өстәлдә иде.

— Син генә түгел, мин үзем дә акылдан язам, ахрысы! — диде гаҗәпкә калган ата. — Кайдан бу? Әллә юкса без үзебез өстәлдә яткан әйберне күрми тордыкмы?

Гайшә апа иренең сорауларын да ишетмәде, аның хәйран калуын да күрмәде. Ул, бөтен дөньясын онытып, букча эчен актарырга тотынды. Гүя букча эченнән Рөстәм үзе килеп чыгачак иде. Дер-дер калтыраган куллар астында өстәлгә китаплар, дәфтәрләр, карандашлар төштеләр.

### Эзләмә мине!

Букча эченнән игътибарга алырлык бер язу да чыкмады. Шулай да Гайшә апа, үз гомерендә очраган иң кыйммәтле әйберләрне караган кебек, улының китапларын, дәфтәрләрен бик җентекләп карап утырды. Рөстәмнең каләме дә хәзер аңа шундый кадерле, ул аны күкрәгенә кысып сөйде.

— Их, бала, бала...

Эчтән уфтанса да, тыштан тыныч булырга тырышкан Һашим абый да китап, дәфтәр битләрен актарды; химия китабын карап, уйга калды:

— Юк, булмас! — диде. Гайшә апа аңа сорау бирде:

— Нәрсә «булмас», Һашим? Ни турында сөйлисең син?

— Бу кадәрле тәртипле бала болай кинәт югалмаска тиеш, дим.

Кара син аның китапларына, кара син аның дәфтәрләренә. Берсендә бер кер-тап күрмәссең... Тукта, тукта... Монда ниндидер язу бар.

Һашим абый химия китабы эченнән хат сыман бер язу алды. Гайшә апа: «Тиз бул!» — дип, язуны, үзе дә сизмичә, иренең кулыннан тартып алды һәм укый башлады. Аерым кәгазьгә зәңгәр кара белән түбәндәге сүзләр язылган иде:

*«Мин үземнең теләгемә ирештем. Хыял барлыкка килде. Яшәсен әби! Миндә хәзер кеше ышанмаслык искиткеч корал бар. Көчле мин, көчле! Кодрәтле мин, кодрәтле!*

*Бары тик кечкенә булуым гына борчый. Ник мин дәү түгел? Нигә өч-дүрт ел элек тумаганмын? Их, күрсәтер идем соң бу ерткыч фашистларга совет кешесенең көчен!*

*Әтием-әнием мине югалганга хисапларлар. Елыйлар булыр һәм еларлар. Бичара әнкәй! Миңа дип ул иртә белән сөт өсте әзерләр, әмма мин булмам. Өсте ачылгандыр дип, төнлә минем карават янына килер, әмма мин булмам. «Елама, әнкәй, мин исән! — дип кычкырасым килә минем. Эзләмәгез мине — барыбер таба алмассыз!» — диясем килә минем.*

*Кызык шул: мин бар да, юк та.*

*Туган йорттан аерылуы авыр. Ләкин нишлисең... Шулай инде».*

Ата-ана бу сүзләрне кабат-кабат укыдылар, һәрбер сүзнең серенә төшәргә тырыштылар. Ни өчен монда «Яшәсен әби!» дип язылган? «Мин бар да, юк та» сүзләрен ничек аңларга? Нигә үзен «Мин көчле, кодрәтле» дигән? Нишләп «Эзләмәгез мине — барыбер таба алмассыз» дип язган? Сораулар күп, тик җавап табуы гына кыен иде.

Гайшә апа иренә ялварды:

— Аңлат, Һашим, ни бу? Нинди язу? Әллә юкса... Сорарга да куркам инде... Акылдан яздымы? Бигрәк күп укый иде шул. Русча, немецча, татарча сөйләшә иде. — Гайшә апа, күз яшен сөртә-сөртә, тагын әлеге язуны укырга кереште.

— Һичнәрсә аңламыйм, — диде ата, — башым эшләми башлады. Ләкин йөрәгем сизә: ул кайтачак, исән кайтачак.

— Син гел шулай дисең, ә ул, бәлкем, хәзер газап чигә торгандыр. Тамагы ачтыр... Өстен-башын чишендергәннәрдер... Үзен хур итеп ташлаганнардыр... Йә, ник дәшмисең? Тик торып булмый бит... Нишлик?

Бу сорауларны тыңлаганда, ата, балалар үстерүе никадәр читен, дип уйлый иде. Баласын югалткан ананы тынычландырырга сүз тапмады ул. Чөнки үзе дә тынычсыз иде. Рөстәм югалганнан бирле Һашим абый үзе дә бик ябыкты. Болай да озын буйлы кеше, ул тагын да озынайгандай булды. Яңаклары суырылды. Рәтләп йокламаганга, күз кабаклары авырайдылар. Өч-дүрт көн инде кырынганы юк — картаеп китте.

— Йә, ник дәшмисең?

Гайшә апаның соравы аны сискәндереп җибәрде.

— Кеше югала торган ил түгел бу, Гайшә. Хәзер мин милиция идарәсенә барам. Анда ярдәм итәрләр. Менә бу язуны да күрсәтермен. Эзләү, эзләтү чараларын күрерләр. Бәлки...

— Нәрсә «бәлки»?

— Бәлки, фронтка киткәндер?

— Рөстәмме? Унөч яшьлек баламы?

— Әйе, Гайшә, син моңа гаҗәпләнмә. Беркөн мин аны Гали абый докладына алып барган идем. Ул анда балалардан оешкан партизаннар отряды турында тыңлады. Аннары үзең дә беләсең: сугыш белән бик кызыксына иде.

— Илаһым! Кайсы пәри хатыны тудырды бу Гитлерны. Бөтен кайгы-хәсрәтләребезгә шул немецлар сәбәп. — Ана күзләре яңадан язуга төште: — Соң, нишләп фронтка киттем дип язмаган? Юк, фронтка түгел. Фронтка булса, күптән тотып кайтарган булырлар иде инде...

Һашим абый милиция идарәсенә китте. Ул анда иң авыр, иң чуалчык эшләрне дә ерып чыга ала торган зур начальникны күрде. Аңа Рөстәмнең язуын күрсәтте, серле букча турында сөйләде, ата-ананың кайгы-хәсрәтен аңлатты.

— Әйе, — диде начальник, язуны укып, — серле! Кайчан югалды.

— Егерме тугызынчы майда.

— Димәк, бүген дүртенче көне икән инде. Ә бу язуны кайчан таптыгыз?

— Бүген.

Начальник өстәл кырыендагы кнопкаларның берсенә басты. Кабинетка күзлек кигән икенче бер начальник сыман милиционер керде.

— Иван Петрович, — диде аңа өлкән начальник, — ашыгыч эш бар. Менә шушы язуның кайчан һәм нинди хәлдә язылуын белергә кирәк. Аны менә бу иптәшнең юкка чыккан унике-унөч яшьлек улы яза. Эчтәлеге турында үзегезнең фикерегезне язарсыз. Бүген кич унда миңа тапшырырсыз.

— Тыңлыйм, иптәш начальник! Күзлекле милиционер чыгып китүгә, өлкән начальник Һашим абыйга борылды:

— Бу эш белән мин үзем шөгыльләнәчәкмен. Балачак приключениеләре дисәм, хата булыр төсле. Шунсы ачык мәгълүм ки, улыгыз исән, тап-таза һәм табылыр.

Начальник, нидер уйлагандай, бераз дәшми торды. Урыныннан кузгалды һәм тагын сүз кушты:

— Рөхсәт итсәгез, мин үзем сезгә барып чыгар идем.

— Рәхим итегез! — диде Һашим абый. Начальник аңлатырга ашыкты:

— Зинһар, тентү-фәлән дип уйлый күрмәгез... һич юк! Мине Рөстәмнең өстәле, китаплары кызыксындыра. Бер уңайдан әлеге серле букча белән дә танышырмын. Иртәгә иртә белән сигездә мөмкинме?

— Иртәгә якшәмбе бит? Әйе, якшәмбе. Мөмкин, керегез. Үзем дә, хатыным да өйдә булырбыз.

Гадел КУТУЙ

*Дәвамы киләсе саннарда.*

***

*Бу язманың авторы — Хәмзә Зарипов. Үз вакытында төрле редакцияләрдә, шул исәптән «Казан утлары»нда да эшләгән танылган журналист. Өлкән буын иҗат кешеләре аны киң карашлы, тирән эрудицияле, үзенчәлекле публицист буларак яхшы хәтерлидер. Язмада, нигездә, Балык Бистәсе район газетасы (ул вакыттагы «Октябрь юлы», хәзер — «Авыл офыклары») каршындагы әдәби түгәрәк эшчәнлегенең бер эпизоды чагыла. Заманында бу әдәби түгәрәк татар поэзиясенең зур вәкилләре — Роберт Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, Равил Фәйзуллин кебек шагыйрьләрнең башлангыч иҗатында зур этәргеч булган. Бу язма 1978 елда, Равил Фәйзуллинның Г.Тукай премиясенә тәкъдим ителүе уңаеннан язылган булган. Мәкалә 37 ел элек язылса да (ул аны балалар басмасы өчен язган), укучыларыбыз, бигрәк тә «Ак җилкән»дә катнашучылар өчен кызыклы һәм гыйбрәтле булыр дип уйлыйбыз.*

## КЕШЕ БАТЫР ТУРЫНДА ПОЭМА

1959 ел. Кама ярына утырган Балык Бистәсе авылы. Ике катлы авыл йортының арткы өлешенә урнашкан редакция бүлмәсе. Көз. Йорт якка һәм бәрәңге бакчасына караган тәрәзәләрне яңгыр юа. Ничәнчедер көн рәттән сибәли дә сибәли ул. Күк Кама белән тоташкан.

Кич. Хезмәттәшләр китеп беткән. Бүлмәгә күзгә күренеп караңгы иңә. Анда кара-каршы куелган өстәлләр янында без икәү: газетаның авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире Рәшит Гарипов. Шагыйрь. Йомшак, моңлы тавышы белән әкрен генә җыр суза. Икенчесе — мин, редакциядә яңа гына эшли башлаган кичәге студент. Шигырьләрне, шагыйрьләрне яратам. Кешегә күрсәтми генә үзем дә язгалыйм.

— Ут белән кәтик, — ди Рәшит, барып утны кабыза. Мин аның борчулы йөзен күрәм. Болай ул үзе уен-көлкеле кеше. Мин аңлыйм аны: бу минутларда күңеле белән ул караңгы яңгырлы урамда, районның икесе ике ягына киткән озын, пычрак басу юлларында. Авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире ул юлларның газабын күп татыган инде.

— Яхшы хуҗа этен дә чыгармаслык көн шушыдыр инде, — ди Рәшит, караңгы тәрәзәгә карап.

— Борчылма, егетләр ич, — дим мин, алдымда яткан дәфтәр битләренә ымлап. Шигырьләренә караганда сират күперен дә үтәрлек егетләр күз алдыма килә: башлылар, йөрәклеләр... Менә икесе ике яктан караңгылык һәм яңгыр эченнән килеп чыгарлар кебек.

Рәшит тынычланмый, үзалдына сөйләнә:

— Пионердан әле генә чыккан малайлар. Мәктәп балалары...

Без көтәбез. Редакциядә Рәшит Гарипов оештырган әдәби түгәрәк утырышына килергә чыккан ике малайны көтәбез. Дәресләрен тәмамлагач, берсе район үзәгеннән кырык, икенчесе утыз чакрымдагы авылдан килә. Хәзер алар юлда.

Көз. Кич. Яңгыр. Алар Кама ярына утырган авылга икесе ике яктан якынлашалар. Ут алып көтәбез. Күчтәнәчебез дә бар. Иртәгә чыгасы газетага икесенең дә шигырьләрен янәшә бирдек. Саранланмадык, мул итеп бирдек. Шигырьләре дә шәпләр шул. Әй шатланырлар инде! Язганнары турында фикер ишетер өчен шушы төндә атка атланып шундый юлга чыккан малайларга зур бүләкмени бездән ул газета...

Менә хәзер килеп тә керерләр. Районның икесе ике ягыннан: Олы Солтаннан һәм Котлы Бөкәштән бер-берсенә якынаялар алар. Иртәгә чыгасы газета битендә аларның шигырьләре янәшә, исемнәре янәшә.

Гомер юлын да шулай шигърияттә янәшә уза алсалар иде.

Рәшиткә карыйм. Аның битендә сипкелләре ешайган кебек. Уйлыйм: «Ә бит шагыйрь булырга җыенучы әлеге малайлар аның сүзен ишетергә киләләр...»



*Хәмзә Зарипов (сулда) һәм Рәшит Гарипов. 1959 ел.*

***

1978 ел. Бүген теге малайлар икесе дә исемнәре һәм китаплары Балык Бистәсеннән еракларга билгеле шагыйрьләр. Кадыйр Сибгатуллин шунда ук, ягъни Бистәдә яши. Теге чакларда беренче шигырьләрен бастырган газетада күптән инде үзе эшли. Журналист. Үзе дә, шигърияте дә тамыры белән туган якларына береккән. Игенче шагыйрь, күңелләрне яулаган шагыйрь.

Равил Фәйзуллин — малайларның икенчесе, студент, солдат булырга, Әлмәттә язучылар бүлеген җитәкләргә дә өлгерде, инде күптән Казан — башкала кешесе, инде күптән шагыйрьләр арасында беренчеләр рәтендә. Күп телләрдә укыла торган шагыйрь. Быел менә аның иҗатын Язучылар берлеге үзе татар әдибе өчен иң зур бүләккә — Тукай премиясенә тәкъдим итте.

Бүген минем алдымда пөхтәләп шигъри юллар язылган дәфтәр битләре түгел инде, бәлки Равил Фәйзуллинның соңгы унике елда басылып чыккан унике китабы. Татарча шигырьләр, русча шигырьләр. Тырыш малай иде, тырыш шагыйрь үсте. Иренчәк булмавын, куркак түгеллеген, шигърият хакына теләсә нинди кыенлыкларны җиңәргә дә әзер булуын Котлы Бөкәш мәктәбе укучысы Фәйзуллин Равил теге чакта ук раслаган иде...

Һәр зур шагыйрьгә хас булганча, мөгаен, моның бер хикмәте дә бардыр (анысын сез аның үзенә язып сорый аласыз), зурлар өчен яхшы әсәрләр язу белән бергә Равил Фәйзуллин балалар өчен дә илһамланып, кайта-кайта иҗат итә. Бәлки бу — шагыйрь җанның эчке бер ихтыяҗыдыр!.. Аның «Икмәк пешерүчеләр җыры» дигән шигыре зур тиражлар белән рус һәм татар телләрендә аерым китап итеп тә таратылды. Сезгә дә барып җиткәндер...

Мин әле менә аның иң беренче китабын кулга алам. «Рәсем ясыйм» дип атаган аны шагыйрь.

Көнбагыш чәчәге ясыйм,
Сары карандаш алдым.
Эшем бетте, исем китте:
Кояшны ясаганмын,

— дип, ул үзе дә гаҗәпләнеп куя. Гаҗәпләнерлек тә бит: шау чәчәктә торган көнбагыш чыннан да кояшка охшаган ич. Кайберәүләр моңа игътибар да итми яшиләрдер әле. Шагыйрь Равил Фәйзуллин шулай безнең күңелләрне ача, безнең күңелләрне дөньяның шундый гаҗәеп якларына, тормышның матурлыкларына якынайта.



*9нчы сыйныф укучысы*
*Фәйзуллин Равил. 1958 ел.*

Шигъриятькә ул әнә шулай рәсемле, димәк, аз сүзле һәм күп фикерле шигырьләре белән килеп керде. Хикмәтләрне ачарлык дәрт һәм дәрман сизелә иде аңарда.

Аның шушы иң беренче китабында иң беренче биткә басылган шигыре «Безнең ил» исемле. Бусы да очраклы түгел, чөнки һәркемнеке кебек үк, шагыйрьләрнең дә (бәлки алар аеруча шундыйлардыр әле) телләре Әни, Әти, Туган тел, Туган ил сүзләре белән ачыла. Изге сүзләр шул...

Һәм менә Равил Фәйзуллинның да беренче шигыре «Безнең ил» турында. Ул болай дип җырлый:

Карталарда безнең илне
Буяганнар алсуга.
Чөнки кояш иртүк торып,
Алсу утлы шардай булып,
Иң башта бездә чыга.

Картада илебезнең алсу төскә буялуын революция флагы төсе белән бәйләп аңлатканны ишетергә туры килгәне бар иде, ә менә бусы яңалык бит әле... Чыннан да кояш алсуланып иркен илебезнең иң ерак көнчыгышыннан күтәрелә... Һәм илебез буйлап яктыртып үтә... Кояш алсуыннан илебез алсулыкка күмелә килә. Илебез — Кояш иле... Октябрь байрагы төсе әнә шулай Көн, Кояш, Тормыш, Бәхет төсе белән кушыла...



*9нчы сыйныф укучысы*
*Сибгатуллин Кадыйр. 1958 ел.*

Шулай, уйларга, ачышларга этәрә безне шагыйрь. Шул «этәрүе» белән безнең күңелләрне үзенекенә бәйләп тә куя.

Билгеле инде, ачышларны башта ул берүзе ясый. Моның серләрен дә белми түгелдер. Әгәр дә ул серләр икәү булса, берсе, һичшиксез — Кешеләргә, Тормышка мәхәббәт, аларны бәхетле һәм бәхетсез иткән һәр нәрсәгә карата битараф булмау. Равил Фәйзуллинның бар язганы (әйтелгәнчә, алар төрле телләрдә дистәдән артык китап) Кеше турында бербөтен поэма кебек укыла. Аерым-аерым меңләгән шигырь язган шагыйрьнең үз күңеле дә сизә мондый бөтенлекне: кайбер китапларында әсәрләрен аермый, бер агымга сала, бер сулышка куя. Һәм китаптан замандашыбызның уй-фикерләрен, хис-тойгыларын үз күңелеңә дә күчерәсең...

Әле быел ул сезгә «Яшь ленинчы» аша үзенең кайбер кыска шигырьләрен тәкъдим итте. Укыгансыздыр. Алары әле чыгасы китабыннан. Ә аның «Шигырьләр, поэмалар» китабы былтыр дөньяның йөз туксан иленнән җыелган иң яхшы китаплар күргәзмәсендә катнашты. Шигырьләре Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан, Хәким әсәрләре белән бергә «Бөтендөнья әдәбияты» сериясендә басылды. Аның нәкъ менә шушы сайланмалары Тукай бүләгенә тәкъдим ителде дә.

***

Балык Бистәсеннән калган танышлыгыбыз әле дә дәвам итә. Очраша, сөйләшә торабыз. Олы шигърият хакына Равил Фәйзуллин әле һаман авыр тауны да күтәрергә риза. Ул һәрвакыт хәрәкәттә, эштә, эзләнүдә. Ул белә: шигъриятнең тамыры — халыкта. Халыкның асылы, рухы, теле — аның авыз иҗатында. Равил Фәйзуллин халык иҗатын галим буларак өйрәнә. Бер сөйләшүдә әкиятләргә кагылып, фикерләр көрәштергән идек. Бермәлне әңгәмәбезне кырт өзеп, Равил Фәйзуллин ашыгып китеп барды. Ә бераздан... ул миңа шигырь укыды:

Булган диләр
Камыр батыр,
Агач батыр,
Тимер батыр...
Һәркайсысы
зур эшләргә
маһир батыр!
Игелекле
Асыл батыр!

...Син нишләрсең
Кеше батыр?..



*Хәмзә Зарипов (сулда) — «Яшь Ленинчы» газетасының җаваплы секретаре, Равил Фәйзуллин – Казан университетының 5 курс студенты. Тукай һәйкәле янында үткәрелгән шигъри митингтан соң. 1965 ел.*

Менә шул. Бу шигырьнең тууына, әйткәнемчә, үзем шаһит. Шагыйрь Равил Фәйзуллинда шигырьнең кем хакына (Кеше хакына!) һәм ничегрәк туганын тагын бер мәртәбә менә шулай күрдем. Шул чагында кайчандыр шигырьләре хакында фикер ишетер өчен көзге яңгырлы төндә озын юлга чыккан укучы Фәйзуллин Равилне искә төшердем...

Ә бүген Равил Фәйзуллин шигъриятe Тукай бүләгенә тәкъдим ителде. Республикабызның иң югары бүләгенә лаеклы шигърият тудырган шигъри куәт әнә шулай ныгыды.

**Хәмзә ЗАРИПОВ.**
*1978 ел, 19 март*

# Подписка өчен ipad һәм башка бүләкләр!



АҖ «ТАТМЕДИА»
газеталарына,
журналларына языгыгыз
һәм бәйгедә катнашыгыз!

**Бәйгедә катнашыр өчен өч һәм аннан да күбрәк басмага языу кирәк. Акциядә катнашучы басмаларның исемлеген www.tatmedia.ru сайтыннан карый аласыз.**

**«Бәйге» билгесе белән языгылган басмаларыгызның квитанция күчермәләрен Казан ш., Декабристлар ур., 2 яки podpiska@tatmedia.ru адресына җибәрегез. Элемтәгә керү өчен телефоныгызны күрсәтегез!**

**Тулы мәгълүмат һәм бәйгенең кагыйдәләре - www.tatmedia.ru сайтында.**

**Акцияне «ТАТМЕДИА» АҖ оештыра.**
Акция 2015 елның 15 апреленнән алып 30 июньгә кадәр дәвам итә.
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222 09 84 (1261)

16+ Реклама

# «ТАНЫМЫШ» ДӘРЕСЕ

*Җавапсызлык бу, җәмәгать! Ошбу шаржларга бер генә җавап та килмәде. Ялгыш аңлагансыздыр, эпиграмма язу мәҗбүри түгел. «Бишле» алу да мәҗбүри түгел, дүртесен, өчесен булса да таныйсыз бит инде. Танылган кешеләр бит алар! Үпкәләтмик бу күркәм затларны... Кайберләре сезгә әнә ничек нәүмизләнеп карап тора.*

①

②

③

④

⑤



---



*3нче сандагы бу ханым, З.Низамова әйткәнчә, Хәмдүнә Тимергалиева, һич тә, ике укучыбыз язганча, Бәширә Насыйрова түгел. Әмма охшашлык бар, димәк!*

---

①

②

③

④

⑤


---

«Хикәя яза аласызмы?» дигән сорауга матур-матур җаваплар килә тора. Тагын да килсен әле. Башламнарны былтыргы 12нче яки быелгы беренче саннарда карый аласыз. Күләм бер журнал битеннән артмаска тиеш.

## ТУГАН ТЕЛ БӘЙРӘМЕ

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Туган тел бәйрәме үткәрелде. Бәйрәмдә ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Тантанада Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатлары игълан ителде. Алар – шагыйрә Клара Булатова, рәссам Ирина Колмогорцева, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының иҗат төркеме (Рәүфәл Мөхәммәтҗанов, Георгий Ковтун, Кристина Андреева, Михаил Тимаев). Рөстәм Миңнеханов аларны ихластан котлады һәм дәрәҗәле бүләкне тапшырды.

## ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Г.Тукайның туган көне шагыйрьнең Казан үзәгендәге скверындагы һәйкәленә чәчәк салудан башланды. Бу тантанада ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министр урынбасары, ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, башкалабыз кунаклары – республикабызга эшлекле сәфәр белән килгән Дагыстан Республикасы башлыгы Рамазан Абдулатипов җитәкчелегендәге зур делегация, Төрекмәнстан парламентыннан бер төркем вәкилләр, төрки телләрдә иҗат итүче яшь язучыларның халыкара фестиваленә килгән каләм ияләре катнашты. Көндез Г.Тукайның Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы һәйкәле каршында Шигырь бәйрәме үткәрелде. Тантанага җыелган халыкны ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады. Дагыстан Республикасы башлыгы Рамазан Абдулатипов, Казакъстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Галым Җайлыбай, Кабарда-Балкар Язучылар берлеге рәисе урынбасары Абдуллаһ Бигиев, Чувашстанның халык шагыйре Юрий Семендер, Саха (Якутия) Язучылар берлеге рәисе урынбасары Гаврил Андросов та үзләренең изге теләкләрен әйттеләр. Котлауларны шигырь, җыр, музыка алыштырды. Бәйрәмдә күренекле шагыйрьләр, сәнгать осталары чыгыш ясады.

Г.Тукайның туган көне уңаеннан бәйрәмнәр Тукай, Балтач, Арча районнарында да үткәрелде. Язучылардан Тукай районында – Фәйрүзә Мөслимова, Рифат Җамал, Рифат Сәлах, Балтач районында – Фоат Галимуллин, Марат Әмирхан, Әнәс Хәсәнов, Фәнзаман Баттал, Вакыйф Нуриев, Эльмира Шәрифуллина, Наил Ишмөхәммәтов, Мансур Шаһимәрданов, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Арча районында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, аның урынбасарлары Данил Салихов, Рәмис Аймәт, каләм ияләре Вахит Имамов, Наил Касыймов, Фатих Кутлу, Рөстәм Галиуллин, Рифат Сәлах, Эльвира Һадиева, Кабарда-Балкар Язучылар берлеге рәисе урынбасары Абдуллаһ Бигиев, Саха (Якутия) Язучылар берлеге рәисе урынбасары Гаврил Андросов, төрки телләрдә язучы яшь язучыларның халыкара фестивалендә катнашучылар булды.

## ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

ТР Дәүләт Советында матбугат әһелләренә Әдәбият елына багышланган чаралар хакында бәян иттеләр. Утырышны ТР Дәүләт Советының мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев алып барды. Аның сүзләренә караганда, киләчәктә «Иҗат әһелләре һәм иҗат оешмалары турында» закон кабул итү күздә тотыла.

ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина Әдәбият елында районнарда әдәбият көннәре, әдәби турне, Милли китапханә көннәре, китап ярминкәләре, яна экспозицияләр, концертлар уздачагын әйтте. Быел шулай ук Б.Пастернак, С.Аксаков, Д.Лихачёв, М.Цветаева укулары, Е.Боратынский, К.Насыйри, А.Чехов, Б.Пастернак, К.Иванов, Т.Гыйззәт, С.Есенин, Ш.Маннур, М.Шолохов, А.Расих, К.Симонов, Г.Ахунов, А.Стругацкий, Т.Миңнуллин юбилейлары үткәреләчәк.

## ИНГУШЕТИЯДӘ ТАТАРСТАН МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Ингушетиядә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре үткәрелде. Төньяк Кавказ республикасы башкаласы Магас һәм Назрань шәһәрләрендә ТР Дәүләт Советының мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев җитәкчелегендәге делегацияне милли җырлар һәм биюләр белән каршы алдылар. Аннары Татарстан вәкилләре

Хәтер һәм Дан комплексындагы Мәңгелек утка чәчәкләр салды, музейда булды.

ТР мәдәнияте көннәре Назраньдә ТР Беренче Президенты Минтимер Шәймиев урамын ачу тантанасыннан башланды. Ике республика арасындагы икътисади һәм сәяси багланышларны ныгытуга үзеннән зур өлеш керткән шәхеснe монда әнә шулай зурладылар.

Ингушетиядә Татарстан мәдәнияте көннәре кысаларында «Матди һәм рухи мәдәни мирас» дигән темага «түгәрәк өстәл», республика Милли китапханәсендә иҗади кичә, Татарстан фильмнарын җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү һ.б. чаралар үткәрелде. Бу чараларда катнашкан һәм чыгыш ясаган ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), галим, әдәби тәнкыйтьче Фоат Галимуллинның татар мәдәнияте, шул исәптән татар әдәбияты турындагы чыгышлары тамашачыларда зур кызыксыну уятты. Ингушетиядә Татарстан мәдәнияте көннәре ТР дәүләт җыр һәм бию ансамбленең зур концерты белән тәмамланды. Аны Ингушетия Республикасы җитәкчесе Юныс бәк Евкуров та карады һәм безнең делегациягә олуг рәхмәтен ирештерде.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ХАЛЫКАРА ФЕСТИВАЛЕ

Казанда төрки телләрдә иҗат итүче яшь язучыларның халыкара фестивале үткәрелде. Анда Төркия, Казакъстан, Төрекмәнстан, Дагыстан, Башкортстан, Саха-Якут, Кабарда-Балкар, Чувашия, Кырым республикаларыннан вәкилләр катнашты. Фестивальне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов ачты. Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, Чувашиянең халык шагыйре Юрий Семендер, Казакъстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрь Галым Җайлыбай, Кабарда-Балкар Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрь Абдуллаһ Бигиев яшь каләм әһелләренә матур теләкләрен ирештерде. Фестивальдә катнашучылар проза, шигърият, драматургия, әдәби тәнкыйть остаханәләрендә фикер алыштылар, үзара тәҗрибә уртаклаштылар, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Туган тел көненә багышланган тамашаны, «Шагыйрь мәхәббәте» операсын карадылар. Фестивальне йомгаклау тантанасында кунакларга дипломнар һәм бүләкләр тапшырылды.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш үткәрелде. Анда еллык эшкә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов хисап ясады. Аннары әдәби жанрларга (проза, шигърият, драматургия, әдәби тәнкыйть, балалар әдәбияты, рус телендә язучылар иҗаты) нигезләнгән докладлар тыңланды. Җыелыш киләчәккә эш-гамәлләр тәгаенләнгән резолюция кабул итте.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Әхмәтҗановның тууына 80 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе үткәрелде. Күренекле шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, язучылар Газинур Морат, Рифә Рахман һ.б. сөйләде. Кичәдә әдипнең шигырьләре һәм җырлары яңгырады.

## ЯҢА ПРОЕКТ

Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан Әлмәт татар дәүләт драма театры яңа проект тәкъдим итә. Архив документларына нигезләнгән бу тамашада — якташларының язмышлары, яу кырында яздырылган «тере тавышлар». Моннан тыш театр Әдәбият елында «Шагыйрь сүзе», яшь тамашачылар өчен «Әкият арбасы» һ.б. проектларны гамәлгә ашыра.

## ОЧРАШУЛАР

«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре Кукмара һәм Чирмешән районнарында булып, укучылар белән очрашты. Бу очрашуларда баш мөхәррир Илфак Ибраһимов, аның урынбасары Рамил Ханнанов, бүлек мөхәррире Камил Кәримов, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, язучылар Марсель Галиев, Газинур Морат, яшь шагыйрьләр Фәнил Гыйләҗев, Дания Нәгыймуллина, Татарстанның халык артисты Рөстәм Маликов катнашты.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Татарстан белән Ингушетия республикалары арасындагы багланышларны ныгытуда, милли мәдәниятләрне үзара якынайтуда нәтиҗәле эшчәнлеге өчен **Разил Вәлиевкә** «Ингушетия Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

2015 елның 20 апрелендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Державин, М.Горький исемендәге әдәби премияләр лауреаты **Нонна Орешина** 82нче яшендә вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: стихи Р.ХАРИСА; рассказ Н.ДАУЛИ «Выстрел»; стихи поэтов-фронтовиков и современных поэтов, посвящённые ВОВ.
«Конкурс на повесть малого формата»: документальная повесть Ф.ХУЗИНА. «Войну мы знали и не знали...»
«70 лет Великой Победе»: «круглый стол» на тему: «ВОВ. Взгляд с XXI века.
Подготовил В.НУРИЕВ; статьи Ш.МУСТАФИНА, И.БИЕКТАУЛЫ, Р.ЗАРИПОВА, Я.ШАФИКОВА, посвящённые ВОВ; Г.АБСАЛЯМОВ. «Солдатские письма о журнале «Совет эдэбияты».
«Литературная критика»: статья И.ВАЛИУЛЛЫ, посвящённая современной поэзии.
«100-я страница»: Р.ЮНУС. «Не всё радует в Победе».
«Искусство»: Г.РАХИМ. «Как рождался гимн ветеранов»; статья Ф.АРСЛАНОВОЙ, посвященная 105-летию со дня рождения Ш.Кутдусовой.
«Наука»: статья М.ХАБУТДИНОВОЙ, посвящённая прозе А.Гилязова;
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: А.ШАМОВА. «Ваши судьбы связаны с огнём войны»;
воспоминания А.ХАСАНА «Наша судьба».
«Наши юбиляры»: статья Р.ШАРАФИЕВА, посвящённая 85-летию М.Хузина.
«Рассказы из жизни»: рассказы Г.ВАСИЛОВОЙ.
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Белый парус»: Г.КУТУЙ. Повесть «Приключения Рустема»; Х.ЗАРИПОВ. «Поэма о человеке-батыре»; «Узнавайка».
Из фотоархива журнала. Рубрику ведёт Р.ФАЙЗУЛЛИН.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Красный флаг над Рейхстагом. Фото Евгения Халдея. 1945 год;
Парк Победы Казани.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: poems by R.HARIS; story by N.DAULI «The Shot»; poems by war poets and contemporary poets dedicated to the Second World War.
«Competition for small-format novel»: documentary story by F.HUZIN. «The war we knew and did not know...»
«70th anniversary of the Great Victory», «round table» on the theme: «World War II. View from the 21st century.
Prepared by V.NURIEV; article by SH.MUSTAFIN, I.BIEKTAULY, R.ZARIPOV, YA.SHAFIKOV dedicated to the Second World War; G.ABSALYAMOV. «Soldiers' letters about the magazine «Sovet edebiyaty».
«Literary criticism»: article by I.VALIULLA dedicated to contemporary poetry.
«100th Page»: R.YUNUS. «Not everything is happy in victory».
«Art»: G.RAHIM. «How the hymn of veterans was born»; article by F.ARSLANOVA dedicated to the 105th anniversary of Sh.Kutdusova.
«Science»: article by M.HABUTDINOVA dedicated to prose by A.Gilyazova;
Pages from «Tatar encyclopedia».
«Memory»: A.SHAMOVA. «Your fate is linked with the fire of war»;
memories by A.HASAN «Our fate».
«Our heroes of the day»: article by R.SHARAFIEV dedicated to the 85th anniversary of M.Huzin.
«Stories of life»: stories by G.VASILOVA.
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
«White Sail»: G.KUTUY. Story «Rustem's adventures»; H.ZARIPOV. «Poem about Batyr-man»; «Find it out».
From the photo archive of the magazine. Section is led by R.FAYZULLIN.
Diary of the social-cultural life.
On our covers: Red flag over the Reichstag. Photo by Eugeniy Haldey. 1945;
Victory Park of Kazan.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Рейхстагка Кызыл Байрак кадау. ***Евгений Халдей** фотосы. 1945 ел.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казан шәһәрендәге Җиңү паркы.




*Бөек Ватан сугышында катнашкан язучыларыбыздан бер төркем. Беренче рәт: сулдан-уңга — Әдип Маликов, Мөнир Мазунов, Сибгат Хәким, Зәйни Шаһиморатов, Мәхмүт Хөсәен, Шәрәф Мөдәррис; икенче рәт — Халикъ Садри, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Афзал Шамов, Риза Ишморат, Госман Бакир; өченче рәт — Габдрахман Әпсәләмов, Гамир Насрый, Әсгать Айдар, Абдулла Әхмәт, Вадим Земной, Хатыйп Госман; дүртенче рәт – Әмирхан Еники, Әхмәт Исхак, Әхмәт Фәйзи, Хәсән Шабанов. 23 апрель, 1947 ел.*

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)